ISSN 0206-4189
Индекс 73210

# Казан утлары

3.2009





**Әмирхан Еники**
**(1909–2000)**

# Казан утлары
# Qazan utları

2009

3
(1037)

**ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:**
*Татарстан хөкүмәте,*
*Татарстан Язучылар берлеге,*
*Редакциянең хезмәт коллективы*

**НАШИРЕ:**
*«ТАТМЕДИА» ачык акционерлык җәмгыяте*

татмедиа

*БАШ МӨХӘРРИР*

**Равил Габдрахман улы**
**Фәйзуллин**

*ИДАРӘ:*

**Рабит Батулла**
**Зилә Вәлиева**
**Разил Вәлиев**
**Мөдәррис Вәлиев**
**Тәлгат Галиуллин**
**Миркасыйм Госманов**
**Алмаз Гыймадиев**
*(җаваплы сәркәтип)*
**Илфак Ибраһимов**
**Дамир Исхаков**
**Туфан Миңнуллин**
**Хатыйп Миңнегулов**
**Назиф Мириханов**
**Гәрәй Рәхим**
**Розалина Шаһиева**
**Рәфикъ Юныс**
*(баш мөхәррир урынбасары)*

---

*Мөхәррирләр:* **Мансур Вәли, Рәдиф Гаташ, Марат Закир, Камил Кәримов, Рашат Низами, Алмаз Хәмзин.**

*Гамәли хезмәткәрләр:* **Гөлзадә Бәйрәмова, Радик Вәлиев, Лилия Гатауллина, Флера Сабирова, Тәгъзимә Шиһабиева.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Асия Рәхимова** (баш бухгалтер), **Эльвира Камалова.**

---

420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.
Баш мөхәррир—292-38-60.
Баш мөхәррир урынбасары—292-36-49.
Җаваплы сәркәтип, компьютер үзәге—541-38-77.
Шигърият, публицистика, фән һәм сәнгать бүлеге—292-38-61.
Чәчмә әсәрләр һәм әдәби тәнкыйть бүлеге—292-39-63.
Гамәли хезмәткәрләр—292-39-65.
Исәп-хисап бүлеге—292-93-16. kazanutlari@yandex.ru
**Факс**—(843) 541-38-77.
**E-mail:** kazanutlari@telebit.ru.

# КАЗАН УТЛАРЫ

ӘДӘБИ–НӘФИС ҺӘМ
ИҖТИМАГЫЙ–СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН
БАШЛАП ЧЫГА

Бу санда

ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

Нәҗибә САФИНА. Җанда–гамьле моң. *Шигырьләр.* ........ 5
Нур ӘХМӘДИЕВ. Мөнирстан. *Роман.* ........ 10
Клара БУЛАТОВА. Язгы уйлар, яңа шигырьләр. ........ 52
Ирек САБИРОВ. Ә уйларым–зарлы һәм ачы... *Шигырьләр.* ........ 91
Рашат НИЗАМИ. Бомж. Ике көтүче. *Хикәяләр.* ........ 95

ДРАМА ӘСӘРЛӘРЕ

Равил САБЫР. Абага алмасы ачы була. ........ 56

ӘМИРХАН ЕНИКИНЕҢ ТУУЫНА 100 ЕЛ

Күңел азатлыгы (Ә. Еники турында каләмдәшләре) ........ 104
Әлфия МОТЫЙГУЛЛИНА. Әдип бәхете. ........ 108
Рәфикъ ЮНЫС. Җиз кыңгырау татарны алга дәшсен! ........ 118
Әмирхан ЕНИКИ. Тигезлек аша татулыкка. ........ 122
Әмирхан ЕНИКИ. "Фактлар дәфтәре"ннән. ........ 128
"Миннән "Матурлык" кала..." *(Әдипнең төрле кәгазь кисәкләренә язылган уй-фикерләре.)* ........ 129

ХӘТЕР

Нурихан ФӘТТАХ. Беренче шигырь күк балачак... *Истәлекләр.* ........ 130
Гомәр БӘШИРОВ. Күңел дәфтәре. ........ 145

ПУБЛИЦИСТИКА

Тәфкил ВАФИН. Мәкруһлар. ........ 151

ӘДӘБИЯТ ТАРИХЫНА

Тәлгат ГАЛИУЛЛИН. "Гаяз әфәнде шагыйрьдер". ........ 158

ГАБДРАХМАН СӘГЪДИНЕҢ ТУУЫНА—120 ЕЛ

Хатыйп МИҢНЕГУЛОВ. Олуг мөгаллим һәм әдәбиятчы. ........ 170

ӘДӘБИ МИРАС

Әнвәр ДАВЫДОВ. Төрле еллардан. *Шигырьләр.* ........ 175

СӘНГАТЬ

Ким САДЫЙКОВ. Үзебезнең рәссам. ........ 179

ЮБИЛЕЙЛАР

Миргалим ХАРИСОВ. Парчалар. ........ 183
Хәмит ЛАТЫЙПОВКА 60 яшь. ........ 185

"Казан утлары" архивыннан. ........ 186
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан. ........ 188

## В ЭТОМ НОМЕРЕ:

*Журнал выходит один раз в месяц*


"Проза и поэзия": роман Н. АХМАДИЕВА "Мунирстан" (продолжение), рассказы Р. НИЗАМИЕВА; стихи Н. САФИНОЙ, К. БУЛАТОВОЙ, И. САБИРОВА.
"Драматургия": Р. САБИРОВ. "Кислое яблоко папоротника".
"К 100 летию А. Еники": (Писатели о нем, А. МУТЫГУЛЛИНА. Доля писателя; Р. ЮНУС. Пусть колокольчик зовет вперед; Через равенство—к согласию. Неизвестная статья ЕНИКИ; О взаимоотношениях татар и башкир.)
"Память": Н. ФАТТАХ. "Детство—как первый стих"... (окончание); Г. БАШИРОВ. "Дневниковые записи".
"Публицистика": Т. ВАФИН. "Отпавшие" (продолжение);
"К истории литературы": Т. ГАЛИУЛЛИН. "Исхаки и татарская поэзия".
"К 120 летию Г. Сагди": Х. МИННЕГУЛОВ. "Великий просветитель и литератор".
"Литературное наследие": стихи А. ДАВЫДОВА.
"Искусство": К. САДЫКОВ. Художник.
Наши юбиляры.
Из фотоархива журнала.
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: Композитор З. ЯРУЛЛИН—картина Р. ИМАШЕВА; литературный критик Д. ЗАГИДУЛЛИНА.


## IN THIS ISSUE:

*The magazine edits monthly*


"Prose and Poetry: novel by N. AHMADIEV
"Munirstan (continuation), stories by R. NIZAMIEV; verses by. N. SAFINA, K. BULATOVA, I. SABIROV.
"Dramaturgy: R. SABIROV. "Sour apple of fern".
"To 100th anniversary of A. ENIKI": (Writers about him, A. MUTYGULLINA. Destiny of writer; R. YUNUS. Let bell calling ahead, Through equity to agreement. Unknown article by ENIKI, Relationships of Tatars and Bashkirs.)
Memory: N. FATTAH. "Childhood as the first verse..." (ending);
G. BASHIROV. "Diaries".
"Publicism": T. VAFIN. "Fallen down" (continuation);
"To history of literature": T. GALIULLIN. "Ishaki and Tatar poetry".
"To 120th anniversary of G. Sagdi": H. MINNEGULOV. "Great educator and writer."
"Literary heritage": poetry by A. DAVYDOV
"Art": K. SADYKOV. Artist.
Our jubilees.
From photo archive of magazine.
Diary of social-cultural life.
On our covers: Composer Z. YARULLIN-picture by R. IMASHEV; literary critic D. ZAGIDULLINA.



★ Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★ Редакциягә килгән кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★ Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 519-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.



Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды.
Басарга кул куелды 13.02.2009, график буенча 22.02.2009.
Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70X108 $^{1}/_{16}$.
Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12 (16,8). Заказ В–190 Тираж 4788.
Журнал Татарстан Республикасының Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында теркәлгән.
Теркәлү таныклыгы № 7. Индекс 73210. Бәясе ирекле.

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
Казан, Декабристлар урамы, 2



© «Казан утлары», 2009 ел.



Нәҗибә
Сафина

# ҖАН—ГАМЬЛЕ МОҢ

## Яшьлеккә дәшү

*Агроуниверситет яшьләренә*

Исәнмесез, саулармы?—
Җанда янар таулармы?
Безнең йөрәк ярсуларын
Сезнең йөрәк аңлармы?

Әйтеп карагыз, дисезме,—
Йөрәкнең ни диюен?
Аңлатырга тырышыйммы
Нидән аның көюен?

Һәрчак югалтканын эзли,
Тапмыйча тынмый кеше.
Инде ул бишенче гасыр
Милли дәүләтсез өши.

Югалтулар шулкадәр зур,—
Төшмәс өчен төпләргә,
Канат куярга мәҗбүр без
Мәңге очмас күпләргә...

Данны түгел, җан сакларга
Түгелә, аһ, көчебез...
Яшәми бакыйга кучә
Шулай күпме кешебез?!

Тарихның сират күперен
Кучү чоры татарның...—
Кирәк икән, шул күпергә
Басма булып ятармын!

Нык булса минем үзәгем,
Милләт басып атласын.
Тик туар таңнары гына
Үз дәүләтсез атмасын!

Үз илендә, үз җирендә
Сөйләсен үз телендә.
Рухи афәт—болай яшәү
Ата-баба көлендә...

Минем җанда бабайлардан
Кабынган ялкын үрли.
Аһ, тик мин дә китеп барам
Үз дәүләтемне күрми...

Алыгыз сез шул ялкынны!—
Алыгыз, җаным белән:
Шагыйрь җиргә шул ялкынны
Тик күчерергә килгән.

## Бармы дару?

Мин яшәүдән арыганмын...
Юк, түгел шул яшәүдән:
Яшәмәүдән арыганмын
Һәм ихлас сүз дәшмәүдән.
Кысылудан арыганмын,
Күңелләр тарлыгыннан.
Күпләрнең качасы килә,
Түгел татарлыгыннан!
Үзе булып яшәмәүдән
Арыды инде җаннар.
Җансыз гына шуышалар
Фани дөньядан саннар.
Туры сүзгә турсаялар:
"Рәнҗедек"—диләр хәтта.
Ышандыру мөмкин түгел,
Антлар эчсәң дә Хакка.

Бу арудан дәва бармы?
Бар микән дарулары?!
Бу җанымның саннарында
Соң чиктә барулары...
Көн артыннан көннәр үтә,
Ә ник шатлыкка түгел?
Үз-үзеңнән киткән саен
Тарая бара күңел.
Кысыла җан, кысыла аң
Үз-үзеңнән киткәнгә,
Җанда туасы ирекне
Читтән өмет иткәнгә.

Дару—билгеле күптән,—
Ай әйтеп тора күктән:
Милләт язмышы җирдә—
Хөррият сөяр ирдә!

***

Кан бар, җан бар—
Ә кан мәңге хәтерле.
Мәңгелекне юк итмичә
Җуеп булмый хәтерне.

Мәңгелекне, йә, кайсыгыз
җиңә ала?

Йә Вакытны, арбасына
җигә ала?

Илләр, таулар, полюслары
күчәр дә...
Кан хәтере җирне тота
күчәрдә!

## Без булмасак...

Туган җирдән еракларда чакта
Күтәрелеп карыйм мин күкләргә.
Бәлки минем мондый гадәтләрем
Сәер күренәдер бик күпләргә.

Әмма гади күк тә үзгә кебек,
Еламыйча чак-чак түзә кебек,—
Күперенеп тора болытлар,
Әллә ничек кенә боеклар...

Туган җирдә алар шундый горур,
Йә арыслан йәки барыс булыр,—
Өерелерләр Урал тау булып,
Ургып аккан ярсу шау булып.

Ялтыр-йолтыр яшен камчылары
Болыт кыяларны кискәләсә,
Карурмандай кара болытларны
Йолыккалап җилләр искәләсә,
Рәхәтләнеп җылы яңгыр кояр,
Кузачкысыз буран котырыр.
Бар дөньясы туктап тынып торыр,—
Туган җирдә күкләр, һай, горур!

Туган җирдән еракларда чакта
Күтәрелеп күккә карасагыз,
Минем хәлләреме аңларсыз сез,
Җирсү дигән хәлгә тарысагыз.

...Туган җирнең тузан исе тәмле,
Болытлары—кояш, ае—ахак.
Тик туган җир башка булыр иде,
Шулай сагынучы без булмасак...

## Карлар да белми

Әкрен генә җиргә карлар төшә,—
Капланалар эзләр.
Күңелләрдә ләкин уелып кала
Үткән елгы сүзләр.

Әкрен генә җиргә карлар төшә,—
Ап-ак чәчәк, гүя,
Көтелмәгән түбә-урләренә
Көмеш таҗлар куя...

Әкрен генә җиргә карлар төшә,
Керә алмый җанга.
Җиргә салган эзләр яңаралар,
Яңару юк җанга.

Әкрен генә җиргә карлар төшә,
Тапталасын белми.
Җирдән кабат күккә ашкач кына,
Акланасын белми.

## Көзнең бер көне

Күкне күк болыт каплаган,—
Шундый да калын!
Җил котыра, бәргәләнә,—
Оныткан ялын.

Исенә төшкән, яңгыры
Түгелә генә.
Әйтерсең, бар да җыелган
Бүгенгә генә.

Сыгыла-бөгелә шаулый тирәк,
Болытлар ага.
Яшел яфраклар өстенә
Карларын кага.

Бер көндә—җил дә давыл да,
Яңгыр, буран да...
Көзне җибәрәсем килми.
Торам урамда.

Яфрак очларыннан тып-тып
Тама кар суы.
Карлар хәтерендә калган
Язлар ярсуы...

Кар хәтере болытларны
Ничек тиз куды!
Тик соң иде, зәңгәр күктә
Салкын ай туды.

Һәм... барысы да бер көндә,
Бары бер көндә!—
Яфракларны коткаралмас
Инде бер кем дә...

***

Хәсрәт керсә җанга,
Кояш түгел, ут шары
Тәгәрәп чыга таңга.

Җанга сөю иңсәме,
Чыгам диеп ике канат
Төртеп тора иңсәне.

Хәсрәт утыра төпкә,
Канатлар үсеп чыга да
Бәхетле оча күккә!

Мәхәббәт барсын җиңә,—
Зурмын дигән хәсрәте дә
Үз кабыгына иңә.

## Кабатланмау

Күзге урман.
Моңсу тынлык.
Сары яфраклар җирдә.
Ә ничек шаулады алар!—
Китмәстән иде бер дә...

Ул җырлар
Нинди иделәр!—
Отып алды Иделләр.
Дулкыннар да ул җырларны
Онытмастай иделәр...

Иделдә күз,—
Су өстендә
Дулкыннар йөгерешми.
Яфракларның соңгы җыры
Иделләргә ирешми...

Язларда
Ташыр Иделләр,
Ямь-яшел булыр урман.
Ачып кына карый алмам,—
Өсләремдә Җир-юрган...

## Җан—гамьле моң!

Мәңгелек сорау: җан ни ул?—
Җавап һаман табылмый.
Ул илаһи, ул гөнаһлы,
Җиргә бер дә кагылмый.

Кагылмый, тик очып кына
Йөри җиһанда, янда.
Ә нигә соң "моңсыз"диләр
Гаме булмаган җанга?

Җан—гамьле моң, әгәр шул моң
Чыгып китсә саныңнан,
Күренә ул—инде синең
Аерылганың җаныңнан...

Баш ватмасын галимнәр дә,
Гадиләр дә аңласын:
Җанны-моңнан, моңны-җаннан
Аерырга калмасын.

**Редакциядән:**

***Бу айда—журналыбызның даими авторы, шагыйрә, публицист Нәҗибә Сафинаның гомер бәйрәме. Күпсанлы укучылар исеменнән каләмдәшебезне юбилее белән котлыйбыз, сәламәтлек, яңа иҗат уңышлары телибез.***

Нур
Әхмәдиев

# МӨНИРСТАН

РОМАН

* * *

Атлар—колхозның терәге, бар карап торган тарту көче. Мөнирҗан белән Фазылны менә шушы гаять җаваплы эшкә, ягъни бригада атларын карарга куйдылар. Гайниянең бил тирәсе тулылана баруы хәзер берәүгә дә сер түгел. Авылның кендек әбисе Гөлнаһар карчык гыйнвар азакларына бәби алып кайтырсың ди. Ул әйттеме, нәкъ шулай булачак. Әскәй халкының яшьрәкләре барысы да Ходайның рәхмәте һәм Гөлнаһар карчыкның бисмилласы, шифалы куллары белән дөньяга килгән. Гайниянең үзенең дә кендек әбисе—ул.

Колхоз рәисе тырышлыгы белән юнәлтелгән саламга да, печәнгә дә хәзергә тимиләр. Анысы кара көнгә саклана. Хәзергә кырда булган саламны ташып ашаталар. Атларны исән-имин саклау тулысы белән ат караучылар өстендә. Шуна күрә һәркөнне диярлек икесенең берсе атлар янында кала: ашата, эчертә, асларын җыештыра, кайберәүләргә баш бирмәс атларны тотып җигәргә булыша. Ат бит ул шундый хайван, аз гына хәл кердеме, теләсә кемгә баш бирергә яратмый. Тазарагын әйткән дә юк, кайвакыт хәлсезе дә әлләкем булып кылана.

Авыл халкының бәхетеннән ул елны көз соң килде. Июнь ае тоташ яңгырлы булды да, июль, августта кояшлы коры көннәр хакимлек итте. Сентябрьдә бәрәңге алыр алдыннан берничә көн яңгыр ыс-пыс итеп маташкан иде, китте аннан әбиләр чуагы! Чишенеп эшләгәннәрнең тәне ком гарәбе төсенә керде. Әбиләр чуагы узганнан соң да, җәйне көнләштерерлек көннәр житәрлек булды. Моның өчен Ходайга кемнәр генә рәхмәт укымагандыр. Хәтта Хәсьянов булып Хәсьянов та Ходайны искә төшерде. Төшерерсең дә шул. Әгәр октябрь башында ук кар төшеп, туңдырып куйса нишләр иден? Болай, ичмасам, унбишенче ноябрьләргә кадәр маллар кырда йөрде. Тамаклары туядырмы, юкмы, тояк астыннан барыбер авызларына нидер эләгә. Ашарга сорап абзарда кычкырган тавышлары да йөрәгенне өзәр иде. Аннан соң бер җилләнеп кайту малларның алгысуын да баса.

Әскәй җиде бригадага бүленгән. Һәр бригаданың атлары аерым асрала. Атларга мөмкин булган хөрмәтне күрсәтергә тырышалар. Ләкин, юрганың кыска булгач, аякны капласаң, баш ачыла, башны капласаң—аяк шәрә кала. Хәер сорашып дигәндәй тапкан такы-токы ризыкны кемгә берәүгә житкерсеннәр. Сыерлардан сөт, сарыклардан йон сорала, ә атлар җаны чыгар-чыкмас колхозның, әйтергә кирәк, бердәнбер терәге. Алар бетсә,

---

*Дәвамы. Башы 1нче санда.*

маллар гына түгел, колхоз үзе дә күтәрәмгә калачак.

Хәсьянов моны яхшы аңлый иде. Шуңа күрә атларга бирү өчен саламның төгәл нормасын билгеләде. Һәр иртәне җиде бригаданың да берәр ат карауччысы Карагыш кулындагы эскерттән арыш саламы төяп алып кайта. Ул саламны башта атлар алдына болай гына салалар. Соңыннан калдык-постыгын, кәҗә сакалы, билчән кебек кураларыннан арындырып, башак итеп болгаталар. Әлбәттә, ул башак һәммә атка да эләкми.

Ул көнне саламга барырга Фазыл чираты иде. Атлар янында эшләрне иртәнге якта бер катка бетергәч, үзләренә беркетелгән Күк бияне җигеп, Фазыл Карагыш кулына юнәлде.

Әле башка бригадаларның ат караучылары килеп җитмәгән. Эскерт төбенә утырып, Фазыл уйга калды. Сугыш тәмамланганга да икенче ел китте. Тормышыбыз менә арулана, менә арулана дип өмет йолдызына күз текәгән халык көннән-көн хәерчелек сазлыгына бата бара. Җитмәсә, быелгы җәй болай да очын очка көч-хәл белән ялгап барган авыр тормышны бөтенләй соң чиккә терәде. Менә бу атларны гына ал: Хәсьянов биргән норма белән генә ашатсаң, озакламый алар хәлсезләнеп, күтәрәмгә калачак. Хәер сорап, теләнеп күпме яшәп була.

Күршеләрнең хәле алай ук авыр түгелдер. Әнә бит аларның күпме эскерте тезелеп тора. Нинди гөнаһлары өчен Ходай Тәгалә быел Әскәй халкын шулай җәзалады икән? Ходай Тәгаләгә тел-теш тидерергә ярамаганын мулла малае белмиме? Ничек кенә белә әле! Барыбер дә авылы, авылдашлары өчен рәнҗи ул.

Иптәшләре һаман юк та юк. Фазыл түзмәде, утырган җиреннән күренеп торган Митрәй басуындагы эскертләрне санарга керешге. Чик буендагы басуда гына да унлап эскерт санап, митрәйләрдән чын-чынлап көнләште ул. Яшәп куялар болай булгач күршеләр!

Тукта, тукта, бер эскерт янына җигүле ат килеп туктаган түгелме? Әйе. Димәк, алар да саламны моннан ташый башлаячак...

Ул арада бүтән ат караучылар да килеп җитте. Салам ташуда «пырафиссырга» әверелеп беткән ат караучылар өчен бер йөк ул май ягып бер телем ипи ашаганише генә. Төш җиткәндә, йөкләр төялеп бетеп, җиде ат бер-бер артлы тезелеп, кайтырга кузгалды. Фазыл кайтып кергәндә, Мөниржан әле яңа гына төшкелеген капкалап килгән иде. Алып кайткан саламның кирәк кадәресен тиз генә икәүләп атлар алдына салдылар. Калганын кертеп куйдылар. Шуннан соң Фазыл ашарга кайтып китте. Күңелендә бүген туган уен хәзергә Мөниржанга әйтми торырга булды. Ул әйләнеп килгәндә, атларны төнгелеккә эчертеп, абзарга ябасы гына калган иде.

Озакламый эңгер-меңгер төшәчәк. Бүген һава алмашырга итә. Иртән үк берән-сәрән төшкән кар бөртекләре һаман саен ешая барды. Ниятне тормышка ашырырга Ходай Тәгалә үзе үк шартлар тудыра түгелме соң...
Икеләнеп шактый йөргәннән соң, кулдашына серен чиште:

—Мөнир...

—Тыңлыйм, дус.

—Безнең бит озакламый атларга ашатыр нәрсәбез калмаячак. Басуда да дим...

—Монысын әйтмәсәң дә беләбез, яңалык түгел. Син менә ни эшләргә икәнен әйт. Шул чагында булырсың кеше!

Хәзер инде артка чигенер урын юк, әйтми кала торган түгел...

—Митрәйләрнең саламы бар...

—Башкортларда тагын да күбрәктер әле ул, ә Америкада бодай оның кая куярга белмиләр ди.—Мөниржан киная белән көлеп җибәрде.

—Син көлмә. Мин чынлап әйтәм. Без саламга барган җирдән ерак түгел бер эскертне башлаганнар...

—Башласа соң. Шуннан ни булган?—Мөнирҗан һаман да Фазылның тел төбен аңламады.

—Әллә соң төнге якта берәр йөк саламга юллыйбызмы, диюем...

—Син нәрсә? Кемнән сорап?

—Кемнән сорап, кемнән сорап!—дип үртәлде Фазыл.—Кемнән сорыйсың инде? Аларның быел саламы күп. Бер йөктән генә бөлмәсләр әле.

—Һм-м... Әгәр эздән килсәләр?

—Соң, Мөнир дустым, кара әле, кар ничек ява, җил дә себереп тора. Мондый һавада кайдан килеп эз калсын.

—Анысы шулаен шулай ла ул. Нигәдер күңел тартмый. Гайния дә соңгы көннәрдә кәефсез йөри. Аны калдырып чыгып китүе әллә ничек...

—Ярый, алай булгач, мин үзем генә барып кайтыйм. Төйи алган кадәр төярмен,—диде Фазыл, дустының хәленә керергә теләп.

—Ничек, бер үзеңме?

—Төямәгән йөк түгел лә!

—Төявен төягән дә бит...

—Шулай булгач...

—Юк, мин синең үзеңне генә җибәрмим!

—Ярар, бармыйм алайса, син теләмәгәч.

—Юк, барасың!

—Аңламыйм.

—Икәүләшеп барабыз.

—Әле генә бармыйм дигән идең...

—Ә хәзер барабыз дим! Әйдә, кайсы атны җигәбез?

—Мөнирҗан, бәлки йөрмәссең. Күңелең тартмый бит. Гайнияне дә кәефсез дидең.

—Ул берүзе түгел. Өйдә анда миннән башка да кешеләр бар.

—Син дә өйдә калсаң, яхшырак булыр.

—Үзеңне генә җибәримме? Булмый. Син дөрес әйтәсең, китап барны бүлешергә кушкан. Безгә ничек тә атларны исән-имин кыш чыгарырга кирәк.

Мөнирҗанның гадәтен белгәнгә, Фазыл дустының сүзеннән кире кайтмасын аңлады. Силсәвит рәисе Садрый Минһаҗев җигеп йөри торган Чәкчәк белән ике дус төнгә каршы саламга юнәлде.

Өч сәгатьләп вакыт уздымы икән, алар салам төяп кайтып та җитте. Ялкау гына искән җил ат караучыларның эзен кар белән тигезләде.

Беренче барулары уңышлы чыккач, Фазыл белән Мөнирҗан ул басуга көн аралаш диярлек тагын биш-алты тапкыр сәфәр кылды.

Атлар колынлый. Яшь колыннар йөгереп уйныйлар да, койрыкларын чәнчеп, тизрәк әниләренең имчәген суырырга керешәләр. Каты саламнан башка ризык күрмәгән, әле анысы да җитәрлек түгел, кабыргаларын мандолина кылы урынына чиртеп уйнарлык арык бияләрнең болай да чыкмаган җаны гына калган. Такы-токы ризык белән ул мескенкәйләр кая барсын. Их, бирәсе иде чак кына чемченә башлаган колыннарга бераз гына булса да чәй урынына кайнатып эчәрлек хуш исле урман печәнен! Бирәсе иде, тик аны кайдан аласың. Хәсьянов рөхсәтеннән башка фуражир аның сыңар бөртеген дә бирми. Председательгә дә үпкәләп булмый, чөнки башка бригадаларда да шул ук хәл.

Беркөнне, саламга баргач, ат караучылар җыелып сөйләште дә уртак фикергә килде: иртәгә барысы бергә Хәсьянов янына керә һәм хәлне аңлатып бирә. Таш булмаса, йомшамый калмас «Дәҗҗал» күңеле.

Мөнирҗан белән Фазыл анда керүнең уңышлы тәмамланасына алдан ук шикләнгәннәр иде, хак булып чыкты. Хәсьянов бу хакта ишетергә теләмәде генә түгел, ат караучыларны бүтән борчып йөрмәслек итеп куып ук чыгарды. Башта аты-юлы белән сүкте, соныннан әйтте:

—Минем жилкәдә ат кына түгел, сыеры, сарыгы, дуңгызы, хәтта үләлмәгән бетле тавыгына кадәр! Кашынып йөрмәгез, башыгызны эшләтегез. Мин сезгә печәнне бирмим, әмма атларны, колыннарны үтерсәгез, рәхим-шәфкать көтмәгез!

Бу сүзләргә каршы ни әйтсеннәр ат караучылар: закон көчленеке! Хәсьянов белән бәхәсләшкәнче, ишәккә акыл өйрәт яки жилгә каршы пес ит! Битенә чәчрәсә чәчрәр, хет тәненә жинеллек килер.

Кышка шулай хәерче кергәч, аны ничек тәмамлар Әскәй халкы? Бу хакта кычкырып уйларга да куркыныч иде. Һаман-һаман күршеләрнең саламын урлап яшәп булмый ич.

Салам дигәннән... Мөниржаннар хәзер шактый гына запас туплады. Салам кайдан килгән, бу хакта беркемгә, хәтта бригадирга да әйткәннәре юк. Югыйсә Харрас сукыр түгел, аксак булса да, күзе үткен, яшереп эчкә тутырган саламны күрми калмагандыр. Сак кына тотканда, шактыйга житәр бу запас. Бераз печән дә юнәткәндә, бигрәкләр дә шәп буласы иде дә бит...

Бу юлы инициативаны Мөниржан күрсәтте:

—Хәтерлисеңме, урманайларның Бүре убасында печән эскертләре бар иде,—дип башлады ул сүзен.

—Ничек хәтерләмәскә! Дүрт эскерт тора анда.

—Менә, менә! Әллә, мин әйтәм, ике ат жигеп, берәрне юллыйбызмы? Колыннарга гына салсак, шактыйга житәр иде.

—Ә тотсалар...

Тотсалар, печән өчен жәза саламныкы ише генә булмаячагын чамалыйлар алар. Печән бит аның исеме дә!

—Тотсалар, баштан сыйпамаслар. Шуңа күрә тоттырмаслык итеп эшләргә кирәк. Саламга баргандагы кебек. Аннан соң без бит үзебезгә түгел, колхоз маллары өчен алабыз.—Шушы дәлил аларны тынычландыра төште.

Ул көнне һава тыныч иде, артык суык та түгел. Салам, печән ишене төяргә менә дигән. Ләкин моның бер унайсыз ягы бар: тын һавада карда эз кала. Ак кәгазьгә шигырь юллары язган сыман. Егетләр моны гына белә иде югыйсә, шулай да тәвәккәлләргә булдылар. Янәсе, калган эшкә кар ява. Өстәвенә, эскертләр Урманайдан бик ерак, ул эскертләргә чират житкәнче, йөз тапкыр кары да явар, жәяүле бураны да күтәрмәс. Аннан соң тап эзләп дингездән ком бөртеген!

Иренең кичләрен озак кайтмый торуларына эче пошса да, Гайния моңа кадәр сүз әйтмәде. Эш белән йөрим ди бит. Эш диюе әллә сылтау гынамы? Эшне пәрдә итеп, берәр чәчбикәгә иязләшмәгәнме аның ире? Кияүгә гыйффәтле көе чыга алмаганга үзен Мөниржан каршында гаепле санап йөргән Гайниянең никадәр генә теле кычытмасын, бу хакта сүз кузгатканы булмады. Бүген түзмәде, ире кайтмый торгач, каенанасына сүз катты:

—Инәй, ни эшләптер, соңгы араларда Мөниржан өйгә озак кайтмый тора башлады. Әллә атларга булмаган тозны үзләре ясый инде.

Ана күңеле дә сизә, шөбһәләнә. Әмма корсагы борынына көннән-көн якыная баручы киленен, ул да тынычландырмаса, кем тынычландырыр?

—Кызым, юкка борчылма, эше бардыр, кайтыр. Исән-сау гына булсын,—дип юатты аны Минсафа карчык.

—Караңгы бит инде, төн. Бу караңгыда ни эшләмәк кирәк?

—И-и, килен, эшләгән кешегә эш бирермен дигән Ходай.

Каенанасы шулай дип юатса да, Гайния түзмәде, берәүгә бер сүз әйтмичә, ат абзарына китте. Анда ат караучыларның ник берсе булсын! Бу аның шиген көчәйтте генә. Ул иренә чын-чынлап үпкәләде генә түгел, күңелендә моңа кадәр кыяр-кыймас яткан көнчелек корты баш калкытты.

—Оятсыз, бүген-иртәгә бала атасы булырга торган башы белән! Башка жирдә түгелдер, берәр сөяркәчекне тапкандыр. Әйтәм аны арып-талып

кайта. Адәм рәтле кочаклаганы, яратканы да юк соңгы вакытларда. Алдакчы!

Яшь хатын үзен алданган һәм кимсетелгәнгә санап, Мөнирҗанны да өзгәләп ыргытыр хәлгә килде. Хәзер аның берәүне дә күрәсе, беркем белән дә сөйләшәсе килми иде, шуңа күрә, өенә кайткач, чыбылдык эченә керде дә, мендәргә капланды.

Бу вакытта Мөнирҗан белән Фазыл Урманайның эскертенә әле генә килеп җиткән һәм, ашыга-кабалана, печән төяү хәстәренә керешкән иде.

Ике чанага печән төяү һәм алып кайту артык авыр булмады. Беренче көн сәнәк тотулары түгел ләбаса! Кайтуын да тиз кайттылар, ни дисәң дә юл үргә түбән, атлары да бөтенләй үк хәлсез түгел. Сәгать уннар тулганда, печән, кертеләсе җиргә кертелеп, салам белән капланган, чана төбе «ялап» алынган иде. Дуслар шунда гына җиңел сулап куйдылар.

—Аллага шөкер, бүгенгә эш бетте!—диде Фазыл.

—Әллә колыннарга бераз салыйкмы?—Мөнирҗанның тизрәк колынкайларын сөендерәсе килде.

—Ашыкма,—дип каршы төшете Фазыл.—Ашыккан ашка пешкән. Тыныч кына бер-ике көн көтик әле.

Гөнаһ шомлыгына каршы, печән алып кайтканның икенче көнендә урманайлылар кырдагы эскертләргә ревизия ясарга чыктылар. Төш җитәрәк, алар Бүре убасына да килде һәм, эскертнең башланганын күреп, аһ иттеләр. Мондый хәлнең күптән булганы юк иде.

—Кем эше булыр бу?

Карак исемен язып калдырмаган, ләкин карда өр-яңа эзләр ярылып ята.

—Күрмисеңмени, Әскәй ягына юл тотканнар!

—Ашыкма, митрәйләр йә үчәлләләр булуы да бар.

Бу фаразларга аучы Шәвәли нокта куйды:

—Җәмәгать, юкка бәхәсләшмәгез, эз буенча барырга кирәк, шунда ук кайдан икәне ачыкланыр печән бурларының,—диде ул.—Теләсәгез, мин карап кайтам.

Чыннан да, эз тануда аучы буларак даны тирә-юньгә таралган Шәвәли барында, алар көтүләре белән йөрмәс бит инде.

Чана эзе аны адаштырмый-саташтырмый гына туп-туры Әскәйгә алып килде. Авыл эченә кергәч, эз югалды, чөнки иртәдән бирле ул эздән күпме ат узгандыр, Ходай белсен. Шәвәли үзенә тапшырылган бурычны үтәде. Карак—Әскәйнеке! Бусына иманы камил, калганын прсидәтел белән милитсия карасын. Ник Әскәйнең астын өскә китермиләр шунда—Шәвәлинең анда эше юк.

Хәерле юлга чыккан икән Шәвәли. Кире кайткан чагында, Әскәйне чыгып күп тә китмәде, һич уйламаганда төлке атып алды. Зур төлке иде ул! «Оныгыма бүреккә булыр»,—дип куанды яше алтмышка житеп килүче аучы, төлкене көлтә койрыгыннан чанага алып салганда.

Идарәдә колхоз рәисе аның кайтуын көтеп утыра иде.

Озакламый район милиция идарәсенә Урманайдан: «Әскәйләр безнең эскерттән печән урлаганнар»,—дигән хәбәр алынды. Мондый хәбәр нәтиҗәсез каламы соң! Икенче көнне иртән үк авылга участковый Исхак белән тикшерүче Ильин килеп төште. Болар инде тикшерү эшендә азау теш ярган, моның эше вак-төякне генә түгел, кибет басуларны да күргән кешеләр.

Исхак кечкенә гәүдәле, бөтерчек кебек кенә булса, Ильинны урталайга ярсаң, нәкъ ике Исхак чыгар иде.

Әскәйне Исхак ярата да, яратмый да. Яратуы шуның өчен: бу авылда җинаять эзен табуы җиңел. Ник дисәң, халык көнчел, бер-берсен чагып кына тора. Әнә күрше Митрәй авылына барып кара син! Анда барысы да белә, тик ник шунда берсе әйтсен. Ләм-мим! Тикмәгә генә Митрәйгә тагын

Җүнәй дигән исем дә кушмаганнар. Халкы бик юнәтергә ярата.

Әскәйне яратмавының да сәбәбе бар: ул милициядә эшли башлаган елында нәкъ менә Әскәйдә адәм көлкесенә калды.

Ничек дисезме?

Вакыйга болай булды.

1938 ел иде. Кызыл Армиядә хезмәт итеп кайткан Исхак Әюповны райком милициягә эшкә җибәрде. Күпмедер инструкцияләр алганнан соң, Әюповны Әскәй, Митрәй, Урманай авылларына участок милиционеры итеп билгеләделәр.

Участок милиционерының хокуклары зур. Үз биләмәсендә ул кечерәк кенә булса да—хан. Карасаң, чыраең күренерлек итеп ялтыраткан итекләрен киеп, үтүкләнгән формасын изеп таушалдырудан курка-курка гына, үзенә беркетелгән аты Орликка атланды да бер иртәдә ул Әскәйгә танышырга китте. Декабрь урталары иде. Азнакайдан Әскәйгә кадәр унике чакрым ара булгач, ул юлга караңгыда ук кузгалды.

Исхак Әскәйгә килеп җиткәндә, әле янарак кына яктырган иде. Яна участковый танышуны колхоз председателеннән башларга уйлады. Аннан башламый, тагын кемнән башласын? Колхозга ул хуҗа. Димәк, тәртип өчен дә ул җавап бирә.

Әюпов килеп кергәндә, председатель кабинетында ялгызы гына иде. Участок милиционеры исәнләшергә һәм танышырга гына өлгерде, кулларына беләк буе пычак тоткан дүрт адәм килеп керде. Аларның берсе керә-керешкә:

—Башта прсидәтелне суябызмы, әллә милитсиянеме?—дигән сорау биреп, Исхакның ушын алды.

Исхак тикмәгә генә армиядә биш ел хезмәт итмәде. Ул пычаклы адәмнәрнең тазалыгын һәм дүртәү икәнлекләрен күреп, тегеләр һөҗүм итә калган очракта, алышның үз файдаларына тәмамланмаячагын шунда ук бәяләп өлгерде. Каушавыннан кобурасында корылган пистолеты барлыгы да исеннән чыкты.

Армиядә хезмәт итү кискен очракларда Исхакны тиз арада карарлар кабул итәргә өйрәтте. Бу юлы да ул хәлне тиз бәяләде: каршылык күрсәтү файдасыз, тизрәк районга кайтып, тревога игълан итәргә һәм, отряд белән килеп, биредәге халык дошманнарының тамырына балта чабарга!

Исхак ишек төбендәге һичнидән шикләнми басып торган адәмнәрнең берсенә башы белән бәреп, үзенә юл ачты һәм Орликка атланып, җан-фәрманга Азнакайга элдертте.

Милиция идарәсенә кайтып житүгә, ул начальник бүлмәсенә атылып барып керде һәм сулышына буыла-буыла кычкырды:

—Иптәш начальник, Әскәйдә бунт күтәрделәр, сручны әтрәт җибәрүегезене сорыйм!

Бунт сүзен ишетүгә, милиция башлыгы Зәйнуллин ничек сикереп торганын сизми дә калды:

—Нинди бунт? Аңлатып сөйлә!

Зәйнуллинның хәлен аңларга була. Кулакларның, халык дошманнарының тамырын корытып килгәндә, аның биләмәсендә дошман элементлар баш калкыта икән, рәхим-шәфкать көтәсе түгел. Киресенчә, моннан файдаланып калырга кирәк. Бәлки күптән тынычланып калган Татарстанда бу очрак аңа танылырга, үсәргә ярдәм итәр. Нәкъ шушы очрак аркасында Зәйнуллин бәлки каһарманга әверелер...

Исхакның:

—Председатель бүлмәсенә пычак тоткан дүртәү бәреп керде һәм прсидәтелнеме, әллә милитсиянеме алдан суябыз диюгә, икесен бәреп егып, мин көч-хәл белән чыгып ычкындым! Прсидәтелне харап итеп кенә өлгермәсәләр ярар иде!—дигән сүзләрен ишетүгә, Зәйнуллин, әлеге минутта

кул астына кем эләксә, шуны тревога белән күтәрде:

—По коням!

Унбишләп кешедән торган отряд тагын бер ярты сәгатьләрдән Әскәйгә килеп житкән иде инде. Алар шунда ук колхоз идарәсе урнашкан йортны урап алды.

Пистолетын әзер тоткан хәлдә, Зәйнуллин, Исхак һәм тагын берничә милиционер белән бергә, председатель кабинетына бәреп керде. Үз урынында исән-имин утырган Гайнаншинның:

—Лилин! Лилинны бир дип әйтәм мин сина, ананны фәлән итим! Син нәрсә, Лилинны да аңламаслык тавык мие эчтең мәллә? Безнең вождь, плитиариат юлбашчыбыз! Бездә бар да нурмалны, иптәш секретарь!

Керүчеләр анын районнын беренче секретаре белән сөйләшкәнен аңлап алды!

Председательне исән-имин күреп, Исхакның күзләре маңгаена менде. Ә Гайнаншинның аптыравы аныкыннан да артык иде.

—Сезгә нәрсә булды? Көтүегез белән йөрисез. Берәр жирдә пужар түгелдер бит? Әллә корт чактымы?—дип сорады ул, күрешер өчен Зәйнуллинга кулын сузып.

—Нинди бунт монда сезнен?

—Бунт?—дип кайтарып сорады Гайнаншин.—Нинди бунт?

—Соң йә сине, йә мине суярга теләгәннәр иде бит!—дип сүзгә катышты Исхак.—Син ничек исән калдын?

—Кем суйсын мине? Минем карт сөяк кемгә кирәк булсын. Әллә саташасыңмы? Иртән дә кеше төсле чыгып китә белмәдең.

—Ничек инде саташам? Иртән бит пычак тоткан дүрт адәм кереп, прсидәтелнеме, милитсиянеме алдан суябыз, дип сорады.

Гайнаншин Исхак Әюповка карап торды-торды да шаркылдап көләргә тотынды. Көлә торгач, ютәлли башлады. Ютәлен басар өчен өстәлдә торган графиннан сырлы стаканга су агызып эчте. Аннан соң гына:

—И энем, энем, алар бит сугымчылар. Мин аларга ике ат суярга куштым. Атларның берсенен кушаматы Милиция, икенчесенеке—Прсидәтел. Шуларның кайсысын алдан суябыз дип сорарга кергәннәр алар.—Ул тагын көлә башлады. Хәзер инде аңа эшнең нидә икәнен аңлаган Зәйнуллин һәм тревога белән атка атландырылган бүтән милиционерлар да кушылды. Тәмәке төтененнән саргаеп беткән, бүрәнә арасына кыстырган мүкләренә кадәр төтенгә уралган идарә диварларынын шушы кадәр ир-атның шаркылдавын күптән, ә бәлки гомерендә дә ишеткәне булмагандыр. Түшәмнәренә кадәр селкенде бугай, мич кырыендагы түшәм арасыннан туфрак коелып, нәкъ Исхак өстенә туры килде.

Исхак Әюповның ничек көлкегә калуы көне-сәгате белән илгә таралды. Әскәйнең үзендә дә халыкка житә калды—Исхакка эте дә, бете дә аңардан көлеп каладыр кебек тоелды.

Әскәйне яратып бетермәвенең сәбәбе менә шул иде. Дөресен әйткәндә, авылда инде бу хәл күптән онытылды. Исхак үзе генә никтер оныта алмый.

Садрый Минһажев участок инспекторы белән милиция тикшерүчесенең тикмәгә генә йөрмәгәнен белә.

—Ни эшләр майтарасыз?—дип каршы алды ул килүчеләрне.—Нәрсә, әллә тагын берәр жирдә кибет басканнармы?

Килү сәбәбен белми торып, Садрый тынычланмаячак иде. Ә моның өчен тел ачкычы кирәк. Авыл советына «важный» кешеләр гел килеп тора. Коры кашыкның авыз ерткаnын белә Садрый, шуңа күрә эшендә һәрвакыт ким дигәндә бер шешә аракы белән ике-өч баш суган, ипи катые тота. Район кешеләрен көйләп-чөйләп тормасаң, тәртәгә тибү ягын гына карыйлар. Ә анын һич кенә дә «былач» башыннан төшәсе килми иде.

Садрый кулындагы шешәне күргәч, тикшерүче куанычыннан улап жибәрде:

—У—у, мать честная, Садрый Мингазович!—диде ул төкерекләрен йота-йота.—Валлаһи, син күрәзәчедер. Кичә бик каты эшләргә туры килде, шуна күрә бүген башнын чатнавына түзә торган түгел.

Ильин тарафыннан әйтелгән мондый мактау сүзләреннән Садрыйнын тыны кысылды. Ильиннын районда абруе югары, шундый кеше мактап торсын да, тынын кысылмасын.

—Дарагуй Алексей Митрофанович,—Садрый дулкынлануын милициягә сиздермәскә тырышты.—Низнал бит сезнен кебек кадерле кунак киләсен. Аш салдырып куйган булыр идем. Извиняйте, закуска каты-коты гына.

—Не болтай ерунду! Аш—потом. Без монда әллә ашарга килгән дип беләсенме? Наливай тизрәк! Ә син, Исхак, суган кис.

Татар районында эшләгән Ильин татарчаны анлый, ипилек-тозлык кына сукалый да иде.

Жыештыручы булып Хәят силсәвиттә унынчы елын эшли. Жыештыручы дигәч тә, эше идән юу-себерү белән генә чикләнми, йомышчы вазифасы да ана йөкләнгән. Силсәвиткә Хәят аша әле тегесен, әле бусын чакырталар. Бигрәк тә финагент килгән чакларда тынычлык бетә. Ике йөз илле йортлы авылнын салым түләмәгән кешесен Түбән очтан дәшеп кайтып керүе була, икенчесе артыннан Әрәмә тавы астына жибәрәләр. Андый чакларда хәлдән таеп, тәмам аяктан егылыр чиккә житеп арый Хәят.

Авыл советында рәис булып колхозлашкан еллардан бирле Халикъ Насрыев эшләгән иде. Хәятне эшкә дә ул алды. Насрыев элеккеге хәлфә малае, укыган, тәрбияле, чын мәгънәсендә зыялы кеше иде. Кемгә кай ягы белән ошамагандыр, анын «япун шпиуны» булуы хакында шикаять кулларына эләгүгә, органнарга уяу икәнлекләрен расларга жай чыкты: бер төндә килделәр дә, озакламый кайта дип, алып та киттеләр. Кая ул аны кайтару, әле Хәяттән дә әлләниләр сораштырып, башын бутап бетерделәр.

Совет властенын авылдагы ин югары органын озак буш тотарга ярамый иде, авылнын үзендә, күрәсен, лаеклы кеше булмагандыр, күп тә үтми район үзәгеннән утыз биш-кырык яшьләрдәге Садрый Минһажев дигән берәүне китереп куйдылар. Насрыевнын хатыны Мөслим районыннан иде, ире кулга алынганнан сон, ата-анасы янына кайтып китте.

Буш калган йортка Минһажевны урнаштырдылар. Авыл советынын яна рәисе ни өчендер хатынын шунда ук алып килмәде. Бусы авыл халкы өчен сер булып калды.

Йорт йорт инде, бер генә кеше яшәсә дә, аны карап, жыештырып торырга кирәк. Садрый Хәяткә бу вазифаны да йөкләде.

Теләсә дә барды Хәят, теләмәсә дә барды. Ачуын китерсән, Садрыйнын холкы кырыс, эштән куарга да күп сорамас. Ә Хәятнен һич кенә дә көннәр буена урак урып, көлтә бәйләп йөрисе килми. Юк, килми. Авыл советындагы эше жинел булмаса да, декабрь айларында чабагач белән ашлык сугу түгел инде ул.

Хәят өй жыештыруны бер дә авырга санамады. Исен киткән икән атнага бер тапкыр юып чыгаруга.

Садрый эшли башлаган елнын июле бик эссе килде. Күләгәдә утыз-утыз биш градус. Сулыш алыйм дисән, борын яфраклары көя, эсселек тынга каба. Уракка төшәргә чак кына иртәрәк булса да, файдага ярардай һәркем кырда, печән хәзерләүдә.

Минһажев белән колхоз рәисен урып-жыюга әзерлек мәсьәләсе буенча районга кинәшмәгә чакырдылар. Садрый Хәяткә телефоннан ерак китмәскә кушкан иде. Авыл советында утырды-утырды да Хәят төш житкәндәрәк

Минһажевның өен җыештырып кайтырга булды. Гадәттә ул бу эшне йорт хуҗасы өйдә юкта башкара.

Ул ике чиләк су, мунчала алып керде. Авылда кеше юк-югын, ләкин Ходай сакланганны саклармын дигән. Усал күзләр күрмәсен дип, тәрәзә пәрдәләрен тартып куйгач, ашыкмыйча гына күлмәген салды һәм аны чөйгә элде. Оят булмаса, калганын да салыр иде дә... Юк, ярамый, ялгыш берәрсе күреп калса...

Хәят стенага эленгән зур көзгә каршысына басты. Монда килгән саен ул шул көзге каршысында боргаланмый түзми. Менә хәзер дә ул күкрәкләрен сыйпап, үзенең йомры тез башларына, төпкә таба матур юанаеп күтәрелгән ботларына суккалады, кызларныкына алыштырмас билен сыйпап, рәхәт бер елмаю белән елмайды. Тора-бара бу елмаю көрсенү, сагыш белән алмашынды. Дүрт ел элек кулаклар атып үтергән тракторчы Шакирҗанның егерме сигез яшьлек хатыны, үткәннәрне уйласа, тәненең тартыша башлавын тоя, барча күзәнәкләренә өстәмә кан тула.

Хан кызы булса, Хәят көзгә каршысыннан китмәс, болай көрсенеп тә тормас иде. Ләкин, кызганыч, ул шушы авылның Гыймади батрак кызы гына, һәм аны эш көтә.

Тагын бер тапкыр көрсенде дә, иелеп, Хәят идән юарга кереште. Бераздан аның сагышы узды һәм ул җырлап җибәрде:

Көймә килә, көймә килә,
Көймә килә, эзе юк.
Хаты гына килә генә,
Сүзе генә килә генә,
Сөйләшергә үзе юк.

Садрыйларның кинәшмәсе, ни гаҗәптер, озак бармады. Кинәшмә тәмамлануга, ул туп-туры Әскәйгә кайтып китте. Хатыны янына кереп, нервыларын бозасы килмәде. Тискәре дисәң дә тискәре аның Мәгъфиясе: Әскәйгә бармас өчен җан тартыша. Әйтерсең анда мөгезле кешеләр яши. Сәнәктән көрәк булган дивана баш ни өчендер Садрыйның партия солдаты икәнен анларга теләми.

Озаграк торырга туры килгән чакларда, ул Азнакайда өенә кагылып, капкалап кайта торган иде. Бу юлы төшкелекне авылга кайткач кына ашарга уйлады. Җырлый-җырлый идән юып йөргән Хәят, Садрыйның кергәнен сизмичә, эшен дәвам итте.

Хәятнең кыяфәтен күреп, Садрый башта сиздермичә генә кире чыгып китәргә дә уйлаган иде, әмма бармаклар белән инләп алырлык нечкә бил, таза аяклар аның күзен томалады, үзенең ир икәнен, бу гүзәллек каршында көчсез икәнен сиздерде. Хатыны янына да ике атналап кайтканы юк, өстәвенә, соңгысында Мәгъфия белән ачуланышып та аерылышканнар иде.

Беренче эш итеп карт төлке ишек келәсен элеп куйды. Калганы күз ачып йомганчы эшләнде: ажгырып торган ир арттан килеп Хәятне күтәреп алды да түшәгә иртән җыештырылмый калган сәкегә илтеп салды. Ул шашып-шашып Хәятне үбәргә керешге һәм иреннәре бушаган арада:

—Хәят, акыллы бул, акыллы бул. Мин сине яратам!—дип сөйләнде.

Хәят башта чын-чынлап карышып карады, чәбәләнде. Ләкин аның бу чәбәләнүе чебеннән имән ишеккә килеп бәрелүенә генә тиң иде. Чәбәләнеп берни дә барып чыкмагач:

—Кычкырам, җибәр!—дип куркытты. Ләкин үзе кычкырмады, югыйсә авызын каплаучы да юк иде. Аның тартышуы озакка бармады, наз теләгән яшь тән әдәп-ояттан көчлерәк булып чыкты. Ул берзаманны Садрыйны кысып кочаклап алганын сизми дә калды...

Аларның мәхәббәт уены, Мәгъфия күчеп килгәнче, шул өйдә дәвам итте.

Мәгъфия килгәч, Садрый Хәятне барыбер онытмады: йә авыл советында берәр җаен таба, йә кеше-карага сиздермичә генә өенә сугылып чыга. Авыл советы рәисенең хокуклары киң вә широкий, кемгә керсә дә гаеп түгел.

Баштарак Хәят, халык моны сизәдер дип, унайсызлану кичерә иде. Адәм баласы һәр нәрсәгә күнегә, тора-бара бу гыйшык-гошрәт уенын шулай булырга тиеш кебегрәк хис итә башлады.

Авыл советында эшләгән ун ел эчендә күпне күрде Хәят. Күрергә яраганын да, ярмаганын да. Садрый аны килгән көнендә үк кисәтеп куйган иде:

—Минем янга кешеләр килсә, чык, безнең важный сүзләрне тыңлап утырырга ярамый!

«Важный» сүзләр дә булгандыр силсәвиттә, булмый калмагандыр, шулай да Хәяткә мондый «важный» сөйләшүләр тәмамлангач, кагыйдә буларак, буш шешә, тозлы балык калдыклары, ипи валчыгы кебекне җыештырырга туры килә иде.

Белә Хәят, белә үз урынының кайда икәнен: прсидәтел кочагына кергәләп торса да, силсәвиттә аның янында «важный» сүз барган чакларда, алгы бүлмәдә мич янындагы эскәмиядә аның урыны. Эскәмиягә иске чикмән җәелгән. Хәят шунда утырып, кеше юкта ятып та торгалый. Ул Минһаҗев абыйсына әйтми генә: рәис бүлмәсендәге «важный» сүзләр барысы да диярлек Хәяткә ишетелеп тора. Садрый шуны әллә белми, әллә белеп тә колагына элми. Менә бүген дә ул башта кабинет хуҗасының:

—Исхак белән без ешрак күрешәбез. Сезнең приезлар хөрмәтенә, дарагуй Алексей Митрофанович!—дигән тавышын ишетте.—Сезнең кебек зур кешеләр зерәгә генә йөрмәс, берәр чыпы булдымы әллә?

—Тост тәкъдим иткәч, күп сөйләшмиләр, югыйсә стакандагы ризык үпкәли.—Ильинның инде баядан бирле тәкате коргаксыган иде.—Башта салганын эчеп җибәрик.—Тикшерүче аракысын голт-голт йотып куйды.—Уф, дөньялар яктырып китте. Нәрсә сорамакчы идең әле? Спрашивай!

—Чыпы случилсамы әллә, дим!

Ильин суган капкан иде, ул авызындагын йоткалаганчы, Исхак килүләренең максатын ярып салды.

—Начар, начар, Садрый абзый. Авылыгызда урлашалар.

—Юкны сөйләмә, апай. Нәрсә урлашалар, кем урлаган?

Әйтергәме-әйтмәскәме дип, Исхак тикшерүчегә карады. Тегесе, фатиха биргәндәй, баш какты.

—Урманайлар жалу итте: аларның эскертеннән печән урлаганнар!

—Кем әйтте?

—Сүз иясе белән йөрми. Кем әйтсә дә, барыбер түгелмени? Ә печәнне сезнең авылныкылар урлавы—туп-тучны!

—Кайчан?

—Ике-өч көн элек.

Шул чакта Садрыйның өченчекөн төнлә белән күргәне келт итеп исенә төште. Мөршидә яныннан чыгып, тугыз сәгатьләр тирәсендә өенә кайтып бара иде. Беренче бригада турысына җиткәндә, чаптырып килгән ат аның өстенә менә язып үтеп китте. Йөктәге печән хәтта йөзенә ышкылып диярлек узды. Мөршидәнең әче балын эчеп, шактый мәлҗерәгән булса да, чанадагы йөкнең салам түгел, печән икәнен борынын ярып кергән исеннән таныды ул.

Эченнән генә сүгенә-сүгенә, Садрый бригада капкасыннан кереп киткән йөк артыннан карап калды. Башта кереп пыр туздырырга уйлаган иде, башында адашып калган кичтеки генә аек акылы аны бу адымын эшләмәскә үгетләде.

Садрый Әскәйнең бер-бер артлы утлары сүнә барган урамыннан чайкала-чайкала өенә кайтты да мыштым гына урынына менеп ятты. Мәгъфиясе гырлый-гырлый йоклый иде.

Икенче көнне йокыдан торганда, ул бу хакта оныткан иде инде. Моның өше чакта кайсысы мөһимрәк: печән йөгеме, әллә Мөршидә янында булганыңны сиздертмәүме? Әлбәттә, соңгысы!

Бөтенләй онытты дисә, бик үк дөрес булмас иде. Төштән соң исенә бер кереп чыкты ул. Ләкин моны төшендә күрдеме, әллә өнендәме—тәгаен генә әйтә алмас иде. Ә хәзер, Исхак урманайларның печәнен урлаганнар дигәч, тамчы да шиге калмады. Кызганыч, йөк өстендә кемнәр утырганына игътибар итмәгән. Хәер, беренче бригада ишек алдына борылып кергәч, Чулак Мөнир белән Фазылдыр. Бүтән кем булсын.

Уйларыннан аны Ильин бүлдерде:

—Садрый Мингазович, как ты думаешь, кто может быть бу печән бурлары?

Күңелендәгесен әйтергәме, әйтмәскәме? Садрый икеләнеп калды. Милитсия каршысында бик «әфтәритит» тә казанасы килә, шул ук вакытта авылдашларына әверелгән әскәйлеләр өстеннән сөйләүнең дә килешмәгәнен сизенә. Нишләп соң алар, урлагач, ул печәнне өйләренә бушатмыйча, бригадага алып кереп киттеләр. Ник? Менә шунысын аңлый алмый, шунысы Садрыйның башына сыймый. Колхоз атлары өчен алып кайтмаганнардыр бит инде канса да кансуф?! Булмас, булмас, кеше ышанмаслык сүзне чын булса да сөйләмә! Ат карый торгач, башларына тай типсә генә инде. Барысы да колхозныкын урлаганда, болар гына башка камырдан түгелдер. Әһә, кеше шикләнмәсен дип, башта бригадага бушатып торырга уйлаганнар!

Әле генә эчкән аракы пары Минһаҗевның ми күзәнәкләренә таралды. Ул шешәдәге калганны да өч стаканга бүлеп салды.

—Эчик әле. Мужым без печән бурларының кем икәнен беләбездер дә. Садрый Минһаҗевичның күзләре үткен, колаклары сак. Әйе-әйе, кем икәнлекләрен мужым без беләбездер,—дип кабатлады ул. Садрый җай чыкканда урыс сүзләрен кыстырып сөйләргә ярата иде.

Исхак Әскәй авыл советы рәисенең гадәтен күптән белеп бетергән. Садрый чыннан да күпне белә, күпне күрә. Ләкин җаен тапмасаң, берсен дә әйтмәячәк.

Кешелекнең иң зур гөнаһларыннан берсе—аны мактау. Урынлымы ул, урынсызмы—анысы башка мәсьәлә. Шушы мактау кемнәрнең генә телен чиштермәгән дә, кемнәрнең генә башына җитмәгән. Мактау ишеткән черки үзен кигәвен, кигәвен—чыпчык, гади эт—овчарка, ә овчарка исә үзен арыслан итеп тоя башлый. Үгез исә филгә әверелә.

Исхак Садрыйга ничек ачкыч табарга икәнен белә иде, һәм ул ялгышмады.

—И-и, Садрый абый, райондагы барлык местный влач та синең кебек булса, милициягә эш тә калмас иде. Сине белеп кенә бетермиләр, югыйсә районга гына түгел, Казанга ук алырлар иде!—Исхак тикшерүчегә күз кысты.—Шулай бит, Алексей Митрофанович?!

—Что правда, то правда, Исхак. Кеше түгел, алтын ул Садри Мингазович!

—Спасиба, спасиба, рәхмәт, иптәшләр!—Башына аракы пары киткән Садрыйның күңеле тәмам нечкәреп, кайсы төстән икәнлеген күптән җуйган кульяулыгына ул лыңгырдатып борынын сеңгерде.

Исхак иң унайлы мизгел җиткәнен сизеп, тактикасын үзгәртте:

—Түлке бу юлы син булып син дә белмисең, Садрый абый!

Исхак нәкъ ноктасына басты. Садрый бу сүзләрне үзен мәсхәрәләү дип кабул итте.

—Мин белмимме?—дип сорады ул, ярсый төшеп.

—Белмисең шул. Белсәң, әйтер идең.

—Белми дисең инде, ә? Әйдә бәхәсләшәбез!

—Әйдә әйт, нәрсәдән? Бер яртыданмы?

—Юк, бер литрдан!—Садрый, үзен инде жинүчегә санап, бу бер литрның тәмен авызында тоя башлаган иде.—Бер литрдан!—дип кабатлады ул.

—Ярар, синенчә булсын, бер литрдан булсын. Белмисен!

—Беләм!

Бала-чага сыман тарткалашу Ильинны туйдыра башлаган иде.

—Житәр сезгә, хватит! Тизрәк кул бирешегез, мин аерам.

Шулай иттеләр дә.

Садрый куанычыннан кычкырып жибәрде:

—Һа! Бар, Исхак энем, йөгер кибеткә! Алып кайт бер литрыңны!

—Акылың алтын икән! Башта әйт, миннән тормас. Егет сүзе бер була.

Бу сүзләрне алгы якта ишетеп торган Хәятнен колаклары сагайды.

—Печәнне беренче бригададан эзләргә кирәк. Аны ат караучылар Мөниржан белән Фазыл алып кайтты.

—Әллә бергә урладыгызмы? Кайдан беләсен?

Ильин ялтырый башлаган күзләре белән Садрыйга текәлде.

—Күрдем. Өченчекөн кичке тугызларда бригада капкасыннан кереп баралар иде.

—Ә син, карт шайтан, төнлә белән ни эшләп йөри иден?

—Мин бит, Исхак энем, местный блач, сәвитски былач. Барысын да күрергә, белергә тиеш. Правдамы, товарищ Ильин? Мин дә йоклап кына ятсам, ирсез хатыннарнын күнелен кем күрер! Берсенең хәлен белеп кайтыш иде. Ха-ха!

Бу сүзләрне ишеткән Хәятнең ачудан тәне кызышып чыкты. Тфү! Хатыны булган өстенә Хәят белән йөрүе житмәгән, тагын әллә кемнәр белән сөйрәлә икән бит, карт тәре! Итәк бете! Күрсәтермен әле мин сина ничек итеп ирсез хатыннарның күнелен күрергә икәнен!

Эчтән тагын тавышлар ишетелде:

—Әйдәгез, ул бурларны тизрәк кулга алыйк!

—Стоп, Исхак энем! Башта бәхәстә оттырган бер литрыңны алып кайт. Ат караучылар пычагыма да китмәс, сонынннан кулга алырсыз.

Хатын-кызны мәхәббәт һәм нәфрәт утларга сала, бозлы суга ыргыта, көчле итә, хәлдән тайдыра, тауларга күтәрә, упкынга төшерә. Мәхәббәт һәм Нәфрәт хатын-кызны тыеп булмый торган бер затка әверелдерә. Менә хәзер дә Хәят ачуыннан буыла-буыла чыгып йөгерде. «Карт тәре, әләкче! Сатлык жан! Кулга алмый гына торыгыз әле!»

Кинәт уянган көнчелек хисе аны туп-туры беренче бригадага алып килде. Ул барып кергәндә, Фазыл атлар астын чистартып йөри, ә Мөниржан саламга киткән булып чыкты.

Хәятне күрүгә, Фазылның йөрәге жу итеп китте: силсәвитнең йомышчысы юкка гына йөрмәс.

- Фазыл апаем, авылга ике милитсә килде. Урманайларның печәнен урлаганнар икән. Мөниржан белән икегездән шикләнәләр. Сезне кулга алырга жыеналар. Булдыра алсагыз, качыгыз, апаем! Мөниржанга да әйт.

Хәят күңелендәге ярсуын пулеметтан аткандай тиз-тиз сипте дә жәһәт кенә китеп тә барды. Фазыл таш кебек катып калды. Кан тамырлары киңәйде, сулышы кысылды. Баш миен яндырып, «беттем!» дигән уй сызылып узды. Төрмәдә бер утырып кайткан кешегә котылу юк. Эш судка барып житә икән, срок чәпәми калмаячаклар. Фу, шайтан! Ичмасам, Мөниржан да юк. Ни эшләргә?

Әйе, бик хәтәр хәлгә килеп капты Фазыл. Мөниржанның утырганы булмагач, ана, бәлки, әлләни булмас та. Хәят аягы кычытканнан йөрмәс. Кулга алганнарын өйгә кайтып котәргәме, әллә бригададамы? Әллә тиз генә Әскәйдән табан ялтыратыргамы? Мөниржан ни эшләр? Ул бит әле милиционерлар килгәнен дә белми. Ана берни әйтми ташлап китү егетлек булырмы?

Фазыл Чәчкәгә ничек итеп йөгән кидергәнен һәм сикереп менеп атланганын сизми дә калды. Хәзер аның башында бер генә төрле уй: тизрәк, тизрәк!

Чәчкә Мөниржан саламга киткән тарафка очты. Ул килеп җиткәндә, ат караучылар бер генә чана төяп өлгергән иде әле.

—Егетләр, сәлам!

—Сәламенә—салам! Ярдәмгә килдеңме? Бигрәкләр вакытлы йөрисең дә инде үзең!—Җор телле саламчылар аны шаяртып каршы алды. Ләкин Фазылның шаяртып торырга теләге дә, вакыты да юк иде. Ул башкаларга игътибар итмәстән, Мөниржанны бер читкә чакырып алды:

—Кил әле...

—Ни булды, әллә нашатыр кыстырып җибәрделәрме?

—Ташла әле юк-бар сүз сөйләвеңне, уен кайгысы түгел монда. Беттек!

—Аңлатып сөйлә, ничек инде ул беттек?

—Урманайларның печәнен алып кайтканны сизгәннәр. Авылга ике милиционер килгән. Силсәвиттә утыралар икән. Хәят апа синең белән мине кулга алырга җыеналар дип кисәтеп китте.

—Кем әйткән? Кайдан белгәннәр?

—Анысын сорамадым. Кем әйтсә дә, барыбер түгелмени? Ни эшлибез? Кулга алсалар, баш бетәчәк. Сизеп торам: мине төрмәгә тыкмый калдырмаячаклар. Корчаңгы тайга тизәк тиз ябыша.

—Шуның өчен дә кулга алырлар дисеңме? Юкны сөйләмә!

—Ә син ничек уйлыйсың: ике йөк печән алып кайту бурлыкка керәме, әллә юкмы? Бер уч ашлык өчен дә утырткannарын оныттыңмы?!

—Ул бит сугыш чорында. Аннан соң без бит ул печәнне үзебезгә түгел, колхоз колыннарына дип алдык.

—Урманайларга аннан җинелрәктер дип беләсеңме?

Мөниржан уйга калды.

—Ни эшлибез соң?

—Белмим. Әйт. Минемчә, авылдан вакытында сыптырырга кирәктер.

—Кая?

—Әгәр белсәм... Ләкин, кулга алсалар, миңа әбизәтелне икенче судимость чәпәячәкләр. Мин инде төрмә баландасының тәмен беләм, икенче тапкыр эчәсем килми. Әйдә, ни уйладың?

—Уйламадым. Сиңа ансат, берүзең. Гайнияне ташлап, кая китим. Аннан соң шуның өчен генә хөкемгә тартуларына да ышанмыйм. Бер сугәрләр дә бетәр.

—Миңа калса, Мөниржан дустым, син ялгышасың. Соңгы тапкыр әйтәм: китик!

—Юк.—Мөниржан гажизләнгән карашын Фазылга текәде. -Миннән булмый. Бар, син кит, миңа карама.

—Хуш, дустым! Үпкәләп калма.

—Хуш, Фазыл, бигайбә.

Алар башта кул биреештеләр, соңрак кочаклаштылар һәм, атына атланып, Фазыл чаптырып китеп барды.

Ындыр артына җиткәч, Фазыл, атыннан төшеп, тезгенне йөгәнгә бәйләп куйды да Чәчкәнең сыртыннан сөйде:

—Бар, малкай, бар! Күрешәбезме синең белән, юкмы—Хода гына белә.

Ник монда каласың дигәндәй, ат, башын борып, аңа карап торды һәм, әкрен генә юыртып, бригадага табан китеп барды.

Фазыл ни эшләячәген инде уйлап куйган, бер карарга килгән иде. Башта өйгә кереп, тиз генә жылырак кием, беразга житәрлек азык-төлек ала һәм, дөньялар тынычланганчы, хәлләр ачыкланганчы, берәр жиргә китеп, күзгә-башка чалынмыйча яшәп тора.

Шулай да ашыгырга, вакытны юкка әрәм итмәскә кирәк.

Өенә кереп, әнисенә хәлне өстән-өстән генә булса да аңлаткач, Хөршит абыстай бөтенләй коелып төште: картайган көнендә бер ялгызы торып калыр микәнни?

Озын-озак кәнфитләнеп торыр чак түгел, ашык-пошык җыйналып, Фазыл тизрәк өеннән чыгып китү җаен карады.

Кая барырга? Кемгә сыенырга? Уйлый торгач, Әгерҗе авылында яшәүче Нажия апалары барлыгы исенә төште. Кабул итсәләр, хәзергә аларда яшәп торырга кирәк. Соныннан күз күрер.

Олы юлдан атлау куркыныч, әллә кемнәр очравы бар. Авылда хәбәр таралып өлгергәндер инде, анда сүз тиз йөри, бәладән башаяк. Су буендагы таллыкларга ышыкланып, Шомыртлыкка кадәр барды да, туктап, караңгы төшкәнне көтте Фазыл. Аннан соң гына басу аша туп-туры Әгерҗегә юл тотты. Бәхетенә күктә яна туган ай елмая, йолдызлар күз кыса. Ә бүреләр очрау ихтималы хакында ул никтер уйлап та карамады.

Әгерҗегә килеп житеп, Нажия апаларының ишеген шакыганда, сәгать төнге уннар тирәсе иде. Бу вакытта көтмәгәндә-уйламаганда килгән кунак нык гаҗәпләндерсә дә, рәхмәт төшкән хуҗалар исәнлек-саулыктан башка берни дә сорашмады. Фазыл да бик ачыласы итмәде. Чәй эчүгә, тизрәк үзенә салып биргән түшәккә яту ягын карады. Бик нык арыган иде ул. Арымассың сиңа, көне буена суыкта качып ят та янадан егерме чакрымлап араны шул суыкта җәяү килеп кара!

Иртәгәсен ул уянганда, өйдә беркем дә юк, апасы белән җизнәсе эшкә киткән иде. Алар төш алдыннан гына кайтты. Икесе дә ындыр табагында ашлык чистартуда эшлиләр икән.

Төшкелекне ашаган чакта, Фазыл үз хәлен бәян итте.

—Рөхсәт итсәгез, бераз сездә торыр идем,—дип тәгәлләде ул сүзен.

Нажия апаларының балалары булмады. Шуңа күрәдерме, туган-тумачаларының балаларын ул үзенекедәй якын итте. Сөргенгә киткәнче дә, кайткач та, абыйлары белән атналар буена Әгерҗедә кунакта яткан чаклары бар иде Фазылның. Никадәр рәхәт көннәр булган икән.

Илленең өске ягына чыккан туганнары һич авырыксынмады:

—Әлхәмделиллаһ, арышныкы булса да, ипиебез бар, сыерыбыз бозаулады. Җаның теләгән кадәр яшә,—диде җизнәсе. Җизнә кеше шулай дип торганда, апасы каршы төшә димени!

Гомере буе киләп сарып йөрүнең ни икәнен белмәгән Фазыл эшсез торуның нинди зур газап икәнен аңламаган икән. Нажия апаларында ятканда, башыннан кичергәч, аңлады. Өй эчендә ничек вакыт уздырырга белми аптырады ул: эшләргә эш, укырга хәтта китап та юк. Бу яктан караганда, тфү-тфү, төрмәдә дә вакыт тизрәк уза, анда эшсез тотмыйлар, берәр шөгыль табалар. Ичмасам, ишек алдына да чыгарга ярамый, берәрсе күреп калса? Әгәр милициягә хәбәр итсә? Әле берәр керүче күренсә дә, коты оча Фазылның, тизрәк базга төшеп качу ягын карый.

Хуҗалар киң күңелле, ләкин житкән егет башың белән гомереңбуена алар җилкәсендә ничек оялмыйча ятарга мөмкин. Моны Фазыл яхшы аңлый. Тик, авылдагы хәлләрне ачыкламый торып, нидер эшләргә дә чарасыз ул. Апасы белән җизнәсе бу эштә ярдәм итә алмаячак, анысы көн кебек ачык. Димәк, үзенә берәр чара уйлап табарга кала. Күпме генә баш ватмасын, Әскәйгә барып кайтудан да дөресрәк юл юк. Әйе-әйе, караңгы төшүгә кузгалыр да, ни булганын белешеп, кире китәр. Берәүнең дә күзенә чалынырга ярамый.

Ниһаять, килүенә ун көнләп узгач, ул тәвәккәлләде. Караңгы төшүгә, юлга кузгалды. Баштарак берәр атка атланып барып кайту уе булса да, курыкты: алай-болай эләктерә калсалар, срок өстенә срок чәпәячәкләрен көт тә тор.

Авылыннан качкан төндә ичмасам ай бар иде. Бүген күзгә төртсән берни күренерлек түгел, карангы. Иң мөһиме, юнәлешне һәм өметне югалтмаска кирәк, дип уйлады Фазыл.

Ашыгып, ашкынып атлады ул. Вакыт-вакыт, адашмадыммы икән дип, туктап, җилне чамалады. Дөреслегенә ышангач, тагын китте. Әле ярый талгын исүче җил бар, карангы төндә юнәлешне ничек билгеләр идең.

Туйкәгә ул чагыштырмача тиз барып җитте. Тагын уникe чакырымны узса, Әскәйдә булачак. Адашмасын гына...

Ул атлый-атлый да, туктап, алга карап ала: авыл утлары күренмиме? Аллага шөкер, кайтып җитә, ахры. Мүк куагы үрен төшкәндә, күзенә яшь килде. Төрмәдә утырган чакта да бу кадәр сагынмаган иде бугай. Авылда нинди хәбәр көтәдер, билгесез.

Кайтып житкәч, шунда ук өенә керергә ашыкмады Фазыл. Авызы пешкәч, өреп кабарга өйрәнгән иде ул. Бәлки аны кулга алыр өчен сагалап торалардыр. Йөрәгенең дөп-дөп типкәне еракларга ишетелеп, Фазыл кайтканны бар дөньяга фаш итәдер төсле.

Ул, эскерт янына җиткән ау эте сыман, башта каралты-кураны урап чыкты. Шикләнердәй нәрсә тапмагач, тышкы ишекне тартып карады: бикле. Дөбердәтергә теләп күтәрелгән кулы, ишеккә тиде дигәндә, кире төште: берәрсе ишетеп калса! Аяк астындагы карны шыгырдатмаска тырышып, Фазыл сак кына адымнар белән сәке каршындагы тәрәзә янына китте. Әнисе, гадәттә, шул сәкедә йоклый иде.

—Тук, тук, тук!

Өч тапкыр чирткәч, Фазыл дулкынлануыннан тагын да ныграк дөпелдәргә тотынган йөрәген тыярга тырышып, читкәрәк китте. Сулышы кысылды. Ишеттеме икән әнисе, әллә юкмы?

Фазылга вакыт туктап калгандай тоелды, чөнки ул шакыганнан соң әнисенең тәрәзәгә капланып:

—Кем бар анда?—диеп соравы арасындагы ун-унбиш секунд ара бик озак узды. Каушавыннан Хөршит абыстайның качкында йөргән төпчек улы шунда ук җавап та кайтара алмады.

—Кем бар анда?—дип кабатлады беренче соравына җавап ала алмаган әни карчык.

—Мин, инәй, мин...

Фазыл тәрәзә каршысына басты.

Караңгы иде, ләкин абыстай үз баласын күреп түгел, күңел күзе белән таныды.

Ишек ачып кергәч, Фазыл, суык киемнәрен сала да тормыйча, әле генә җылы юрган астыннан чыккан әнисен кочагына алды.

—Инәй, исәнме!

—Исәнме, балам!

Тавышының калтырап чыгуыннан Фазыл әнисенең елавын сизде.

—Елама, инәй, елама!—дип, үзендә әнисен юатырдай көч тапты качкын егет. Югыйсә анық үз күңеле дә тулган иде.

—И-и, мин карт исәрне кара инде, ут та кабызмый торам икән,—диде Хөршит абыстай, бераз аңына килә башлагач.

—Кирәкми, инәй!—Фазыл аның бу теләгенә каршы төште.—Дус бар, дошман бар дигәндәй, йә берәрсе күреп калыр... Карангыда сөйләшик. Мин озак тормыйм. Монда ни хәлләр?

—Ни дип әйтим икән?—Кинәт исенә төшеп, Хөршит абыстай ашыга-кабалана кереште.—Тукта, самавырымны гына яңартыйм әле. Пешкән ашым да бар, казан астына ягып кына җылытып алыйм.

Фазыл ничек итеп әнисе янына барып басканын сизми дә калды:

—Зинһар, дип әйтәм, инәй, яга күрмә! Сон, инәй, анық тәтенен күргән кеше, бу Хөршит карчык төн уртасында юкка-барга мичен якмас, берәрсе

килгәндер, дип уйлаячак бит.

—И-и, улым, башка төшкән хәсрәтләрдәнме, картая-картаямы, дивана булып барам инде. Ашыйсын килгәндер бит?

—Килүен килде дә, салкын көе генә капкаларымын. Самавыр кайнагач, чәй эчәрбез. Сөйлә! Мөниржанны ни эшләттеләр?—Анын тизрәк шул хакта беләсе килә иде.

—И балам, әле дә киттен. Мөниржанны шул көнне үк милитсәләр кулга алды. Хәзер Азнакайдан Бөгелмәгә күчергәннәр диме. Хатыны өч көн элек кереп чыккан иде. Суд буласы ди. Сине сорап та әллә ничә килделәр. Беренче килүләрендә саклап кундылар да әле. Кая китте, дип сорап интектерделәр.

—Ә син нәрсә дидең?

—Белмим, дидем. Белмимнен беләге авыртмый бит. Аннан сон чынлап та белми идем, шулай булгач ни әйтим? Йокыларымны йокламыйча, синең өчен дога кылдым. Аллага шөкер, догаларым кабул булды. Исән-имин көе сине күрер көнем дә бар икән. Кайларда нужа чигеп яттын сон, улым?

Әйтергәме, әйтмәскәме? Ә нигә әниеннән яшерергә? Әни кеше барыбер сатмаячак үз баласын. Аннан соң... аннан соң... Әгерҗедә дә гомер буе ята алмас. Бер булмаса бер ачылыр.

—Нажия апаларда булдым мин. Сиңа сәлам әйтергә куштылар. Ул да, жизни дә—икесе дә исән-саулар. Кара әле, инәй, Мөниржанны чыгармаслар микән?

—Ай-һай, улым, суд буласы, эшен суд карасы ди.

—Кем әйтте?

—Шул инде, Мөниржан хатыны—Гайния килен. Суд икенчесен дә тоткач булачак, дип әйтеп әйтәләр икән.

Бу сүз Фазылнын йөрәгенә кадалды. Ул, үзен тыя алмыйча, кайнарланып әйтте:

—Тотмый гына торсыннар әле! Төрмә шулпасын бер тапкыр эчтем, житәр!

—Инде ни эшлибез, балам?

Хәзер генә ни эшлисен төгәл әйтә алмаса да, Фазылнын башында бер план яралып килә иде: китәргә, мәхкәмәчеләр тынычланганчы, күздән югалып торырга! Ләкин кая китәргә? Күпмегә? Монысына жавабы әзер түгел иде әле. Калса, барыбер тотачаклар. Китәргә икән китәргә! Илдә чыпчык үлми диләр. Гомер буена эзләмәсләр, тынычлангачрак кайтыр әле.

Салкын булса да, әнием пешергән аш—әнием пешергән шул. Бәлки ул иң оста пешерүче дә түгелдер, ләкин дөньяда иң тәмле ризык—әнием пешергәне, сабый чактан бирле тәненә куәт жыйдырганы. Сугышта да, госпитальдә дәваланып ятканда да, ниләр генә ашарга туры килмәде аңа. Төрмәдәгесен әйткән дә юк. Хәтта якын туганы Нажия апасы пешергәне дә... әнисенең ашы кебек тәмле була алмый. Китсә, бу ашлардан тагын мәхрүм булачак бит ул. Күпмегә?

Фазылнын күзенә яшь бәреп чыкты. Ярый әле карангыда утыралар, әнисе күрүеннән куркасы юк.

—Инәй, юлга бирәр төенчек хәзерләсәң иде. Мөмкин булса, бер-ике ипи тык.

Хәзинәдә барын Хөршит абыстай бер киндер капчыкка тутырды.

Фазыл туган йорт жылысын сеңдергән олтанлы итеген мич башыннан алып киде, ашыкмыйча гына өстендәге бишмәтенең төймәләрен элэктерде. Күңеле сизә: кабат тиз генә кайта алмас ул туган нигезенә. Хәтта хат язарга да ярамас. Шуңа күрә китәр минутын мөмкин кадәр сузарга тырышты. Үзеннән бигрәк ул әнисен кызганды: ни эшләр инде, бигрәк бер ялгызы кала, бичара.

Ниһаять, тиздән таң атасын белдереп, аларның карт әтәче аваз салды.

Житте, мәмәйләнеп утырма, яктыра башлаганчы, авылыңнан ераккарак сыпыртуың яхшы!

—Инәй, миңа китәргә вакыт.

—Кая?

—Хәзергә белмим, инәй. Тик син, зинһар, минем өчен борчылма.

—Барап житү белән хат яз.

—И инәй, ул хат буенча мине шунда ук эзләп табып, кулга алачаклар бит... Берәр жае чыкканчы түз инде.

—Ярар, улым, үзең беләсеңдер. Алла хакы өчен үзеңне сакла. Хозыр Ильяс юлдашың булсын. Күрешергә язсын.

Ана белән улы сәкегә янәшә утырды. Хөршит абыстай ашыкмыйча гына юл догасы укыды. Аннан соң ана белән бала тыйнак кына кочаклашып аерылыштылар. Хөршит абыстайның яңаклары дымлы иде.

Фазыл ишекне ачып чыгам дигәндә, әнисе:

—Улым, ашыкмый тор, сабыр ит,—дип туктатты.—Менә монда үлемтеккә дип җыйган бераз акчам бар иде, ал, юлда кирәк булыр.

—Кирәкмәс, инәй, үзенә калсын. Мин яшь кеше, берәр җае чыгар әле.

—Улым, карышма, ал!—дип үзенекен итте Хөршит абыстай һәм ак чүпрәккә төргән акчасын, улының ай-ваена куймыйча, аның кесәсенә тыкты.—Юлда акча артмас, күрерсең...

—Рәхмәт, инәй...

Фазыл арт капкадан чыккач, туган йортына борылып карамаска тырышты. Йә түзәлмәс, кире борылып кайтыр.

Авылдан сөреп җибәргәннәре исенә төште. Ул чакта сабыйлыгы белән туган авылдан, үскән нигездән аерылуның авырлыгын аңлап бетермәгән булгандыр инде, болай ук җаны сыкрамаган иде.

Кая китеп эз яшерәсен белмәгән Фазыл кайткан юлыннан кире китте. Яктырган вакытта ул Туйкәгә җиткән иде инде. Шунда гына туктап хәл алды. Хәзер менә шушында, ике юл чатында, билгеле бер карарга килергә кирәк: кабат Әгерҗегә кайтыргамы, әллә Бөгелмәгә юл тотаргамы?

Уйлый торгач, ул Бөгелмәгә китәргә булды. Әгерҗедә күп дигәндә атна-ун көн ятарсың, аннан соң барыбер эз ялтыратырга туры киләчәк.

Моннан Бөгелмәгә ничә чакрым икән? Кимендә тагын бер утызлап калгандыр. Төне буена аяк өстендә булган Фазыл шактый арыган иде. Шулай да юлын дәвам итәргә булды. Тагын бер ун чакрымлап барды әле ул, шуннан соң гына юлдан читтәрәк бер салам эскертенә килеп егылды. Бераз хәл алгач, саламны йолкып, үзе сыярлык куыш ясады. Куышка кереп урнашкач, тамагы ачканын сизде һәм сындырып бер кисәк ипи капты. Ләкин үзе тунган,үзе коры ипи бик авырлык белән генә чәйнәлде.

Салам эскерте әниең җәеп биргән җылы түшәк түгел. Фазыл күпме йоклаганын белми, туңып уянды. Уянгач бер киерелде дә, монда озак ятудан файда юк, хәрәкәттә бәрәкәт дип, Бөгелмәгә карап үз җаена әкрен генә атлый бирде. Аңа инде ашыгырга кирәкми иде.

Ашыксаң-ашыкмасаң да, сак булырга кирәк. Дус бар, дошман бар, ул юлда күренгән атлыларны да урап узарга тырышты. Фазылны танып, йә милициягә илтеп тапшырырлар.

Икенче көнне төш вакытларына ул Бөгелмә стансасына килеп җитте.

Бирегә поездга утырган кеше ике генә якка китә ала: Мәскәү яки Уфа ягына. Лаеш шулпасын фронтта да, төрмәдә дә чөмереп караган Фазыл Уфа ягын сайлады. Мәскәүдә аны кем көтеп тора? Беркеме дә юк. Мәскәү дигән башкалада әтрәк-әләм болай да күп, тәртип саклаучылары да баштин ашкандыр. Шулай булгач, анда борын тыгуның һич кенә дә кирәге юк. Житмәсә милициядән качып йөргән башың белән. Аягыңны уйламыйчарак атладыңмы, газиз башкайларыңның таш капчыкка барып кергәнен сизми дә калырсың.

Фазылга ничек тә документсыз гына эшкә урнашып, тамак туйдыра ала торган жир кирәк. Ә моның өчен Урта Азиядән, аның таулар арасына сенеп, югалып утырган, халкы Совет власте һәм аның хөкем органнары ни икәнен зур дөньяга чыгучылардан ишетеп кенә белгән кышлаклардан да яхшырак жирне тагын кайдан эзләп табасың? Бар, эзләп кара дингез төбенә төшеп югалган энәне! Көндез чыра яндырып эзләсәң дә таба алмассың. Татар, башкортның яшь чибәркәйләре, туган ягында ир-ат чырае күрүдән өметен өзгән сазаган карт кызлары, алданып, уйнаштан бала көтүче бәхетсезләре, дәртлерәк ирләр елмаеп караганга да балага уза торган тол хатыннары, авылда яшәрлек бүтән рәтләре калмаган ничарадан бичара ирләре, кылган барлы-юклы гөнаһлары өчен жәза алудан курыккан башкисәрләре тикмәгә генә Ташкент якларына агылмый торгандыр. Үзбәк, кыргыз, тажик, төрекмән якларына китеп, Гражданнар сугышы вакытыннан бирле күпме татар бәхетен тапкан, эзен яшергән Урта Азиядә. Бер Фазылга күп кирәкме, анлык кына урын да, ризык та табылыр, боерган булса...

Бөгелмә стансасында поезд көтүчеләрнең сүзләренә катышмыйча гына тынлап торган Фазыл тагын бер кабат үз уенын дөреслегенә инанды. Урта Азия—аның өчен бердәнбер дөрес юл. Ташкент—Урта Азиянең капкасы. Ә Урта Азия—кин, Урта Азия—чиксез, Урта Азия—бай.

Мең бәла белән ул якларга барып чыккан Фазыл туган авылына яңадан кайчан кайтасын белми иде әле.

Кулга алынып, бер ай да тулмады, Мөниржан Исламовка суд булды. Аның кулалмашы Фазыл юк дип тормадылар. Бәлки эш аны төрмәгә утыртуга ук барып житмәс тә иде, әмма Ватан өчен сугышта кулын өздереп кайткан ат караучы Мөниржан Исламовны яклап ни Хәсьянов, ни Минһажев судта бер сүз дә әйтмәде. Аның урынына прокурор ярдәмчесе нинди генә гаепләр такмады да, нинди генә статьялар сорамады. Гаепләүченең сүзләрен тынлап торган Мөниржанның тәне эсселе-суыклы булып китте, чөнки котылып калмаячагын аңлады. Колхоз милкенә кул сузган өчен Мөниржанга биш елдан сигез елга кадәр иркеннән мәхрүм итү каралган икән. Ә бу жинаятьне алар, алдан сөйләшеп, төркем белән эшләгәннәр, димәк, жәза срогы тагын да арта: фәләненче матдәнең фәләненче пункты нигезендә суд жинаятьчене сигез елдан унике елга кадәр хөкем итә ала.

Менә сиңа мә! Менә шулай була ул кычытмаган жирне кашысаң. Ятсыннар иде шунда ул атлар ачлы-туклы, ат караучылар бар булганына шөкрана кылсыннар иде. Мөниржан да ул вакытта хөкем ителүчеләр эскәмиясендә утырмас иде. Их, никләр генә, Фазыл сүзен тынлап, ул да берәр якка чыгып ычкынмады икән! Хәер, Гайнияне бу хәлендә калдырып китү мөмкин идеме соң? Әнә бит, мескенкәй, ничек агарынып калган. Агарынырсың да, туасы баланны тыныч кына өендә саклап ятасы урында милиция, суд юлында йөри башласаң.

Прокурор ярдәмчесе күпне сораса да, судья, Мөниржан Исламовның сугыш инвалиды, яхшы эшләве һәм хатынының йөкле икәнен истә тотып, өч ел бирү белән чикләнде.

Суд карарын ишетүгә, Гайния, аңын югалтып, борынга житкән корсагы белән идәнгә килеп төште һәм судка өстәмә мәшәкать тудырды. Моны күреп торган Мөниржанның жан жепселе өзелде. Ул үзенә бирелгән жәза хакында онытты. Аның ничек тә хатынына ярдәм итәсе, һич югында янында булып, ягымлы сүзләр әйтәсе килде. Ләкин аның янында торган милиционерлар элеккеге танкистка селкенергә дә ирек бирмәде. Көчсезлеген, чарасызлыгын аңлаган Мөниржан:

—Кабәхәтләр!—дип кычкырганын сизми дә калды.

Ашыгыч рәвештә хастаханәгә озатылган Гайниянең үле бала табуы хакында Мөниржан Мордовия төрмәләренең берсендә утырган чагында

ике айдан соң алган хаттан гына белде.

Колхоз атлары өчен печән урлап тотылган Әскәйнең атаклы гармунчысы Мөниржан Исламовның төрмә елъязмасы әнә шулай башланды. Бу елъязманың зур эпопеягә әверeләчәге хакында ул чакта берәүгә дә нәмәгълүм иде.

Китүенә елга якын вакыт узгач кына, Фазылдан беренче хәбәр килде.

Хөршит абыстай ишек алдында тавыкларына җим биреп йөри иде. Биш баш тавыгы бар үзенең. Йомыркасыннан бигрәк иптәш өчен тота ул аларны. Әйе-әйе, иптәшкә! Әй ул тавыкларның кукәй салганнан соң куанып кытаклаулары! Әй мактанулары! Әле ярый бохар мәчесе бар да, шушы тавыклары бар, югыйсә ялгызың акылдан шашарга да мөмкин. Күршекуләннең дә синең белән аралашырга вакыты юк, һәркемнең үз хәле хәл. Барысы да эштә. Сәдака-хәер китерүчесе дә, дога кылуга:

—Абыстай, җиренә җиткереп үзең укырсың инде, нәсел-нәсәбебезне беләсең,—дип тизрәк китү ягын карый.

Аларга үпкәләми Хөршит. Һәркемнең үз язмышы, үз тормышы. Өстән дә, ул кукләрне күз алдында тота, карап-күзәтеп кенә торалар. Ул инде хәтта Фазылдан хәбәр юклыгына да ияләшеп бетә язган иде. Җае чыкмыйдыр, шуңа хәбәр бирми торгандыр. Башкайлары исән-сау була күрсен газиз балакаеның, башкайлары сау булса, дөньяда анасы барын онытмас. Онытa торган бала түгел ул.

—Ти-ти-ти! Килегез, кил, рәхмәт төшкерләре!

Тавыклары белән мавыгып, ул капкадан керүчене күрми калган. Артында гына берәүнең:

—Әссәламәгаләйкүм!—дип сәлам бирүен ишеткәч, сискәнеп китте. Кем булыр бу? Тавышы таныш түгел сыман. Борылып карады, ләкин керүчене барыбер танымады. Әллә соң, Ходаем, тагын берәрсе милитсәдән Фазылны эзләп килгәнме? Алай дисәң, көтәрсең ул дуңгызлардан «әссәламәгаләйкүм»не, кайберсе юньләп исәнләшә дә белми. Туганда ук юньсез булганнармы, әллә яши-яши иблискә әверелгәннәрме? Алар килә-килешкә Хөршит абыстайдан Фазылны таптыра, суд, төрмә белән куркыта башлый.

—Вәгаләйкемәссәлам!

—Сезне Хөршит абыстайдыр дип беләбез. Шулаймы?

—Шулаен шулай да. Үзеңне кем дип тә әйтә алмыйм. Бер дә күргән кешегә охшамыйсың.

Әлеге адәм як-ягына каранып алды да, авызы тулы тимер тешләр арасыннан сүзләрне сөзеп чыгарып, пышылдап кына:

—Абыстай, монда сөйләшә торган сүз түгел, мөмкин булса, өйгә керик,—диде.

Үз-үзен тотышы белән дә сәер, кигән киеме, сөйләшүе дә ят бу кешенең. Бер дә милитсәдән булганга охшамый. Бәлки?.. Абыстайның күңел түрендә өмет чаткылары җемелдәп алды. Ана күңеле сизә шул.

Кергәч, аяк киемнәрен салып, Мирзанур түргә узды.

—Яле, абыстай, утырып бер дога кылыйк.

Торган саен ныграк гәҗәпләндерсә дә, Хөршит абыстай үзе сорамый, кунакның сөйләгәнен көтә. Тикмәгә генә йөрмәс бу кеше.

Дога кылынды, бит сыпырылды. Бары тик шуннан соң гына Мирзанур сәкегә куеп торган төенчеген чишеп, бер яулык һәм кәгазьгә төрелгән күрәгә, киптерелгән алыча, алма, тагын бераз йөзем сузды:

—Менә болары улың Фазыл күчтәнәчләре. Мин әманәтне тапшырдым.

—Фазыл?! Әй, балакаем, ул исәнме?—Хөршит абыстай, улының исеме ишетелүгә, моңа кадәр булган шик-шөбһә, саклык чаралары турында онытты.

—Тсс!—Мирзанур шауламаска кирәклеген кисәтте.—Фазыл, Аллага шөкер, исән-сау, сина күптин-күп, чуктин-чук сәламнәр юллады.

—Ул кайда? Ник кайтмый? Ник мона кадәр бер хәбәр дә бирмәде?—Карчык мөсафирны сораулар белән күмеп ташлады да туктап калды: улының нинди хәлдә икәнен белмимени ул? И тиле карчык та инде син, дип битәрләде ул үзен.

Кунак Хөршит абыстайның соравына игътибар итмәде.

—И абыстай, улыгызның ни өчен моннан киткәнлеге хакында оныттыңмы? Шуңа күрә хат та язмады, хәбәр җибәрергә дә җай чыкмады. Үземә килгәндә, безнең әткәй тумышы белән Туймазыдан. Гражданнар сугышыннан соң шунда төпләнеп калган. Без Фазыл белән очраклы гына танышкан идек, бу якларга кайтасымны белгәч, синең яныңа кереп чыгуымны сорады. Әтинең әнисе, ягъни минем әби була инде, исән, аның янына ике-өч елга бер кайтып торабыз. Күптән түгел генә кайткан идем сыман, инде китәр вакыт та якынлаша. Ачуланмагыз инде, кайту белән килеп булмады. Хәзер күңелем тыныч, әманәтне үтәдем. Үзенә сак булырга кирәк шул. Фазылны әйтәм.

—Әйе шул, улым. Атыңны кем, Мирзанур дидеңме әле? Шул бала өчен хәсрәтләнеп, дивана булып бетәм бугай инде. Сөйлә, зинһар, кайларда ул,ниләр эшли?

Ананың барысын да тизрәк беләсе килсә дә, Мирзанур ашыкмады.

—Аның өчен борчылма. Тамагы тук, өсте бөтен, урыны җылыда, корыда. Ул бит укыган кеше, җиде класс белеме бар. Андыйлар аяк астында аунап ятмый. Үзбәкләр аны хисапчы итеп урнаштырды. Бик әфтәрититле кеше Фазыл. Үзбәкләр аңа әкәҗан дип кенә торалар.

—Алайса үзбәк ягында икән минем улым...

—Абыстай, мин әйтергә яраган кадәресен әйттем, калганын сорамый тор. Инде, абыстай, шунысын беләсем килә: Фазылны һаман эзлиләрме?

—И улым, эзләмиләрме соң! Ун көнгә бер, ике атнага бер килеп төпченеп, куркытып кына торалар. Минем үземне өтермәнгә ябабыз, диләр. Чистый котымны алып бетерделәр.

Мирзанурның көләч йөзе күләгәләнеп калды. Самавырын кабызып йөргән Хөршит абыстайга аның:

—Димәк, димәк, егетне юкка харап итәргә телиләр. Димәк, димәк... бер-бер чарасын эзлисе булыр,—дип, үзалдына сөйләнгәне ишетелде.

Чәйдән соң Мирзанур озак тормады. Саубуллашкан чакта әйтте:

—Апа җаным, малаең өчен борчылма. Ул исән-сау. Аллаһы боерса, киләчәктә дә җил-яңгыр тимәс. Хәзер безгә, иң мөһиме, милициянең эзләвен туктатырга кирәк. Бу бик ансат эш түгел. Алай-болай Фазылның үлде дигән хәбәре килеп ирешсә, чыңга алма. Ул хәбәрне ничек тә милициягә житкерергә кирәк. Шунсыз алар Фазылны тынычлыкта калдырмас. Барыбыз бер сүздә булыйк. Шул чагында малаеңа куркыныч янамас.

Улыннан хәбәр китерүчегә мең-мең рәхмәт укып, кат-кат дога кылды Хөршит абыстай. Чыннан да күңеле тынычланып калды. Үлгән артыннан үлеп булмый: ире белән өлкән улы Котдус авыл зиратында янәшә ята, Әсгатенең Кытайдан хаты килеп тора. Кашаф кызы Мәүҗидәгә дә хат яза икән дигән сүзләр йөри. Анысы яшьләр эше. Мәгәр Мәүҗидә ипле кыз, чәчләре чәчкә ялганасы булса, миннән фатиха. Төпчегеннән хәбәр булмаганга, йөрәге бик сызлый иде, хәзер Фазыл өчен дә кайгысы басыла төште. Адәм баласы өчен иң авыры—якыннарың турында берни белмәү, билгесезлек икән. Инде килеп Мирзанур бу борчылуына да нокта куйды: Фазыл исән. Яшәгән җирендә әфтәрититле кеше ди бит. Анысы ни аңлатадыр, ләкин абыстайның күңеле сизә: начар сүз булырга тиеш түгел.

Мирзанур китеп, ике ай ярымнар узуга, хат алгач һәм конверт эченнән

табут эчендәге Фазыл сурәте чыккач, Хөршит абыстай, башта куркып китсә дә, үзен кулга тиз алды. Димәк, шулай кирәк булган. Мирзанур тикмәгә генә китәр алдыннан бу хакта кисәтмәгәндер.

Сурәт янында кыска гына хат та бар иде.

«Хөрмәтле Хөршит апа!

Ошбу мәктүбебез илә сезләргә улыгыз Фазылның көтелмәгән вафаты хакында хәбәр итәбез вә тирән кайгыгызны уртаклашабыз. Урыны оҗмахта булсын. Мәрхүм әйбәт кеше иде.

Бер төркем дуслары».

Озак карап торды Хөршит абыстай улының сурәтенә, аннан соң карточканы матчага кыстырып куйды, ә конвертын йомарлап мичкә ташлады.

Тагын берничә көннән килгән участок милиционеры Исхак белән карчык көтелмәгәнчә кыю сөйләште:

—Улымны эзләп вакытыңны юкка әрәм итмә. Ул инде күптән оҗмахта...

—Алдашма, убырлы карчык!—Исхак мондый хәбәр көтмәгән иде?!—Шайтан таягына кырау тимәс, докажи!

«Докажи» сүзенең ни аңлатканын белми Хөршит абыстай, шулай да ул сүзнең Фазылның дөньяда юклыгынраслаучы дәлилләр хакында барганын төшенде. Ләкин башын тилегә салды:

—Нәрсә дисең?

—Кайдан белдең, дип сорыйм мин синнән! Ышанмыйм!—дип, Исхак бораулый торган күзләре белән Хөршит абыстайга текәлде.—Беләм мин сезне, кулак калдыкларын!

Исхак кызса да, Хөршит абыстай тыныч калды. Ул матчага кыстырган сурәтләрне ашыкмыйча гына Исхакка сузды, хатны да кулына тоттырырга онытмады:

—Мә, кара! Максатыгызга ирештегез, инде тынычлансагыз да була! Баламның башын ашадыгыз, җәлладлар!

Кулына алганчы, Исхак бу хат һәм сурәтләрнең ни дәрәҗәдә кыйммәтле икәнен күз алдына да китерә алмаган иде. Өшкерә-төшкерә торган җен... тфү, мулла карчыгы ниләр әйтмәс тә, ниләр кыланмас.

Ләкин сурәткә күз салуга ук, күпне күргән участковый имәнеп китте. Анда совет хөкүмәтенең явыз дошманы, ил буенча эзләнә торган җинаятьче Фазыл Шаһиевның кәфенгә төрелгән гәүдәсе төшерелгән иде.

—Укы, укы, хатын да укы, күңелең тынычлансын!—Хөршит абыстай хәзер инде айлар буена җыйналып килгән үпкә-рәнҗешен тыеп торыр хәлдә түгел иде.—Колхоз атларын ач үлемнән коткарган өчен медаль бирәсе урында, башын ашадыңмы улымның?! Хәзер тынычланырсыз инде. Алланың каһәре төшүдән дә курыкмыйсыз.

Башка вакытта Алла сүзенә исе китми торган Исхакка кинәт әллә нәрсә булды. Моңа кадәр гади гражданнар алдында аклануның ни икәнен белмәгән, азау теш ярган участок милиционеры әле генә ишетелгән каһәр сүзләреннән шомланып калды:

—Син, абыстай, теленне тый. Сүзеңне чамалап сөйләмәсәң, власть кешесен әскәрбит иткән өчен үзеңне таш капчыкка тыгып куярлар, бер аягың белән кабердә дип тормаслар. Шуны онытма: мин дәүләт хезмәтендәге кеше, ни кушсалар, шуны эшлим. Печәнне синең малай урлады дип кәнкритне әйтмәсәләр, без эшне шул көенчә ябып куя идек. Падумаеш, бер-ике йөк печән, әлләниләр югала!

Моңа кадәр берсенең бер авызыннан милициягә әләкләүче турында сүз чыкканы юк иде. Кайсы сатлыгы барып әйтте икән?

—Алдашма!—диде Хөршит абыстай. Ул инде бераз тынычлана төшкән иде.—Кем әйтте? Кем әйтте, дип сорыйм мин синнән!

Бу мулла карчыгы әллә күз буа инде, бер генә кагыйдә буенча да хәбәр итүченең кем икәнен әйтергә хакы булмаганын белә торып, авызын ачканын Исхак сизми дә калды:

—Кем дип... Соң, шул инде...—дип мыгырданды ул авыз эченнән.

—Кем ул шул?

—Силсәвит Минһажев...

—Алдашасын!

—Икмәктер, валаһи газыйм! Алдашсам, ике күзем чәчрәп чыксын! Следователь Ильин да бар иде. Ышанмасаң, анардан сора. Аның алдында әйтте: беренче бригада ат караучылары урлады, диде. Әле минем бер литр аракыны да эчте. Үзем генә булсам, рәже мин пыртакул төзер идем...

Соңыннан Исхак бетәшкән бер карчык алдында манка малай кебек бөтенләй ачылуына аптырап йөрде һәм моңа үзенчә аклану тапты:

—Убырлы карчыктыр ул, валлаһи, сихерләде мине...—Ләкин моны кычкырып әйтергә курыкты.

Ничек кенә булмасын, Фазыл, Мирзанур, Хөршит абыстай катнашындагы "спектакль" уңышлы чыкты: җинаять кодексы буенча яраган булгандырмы, юкмы, әмма шул көннән Фазыл Шаһиевны эзләүне туктаттылар.

Мөниржан башта Мордовия төрмәләренең берсендә утырды. Җинаять дөньясының югарырак баскычларында торучылар кемнең кем икәнлеге хакында надзирательләрдән дә болайрак хәбәрдар иде: Мөниржанны алар колач җәеп каршы алмасалар да, авыл мокытын рәнжетмәделәр.

Мөниржан килгән чорларда төрмәдә бет мыжлап тора иде. Бет белән көрәш-көрәшмә, ул каһәр суккан җан иясе көнләп түгел, сәгатьләп үрчи.

Мөниржан бет күрмәгәнме! Фронтта да алай бик тансык нәрсә түгел иде ул хәшәрәт. Ләкин өстенә ажгырып дошман килгәндә яки: «Ватан өчен! Сталин өчен!»—дип һөҗүмгә ташланган чакта, бет турында уйлап, кычыткан җиренне кашып тора алмыйсың. Бет барлыгы бөтенләй онытыла, гүя ул юк, булмаган да. Онытыла, тик, аз гына иркенрәк вакыт булдымы, кырыеңда кеше бармы, юкмы, шатыр-ботыр кашынырга тотынасың. Моны берәү дә әдәпсезлеккә санамый, чөнки аларның үзләрендә дә шул ук хәл. Бет җенесенә дә, погоннарындагы йолдызга да карап тормый.

Чып-чын төрмәгә барып эләккәнче, Мөниржанның тәне әле бетләргә өлгермәгән иде. Сигез кешелек камерага урнаштыргач кына, мондагы мәхбүсләрнең, дөньяга исләре китмичә генә, гел кашынып торуларын күреп, барысының да бетле икәнен аңлап алды. Моның өчен әлләни зур акыл яки тәҗрибә кирәк түгел.

Бетлеләр арасында, әлбәттә, бер генә бетсезнең дә ятасы килмәс. Ләкин син төрмәдә, атаң йортында яки туганыңда кунакта түгел, ошамаса, тавыш куптара, урын сайлый яисә үпкәләп кайтып та китә алмыйсың. Бүтән камерага да күчермиләр. Күчерсәләр дә аның бетсезен кайдан табасың. Яратсаң да шулар, яратмасаң да шулар. Өч-дүрт көннән бу җәнлекләр Мөниржанны да «яратып, үз итеп», ягъни «оккупацияләп» өлгерде. Бәлки алар бик күптән «сбежий» кеше, яңа кешене тансыклаган булганнардыр.

Тоткыннар иң авыр җәзаны ялгызлык, диләр. Камерада берничә кеше утыра икән, монда инде күңелсезләнергә урын калмый. Тоткыннарның шариклары әйбәт эшли, әле берсе, әле икенчесе ни дә булса уйлап таба. Мәзәк сөйләшкәннәрне инде әйткән дә юк.

Әнә бит Мудрый нәрсә тәкъдим итә. Әйтсәң, кеше ышанмас. Бет ярышы уздырмакчы. Башта әйткәч, аны шаярта гына дип уйлаганнар иде, чынлыгына ышанырга озак вакыт кирәк булмады.

Тора-бара бу ярыш бик кызык булып, барысына да ошап китте.

Ярыш асылы түбәндәгедән гыйбарәт: өстәл дип аталган нәрсәгә бер

түгәрәк сызыла. Түгәрәк үзәгендә тагын бер кечерәк түгәрәк бар. Бетләре арасыннан һәркем берсен сайлап ала да кече сызык эченә җибәрә. Шуннан күзәтә башлыйлар: кемнең бете зур сызыкны беренче булып кисеп чыга, шул—җиңүче.

Әйе, беренче карауга бетләр барысы да бер төсле хәшәрәтләр кебек. Ләкин алар да, адәм баласы төсле, төрледән төрле икән. Холык-фигыльләренә кадәр аерыла. Кайвакыт синең ярышка дип махсус «симерткән» бетең, сызыкка ук барып җитә. Менә хәзер чыга, менә хәзер чыга дип, ике күзеңне ертырдай булып, комарланып карап торасың. Ә ул, хыянәтче кебек, булды дигәндә генә, йөз сиксән градуска "койрыгын бора" да кирегә китеп бара!

Ни сәбәпледер, күбрәк Мудрыйның бетләре җиңә. Әйтерсең лә алар Мудрыйның төрмә авторитетларының берсе икәнен белә.

Җиңүчеләргә һәрвакыт кадер-хөрмәт. Сытыласы, изеләсе урында Мудрый җиңүче бетләренең берсен дә әрәм итми: кадерләп-хөрмәтләп үбә дә, сул як култыгы астында урман булып үскән ешлыкка иркенгә җибәрә.

Тора-бара бу ярышлар да туйдырды. Инде кем нәрсә уйлап табар дигәндә, беркөнне Мөнирҗанга әйберләрен җыеп чыгарга әмер килде. Башка төрмәгә күчерәләр икән.

Юлга кузгалганчы, өеннән ике хат алып өлгерде Мөнирҗан. Гайния яза хатларны. Әле ярый ул бар, рәхмәт төшкере. Их, кабәхәтләр, нишләттеләр аның тормышын! Дөньялары бик үк җитеш булмаса да, матур гына яшәп яталар иде. Судта Гайния аңын югалтып егылмаса, бала үстерәселәр иде. Ир бала булган, нәсел дәвамчысы булган бит!

Бу хакта язулары җиңел булмагандыр Гайниягә. Мескенкәй, ул ниләр кичергәндер, күз алдына да китерүе кыен. «Баладан соң, өзлегеп, мин айдан артык өйдә яттым. Шул арада хисапчы итеп минем урынга бүтән кешене алганнар. Кем икәнен язып тормыйм. Хәер, кем булса да барыбер түгелмени. Хәзер йөри башладым инде. Улыбызны саклап кала алмаганга, син миңа, зинһар, ачуланма. Ни эшлим соң, җаным. Язмыш тактасында шулай язылган булгандыр.

Әтәй, инәй бер көе кыштырдап йөриләр. Ярдәмнәреннән ташламыйлар. Алардан башка ни хәлләр итәр идем. Үзеңне сакла, Мөнирҗан. Өч ел үтәр дә китәр, Аллаһы боерса. Син яңа җиргә күчерәчәкләр, дип язгансың. Барып урнашу белән үк яңа адресыңны хәбәр ит. Бәлки, яныңа барып кайта алырмын. Сине бик сагындым. Бигрәк тә төннәрен җанымның җиденче тамырына кадәр сагынудан сызлыйм. Посылка салырга уйлаган идем дә, күчерерләр дигәч, тукталып калдым...»

Гайниядән килгән хатларны Мөнирҗан түш кесәсендә саклый. Кайвакыт көненә әллә ничә тапкыр алып укый ул аларны. Чөнки ул хат кына түгел, Мөнирҗанны өе, Гайниясе белән бәйләп торучы җеп тә. Хатны кайчан гына укыса да, күңелендә Фазылдан отып алган җыр тирбәлә.

Тауга менәр булсаң, дустым,
Дагалат атларыңны.
Күкрәгемә куеп йоклыйм
Җибәргән хатларыңны.

Җырның кушымтасы «Мәдинә гөлкәем» дип башлана. Ләкин Мөнирҗанның аны Мәдинә диярга берничек тә теле әйләнми, «Гайния гөлкәем» дип җырлый. Шулай инде, сагынсаң, Галиябану Гайниябануга, Мәдинә Гайниягә әверелә.

Ничә көн барганнардыр, Мөнирҗан санамады. Санаудан ни файда? Санасаң, санамасаң да, өч ел буена төрмә шулпасы эчәсең бар. Яңа төрмәгә бер-ике көнгә алдан килдең ни дә соңрак килдең ни, аермасы юк. Срок бара.

Ул инде язмышына күнеккән иде. Берзаманны, поездлары туктагач, башын күтәреп караса, Курган шәһәренә килеп житкәннәр икән. Монда гына калдырырлармы, әллә тагын да ераккарак алып китәрләрме? Туктаган һәр станция саен тоткыннар шул хакта сүз куертмый калмый.

Вокзал мәйданында халык күп. Их, чыгасы, йөрисе иде шулар арасында. Сулыйсы иде ирektәге һаваны! Күзләрне рәхәтләндереп, күк зәңгәрлегенә карап торасы иде. Юк шул, аларның хакы юк. Алар иптәш түгел, гражданин гына. Югыйсә бер вагонда баручылар белән аралаша торгач, аңлаган иде: мондагыларның берсе дә кеше үтереп, кеше талап, хатын-кызны көчләгән өчен алмаган срокны. Берничә кешене исәпләмәгәндә, күбесе аның кебек үк юкка-барга утыртылган: кайсы бер чиләк ашлык урлап тотылган, кайсы начальнигын өч хәрефкә жибәргән. Арада хатыннары утырткан ирләр дә бар. Шулай инде, күрәсең булса, күркә талап үтерер диләр бит.

Курганнан кузгалып китмичә, состав озак торды. Ни өчен икән? Башкаларында алай ук озак торган сыман тоелмаган иде. Ниһаять, янәшәдәге юлга тагын бер пассажир поезды килеп туктады. Кайсыдыр ки үткен күзе ул составның ниндилеген шунда ук чамалап алды. Вагон буйлап:

—Зеклар!—дигән хәбәр таралды. Ристаннар тәрәзәгә ябырылды. Теләртеләмәс кенә булса да, Мөниржан да урыныннан кузгалды. Белмәссең, бәлки, танышлары да очрап куяр.

Гади пассажирлар перронга төште. Зеклар вагонын, әлбәттә, ачучы юк. Андагы тоткыннар да тәрәзәгә ябырылган.

—Инәләрен фәлән!.. Болар бит хатын-кыз!

Шушы сүз вагонны умартага әверелдерергә житә калды.

—Пошел ты! Ниткән хатын-кыз булсын ди. Әнә ич, башлары таптакыр!

—Булса соң. Баштамыни хикмәт! Син аларның имиенә кара! Колакларына кара. Уф, егетләр, беттем, төпчек улым ыштанымны ерта. Их, мать честная!..

Янәшәдәге вагонда мәхбүс хатын-кызлар булуы ирләр вагонын исертте, кем ничек тели, шулай сөйләнергә кереште. Озата баручы солдатларның тәрәзә янынннан куарга тырышулары да ярдәм итмәде.

Менә каршыдагы ул вагонның ишеге ачылып, аннан башта дүрт хәрби төште. Алар, автоматларын әзер тотып, ишекнең як-ягына басты. Инде ристаннарны чыгаралар дисәң, түгел икән. Бозау кадәр ике овчарка житәкләп, янә ике солдат чыкты. Овчаркаларның күзен кан баскан, тешләрен шыгырдатып, алар усал ырылдый. Ычкына калсалар, кем туры килсә, шуларның бугазын ә дигәнче чәйнәп ыргытачаклар. Әнә ич, хужалары үзләрен чак тыеп тора.

Конвоирлар да тынычландыра алмаган иде, кулларына богау кигертелгән хатын-кызларны күргәч, Мордовиядән килүче ир тоткыннар бердәм тынып калды.

Ристан хатыннарны бер-бер артлы күрше вагонга менгерә башладылар. Күбесенә утыз-кырык яшьләр булыр. Кырдырып алынган чәч һәм төрмә киеменнән аларның төгәл яшен кем әйтә алсын. Шулай да бер хатынның кыяфәте алтмыш биш-житмешләр тирәсендә иде. Тоткыннарга кабат жан инде:

—Карагыз әле, карагыз, бер әби дә бар!

—Болар безнең өчендер инде. Барасы юл озын, күңел ачсыннар дигәннәрдер.

—Тот капчыгыңны, ачтырырлар...

—Их, егетләр, хатын-кыз тансыкладым. Бер кичкә әнә теге убырлы карчыкка да риза булыр идем!

Барысын да күчерәләр дип торганда, башта этләр житәкләгән солдатлар,

алар артыннан солдатларның калган дүртесе вагоннарына кире менде һәм алар артыннан шап итеп ишек ябылды. Төшми калган хатын-кызлар тәрәзәгә ябырылган көе тора бирде. Шунда урта тәрәзәләрнең берсеннән күренде: җыйналган хатын-кызлар як-якка аерылды һәм иренмәгән һәркем күрә алырдай итеп, тәрәзә каршына егерме биш-утыз яшьләрдәге хатын килеп басты да итәген күтәрә башлады. Аның ыштаны юк иде. Гаурәтен бар булганча уйнатып, ирләрне үртәп шактый басып торды ул. Аңа җавап рәвешендә ирләрнең дә берсе ыштанын төшерә башлаган иде, өлкән конвоир тегенең арт санына күн итеге белән шундый итеп типте ки, башы белән ул бичара вагон стенасына бәрелде һәм чүнкелеп идәнгә барып төште. Бүтән мондый «батырлык» күрсәтергә теләүче табылмады.

Тоткыннарның тынычлыгы качты. Әле поезд кузгалып киткәч тә бик озак шул хакта гәп куерттылар:

—Ну кабахәт тә инде бу хатын-кыз! Белә бит канны ничек кыздырырга!

—Ул б... миңа эләксәме! Йонын язар идем мин аның исемен оныттырганчы!

Мөнирҗанны Курган стансасында күргәннәре бик тетрәндерде. Ирләр генә утырган камерада ул тоткынлыкның ни икәнен аңлап бетерә алмаган икән. Әле башланмаган ике ел да сигез айлап бар. Ниләр күрер дә, ниләр кичерер аның газиз башкае.

Ул чакта берәрсе Мөнирҗанга тагын җиде тапкыр хөкем ителәсен һәм союзның әллә нинди төрмәләре нарларында көннәр санарга туры киләчәген әйтсә, үлсә дә ышанмас иде. Моңа кадәр күргәннәре баласы гына икәнен кайдан белсен ул.

Бауны күпме генә сузма, барыбер очы бер чыга. Озакка сузылган сәяхәт Кемеровода тәгәлләнде. Аларның күбесен, шул исәптән Мөнирҗан Исламовны да халык хуҗалыгында файдаланырга карар кылганнар икән. Ил күмергә мохтаҗлык кичерә, сугыш җимергән күпме шәһәр, авылны, завод-фабрикаларны аякка бастырасы бар. Моның өчен энергия кирәк. Ә энергия алуның төп чыганагы—ташкүмер. Нефть әле аз чыга, ә ташкүмер шахталары кайда гына юк. Кемнәрдер Донбаста күмер чапса, Мөнирҗанга Кемерово язган икән.

Аларны сакчылар эшкә алып бара, карап эшләтә, алып кайта. Чын төрмә белән чагыштырганда, монда үзеңне бераз кеше итеп сизәсең. Сак астында, тоткын икәнеңне белсәң дә парашалы камера түгел инде бу.

Көннәр бер-бер артлы уза тора. Гайниядән ике тапкыр посылка алды Мөнирҗан. Посылканы, ни килсә дә, әлбәттә бергә яшәүчеләр белән бүлешәсең. Ә алар дүрт кеше: урыс Николай, казакъ Мекебай, чуаш Петр. Әйтерең бармы, менә дигән интернационал!

Ул көнне Мекебай белән икесе алар төнге сменадан кайтты, Коля белән Петя шахтага төштеләр.

Мекебай ачык йөзле, киң күңелле егет. Ни генә әйтсәң дә: «Жаксы»,—дияр, елмаер, бүтән сүз катмас. Аның утыруы ат белән бәйле: күршедәге җәйләүгә сөйгән кызы янына атланып барган атын бүреләр ашаган. Бүреләрнең тамагы туйгандырмы, юкмы, әмма Мекебайга биш елны шапылдатканнар.

Кичә кич, шахтага төшәр алдыннан, аңа посылка барлыгы турында хәбәр китергәннәр иде. Бүген ул беренче эш итеп шуны алып кайткан.

Казакъ халкы ит ярата. Куй ите, елкы ите. Посылкага да казылык, киптерелгән бавыр салганнар иде—капкачын ача башлауга, авыздан су килде.

Казылык татарның да иң затлы милли ризыкларының берсе. Сугышка кадәр Мөнирҗанның әтиләре дә кайбер елларны яшь тай суеп, эчәгесенә казылык тутыра иде.

Казылыкны да, күрәсең, тутыра белергә кирәктер. Гаптелихсан абзый йорттагыларны бу эшкә якын җибәрми, үзе тутыра. Мөнирҗаннын карап торганы булды: башта ул итнең үзенә ошаган җирләрен, маен телемләп кисеп ала. Аннан соң шуны тозлап, борычлап, сарымсаклар куша-куша болгатып, базга төшереп бер кич кундыра. Соңыннан эчәгеләргә тыгызлап тутыргач, өй түбәсенә элеп куялар да өлгереп җиткәнен көтәләр. Ай ярым-ике айлар узгач, әтиләре чормадан түгәрәк казылыкларнын берсен алып төшә дә, кичке ашка өстәл тирәли тезелеп утырган гаиләсе каршында, бисмилласын әйтеп, шушы көн өчен махсус кайралган чалгы пычагы белән юка телемнәргә кисә. Казылыкнын хуш исеннән бер исерсәң, авызга алуга һуштан язар хәлгә киләсең. Капкан телемең авызда май булып эри, чәйнисе дә калмый. Бер түгәрәк казылык шул бер утыруда ашалып бетә. Бу өйдәгеләр, бигрәк тә балалар өчен гаеп бәйрәменә тиң, чөнки янадан ата-ана тарафыннан мондый юмартлык бүтән күренми.

Казылык күчмә заманнардан ук калгандыр. Мөнирҗаннар гына түгел, ат суйган, казылык хәзерләгән кешеләр барысы да диярлек аны көннәр җылыткач, мондый ит беткәч, әҗәл даруы урынына гына ашыйлар. «Күп ашасаң, аз ашарсың, аз ашасаң, күп ашарсың»,—дияргә ярата иде әтиләре Гаптелихсан. Бу мәкальнең ни анлатканын Мөнирҗан шактый еллардан соң гына анлады.

Казылыкны казакълар икенчерәк әзерли икән: Мекебайга килгәнендә ите аз, мае күп иде.

Ярар, майлы булса да, казылык казылык инде ул. Бавырын да күргән-ашаган бар. Авыз иткәч, чын күңеленнән Мөнирҗан рәхмәт әйтте.

Посылкада кечкенә капчыкка салынган тагын нидер бар иде. Мекебай капчык эченнән бер чеметем салып, «кәҗә тоягы» төреп, аны авызына капты һәм кабызып, суыра башлады. Икенче «кәҗә тоягы»н ул Мөнирҗанга сузды.

—Рәхмәт, мин бит тәмәке тартмыйм,—диде Мөнирҗан.

—Ә бу тәмәке түгел.

—Нәрсә соң?

—Суырып кара. Шуннан белерсең.

Күрмәгәннең күрәсе килә, күргәч, тотып та карыйсы килә. Кызыксынып, Мөнирҗан да бер суырды, ике суырды, авызында әчкелтем тәмнән башка нәрсә сизмәде.

—Син аны ашыкмыйча гына суыр,—дип кинәш бирде Мекебай. Ул авызына капканны тарта-тарта, койкасында яткан көенә әкрен генә «кәҗә тоягы»н пыскыта.

Бергә яшәүчеләрнең Мөнирҗаннан башкалары тәмәке тарта һәм, шушы яшькә җитеп, сугыш мәхшәрен кичкән башы белән анын тартмавына чын-чынлап гаҗәпләнәләр иде. Ә Мөнирҗан шул әшәкене тарткан кешеләргә гаҗәпләнә. Әнә чуаш Петрнын сирәк тешләре элек ни төсле булгандыр, хәзер сап-сары. Ул тарту мәсьәләсендә бигрәк тәкатьсез: тәмәкенең берсе артыннан икенчесен кабызып кына тора. Үпкәсе ничек чыдый торгандыр мескеннең. Нәкъ инде Черепанов паровозы. Болай дәвам итсә, озак чыдамас, хәзер үк, ютәл зәхмәте кузгалса, тиз генә туктый алмый, төкерегә дә кан аралаш. Шулай булмыйча соң, җир астына төшкәч тә шифалы су түгел, күмер тузаны эчә бит аларнын үпкәсе!

Мекебай кинәшен тотып, Мөнирҗан әкрен генә тартуын белде, анын арыган вә талчыккан җаны-тәненә рәхәтлек иңә барды. Күз алдында яшеллеккә чумып утыручы бакча пәйда булды. Алар Гайния белән шул бакчада йөриләр икән. Бер җире авыртмый, бер җире сызламый. Әллә оҗмах бакчасына эләккәннәр инде?

Күз алдында тагын ниләр күренер иде, татлы хыялыннан аны Мекебай тавышы бүлдерде:

—Йә, ничек?

—Рәхәт. Мин үземнен гәүдәмне сизмим, күктә йөзәм. Төреп бир тагын берне!

—Житеп торыр. Күп булып китәр.

—Булмас! Жәлләмә! Төр дигәч төр!

—Жарар, бик сорагач, мә алайса. Тик үзенә үпкәлә.

Мекебай тагын берне төреп бирде.

Шуннан арысын Мөнирҗан хәтерләми. Күпме йоклагандыр, башы чатнап ярылуга түзә алмыйча, күзләрен ачарга мәҗбүр булды. Күпме яшәп, башының болай авыртканын хәтерләми иде. Йа, Хода, сабырлык бир! Уф, чатный, ярыла бит башы, ни эшләргә?

Мекебай аяк өстендә. Николай белән Петрның урыннары буш, димәк, кайтмаганнар әле.

Аның уянганын күреп, Мекебай:

—Жаксымы?—дип сәламләде. Башка вакытта бу егетнең шундый эчкерсез елмаюы кәефен күтәрә иде, бу юлы косасын китерде.

—Жок!—диде ул казакъчалатып.—Берни хәтерләмим. Ни булды?

—Жаман гой, жаман! Мин сине акыллы жегеткә саный идем, тиле икәнсең.

Мондый сүзне көтмәгән Мөнирҗанның Мекебайга хәтере калды:

—Тилереп мин ни эшләгән?

Мекебай икеләнеп калды: әйтергәме, әйтмәскәме? Кызып китәргә генә тора бу дала егете.

—Чынлап та хәтерләмисеңме?

—Юк, валлаһи, берни дә хәтерләмим.

—Ай, жолдас Мөнирҗан, булуың житте, миннән хатыныңны таптыра башладың гой. Кайтып китәм дип тәрәзәдән сикерергә теләдең. Көч-хәл белән туктатып калдым. Ай-һай, гайрәт икән үзеңдә, жолдас Мөнирҗан, тотып тыеп кына булмый. Сикерсәң, пешерә идең бишбармакны!

Башы авыртуын да онытып, Мөнирҗан курка калды. Куркырсың да шул, кыланмышларың кырга сыймаса. Ярый әле, бәхетеннән, Мекебай, рәхмәт төшкере, янында булган. Ә чынлап торып уйлап карасаң, шул казакъ тәре котыртмаса, бу агуны тартасы идеме ул?! Ну Мекебай, тәре җан, бәреп үтерсәң дә жәл түгел сине!..

Күңел түреннән икенче тавыш каршы төште:

—Син, туган, Мекебайны сүкмә. Әйт әле, әллә ул сине көчләп тарттырдымы?

—Юк.

—Шулай булгач, ник аны гаеплисең?

—Тәкъдим итте бит.

—Итсә соң! Кем нәрсә тәкъдим итмәс. Үз башың кайда?

—Барын бар ла ул. Әллә юк микән? Чын баш моның кадәр дә каты авыртмас.

—Баш авыртуың бер бетәр, тик менә моңардан сабак ала белерсеңме икән?

—Тырышырмын.

Мөнирҗан сүзендә торды: мондый юньсез нәрсәне бүтән авызына якын да китермәде.

Күп еллар узып, бөтен дөньясын наркомания дигән афәт яулап алгач, төрмәдә утыру буенча шактый «тәҗрибә-стаж» туплаган һәм яше өлкәнәя төшкән Мөнирҗан Мекебайга килгән посылкадан «кәҗә тоягы»н бер-бер артлы икене төреп тартканы өчен үзенә рәхмәт укыды. Дөрес, ул көнне нәрсә тартканын Мөнирҗан хәзер дә төгәл генә белми, ләкин аның наркотик булуына иманы камил иде. Әгәр дә бик көчле баш авыртуы белән уянмаган

булса, бәлки ул да шушы кабахәткә иярләшеп китәр иде. Алла саклаган үзен. Наркоманнарның ничек газапланганнарын соныннан аз күрергә туры килмәде аңа. Ул булган төрмәләрдә андыйларга соңгы вакытларда кытлык юк иде. Шунысы гаҗәп: тикшерү арты тикшерү, контроль өстенә контроль, ләкин наркотиклар шундый тылсымлы көчкә ия ки, төрмәнен биек таш диварларын бар дип тә тормый, кораллы сакчыларга да карамый—зонада наркоманнар рәхәтләнеп кәеф-сафа кора. Әле үзләре генә кулланса ярар иде, әллә кемнәрне өйрәтәләр дә, соныннан тегеләре, тәкатьсезләнеп, бер доза өчен бер-берсен үтерүгә кадәр барып җитә. Анламассың бу дөньяны. Хәер, Мөниржан укып белә: аны исемнәре гасырлардан гасырларга күчә барган бөек акыл ияләре, кешелекнен даһилары да анлап бетерә алмаган. «Нәрсә?», «Ничек?», «Кайчан?» рәвешле сораулар һәрвакыт баш өстендә эленеп торган.

Аллаһы Тәгалә үзенең бәндәсен шундый итеп яраткан ки, әгәр дә исән каласы килсә, адәм баласы теләсә нинди шартларга да яраклашырга, җайлашырга тиеш. Мөниржанны гына ал—ул соң ата-анасы нигезеннән аерылырга теләгән идеме? Ул бит Әскәй кырларында иген игеп, мал-туар асрап, гаилә корып, хатыны, бала-чагалары белән күгәрченнәрдәй гөрләшеп яшисе кеше иде. Ә чынлыкта ничек килеп чыкты? Башта аның әле житәрлек кадәр ныгып өлгермәгән канатларын сугыш ялкыны өтте. Сынар канатын көйдереп булса да, шөкер, үзен исән калдырды, анысына рәхмәт. Инде менә тагын бер сынау—мәсхәрәле, газаплы сынау. Шушындый мәсхәрә казанына ыргытырдай житди сәбәбе булса иде әле. Колхоз атларын ачтан үтермәс өчен алып кайткан иделәр бит ул печәнне. Бик үк ярый торган эш түгел икәнлеген белә торып бардылар алар Фазыл белән бу адымга.

Фазыл исенә төшүгә, күнеленнән үкенеч хисе узды. Ул кайларда ни эшләп йөри икән? Нигә соң Мөниржан теге вакытта аның сүзен тыңламады. Тыңласа, ак сакаллы карт булган булыр иде. Гайнияне, ата-анасын кызганды. Кызганып, тагын да зуррак газапларга дучар итте. Газап кынамы, хурлыгы ни тора! Бәгъзеләре, ирен өтермәндә дип, мескен Гайниянең күзен дә ачырмый торгандыр. Фазыл сүзен тыңлап качып китсә, ул иректә булыр, якыннарына да хурлык тамгасы суга алмаслар иде әле. Менә хәзер чап инде күмер…Әй, анысына гына төкерер идең әле, күмер чабуы, шахтадагы эшләр берсе дә түзмәслек түгел түгелен…

Күнелен айкаган хисләр өермәсенә түзә алмыйча, Мөниржан жырлап җибәрде:

Шахтер егет күмер чаба  
Вак-вак итеп кисәгеп.  
Гомерем булып, таш басмаса,  
Ташламам, жан кисәгем.

Әйе шул, татар элек-электән бәхет эзләп читкә киткән, күмерен дә чапкан, алтын приискаларында алтынын да чыгарган, дингездә балыгын да тоткан, бүтән авыр эштән дә тартынмаган. Татар эштә дә, сугышта да үз-үзен аямый торган халык. Хәзер менә Мөниржан шуларның язмышын кабатлый. Ләкин бер бик зур аермасы бар: бәхет эзләп читкә китүчеләрне зимагур дип атаганнар һәм алар очар кош кебек иркле булган. Әгәр бер җирдә ошамый икән, бүтәненә күчкән, сагынса, ялт итеп кайтып та килгән. Ничек җырлыйлар әле: «Зимагурлар талчукта, кайгырмыйлар мал юкка»,— дипме? Ә Мөниржан…Ул бит зек, ристан. Аның бердәнбер хокукы—күмер чабу, калганын аның өчен төрмә түрәләре хәл итә. Моң-зарынны сөйләргә әти-әниең, иркәләнергә хатының юк биредә. Һәркемнең үз кайгысы кайгы, үз кырыгы—кырык.

Үз гомерендә Мөниржан, жырдагыча әйтсәк, «кая гына китеп, кайларга бармады», дистәләгән зонаның лаеш шулпасын эчте, тик аңа наркомансыз һәм таракансыз, кандаласыз төрмә күрергә туры килмәде. Ә андыйлары, гомумән, бармы икән соң? Югыйсә бит «иң яхшы илнең» бөтен нәрсәсе, шул исәптән төрмәсе дә иң яхшы, черегән капитализмның курортына тиң, сыйфат билгесе белән булырга тиеш иде. Хәер, иленә карап сыйфат төшенчәсе дә үзгәрәдер.

Адәм баласы тора-бара һәр нәрсәгә күнегә. Мөниржанга да төрмәдәге наркоманнар һәм тараканнар андагы надзирательләр, сакчылар, сулый торган һава, эчәр су кебек үк, мәжбүри шарттыр кебек тоела башлады.

Төрмә төрмә инде ул. Ул бит автономия эчендә автономия, СССР дип аталган гаять зур дәүләтнең рәсми төстә танылмаган тагын бер союздаш республикасы. Вак-төяк судларны, хөкем органнарын әйткән дә юк, аның президентлар, генераль прокурорлар да борын тыга алмый торган үз конституциясе, кодекслары, кагыйдә-инструкцияләре бар. Иректәгедән аермалы буларак, аларны урап-әйләнеп уза алмыйсың—мондагы законнар һәркем өчен тигез. Дөресрәге, булырга тиеш тигезсезлекне алдан ук күреп тудырылган. Алар белән төрмә житәкчеләре дә исәпләшергә мәжбүр.

1953 елның марты иде. Дөньяны кинәт яшен сукты. Ленинның якын көрәштәше, дусты, бөтендөнья пролетариатының юлбашчысы саналган, аның өчен сугышта кешеләр айнык көе дә, салган баштан да һич икеләнүсез үлемгә барган, Советлар Союзында социализм төзүгә житәкчелек иткән даһи Сталин үлемен халык әнә шулай кабул итте. Иосиф Виссарионович үлгәч, кояш бүтән чыкмас, күктәге йолдызлар барысы да сүнәр, жирдә тормыш бетәр, Советлар Союзы жимерелер кебек иде. Халык канлы күз яше белән елады. Иректәгеләрне әйткән дә юк, моңа чын-чынлап кайгыручылар төрмәдә дә табылды. Тормыш капма-каршылыклардан тора икән: әнә шул чын-чынлап кайгырган кайберәүләрне озакламый азат иттеләр. Чөнки аларның утыртылуы турыдан-туры Сталин исеме белән бәйле иде. Менә шуннан әйт инде: кайгырырга кирәк булганмы бу үлемгә, әллә шатланыргамы—белмәссең. Әлеге тиран 1953 елда жан тәслим кылмаса, сәяси жепшеклек еллары килер идеме?

Кылган эш-гамәлләренә хөкемдар Вакыт булса, сырхау-авыруларына иң зур, иң кодрәтле табип—шулай ук Вакыт галижәнапләре. Менә шушы Вакыт дигән табип яшь хатынның сүнеп бара торган жанына шифалы сулышын өрде һәм, тылсымлы әбелхәят суы белән сугара торгач, язмыш тагын бер могжизасын күрсәтте: Гайния әкренләп тернәкләнеп-терелеп китте.

Кияүгә чыгу, бала табу төрле хатын-кызга төрлечә тәэсир итә. Берәүләре сулып-сулыгып, ямьсезләнеп, карачкыга охшап кала. Икенчеләре исә таңгы чык тамчысы белән ачылган чәчәк бөреседәй, матурланып, чибәрләнеп китә, йөзенә илаһи якты нур иңә. Гайния соңгылары исәбендә—аңа гүзәллек тажы кидерделәрмени—ул янә чәчәк атты.

Әйе шул, тормыш никадәр генә катлаулы тоелмасын, нинди генә сынаулар килмәсен, үлгән артыннан үлеп булмый. Башыңны ташка ору да файдасыз. Мөниржаны, Мөниржаны гына исән әйләнеп кайтсын, балалары тагын булыр, менә дигән итеп яшәрләр.

Шушы фәлсәфә аңа дөньяга якты күз белән карарга көч бирде.

Аягына ныклап басып өлгергәнче үк эшкә чыкты Гайния. Чыкмас иде, бердән, Гайния чирләде дип тормыш туктамый. Колхозында эш барамы, юкмы, бухгалтериядә көне-төне чут сугалар: унга төймәләрне шалт, сулга төймәләрне шалт! Колхоздан район, районнан Казан хисап таләп итә. Казаннан Мәскәү сорыйдыр. Шуңа күрә бухгалтериядә саннар һәрвакыт әзер булырга тиеш. Бөек Ильичка ант бирүче пионер сыман!

Яшьлек үзенекен итте. Бер чикне узгач, тиз савыкты ул. Күзләренә кереп оялаган сагыш та, нужа кидерткән ямаулы кием дә яшь хатынның табигый

гүзәллеген томалый алмады. Кайбер ирләрнең чишендергеч карашлары (тфү-тфү!), аларның ах-ух килүләре Гайниягә үзен кеше итеп, хатын-кыз итеп тоярга булыша, шул ук вакытта сискәндереп, шомландырып та куя.

Колхоз идарәсе шундый җир: авылда яшәгән һәркемнең диярлек аңа йомышы төшә. Йомышы төшкәч, килми чарасы юк. Килгәч, әлбәттә, анда эшләүчеләр дә күзләренә чалына.

Алары бер хәер, әле бит көн саен әллә ничә тапкыр очраган колхоз рәисе Хәсьянов һәм бер бүлмәдә утырып эшләүче баш хисапчы Мисбах та бар.

Савыгып эшкә чыккан Гайнияне күргәч, Мисбах аңа соклануын яшерә алмады. Бу хәлгә хәтта хисапчы Разия да игътибар итте:

—Кара, кара бу аксак шайтанны, кош тоткан диярсең. Кыланышы кырга сыярлык түгел!

Ә Мисбах теге буранлы төндә Доха карчык өендә булган хәлне исенә төшереп, рәхәт бер хис кичерде.

...Бурлы айгыр белән Гайния кайтып киткәннән соң уянган Мисбах баштарак берни аңышмый ятты. Чөнки йокы исереклегенә өстәлгән аракы пары аның фикерләү сәләтен томалаган иде. Житмәсә, ачу китереп, Доха карчык:

—Теге чибәр кыз кайда?—дип сорады.

Эченнән генә Мисбах: «Карт убыр, сиңа барыбер түгелмени?»—дисә дә, теле икенчене әйтте:

—Кайтып китте.

—Ә син ни эшләп калдың?

—Райфода эш бетмәде.

Башбухның күңеленә шик төште. Доха карчык барысын да беләдер, шуңа сораштыра торгандыр кебек тоелды. Гайния, мәмәй авыз, яткан җирдә эз калдырмыйча киткән булса ярар иде. Югыйсә хуҗа карчык эшнең ничек булганын сизәчәк. Сизсә, эш харап, дөньяны сасытырга да күп сорамас. Шуңа күрә хуҗа карчык өйдән чыгуга, башы чатнап ярылуга карамастан, Аксак Мисбах Гайния яткан түшәккә ике атлап бер сикерүдә барып житте дә, шикләнердәй нәрсә күрмәгәч, тынычланып, калган чәен эчеп бетерде һәм берьюлы баш төзәтергә җай һәм кайтырга ат караштырырга дип, ашханә тарафына титаклады...

Гайния авызын үлчәп ача торган кыз булып чыкты. Икесе арасында булган хәлне ник берәрсенә тишсен. Кызык, Мөниржан беллеме икән? Әллә аңа да әйтеп тормаганмы? Хатын-кыз иблис кавеменнән, ирен алдарлык кына җаен таба ул. Алар бит хәйлә капчыгы.

Мисбах берничә көн үзен тыеп йөргән иде. Беркөнне чылбырдан ычкынды.

Ул көнне Разия чирләбрәк тора иде, баш хисапчыга әйтеп, төштән соң эшкә килмәде. Ә районга хисап бирер көн житкән, кичекмәстән отчетны хәзерләп бетерергә кирәк. Моның ише чакта вакыт белән санлашу юк, Мисбах белән Гайниянең икесенә дә сонга кадәр калып эшләргә туры килде.

Эш эш белән, ләкин Мисбахның шешә хәле график буенча. Ягъни җаны теләгән саен. Кырыендагы шкаф ишегең исенә төшкән саен ачкалый торгач, запассыз торырга өйрәнмәгән Мисбах кичке якка шактый кызды. Кызган саен аның карашы алдындагы саннардан бигрәк, дөньясын онытып, күрше өстәл артында отчет хәзерләү белән мәшгуль Гайния тарафына юнәлде. Ә Гайниянең Мисбах гамендә дә юк, ул берничә дә игътибар итмәстән, башын яртылаш игән дә чут төймәсен тартуын һәм саннар язуын белә. Жиделе лампа яктысында яшь хатын искиткеч гүзәл, ымсындыргыч булып күренде. Бу юлы, чарасыздан, Мисбах шкафтагы шешәсенең хәлен «белешергә» мәҗбүр булды. Тагын бер йотып куйгач, теге буранлы төндә Доха карчык өендә булган хәл бөтен ваклыклары белән аның күз алдында җанланды.

Гайниянең чаршау эчендәге саран яктылыкка нур өстәгән, аны акылыннан шашар дәрәҗәгә җиткереп кыздырган алсу мәрмәрдәй тәне, эчке күлмәге сыдырылып, тәнендә җаны булган теләсә нинди ир-атны янып торган утка да, бозлы суга да ташланырга мәҗбүр итәрдәй ялангач бот-аяклары, менә-менә янар тауларга әверелергә җиткән имиләре очындагы куе-көрән чияләр исенә төшкәч, Мисбах үзен тыя алмыйча тилерер чиккә җитте. Ә нигә бәхетен тагын бер сынап карамаска? Идарәдә алар үзләре генә. Гайниянең ире юк, ул да адәм баласы, аңа да ир назы кирәктер. Исерек башындагы шайтан аны шулай котыртты, һәм Мисбах, чатанлавын да онытып, Гайнияне артыннан ничек килеп кочаклаганын сизми дә калды. Юеш ирennәре белән яшь хатынның муеныннан үпте, үзе туктаусыз сөйләнде:

—Гайния, мин теге вакытта безнең арада булганны һич оныта алмыйм. Яратам мин сине... Яратам!..

Гайния башта югалып калды.Аңына килүгә, ике уйлап тормады, башта Мисбахның кулларын муеныннан алып атты, аннан соң утырган җиреннән сикереп торып, алдында яткан чут белән үзенең баш хисапчысын уңны-суллы бәргәләргә кереште. Мисбах әүвәл, башын куллары белән каплап, сакланырга тырышып караган иде, ләкин Гайния бәхетенә кем кул сузганын онытмаган иде, суккан саен кыза гына барды. Ахыр чиктә Мисбах чатанлавын да онытты, өстенә киенеп тә тормыйча, бухгалтериядән ничек чыгып сызганын сизми дә калды.

Ярсыган Гайния аның артыннан кулындагы чутын ыргытты. Ябылып өлгергән ишеккә бәрелеп, чут таралды, һәм төймәләре кайсы кая идәнгә сибелде.

Үзе генә калгач, Гайния үксеп елады. Ялгыз хисапчыга кем дә комачауламады. Ләкин дөньяда вазифаи бурыч дигән нәрсә бар: елап туйгач, кызарган дымлы күзләрен яулык очларына сөртеп, ул янә хисап эшенә ябышты. Чатан Мисбах бәйләнде дип кенә төп эшеңне онытырга ярамый шул.

Гайния ул көнне биаталары йортына шактый соңгарып кайтты. Йокларга ятса да, төне буена керфек какмый чыкты. Кайчандыр Мөниржан белән бүлешкән бала каз мамыгыннан тутырылган мендәре рәнҗетелгән җанның күз яшьләрен сүзсез генә үзенә сеңдерде. Йокыдан торганда, ул кискен бер карарга килеп өлгергән иде инде.

Икенче көнне башбух белән Разия апасын районга хисап бирергә озаткач, колхоз рәисенең үзе генә чагын туры китереп, Гайния Хәсьянов янына керде.

—Иптәш Хәсьянов абый,—дип башлады ул сүзен. Әскәйлеләр ни өчендер исем белән генә дә, иптәш Хәсьянов кына дип тә мөрәҗәгать итми, алар рәсмилекнең аръягына чыгып, өлкәнрәкләр: «Иптәш Хәсьянов апай», ә яшьрәкләр: «Иптәш Хәсьянов абый»,—дип дәшә.

Колхозлашу елларыннан ук калган каен урындыгында утырган көе, Хәсьянов Гайниягә текәлде. «Чибәр бит, каһәр! Кура җиләк тә җир җиләк, кирәк түгел бер чиләк! Әллә инде көннән-көн ныграк чәчәк ата бу хатын? Югыйсә көн саен ничә тапкыр күзенә чалына, ә моның кадәр үк матур күренгәне юк иде сыман. Бер уйласаң, үз чибәрлегенең уннан берен дә аңламаган бу хатын ирсез җәфа чигә бит. Мөнирҗаны кайчан кайтыр. Рәшәткәле казна йорты ул кияү мунчасы түгел. Исән кайтса да, ничек кайтасын белгән юк. Колхоз рәисе үз колхозчылары турында кайгыртырга тиешме? Тиеш! Бигрәк тә чибәррәкләре, кыюсызраклары турында. Аның ямьсез әрсезләре болай да югалып калмый».

Хәсьянов көлемсерәп куйды. Әмма ул карт төлке, хәйләкәр төлке, күңелендәгесен чыраена чыгармаска күптән өйрәнгән. Текәлеп караган көе, Мидхәт Гайниянең сүзен дәвам итүен көтте.

—Иптәш Хәсьянов абый...—Колхоз рәисенең дәшми генә үзенә текәлүе,

аның кергәндәге кыюлыгын юкка чыгарды.

—Ни йомыш, Гайниякәй?—дип сорады, ниһаять, Хәсьянов. Тагын да дәшми торса, ул Гайниянең үпкәләп чыгып китәсен белә иде.— Тартынма, әйт!

Әйтергәме, әйтмәскәме? Болай да шикләнеп кенә кергән Гайния күңелендә икеләнү-шөбһә гарасаты бөтерелде. Юк, әйтергә кирәк. Югыйсә монда кереп торуның ни хаҗәте бар.

—Минем хисапчы булып эшлисем килми.—Тавышының шушы кадәр катгый чыгуына Гайния үзе дә гаҗәпләнде. Шулай да кинәт кенә мондый карарга килүенең төп сәбәбен әйтеп тормады. Хәсьяновның да фәрештә үк түгел икәнлеген ул белә иде.—Зинһар өчен каршы килмәгез инде...

Гаҗәпләнсә дә, Хәсьянов керфеген дә селкетмәде, бары тик чәчләренә көмеш бәс йөгергән башын аңа табан гына борды. Чөнки күпьеллык тәҗрибәдән чыгып белә: гозер белән кергән хатын-кызның күпчелеге барысына да риза. Хәтта иң соңгысына да. Ә андый соңгысы чибәр хатын-кызлар белән була калса, бусы инде Мидхәтнең иң яратканы—«слабосты!» Гүзәлләрнең гүзәле чишенеп, үзен сиңа тәкъдим итсә, Ходай үзе сакласын да, гөнаһ кылсаң—ярлыкасын.

—Кызык...—диде ул шактый сүзсез торганнан соң.—Ни өчен икәнен дә сорарга мөмкинме?

Хәсьянов—карт төлке, ни өчен икәнен төгәл генә белеп бетермәсә дә, сәбәбен күңеленнән сизенә иде. Ник дисән, салып утырганда бер тапкыр, исерә төшкәч, Гайния белән булган мажарасы хакында Мисбах бер тапкыр мактанып алган иде. Ул чакта артык игътибар итмичә, ир-атның гадәти шапырынуы гына дип уйлады. Аннан онытты, чөнки рәиснең бүтән мәшәкатьләре дә җитәрлек. Ир-атның кайберләренең мәхәббәт фронтындагы «уңышлары» белән шыттырырга яратуы да мәгълүм. Исерек шайтан ни сөйләмәс. Икенче яктан, белмәссең, бәлки хактыр да...Таза-таза ир-атларга тәтемәгән чибәрләр кайвакытта адәм гыйбрәтләренә ризык булып куя.

—Алай икән... Шулай да белергә мөмкин булырмы: ни өчен бухгалтериядә эшләүдән туйды икән безнең чибәркәебез? Мин бит беләм: анда эшләү теләсә кемгә эләкми. Әллә Мисбах абыең рәнҗеттеме? Рәнҗетсә әйт, чара күрербез.

Әллә бу рәис күрәзәче инде? Юк-юк, егылып үлсә дә, дөресен әйтергә ярамый. Гайния алдашырга мәҗбүр булды:

—Иптәш Хәсьянов абый, туйдым мин сан сугыштырудан,—диде ул.

—Кая китмәкче, ни эшләмәкче буласың инде?

—И иптәш Хәсьянов абый!—Авылның иң дәһшәтле кешесе сиңа шул кадәрле якын итеп эндәшсен әле! Егылып китәрсең...Гозереңне тизрәк әйтеп калырга кирәк.—Әллә эш беткәнме? Паспорт бирсәгез, нефтьчеләргә урнашыр идем...

Моны ишетүгә, Хәсьянов урыныннан ук сикереп торды:

—Юк! Менә монысын сорама!—диде ул ике әйтергә урын калдырмаслык итеп.—Булмый!

—Ник?—Гайния белә: паспорт кануннары көчле булса да Әскәйдәге кайберәүләр барыбер читкә чыгып китте. Шуңа күрә йөрәк тавышы белән кабат сорады:

—Ник?

—Синдәй матур хатыннарны читкә җибәреп бетерсәң, авылда ямь калмас.

Бу сүздән Гайния кызарып китте:

—И, оялтмагыз инде, иптәш Хәсьянов абый!

—Алайса дөресен әйтим: райком кушмый.

Райком кушмагач, сорап, ялварып торуның файдасы юк. Райком—авылда

мөмкин булганнарның иң соңгы баскычы. Колхоз рәисе дә куркырлык булгач, ул бик дәһшәтле жирдер. Ләкин Гайния шунысына бик үк төшенеп житми: шул колхоз рәисе дә, бик теләсә, райком кушканга-кушмаганга карамый. Чөнки рәис авылда патша да, Алла да. Рәис теләсә, колхоз жирендә яфрак селкенә, бөреләр чәчәк ата, теләмәсә—юк. Хәтта кызларны да башка авыл егетләренә кияүгә бирергә теләсә бирә, теләмәсә—бирми. Әнә Гайнияләрнең күрше кызы Нәзирә Сәпәй егетенә кияүгә чыкмакчы иде, Хәсьянов теше-тырнагы белән каршы төште. Имеш, колхозда эшче көч кими. Ахырда Нәзирә качып китте. Хәзер кунакка килгәндә дә, рәис күзенә бик үк чалынмаска тырыша.

Гайния шуны аңлый алмый: аларга бит мәктәптә крепостное право 1861 елда ук бетерелде, ә хәзер бөтен кешеләр дә бертигез иректә дип сөйләделәр, бу хакта 1936 елның 5 декабрендә кабул ителгән бөек Сталин конституциясендә акка кара белән язылган дип укыттылар. Ә монда авылның алдынгы сыер савучы кызы Нәзирәне күрше авыл егетенә кияүгә бирергә ярамасын! Бу нинди башбаштаклык?!

Гаҗәпләнер нәрсәләр күп шул. Октябрь инкыйлабы булганга өч дистәдән артык ел узды, бөек Ленин, Сталиннар тәгълиматына караганда, капма-каршы сыйныфлар булмаган җәмгыятьтә һәркемнең дә хокуклары тигез булырга тиеш иде. Тигезме соң? Эшчеләр югары сорттан, чөнки аларның паспортлары бар. Авыл халкы түбән сортлыга керә. Чөнки аларның паспортлары юк.

Башында рәнҗүле дуамал хисләр котырган Гайния колхоз рәисенә кыяр-кыймас карап, аның хөкем сүзен көтә.

—Тәк... тәк-тәк! Ярар алайса, син дигәнчә булсын: хисапчылык ошамый икән, эшкә фермага барырсың.

—Кем булып? Сыер саваргамы, бозау карарргамы?

—Юк, мөдир булып!

Гайния утырган жиреннән ничек итеп сикереп торганын сизми дә калды:

—Мөдир булып? Минме?

—Син инде, син, мин түгел.

—Ә Шәрип абыйны кая куясыз?

—Аны күптән эшеннән алырга дип йөри идем, кеше таба алмаганга гына торды. Адәм рәтле эшләми бит. Салдымнан гел башы чыкмый. Синең керүең бик вакытлы булды әле. Кемне куярга белмичә аптыраган чак иде.

—Булдыра алырмынмы икән соң?

Хәсьянов килеп, Гайниянең җилкәсенә кулын салды:

—Кайгырма, булышырбыз. Мидхәт абыең ярдәменнән ташламас. Хезмәт хакың да зуррак булыр. Иң мөһиме—сөт савып алуны арттыру. Соңгы бюрода строгач алып кайттым. Хәзер бөтен өмет синдә, Гайния. Сынатмассың дип уйлыйм.

Хәсьянов Гайниянең кулын кысты.

Ишек ачылды һәм анда идарә атларын караучы Шәһитнең башы күренеп алды.

—Иртәгә эшне кабул итеп алырсың. Ә хәзер миңа районга китәргә кирәк.

Хәсьянов белән Гайния кабинеттан бергә чыкты.

Менә сиңа мә! Гайния гозере бу кадәр тиз хәл ителер дип уйламаган иде. Моңа сөенергәме, көенергәме—белмәде. Икенче көнне үк ул баштанаяк ферма эшенә һәм...тездән сазга чумды.

Әлбәттә, адәм рәтле сыерлар булмагач, аларны ничекләр генә ашатсаң да, сөт елгалары турында бары тик хыялланырга гына кала. Әле ашатуы да ташкаулчим.

Ләкин тырышлык барыбер үзенекен итә. Гайниянең ферма маллары дип көне-төне чабуы, сөтбикәләрнең авызына оныткан да бер булса да фураж эләгүе эзсез узмады—ике айдан сөт савуны бераз арттыруга ирештеләр. Моңа райкомда да игътибар иттеләр: Хәсьяновка бирелгән каты шелтәне кире алдылар.

Яз артыннан җәй, җәйдән соң көз килде. Ә көз житү—ул кышка бер генә адым калды дигән сүз. Кышын исә фермада мәшәкать бермә-бер арта. Азыкны ташып ашату гына түгел, сыерлар бозаулый башлый. Бу чорда ферма сыерлары янында һәрвакыт кемдер булырга тиеш. Узган ел, Гайния әле хисапчы чагында, яна туган ике бозау катып үлгән иде. Быел моңа юл куярга ярамый. Хәсьянов белән киңәшеп, кышкы чорга фермага колхоз активыннан төнге кизү куярга булдылар. Якындагы идарә утырышында график расланды.

Малларга тәүлек буена күз-колак булу ярады, тфү-тфү, моңа кадәр сыер, сарыклар арасында үлүчеләр булмады.

Җанны ашардай салкын янгырлы көз узып, беренче кырпак кар әле генә төшкән кебек иде, борылып карарага да өлгерә алмый калдылар, Яна ел да килеп житте. Тикмәгә генә әйтмиләр бит, кеше гомере аккан су, дип.

Яңа елга каршы төнгә Гайния кизүлеккә үзен куйган иде. Иртәдән бирле күңеле җырлап тора. Алдагы елда, Аллаһы боерса, аның Мөнир-Мөниржаны кайтачак! Әле менә төштән соң гына Мөниржанынннан хат килде. Сагындым, дигән. Кайтыр вакыт якыная, берүк, көт, дигән. Шушы сүзләр яшь хатынның йөрәгенә җылы бирә, бергә яшәгән көннәрдәге татлы-ләззәтле минутларны искә төшерә.

Хатны ул кат-кат укыды. Аерыласы килмичә бөкләп, аны күкрәкчәсе эченә тыкты. Иремнән хат килде дип кенә хискә бирелеп ятарга ярамый, кизү булсаң кизү бул. Иң күп сөт бирә торган Акмангайның җилеме тулган, бүген-иртәгә бозауларга тора. Аны исән-аман котылдырырга кирәк.

Диварга эленгән фонарьны кабызып, Гайния сыерлар янына ашыкты. Абзар ишеген ачуга, борынына сөт һәм эчкелтем тирес исе килеп бәрелде. Салам белән ябылган түбәләре тишек-тошык булса да, ишле мал торган абзарда җылы иде.

Сыерларның күбесе яткан да гамьсез генә күши бирә. Алар өчен бүген елның яңасы булды ни дә искесе булды ни; Гайниягә иреннән хат килде ни дә, килмәде ни, уйлап та карамыйлар. Кешеләр генә ул әллә ниләр уйлап табалар да үзләренә мәшәкать тудыралар.

Акмаңгай түр почмакка баскан. Гайния якынаюга, башын аңа табан борды.

—Хәлең ничек?

Акмаңгай җавап урынына койрыгын гына селтәп куйды, үзең анла, янәсе.

Хәзергә сыерларда ул-бу сизелми, таңга кадәр ерак, сонга табарак тагын бер әйләнер әле.

Бозаулар янына да сугылгач, Гайния ферма өенә кайтты. Салам гына ягылса да, суыктан кергәч, өй бик җылы тоелды. Хәзер бераз черем итеп алмый ярамас, төнлә кизү тордың дип көндез сине берәү дә эштән азат итми.

Гайния өстендәге киемен сәкегә җәйде һәм ятар алдыннан иренең хатын тагын бер тапкыр укып чыкты. Их, хаты түгел, үзе булса икән менә хәзер! Яшь хатынның тәне рәхәт калтыранып куйды. Хатыны сагынганга карап кына срокны кыскартмыйлар шул, югыйсә Гайниянең ташыган хисләрен искә алсалар, Мөнирен күптән ирекка җибәрерләр иде.

Фонарьның болай да саран утын тагын да кыса төшеп, Гайния йокларга ятты. Бераздан аның татлы тын алуы тышта усаллана башлаган җил тавышына кушылды. Ә иреннәрендә бәхетле елмаю калды.

Тәмле төшләр күрә генә башлаган иде, ишекнең шыгырдап ачылган тавышына сискәнеп уянып китте.

Жиде төн уртасында кем йөрер? Карак-угры түгелме? Хәсьяновны таныгач, тынычланды. Колхоз рәисе тынгысыз кеше, аның элек тә шулай төннәрен килеп, фермаларны әйләнгән чаклары була торган иде.

Хәсьяновка ияреп, бер кочак суык керде. Ишек ярыгыннан хәтта буран да озын телен күрсәтергә өлгерде.

Гайния инде фонарьның филтәсен күтәрә төшкән иде, торып утырды.

—Исәнме, Гайния!

Итегендәге карларын каккалап, Хәсьянов түргә узды.

—Аллага шөкер, иптәш Хәсьянов абый.

—Әй, ташла әле шул Хәсьянов абый дигәннәреңне! Мидхәт абый дияргә ярамыймыни сиңа! Әллә мине бөтенләй чит итәсеңме?

—Итмим дә, бер өйрәнмәгәч, тел әйләнми бит.

—Әйләнер, әйләнер. Фермада тәртипме?

—Хәзергә тәртип. Акмаңгай гына чирләбрәк тора. Вакыты житкәндер. Бәлки бүген үк бозаулар.

—Син барында күңел тыныч минем, Гайния. Үзеңне Яңа ел белән тәбрик итәргә килдем.

—Рәхмәт инде, искә алгач.

—Искә алгач дисең син...—Хәсьянов тунын салып, чөйгә элде. Һәм Гайния янына килеп утырды. Гайниянең борынына көмешкә исе килеп бәрелде.—Искә алгач дисең,—дип кабатлады ул.—Минем сине онытканым да юк. Бүген дә менә, тукта әле, дидем, Гайния бит анда фермада берүзе, аңа күңелсездер, бәлки берәр ярдәм кирәктер, дидем. Барып хәлен белим, дидем.

—Рәхмәт.

Хәсьянов Гайнияне кинәт үзенә тартып китерде һәм үбәргә үрелде.

Гайния һич кенә дә моны көтмәгән иде. Үз иреннәренә чит иреннәрнең кагылуы аны сискәндереп жибәрде.

—Китегез, нишлисез?!—диде ул ычкынырга тырышып.

—Йә инде, Гайния, яратам бит мин сине. Бер генә тапкыр кочаклап үпкәннән укаң коелмас. Телисеңме, Мисбахны алып, үзеңне баш хисапчы итеп куям!

—Баш хисапчыгыз да, үзегез дә кирәкмисез. Мин ир хатыны! Хәзер үк чыгып китегез, югыйсә кычкырам.

Хәсьянов шаркылдап көлде:

—Син кычкырганга, кем килер дисең? Сыерлар килсә генә инде,—диде ул мыскыллап.—Йә инде, йә, юләр булма. Син бит бала-чага түгел!

—Кабатлап әйтәм: мин—ир хатыны!

—Төрмәдәге ир ирмени ул. Курыкма, эзе калмас. Мин бит сине аңардан аертып алырга жыенмыйм. Мин үзем дә хатынымның ире.—Әз генә бушата төшкән кулы Хәсьяновның янә эскәнжәгә әверелде.—Сиңа әйтәм, кыланма! Барыбер мин дигәнчә булачак. Аксак Мисбахка яраганны, Мидхәт абыеңа ник ярамасын! Әйтәм ич эзе калмый дип! Әле соңыннан рәхмәт әйтерсең.

Мисбах исемен ишетү Гайниянең кинәт хәлен алды, сулышы кысылды, күз алларына караңгылык йөгерде.

Ычкынырга тырышып, ул тыпырчынды, Хәсьяновның битен, кулын тырнамакчы, тешләмәкче булды. Ләкин Мидхәт жил иссә дә очарга торган Мисбах түгел, аю кебек таза гәүдәле һәм мәхәббәт фронтында азау теш ярган рәистән алай ансат кына котылу мөмкин түгел иде. Алпамша ир Гайнияне сәкегә аударды һәм аның өстендә булган киемнәрен йолкырга тотынды. Гайниянең күкрәкчәсенә ияреп, Мөнирҗаннан килгән кадерле хат та идәнгә очты һәм сәке астына барып төште. Каршы торырлык көче

калмаганын аңлагач, Мидхәтнең үзенә кагылмавын күз яшьләре белән ялварып сорады Гайния, тик үгезгә әверелгән бу адәмне туктатырлык көч табылмады... Язмыш бәхетсез хатынны кабат сындырды.

—Менә бит, ә син карышкан идең,—дип тешләрен ыржайтты Мидхәт, чалбар төймәләрен эләктерә-эләктерә.—Мидхәт абыең белән хур булмассың! Үзеннең бигрәк тәмле икәненне белмисеңдер дә әле...

—Кит, кабахәт! Ерткыч!

—Алай тупас кыланырга ярамый. Чибәр хатын-кызга килешми ул. Ярый, мин киттем.—Хәсьянов ишеккә табан юнәлде.—Киләсе дежурыңда тагын очрашырбыз.

Хәсьянов ачып япкан ишектән тышта җил улаганы ишетелеп калды.

Гайния торып утырып, киемнәрен рәткә китерергә тотынды. «Кансыз, хайван!» Хатынның җаны үртәлде, күңеле кыйналды. Аны бит хәзер авылның бер сөйрәлчеге урынына саныйлар икән. Ничек шушы кадәр бәхетсез булды соң ул. Күңелендә Мөнирҗанына булган тугрылык саклanса да, тәне белән хәләл иренә икенче тапкыр хыянәт итте. Юк, итмәде, иттерделәр. Моны, бәлки, кеше белми дә калыр, ләкин адәм баласы өчен иң зур хөкемдар—ул үзе. Мөнирҗан күзенә күренерлеге калмады лабаса!

Тәрәзә артында җил, ә ферма өендә, сәкегә капланып, Гайния үкси. Ничек соң тормышта гел ана гына аркылы килеп тора? Язмышымы, әллә соң берәрсенең каргышымы? Каргышы дияр идең, кемдер каргарлык нинди гөнаһы, кырын эше бар? Намусы, чык бөртегедәй, саф бит. Бәлки бу бәхетсезлекләренең сәбәбе—аның матурлыгындадыр? Ходайдан матурлык түгел, бәхет сорарга кирәк, дигәннәр бит өлкәннәр.

Елап арыгач, күңеле тынычланмасмы дип сыерлар янына чыгып керде. Акмаңгай ятып тора иде. Бәлки бүген бозауламас та.

Янә ферма өенә кайтты. Мичкә салам ягып җибәрде. Өй эче бер яктырып алды да элекке хәленә кайтты. Мичкә ыргытылган салам, яшьлек сыман, шулай бер генә мизгелгә ялтырап ала икән.

Гайния сәкегә утырды. Сәке такталары, аны Хәсьянов көчләгәндәге кебек, шыгырдап, ыңгырашып куйды. Гайния центнердан артык гәүдәле адәм астында калып изелгән күкрәкләренең, тәненең әрнүенә түзә алмады. Тәне авыртуы бер хәл, аның җаныннан кан саркый иде. Ул хәзер аңлады һәм катгый карарга килеп өлгерде: юк, бу хурлыкны җаны күтәрә, ул үзен гафу итә алмаячак!

Билгеле бер карарга килгәннән соң, Гайния өй бетереп бау эзләде. Морҗа арасыннан кыскарак кына берне тапкан иде, черек булып чыкты—тартып карауга шартлап өзелде.

Бик тырышкан чагында ферма кадәр фермада бауны тапмый калмас иде. Тора-бара ул бу уеннан кире кайтты: якты дөньядан мордар китү зур гөнаһ булса, көчләнгән, мәсхәрәләнгән, пычратылган тән белән китү икеләтә гөнаһ булып тоелды. Ходай каршысына пакь көе барырга кирәк. Тәне дә җаны төсле чиста булсын.

Гайния ашыга-кабалана, гүя аны хәзер кемдер килеп тотып калыр, су буена табан атлый. Көчәя барган җил, аны җибәрмәскә тырышып, өстенә кигән бишмәте, башына бәйләгән шәле эченә керә. Көче җитмәгәнен белгәч, ялагай эт кебек, аякларына сарыла, ятып, эзләрен ялый.

Ферма мөдире булганнан соң гына да, аның бу сукмактан ничә тапкыр узганы бар. Терлекчеләр әлеге бәкегә ферма малларын көн дә су эчәргә алып төшә.

Гайния, бәке янына җиткәч, төнге тынлыкка колагын салып, бераз тыңлап торды. Буранның кызганыч шыңшуы бәкедәге су агышын юньләп ишеттерми дә. Эстәрле бу урында бик салмак ага шул. Ул йөз ел да, мең ел да шулай аккандыр. Ничек кенә акса да, аның бит ашыгыр җире юк.

Ахыр чиктә ул барыбер дингезгә барып җитәчәк.

—Хуш, Мөнирҗан! Әткәй, әнкәй, хушыгыз, бәхил булыгыз! Сезгә рәхәт күрсәтә алмадым, зинһар, яманлап телгә алмагыз!

Бу сүзләрне кычкырып әйттеме ул, юкмы, әллә күңеленнән генә кабатладымы, үзе аңламады. Хәер, ни аермасы бар—күңеленнән генә әйтсә дә, ул күкләргә барып ирешми калмас.

Белгәннәрен укып, тәне, җаны мәсхәрәләнгән хатын агымсуда юынды да үзенең гүзәл гәүдәсен караңгы бәке кочагына ыргытты. Караеп торган Эстәрле суы, эһ тә итмичә, корбанын йотты.

Бу дуамал адымнан Гайнияне туктатып кала алмаган җил, елый-елый, бәке авызына кар көртләре өяргә кереште; тырыша-тырыша бәке сукмагында калган эзләрне күмде. Ә үзенең җылы өендә яту белән йокыга киткән канәгать чырайлы Мидхәт Хәсьянов гырлый-гырлый таңны якынайта иде.

Икенче көнне Гайния күренмәүгә башта берәүнең дә исе китмәде. Гаптелихсан абзыйлар аны эштә дип уйлады. Чөнки төнлә белән кизү торган киленнәренең еш кына фермада калып, төш вакытлары җиткәндә генә җил-җил кайтып керүләренә гадәтләнгәннәр иде. Минсафа карчык киленнәрен бу юлы да ашын пешереп, самавырын кайнатып көтте.

Сыер савучылар, бозау караучыларның да эче пошмады. Берәү дә яманны уйламады. Ник дисәң, бердән, төнлә белән эшләгән кешенең көндез ял итүе гаҗәп түгел. Икенчедән, ферма мөдиренең кәнсәләрдә дә эше муеннан, бәлки шундадыр.

Самавырын өч кат шаулатып та, киленнәре кайтмагач, әүвәл Минсафа карчык чаң сукты. Чабата үреп утырган ирен борчымас өчен, Гайнияне эзләп, фермага китте. Тик, кызганыч, киленен бүген анда күрүче булмаган. Фермадагылар, йөгерә-атлап, Гайния керердәй җирләрне генә түгел, кермәстәй урыннарны да йөреп чыктылар. Күңеленә шом төшә башлаган кайнанай идарәгә дә сугылды. Әмма анда бүген аяк та басмавы мәгълүм булды.

Хәзер бердәнбер өмет—Хәниф кодалары калды. Әйтми-нитми генә ата-анасы янына хәл белергә барса да, Гайниянең бер дә озак торганы юк иде.

Бу хәбәрне ишетүгә, Хәнифләрнең куллары салынып төште. Йөрәк өянәге белән интеккән Тәзкирә карчык, башын тотып, сәкегә егылды.

Хәерсез хәбәр шул сәгатьтә бөтен авылга таралып өлгерде. Ни уйларга да белмәделәр. Күңеленә корт кергән, моның төнлә белән булган хәлгә бәйләнеше барлыгын сизенә башлаган Хәсьянов, тыныч калырга тырышып, бөтен җирне айкарга әмер бирде. Ферма тирәсен, силос базларын ничә кат ураганнардыр. Ул арада караңгы төште һәм эзләүне иртәнгә кадәр кичектереп торырга булдылар.

Икенче көнне төшкә кадәр эзләү дә нәтиҗә бирмәгәч, Хәсьяновның милициягә хәбәр итмичә чарасы калмады.

Махсус белеме булмаса да, эшли-эшли карт төлкегә әверелгән участковый Исхак эшне кешеләрдән сораштырудан башлады. Аннан соң бик җентекләп ферма өен карады. Ферманың фәкыйрь өендә ни булсын. Идәндә яткан черек бау өстенә басып түргә узды, игътибарын җәлеп итәрдәй берни дә тапмады дисәң, хата булыр—күзе сәке астындагы кәгазьгә төште. Бәлки җеп очы шушы кәгазьдәдер. Ләкин иртәрәк куанган икән. Кәгазь Мөнирҗан хаты булып чыкты: анда Гайниянең югалу сәбәбенә ишарә итәрдәй бер сүз дә юк иде. Шулай да Исхак хат ташучы Гөлданияне чакыртып сорады:

—Бу хатның кайчан килгәнен хәтерлисеңме?

—Хәтерләмәскә! Безнең авылга көн саен йөз хат килми. Гайниягә 31 декабрь көнне төштән соң үз кулларым белән тапшырдым.

—Һм-м...

Исхак хәзергә берни әйтә алмый. Килгәненнән бирле участковыйдан

бер адым да калмаган Хәсьянов исә йотардай булып ана текәлгән. Мидхәт сизенә: Гайния янына аның төнге визиты белән бу хатынның юкка чыгуы арасында бәйләнеш булырга тиеш. Тик ул шайтан хатын кая киткән? Сугыштан кайтканнан бирле куркуның ни икәнен оныткан ирнең күнелендә шом ялралды. Ул бөтен күңеле белән хәвеф барлыгын сизде һәм…Гайниянең табылмавын теләде.

Хатын бит ана үз ихтыяры белән бирелмәде. Әгәр дә берәр югарырак урынга, көчләде дип, Мидхәт өстеннән шикаять белән барса? Анардан котәргә була, чаялыгы житәрлек. Район белән генә чикләнсә, әлләни майтара алмас, әгәр дә Казанга яки Мәскәүгә сикерсә? Табипларга күренеп, документларын алса һәм судка бирсә?

Хәсьяновның күзләре Исхакка төбәлгән, ә үзенең башында өермә котыра. Берсеннән-берсе күңелсезрәк уйлар коточкыч тизлек белән ярала да, йөрәген тырнап, юкка да чыга.

Ул ферма өендә кылганына хәзер чын-чынлап үкенә иде. Үзе дә инде, көчләп ябышмаса, әйтерсең авылда, авылда булмаса районда колач җәеп торучы юмарт хатыннар беткән! Гайнияне дә әйтәсе юк, кайдан килгән гыйффәт иясе! Чатан Мисбахка яраганны, Хәсьяновтан кызгана. Ярар иде ире белән яшәгән чагы булса! Өтермәндәге иренә тугрылык саклый, имеш. Ахмак! Ә шулай да чибәр хатын, каһәр, ымсындыргыч, азмас жиреннән азарсың. Гайния табылган очракта да Мидхәт аның күзенә туры карый алмас иде.

Исхакның да уйлый-уйлый башы катты, ахры, кулын селтәп, аты-юлы белән сүгенеп куйды:

—Анагызны… Яна елда да кешегә бәйрәм итәргә ирек бирмисез!

Аның ни теләгәнен ярты сүздән аңлаган колхоз рәисе, участковыйны фатирга урнаштыргач, кич белән сугылырга вәгъдә биреп, көндәлек эшләренә ашыкты.

Исхак белән алар ярты төнгә кадәр утырдылар. Исерә төшкән участковый:

—Кызганыч, авыз итеп булмый калды…Чибәр хатын иде, авызын корт чаккыры,—дип сөйләнде.

Аның бу сүзләрен ишеткәннән соң, Мидхәтнең Исхак авызына берне менеп төшәсе килде. «Чү, тынычлан!» Йомарланган йодрыкның бармаклары кире язылды.

—Юк сүз сөйләп утырма әле. Син миңа шунысын әйт: тагын кайдан эзлибез?

—Минем уйлавымча, ул ире янына киткән булырга тиеш. Иртәгә үк анда запрос җибәрербез. Союз буенча да эзләтербез.

—Ә табылмаса?..

—Табылмаса, табылмаса... Иртәме, соңмы табылыр ул. Тере көеме, үле көеме дигәндәй...

Гайниянең гәүдәсен сабан туйлары узгач кына очраклы рәвештә Жәмил буасындагы куе камышлар арасыннан табып алдылар.

Ул көнне авылның яше-карты, бала-чагасына кадәр арык басарга буага жыйналган иде. Эстәрле болай карап торуга зур да, көчле ага торган да түгел. Ләкин яз көне яки көчле яңгырларда дулап-дулап ала. Яз саен авылның бердәнбер буасын ерып алып китми калганы юк. Ә буасыз ярамый, чөнки тегермән шунда корылган. Барлы-юклы ашлыгын, үз тегермәнендә тартмыйча, халык тагын кайда тартсын. Шуңа күрә ташулар кимеп, аяк асты сурка төшүгә, ел саен буада эш башлана: урманнан чыбык-чабык кайтарыла, таш, кызыл балчык ташыла. Инешнең ике ягыннан да буап килгәч, көннәрдән беркөнне су агардай тар ярык кына кала. Бу инде арык басар көн житте дигәнне аңлата.

Арык басу—авыл халкының күмәкләп башкара торган эшләренең берсе.

Бу көнне авылда булган һәркем диярлек буага ашыга. Эш кайный, өмә боткасы пешә. Бала-чаганың эшкә җәлеп ителмәгәне, арык басылып, су кимегәннән соң исәнгерәп калган балыкны җыя.

Кызыксынуын тыя алмаган малай-шалайның җитешмәгән җире юк. Гайнияне дә камыш арасыннан җикән өзәргә кергән ике малай күргән.

Ярты еллап элек югалган ферма мөдиренең табылуы көтелмәгән ыгы-зыгы тудырды, өмә халкының кәефенә кырау төште. Мәетне, арбага салып, районга озаттылар.

Язмышның миһербансызлыгын кара инде син: Гайнияне җирләгәннең икенче көнендә вакытыннан алда төрмәдән чыгарылган Мөнирҗан кайтып төште.

Хатынының эзсез югалуы һәм һаман да табылмавы хакында аңа хатта язганнар иде. Ләкин сөеклесенең юклыгына, бүтән беркайчан да булмаячагына аның һич кенә дә ышанасы килмәде. Мәете табылып, җәсәде гүргә индерелгәнен белгәч, ышанмыйча чарасы калмады.

Мөнирҗан өчен Гайния кояш иде. Төрмәнең шыксыз казармаларында да нур биреп, җылытып яшәтте ул аны. Инде ул бу бәхетеннән дә мәхрүм. Дөньяга аваз салган һәр җан иясенең бәхеткә хакы бар. Адәм баласы бәхетле яшәр өчен, парлап яшәр өчен яратылган. Тик ни өчен язмыш аларга шулкадәр каныга соң? Ни өчен сынау өстенә сынау, михнәт өстенә михнәт биреп кенә тора? Граммлап, мыскаллап та түгел, йөге-йөге белән аудара. Гаделлекме бу?

Олы хәсрәте белән япа-ялгыз калган Мөнирҗан гомерендә беренче тапкыр сугыштан исән кайтканына үкенеп куйды. Керфек очларына эләгеп калган яшь бөртекләре күзен томалады. Яу кырында батырларча үлеп калган булса, ата-анасы, туганнары аның өчен оялмас, ә үзенә рәнҗү-кимсетелүләр күрергә туры килмәс иде. Йа Раббым, Мөнирҗан атлы бәндәңә сабырлыгыңны кызганма!

Мөнирҗан авылга төш вакытларында кайткан иде. Ата-анасы белән күрешеп, хәл-әхвәл сорашкач, беренче эше итеп зиратка юнәлде. Яңа каберне эзләп табуы кыен булмады. Кабер өсте пөхтәләп өелгән һәм кәс белән капланган, зиярат иясенең кемнеке икәне язылган такта да куелган.

Яңарак каберләр тагын бар. Мөнирҗан Гайниянекенә якынракларына күз салды: алары сугыштан авыр яраланып кайткан, яшьләре буенча аңардан чак кына өлкәнрәк Газизулла белән Түбән оч Шакирҗанныкы иде.

«Озакка сузмыйча, каберенә яздырып таш куярга кирәк»,—дип уйлады Мөнирҗан. Каберен тәртиптә тоту яраткан хатынына күрсәткән соңгы хөрмәт булыр. «Их, Гайния, никләр китәргә ашыктың, үлемеңә ни сәбәпче булды?»

Бу соравын ул үз-үзенә дә, бүтәннәргә дә кат-кат бирде, тик җавап кына табалмады. Сер Гайния белән бергә суларга аккан һәм Әскәйнең ике йөз еллык тарихлы зиратына күмелгән иде.

—Бәхил бул, Гайния...Сиңа китергән җәфаларым өчен кичер!—Ул бу сүзләрне күзләрен каплаган яшь элпәләрен сөртә-сөртә пышылдады.—Ахирәттә кавышырга язсын!

Кич белән Мөнирҗан Гайниянең ата-анасы янына китте. Ничек кенә булмасын, ул бит аларның кияве. Бабасы Хәниф тә, әбисе Тәзкирә дә кияүләрен якты чырай белән каршы алды.

—Нихәл, кияү, әлхәмделиллаһ шөкер, исән-сау гына кайткансың икән!

—И бабай, мин кайту беләнмени, Гайния булмагач...

—Әйтмә дә инде, кияү, җылый-җылый, күзләрнең нуры бетте. Ни эшләргә дә белмәдек. Карчык саташа башлаган иде, өшкертә торгач терелде тагын, Ходаның хикмәте. Башлар катты инде, башлар катты, ни эшләргә дә белгән юк.

Ирләр сөйләшкән арада, жырлап торган самавыр өстәл түренә менеп утырды. Әңгәмә табын янында дәвам итте. Ләкин карт та, карчык та Мөниржанның ничек утыруы, төрмә турында төпченеп жанын ашамады. Мөниржанның шуңа күңеле булды.

Гайния үлеменең сәбәбен әти-әниләре дә белми иде.

—Кем белгән инде, кияү. Эчләрендә утлар янгандыр. Бер сәбәпсезгә мордар китмәс. Яшь-яшь көенә салкын гүрләрдә ята бит балакаем!—дип өзгәләнде ана кеше.

Табын янында озак утырды алар. Тегесе, монысы турында күп сөйләштеләр. Ләкин нәрсә турында гына гәп куертмасыннар, жеп очы һаман да Гайниягә әйләнеп кайта иде.

Сагынып кайтса да, бу кайтуында Мөниржанга авылда озак юанырга туры килмәде.

Гайниянең каберенә таш куйганнан соң бер ай, ай ярымнар вакыт үтеп китте. Печән хәзерләвен искә алмаганда, Мөниржан көнен юкны бушка аударып уздырды. Колхоз эшенә дәрте суынган иде, бригадир бер-ике тапкыр эшкә әйтеп караса да, чыкмады. Мыек чылатырга жай килгәндә, баш тартмады. Ул күңелендәге бушлыкны, бер-бер артлы үзенә килгән бәла-хәсрәтләрне жиңәрлек көч тапмады.

Авылда эшнең бетәсе юк. Жәй көнендә—бигрәк тә. Бәрәңгенне утыртып, күмәргә өлгермисең, печән чоры житә. Аннан уракка төшәләр. Урак төгәлләнә алмый кала, көзге мәшәкатьләр башлана.

Мөниржан Бабеч-Каран тугаенда атна буена печән чапты. Печән уңган иде, яратып, күңелен биреп эшләде. Комачаулаучы да юк. Күмер шахтасыннан соң туган якның шифалы һавасы күңеленә сары май булып ятты. Өйдән алып килгән бер шешә сөт белән ашалган ипидән соң чишмә суы эчеп алсаң!.. Моның чын тәмен озак вакытлар туган ягыннан аерылып торган кеше генә белсә белер.

Печәнне чабу гына түгел, киптереп алып та кайтасы бар. Алланың рәхмәте белән көннәр коры торды. Бүген чапканын ике көннән соң жыярлык булды. Мөниржан Гаптелихсан картны борчып тормады, барысын да үзе башкарды. Ниһаять, өстәмә мәшәкатьләрсез генә бар чапканы чүмәләләргә салынды. Хәзер инде янгыр яуса да курыкмаска була.

Ләкин икмәкнең бурага салынганын, печәннең алып кайтып тезмәгә өелгәнен хуп күрә халык. Ялandагысы әле ул синеке дигән сүз түгел. Тир түгеп чапкан печәненне, авыз ачыбрак йөрсәң, берәр озын куллысы шудыртырга да күп сорамас.

Алып кайту өчен ат кирәк. Ә ат—ат караучылар кулында. Калганнары бүленеп беткән, колхоз эшенә дә житкерә алмый иза чигәләр.

Мөниржан беренче бригаданың ат караучысы Шәрәфи янына барып, гозерен аңлатты:

—Бабеч-Караннан печәнне алып кайтасы иде бит...

Шәрәфи Мөниржанның үзе ат караган чагында күрсәткән игелекләрен онытмаган икән, ялындырып-нитеп тормады:

—Кайтарабыз аны. Тик төшкә кадәр вакыт юк. Жыеп куй.

—Жыелган.

—Кемнәр белән барабыз?

—Кемнәр дип... Әтине алсак кына инде... Өстә торырга.

Шәрәфи бу вариантны шунда ук кире какты:

—Олы кешене интектереп йөртмик. Мин булышчым Кәримгә әйтермен дә ике ат белән бер генә юлларбыз.

Егетләр көн саен йөк төяп шомарган, үз эшләренең осталары иде, печәнне тиз тоттылар.

Бар чапкан кадәрлесенең әйбәт көе тезмәгә менеп кунаклавы Мөниржан

өчен дә, аның ата-анасы өчен дә зур куаныч иде. Мөнирҗан ат караучыларны өйгә чакырды. Ләкин тегеләре:

—Юк, кеше мәшәкатьләп тормыйбыз. Сыйларга бик теләсәң бер-ике телем ипи белән суган кыстыр да Кәлимулла бакчасына керик.

Кәлимулла бакчасы кибет янәшәсендә генә. Шуңа күрә кибеттән аракы алган ирләр еш кына шунда сугыла. Анда хәтта шомырт ботагына кигертеп куелган бер ике «дежур» стакан да була.

Шомырт күләгәсендә өч борынга бер шешәне озын-озакка сузмыйча гына бушатып, таралышырга торганда, титак-титак атлап, Мисбах килеп керде. Баш хисапчының өстенә кигән галифе чалбарының кесәсе кабарып тора иде.

—Егетләр, мине компаниягезгә аласызмы?

Анын тәкъдиме көтелмәгән булса да, каршы килмәделәр. Үз сые белән йөргән кешене кем борып җибәрсен инде. Кешенекен бушка эчкән чакта барысының да авызлары шапылдап тора. «На халяву и жид удавился» дип тикмәгә генә әйтмәгәннәрдер. Әллә син Мисбах көн дә сыйлар дип беләсенме. Сыйлар сиңа, тот капчыгыңны!..

Килә-килешкә Мисбах кесәсеннән шешә чыгарып утыртты. Ул инде шактый кызарга өлгергән, шуңа күрәдерме, туктаусыз сөйләнде:

—Мөнирҗанны күптәннән сыйлыйсым килеп йөргән иде. Үтеп барган җирдән тавышыннан таныдым. Туктале, мәйтәм, Мөнирҗан бит бу, кайгылы чагы, күнеле бушанмасмы, мәйтәм. Утырыйк әле, егетләр, төн безнеке!

Мисбах белән утырырга күнеле тартмаса да, егетләрдән яхшысынмады, ризалашты Мөнирҗан. Өстәвенә алданрак эчкәне дә тамагын кытыклап, котыртып тора иде.

Шешәне башлап, берне тотканнар иде, Шәрәфинең хатыны ашларына таракан булып төште:

—Әйдә, утырма, өйдә кырыкмаса кырык эшең тора, ә син монда эчеп ятасын!

Шәрәфи рәхмәт әйтеп кулларын кысты да сүзсез генә хатыны артыннан иярде. Анын артыннан озакламый Кәрим дә кузгалды.

—Егетләр, рәхмәт, гаепләмәсәгез, мин дә кузгалам. Тотып тормасаң, сыер саудырмый безнең. Өйдә бүтән кеше юк.

Их, егетләр, ташлап китмәскә, Мөнирҗан белән Мисбахның үзләрен генә калдырмаска иде бит сезгә!

Эчендәге корт котыра башласа да, әле тагын берне чәкештергәнче түзде Мөнирҗан. Ләкин шуннан соң сабыр канатлары сынды. Гайниянең шушы чатан дуңгызның үзен мәсхәрәләве хакында күз яшьләренә буылып сөйләгәне хәтерендә кабат җанланды. Алай гына да түгел, офыктагы кояш янәшәсендә Гайниянең рәнҗү-сагышлы йөзе күренгәндәй һәм ялварулы тавышы ишетелгәндәй булды:

—Үч ал, Мөнирҗан, болай гына калдырма. Үч ал шул аксак тәредән!

—Син, син, колхоз комыгы, ананны...—Мөнирҗан үзенә төрмәдән ияреп кайткан сүзләрне дә кыстырып, аты-юлы белән сүгенеп куйды.—Син... шушы бер ярты белән минем алда гаебеңне юам дип уйлыйсыңмы?—Исән кулы үзеннән-үзе Мисбахның изүенә үрелде.

—Ни сөйлисең, Мөнирҗан энем?!—Ул югалып калды, чөнки эшнең болайга әйләнәсен көтмәгән иде. Әйбәт кенә эчеп утырганда бит.

—Ни сөйлимме? Ярар, мин сөйләмәм. Гайнияне ни эшләткәнне бәлки син сөйләрсең? Әйт, ни эшләттең Гайнияне?

—Ни эшләтим, берни дә эшләтмәдем. Хисапчылыкка өйрәттем.

—Ә кем ана кул салды? Кем көчләде?

Мисбах коелып төште,бер мәлгә телдән калды. Ул бит бу хакта Мөнирҗан белми дип йөри иде.

—Хода шаһит, энем, көчләмәдем,—диде ул калтыранган тавыш белән.—

Әз генә дә карышмады. Әйдә, үлгән хатын өчен тавышланып утырмыйк. Дөньяда хатын-кыз бетмәгән. Ишеткәнең бардыр, тоз бетмәсә, кыз бетмәс, ди безнең татар. Дулап кына үткәнне кайтарып, үлгәнне терелтеп булмый. Ал стаканыңны кулыңа, тотып куйыйк, китсен үзенең юлына!

Мөниржан селте, кислотага әверелгән иде.

—Син кабахәтнең бар эчкәнен дә кире костырам әле мин! Гомер буена колхозны имдең.

Исән кулы белән Мисбахны үзенә тартып китереп, гарип кулының ташка әверелгән очы белән корбанының корсагына шундый итеп китереп бирде ки, тегесе бөгелеп төште. Ләкин бу әле баласы гына булган икән. Тагын бер сугуы белән Мөниржан аны җиргә аударды һәм ярсып типкәләргә кереште. Кызуы чигенә җитте. Аң төпкеленнән килгән Гайния тавышы аны котыртып торды:

“Минем намусым өчен үч ал шул хәшәрәттән! Үч ал!”

“Тынычлан, Гайния, тынычлан. Үтерәм мин аны!”

Кыймылдарга да куркып яткан Мисбахның яңагына Мөниржан эчелеп бетмәгән шешә белән селтәнде. Бәлки үтергән дә булыр иде, кизәнгән чакта кулы шомырт ботагына эләгеп, шешәсе ычкынып китте. Ярсуыннан күзе тонган адәм аны алып тормады, дошманына алагаем тагын бер тапкыр типте дә бакчадан чыгып китте.

Икенче көнне үк участковый Исхак Мөниржанны кулга алды. Бераздан суд булды. Судта Мөниржан акланып бер сүз дә әйтмәде. Әйтүдән ни файда: Гайниянең исемен телгә алып, дөресен сөйләсә, мәрхүмәнең рухын пычрату булыр иде. Яңак сөяге сынган булганга, авызына арматура тутырылган Мисбах сугышуның чын сәбәбен шулай ук яшерде. Дөресен әйтү аның файдасына да түгел иде. Язма рәвештә биргән күрсәтмәсендә барысын да Мөниржанның исерек булуына сылтады.

Бер тапкыр утырып чыккан кеше хөкем каршысына кабат килеп эләксә, судка эш җиңеләя. Исерек баштан кеше кыйнаган дип, Мөниржанны янә таш капчыкка тыктылар. Төрмәгә барырга бик атлыгып тормаса да, Мөниржан бу юлы үзен утырткаппарына артык хафаланмады. Бәхетенең чите кителгән, тормышының яме кимегән, җанына куркыныч рәвештә битарафлык иңә башлаган иде. Утыртсыннар әйдә. Аңа көнне кайда үткәрсә дә барыбер. Ә Мисбахны кыйнаганына тамчы да үкенми ул. Киресенчә, әгәр дә җәзасыз калдырса, үзен гафу итә алмас иде. Гайния исән чагында ук арт сабагын укытырга кирәк булгандыр ул аксак шайтанның. Әшәкелек тиешле җәзасын алырга тиеш. Хәтта төрмәнең язылмаган законнарында да бу шулай.

*Ахыры киләсе санда.*



Клара
Булатова

## ЯЗГЫ УЙЛАР, ЯҢА ШИГЫРЬЛӘР

***

Мөхәррәм ае азагы.
Март башы. Язлар керде.
Карлар ятса да, яз ае
Язлыгын итә инде.

Салкынын салкын таңнарда—
Җылыта көндезләре...
Ярларда яткан карларда
Югала кем эзләре?

Тамчылар тама башларлар,
Тамарлар бозлар тишеп.
Эреп югалмас тамгаңны
Саласы ничек итеп?

...Кышларны куа яңа яз,
Эзләрне юа җирдән.
Син, Шагыйрь, җырларыңны яз
Югалмас сүзләр белән!

Яз арты язлар килсен дә
Җанга нур салсын әле.
Шагыйрьлек икән шөгылең—
Җырларың калсын әле.

***

Һәрвакыттагыча бу җил йөри,
Җилбәзәк җил инде бу айда.
Такташ аны: «Нечкә билле җил» ди,
Белеп әйтә шагыйрь шулай да.

Нечкә билле җилме шушы көнне
Ияртеп китте үткән язларга?
Шул язларда икәү салган эзне
Хәзер кайдан эзләп табарга?

Ташу суларында акканмы ул?
Йә пар булып өскә күчкәнме?
Йә кәс булып җиргә ятканмы ул?
Йә җыр булып искә төшкәнме?

...Әнә шул эз искә төшергән җыр,
Авыр чирне куып-озатып
(Бу айлардан шундый тылсым бардыр),
Җан-күңелне куйды кузгатып.

Клара БУЛАТОВА—*шагыйрә, "Язлар алда", "Печән өсте", "Шушы яктан, шушы туфрактан без" һ.б. шигырь китаплары авторы. Әлмәттә яши.*

***

Авыл тулы яз сулышы аңкый,
Сәвәләйгә тыны ягыла.
Кул сузымы җирдә йолдыз балкый,
Аяк очка басып ал гына.

Юк, кирәкми! Алма!
Ала калсаң,
Урыныннан купкач аның да
Сүнүе бар.
Сүнгән йолдызларның
Яктысы да калмый, даны да.

***

Мартта дәррәү яз рухы килә,
Рәшәләрне зәңгәр, ал итә,
Тереклеккә тылсым көче белән
Җан иңдерә Умай Алиһә[1].

Төптән килгән сихри сүлләр белән
Агачларда бөре тулыша.
Өстән төшкән ак сихере белән
Кояш-Тәңре Җиргә булыша...

Шагыйрь җанында да шундый халәт
Җирнең астын, күкнең өсләрен—
Умай белән бергә иңләп-барлап,
Туплап йөри шигъри көчләрен.

Ак хыялы булган затлы җанга
Хас иткәндә шатлык табыла:
Мартта балкып килгән якты язда
Җырлар туа, җырлар языла.

Шагыйрь җанында да шундый халәт...

***

Аркылыга, буйга гизгән чакта
Күзләр сукыр килеш бу дөньяны,
Синнән башка һәм үземнән башка
Кем дә белми минем ни кылганны.

Ни кылганны, кайчан, ник кылганны
Белмәгәннәр түгел хөкемдар.
Һәм, гөнаһлы булсам, җәзаларга
Синең генә, Тәңрем, хакың бар!

***

Җан төбеннән сагыш никләр куба?
Йолкынган җан нигә юксына?
Ямансылау тик сагыштан булса,
Түзәр идем әле бусына.

[1] Төркиләрдә—үрчетүче алиһә.

Ямансылау, сагыш, юксынулар
Хас күренеш хисле йөрәккә.
Җан рәнҗетсә сүзләр—
әнә шулар
Кан саудыра аңа бигрәк тә.

Җәрәхәтең әрнеп, сулыгып торса,
Гомереӊ кисеп сулыш кысыла.
Рәнҗетүче үз Якының булса—
Түзеп булмый әнә шунысына.

***

Җәйрәп яткан дала аланының
Урталыгы тигез.
Кырларында
Яшел чирәм сарган тар канаулар,
Элек сулар тулып торган монда.

Алар янындагы сөзәк үрләр
Нинди дәверләрнең эзләредер,
Аны табып-танып белер кемнәр?
Тарих төпкелләре ниләр бирер?

Тын океаннан Дунай тамагына,
Иделбаш Чишмәгә Кырымнан
Колач җәйгән Алтын Урда иле
Ник югалган? Нидән кырылган?

Инде менә җиде гасырдан соң
Бабалардан калган урдабыз
Безнекеме? Үзебезнекеме?
Без кем булып җирдә торабыз?

Йә, кайсыгыз әйтә: бүген кем без?
Ни бәягә лаек шәхсебез?
Бармы хәзер дәүләтчеллегебез?
Без кем булып монда яшибез?

## Көтми ул

*Х. Т.га*

Казанда ул торган фатирда
Мәңгегә сүнде бит ут—инде
Казанга килсәм дә, ахырда
Ашыгыр урыным юк инде...

Ул көтмәс мине тын бакчада,
Йөзсә дә күкләрдә ак болыт.
Яңа җыр күтәреп барсам да,
Ул йөрмәс җилкенеп, ашкынып.

Чәчләрен тузгытып җил белән,
Язын да, көзен дә яланбаш.
Кайтышлый ук Аккош күленнән
Ул миңа чәчәкләр кайтармас.

Җыр булып ай нуры чорнаган
Күпердә, юк инде, көтми ул.
Көтми ул. Соңгардым,
Соңлаган
Сөюне татымый китте ул.

...Казанда ул торган бүлмәдә
Әкияткә чакырган ут инде
Мәңгегә, мәңгегә сүнгәнгә—
Ашыгыр урыным юк инде.

## Түземсезлек әйбәт юлдаш түгел

Вакыт нишләп бик тиз агыла соң?
Көн башланмас борын кич җиткән.
Кем капкасын барып шакырга соң,
Үз газизеӊ сөрсә ишектән?

Кич җиткәндә ялгыз калмас өчен
(Ялгыз башка яшәү авыр бит!)
Үзеңнеке суытмасын хисеӊ,
Үзеңнекен сакла, сабыр ит.

Дәүләт эчендәге дәүләттә дә
Төрле хәлләр була дөньяда...

Түземсезлек әйбәт юлдаш түгел
Ир–атка да, хатын–кызга да.

Ят капкага кагып яр булмассың,
Үз хәләлең сөрсә ишектән.
...Гомер нишләп бик тиз агыла соң?
Көн башланмас борын кич җиткән.

## Коткара алмый

Бу күңел гомер буена
Буйсынмады акылга,
Инде тагын ел буена
Әллә кая ашыга.

Инде аңым, җаным белән
Котылырга аңардан,
"Йа Шәкүр, йа Гафур!"—диеп,
Бер Ходайга ялварам.

Вә ләкин язга чыгуга
Ул тагын алгысына.
Күрәсең, Коткаручы да
Коткара алмый шуңа...

## Телисеңме?

Телисеңме иртән син басасы
Үләннәргә төшкән чык булам?
Җаның теләгәндә бар булам да
Теләмисең икән юк булам.

Телисеңме, юлларыңа чыгам,
Сиңа ияреп йөрер җил булам?
Син әйт кенә бары: мин буйсынам,
Колың булам, әллә кем булам.

Синең колак белән төнне тыңлыйм,
Телең белән көндә сөйләшәм.
Яшәү мәгънәләрен синчә уйлыйм—
Әгәр үзем шулай теләсәм...

## Мин сөям икән әле

Томырылып атылды да биек күгеннән
Янар йолдыз җиргә төшеп сүнде, сүрелде.
Җир дәшмәде, эндәшмәде. Йолдыз бүгеннән
Яктылыгын югалтты да—үлде, күмелде.

Томырылып атылды да күкрәк читләрен
Ватып чыкты минем сөю синең юлыңа.
Син дәшмәдең, эндәшмәдең, кабул итмәдең—
Тик сөюем исән әле, яши җырымда.



Равил
Сабыр

# АБАГА АЛМАСЫ АЧЫ БУЛА

(ИКЕ ПӘРДӘДӘ)

КАТНАШАЛАР:
Н а с ы й б у л л а—беренче күренешләрдә 86 яшьлек авыл карты.
А й б у л а т—яшь журналист.
Г ө л и я—Насыйбулланың хатыны.
Т а х а у—Насыйбулланың яшьтәше.
Л о к м а н—авыл советы рәисе.
Б о л ь ш о й   Т а т а р и н—ата карак, 40 яшьләрдә.
К о м а р и к—Большой Татаринның уң кулы, 25 яшьләрдә.
Н и з а м—сәяси тоткын.
Г е с т а п о ч ы
Н К В Д ч ы

## БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

### I күренеш

*2005 елның апреле. Насыйбулланың өе. Ялгыз карт өендә мөмкин булган чисталык һәм пөхтәлек хөкем сөрә. Өйдә кирәкле әйберләр генә, артык берни дә юк. 70нче елларда чыккан аклы-каралы «Рекорд» телевизорының экраны махсус җәймә белән каплап куелган. Насыйбулла өстәл янындарак идәннән чәшке ватыклары җыя.*

Н а с ы й б у л л а. Лаврентий! Әй, син, җүнсез, җүнсез! Кем ватты чәшкене, ә? Кем аны өстәлдән бәреп төшерде? Кая качтың, явыз?!

*Локман килеп керә.*

Л о к м а н. Исәнме, Насыйбулла абзый!

*Насыйбулла Локманны ишетми.*

Н а с ы й б у л л а. Кая качтың син, оятсыз, ә? Лаврентий, дим!

---

Равил САБЫР (1974)—*прозаик, драматург, публицист; Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы. Чаллыда яши.*

Л о к м а н. Ишетми инде бу, чукрак тәре! Насыйбулла абзый!

Н а с ы й б у л л а. Лаврентий!

*Локман авыр сулап резин итекләрен сала башлый.*

*Шулчак Насыйбулла борылып Локманны күреп ала.*

Н а с ы й б у л л а. Ә, Локман, синмени әле бу? Минәйтәм, каяндыр килә инде песинең тавышы. Өстәлдән чәшкене бәреп төшерде дә качты, ләгънәт.

Л о к м а н. Әйе, песи йөргәнен ишетәсеңдер инде әллә кая! *(Ике кул биреп күрешәләр.)*

Н а с ы й б у л л а. Нәрсә дисең?

Л о к м а н *(Насыйбулланың колагына кычкырып)*. Хәлләрең ничек, авырмыйсыңмы, дим?

Н а с ы й б у л л а. Не дождутись, дип әйткән ди бер җәбрәй.

Л о к м а н. Үләсе килми үзенең бер дә, панимаешь!

Н а с ы й б у л л а. Нәрсә дисең?

Л о к м а н *(тагын колагына иелеп)*. Синең хәлләр әйбәт булгач, без бик шат, дим. Син бит хәзер авылның иң знаменитый кешесе! Әнә Казаннар кызыксына башлаган үзең белән, панимаешь! Синең янга киләләр иртәгә. *(Тураеп басып һәм тавышын әкренәйтә төшеп.)* Тагын берничә ел паспорт алмый йөрсәң, әллә кайлардан килерләр иде әле.

Н а с ы й б у л л а *(курка калып)*. Кем килә?

Л о к м а н. «Идел таңнары» газетасыннан корреспондент килә.

Н а с ы й б у л л а. Ни кирәк аңа?

Л о к м а н. Син кирәк.

Н а с ы й б у л л а. Нигә?

Л о к м а н. Гәжиткә язарга инде, нигә булсын.

Н а с ы й б у л л а. Килмәсен дә, йөрмәсен дә! Кирәк түгел!

Л о к м а н. Сина бернәрсә дә кирәк түгел инде.

Н а с ы й б у л л а. Нәрсә дисең?

Л о к м а н *(колагына тагын да кычкырыбрак)*. Замглавы Лариса Миргазитовна ызванит итте. Иртәгә корреспондент килә сезгә, ди. Насыйбулла абзыйны да әзерләп куегыз, үзегез дә әйбәтләп әзерләнегез, диде.

Н а с ы й б у л л а. Ничек инде, Насыйбулла абзыйны әзерләп куегыз?

Л о к м а н. Кем белсен инде аныкын?! Артык сүз сөйләшмәгез, дип әйтүедер инде.

Н а с ы й б у л л а. Нинди артык сүз? Мин бернинди сүз дә белмим. Хәтер дә юк хәзер, колак та ишетми. Чәй эчәсеңме?

Л о к м а н. Әйдә, яса берне. *(Өстәл янына килеп утыра.)*

*Насыйбулла, Локманга чәй ясап биргәч, өстәлгә кечкенә куна куеп, шуның өстендә инде искергән, катып беткән арыш ипиен зур авырлык белән кисә башлый.*

Л о к м а н. Катып беткән бит инде ипиең! Моның белән кадак кагып була бит, панимаешь!

Н а с ы й б у л л а. Кая кадак кагасы бар, дисең?

Л о к м а н. Ипиең искергән, дим, ипиең! Көн саен кайта бит кибеткә ипи! Ник ысвижыен барып алмыйсың?

Н а с ы й б у л л а *(ачуланып)*. Сез генә ул ипине абзарыгыздагы чучкаларга ашатасыз! Мин, бик беләсең килсә, еллар буе хыялландым, шушы кара ипине туйганчы бер ашарга иде, дип!

Л о к м а н. Әй, ярар ла инде! Кәрүче, иртәгә, сәгать уникеләрдә, матур киемнәреңне киеп мәктәп сталаваена килерсең. Сыйлап та җибәрербез үзеңне шунда.

Н а с ы й б у л л а. Сыйлар-мыйлар кирәкми миңа! Беркая да бармыйм!

Л о к м а н. Шулай диясеңне белгән идем инде!

Н а с ы й б у л л а. Нәрсә дисең?

Л о к м а н. Глава кушты дим, ишетәсеңме? Глава! Хужа кушты! Әбизәтелни килергә кирәк! Корреспондент белән очрашу иртәгә, сәгать уникедә, мәктәп сталаваенда, яме?! (Ут сүнә.)

## II күренеш

*Шунда ук. Карт уйга батып тегендә-монда йөренә. Күзе тәрәзәгә төшкәч, ул җанланып китә: кадакларда эленеп торган киемнәре янына килеп кесәләреннән нидер эзли башлый. Локман белән Айбулат керәләр.*

Н а с ы й б у л л а. И-и-и, мин жыенганчы килеп тә җиттегез әллә? Ачкычым әллә кая киткән, ләгънәт, табалмыйм.

Л о к м а н *(борын төбенә).* Синме соң инде, ачкыч югалта торган кеше! *(Насыйбуллага күрешергә кулларын сузып.)* Исәнме, Насыйбулла абзый! Менә кунак алып килдем әле. Айбулат исемле егет бу. Казаннан, «Идел таңнары» гәҗитеннән сине күрергә дип килгән.

А й б у л а т. Исәнмесез!

*Карт икесе белән дә кул биреп күрешә.*

Н а с ы й б у л л а. Беләм мин аны.

Л о к м а н. Кемне? Айбулатнымы?!

Н а с ы й б у л л а. Әйе.

А й б у л а т *(аптырап).* Каян беләсез?

Н а с ы й б у л л а. Карт дигәч тә инде ул кадәр! Карт булсам да, грамытный мин! Гәҗитләр укыйбыз! *(Өстәлдән «Идел таңнарын» кулына алып.)* Әле менә соңгы санда гына тагын бер мәкаләң чыккан иде.

А й б у л а т. Ә-ә-ә!

Н а с ы й б у л л а *(Айбулатны үртәп).* Менә сиңа мә-ә-ә!

Л о к м а н. Без сине, панимешь, мәктәптә өстәлләр әзерләп көтеп утырабыз, ә син килергә җыенмагансың да, ахрысы?

Н а с ы й б у л л а. Җыенган идем җыенуын. Менә матур киемнәремне кидем, *(кул таягына ишарәләп)* таксины да әзерләп куйган идем. Ачкычымны табалмыйм, ләгънәт! Әллә кая гына киткән. Әллә песи апкиткән инде?

Л о к м а н *(имән бармагын селкеп).* Маташтырма!

А й б у л а т. Йә, ярый. Сөйләшеп алырга иде, Локман абый.

Л о к м а н. Ә без нишлибез?

А й б у л а т. Эш турында сөйләшергә иде дим.

Л о к м а н *(үпкәләбрәк).* Сөйләш соң, сине тыйган кеше юк бит.

А й б у л а т *(Насыйбулланың колагына иелә төшеп).* Бабай! Каршы килмәсәң, Җиңүнең алтмыш еллыгына синең турыда мәкалә язмакчы идек.

*Насыйбулла эндәшми.*

А й б у л а т *(сүзен нидән башларга белмичә).* Сиңа сиксән алты яшь бит, әйеме, Насыйбулла бабай?

Н а с ы й б у л л а. Әйе, тугызынчы дисәтекне тутырабыз инде тиздән.

А й б у л а т. Болай сәламәтлекләр ничек соң?

Н а с ы й б у л л а. Бер көннәрдә әйттем инде мин Локманга, ни даждутись, дип. Тахауга рәхмәт инде! Ул булмаса, әллә кайчан үлгән идем!

А й б у л а т. Кем соң ул Тахау?

Н а с ы й б у л л а. Карале, сез нигә бөтенегез дә минем колакка кычкырасыз?! Мин сезгә саңгырау түгел бит! *(Көлешәләр.)*

А й б у л а т *(Локманга).* Кем ул Тахау?

Л о к м а н. Күршесе.

А й б у л а т. Карыймыни бабайны?

Л о к м а н. Әйе, карап кына тора!

Н а с ы й б у л л а. Әйдәгез, утырып сөйләшик. Утырышыгыз, урын тапсагыз. *(Утырышалар.)* Сора, улым, ни сорыйсын килгән иде?

*Айбулат сумкасыннан блокнот белән каләм чыгарып нидер яза башлый. Язып бетергәч, блокнотны Насыйбуллага суза.*

А й б у л а т *(Локманга).* Сорауларны шулай язып бирсәң, яхшырак булыр. Алайса, чыннан да, кешенең колагына кычкыру мәзәк ничектер.

Л о к м а н. Менә монысын әйбәт уйлап таптың! Маладис!

Н а с ы й б у л л а *(блокнотта язылганны укып бетергәч, ашыкмый гына кызлеген пиджагының түш кесәсенә сала).* Әйе, шушы авылныкы мин. Шушында тудым, шушында үстем... (Озын пауза.)

*Тахау керә.*

Т а х а у. Исәннәрмесез!

А й б у л а т. Исәнмесез.

Л о к м а н. Сәлам, Тахау абзый!

А й б у л а т. Ә-ә-ә, сез буласызмыни инде Тахау?

Т а х а у *(курка калып).* Нәрсә?! Мина ни булган?

А й б у л а т. Юк, берни дә бул...

Н а с ы й б у л л а *(Айбулатны бүлдереп).* Әллә йөрәк түзмәде, Тахау?

Т а х а у. Менә кергән идем әле хәлләреңне белергә.

Н а с ы й б у л л а. Соң кичә утынны мин яткач кына сүндерден бит! Шуннан соң әллә ни үзгәреш булганы юк әле.

Т а х а у. Менә кунак егете бар икән.

Н а с ы й б у л л а. Карале, Айбулат! Менә Тахаудан гына сораштыр син минем турыда! Ул минем үземә караганда да күбрәк белә!

Т а х а у *(Айбулатка)*. Гафу итегез, сез нинди оешмадан буласыз?

А й б у л а т. «Идел таннары» газетасыннан.

Т а х а у. Алай икә-ә-ән... Ярар, чыгыйм әле мин! *(Ишеккә таба китә.)*

Н а с ы й б у л л а. Бар, бар! Житешәсең әле! Почта машинасы ике сәгатьтән генә килә.

*Тахау чыгып китә. Айбулат Локманга сораулы караш ташлый.*

Л о к м а н. Аптырама! Алар икесе шулай үзләре генә аңлаган телдә сөйләшеп йөриләр инде!

*Айбулат тагын блокнотка сорау язып бирә.*

Н а с ы й б у л л а *(күзлеген киеп блокнотта язылганны укып бетергәч, тагын күзлеген пиджагының түш кесәсенә сала)*. Армиягә кадәр калхузда эшләдем. Бухалтир пумушнигы идем. Кырыгынчы елны армиягә алдылар. Сугыш башлангач, фронтка җибәрделәр.

*Айбулат тагын ни әйтәсен дигәндәй карап тора да, бабай эндәшмәгәч,тагын сорау яза башлый.*

Л о к м а н. Армиягә китмәгән ул, кулга алганнар аны. Өйләнгәнен дә әйтмәде әле бу.

Н а с ы й б у л л а *(блокнотта язылганны укыгач, тагын күзлеген пиджагының түш кесәсенә сала)*. Нинди сугышларда катнаштыммы? Сталинградны алып калдык без, улым!

А й б у л а т *(язганда ишетелер-ишетелмәс кенә итеп Локманга)*. Пленга эләгүен сорап карыйм әле, сөйләр микән?

Л о к м а н. Ай-һай! Бик сирәк кенә, кәефе килгәндә генә сөйли ул аны! Аны сында да, һәрвакыт яңача сөйли.

Н а с ы й б у л л а *(сорауны һаман шулай озаклап укып һәм күзлеген пиджак кесәсенә салып)*. Плинга мин Курски өчен сугышканда эләктем. Сталинградтан соң шунда җибәргәннәр иде. Командир бомбардировка вакытында үлде дә, кайсыбыз кайсы якка таралышып беттек инде шунда. Аннан соң немесләр берәмләп чүпләделәр безне.

*Айбулат тагын сорау яза.*

Л о к м а н. Әйттем бит яңача сөйли дип! Мина яраланып эләктем, дигән иде, атышып ятканда патроннар бетте, дип тә сөйләгән инде ул.

Н а с ы й б у л л а *(һаман шулай озаклап сөйләп маташа)*. Гирманиядә мин булмаган канцлагир калмады, улым! Алар анда сугышка алдан әзерләнеп ятканнар инде! Кәлүчий прувылкы белән әйләндереп алганнар, мин сина әйтим! Биеклеге сиялкы тәгәрмәче хәтле! Үзе шундый еш, тыгыз! Аннан кеше түгел, чыпчык та чыгып кача алмый! Ашау начар иде. Хәзер Локман чучкаларын да алай ашатмый.

*Көлешеп куялар. Айбулат тагын сорау яза.*

Л о к м а н. Каныкты инде шул минем дуңгызларга! Мин бит аларны ашарга дип асрамыйм, сатуга! Безнең ике тәңкә зарплатага яшәп булмый бит инде.

Н а с ы й б у л л а *(һаман шулай озак сузып)*. Плиннан үзебезнекеләр коткарды кырык биштә. Аннан авылга кайттым да инде, яшәп ятам менә.

Л о к м а н. Ничәнче елны кайттың, дип тагын бер сорале, Айбулат.

*Айбулат тагын сорау яза башлый.*

Н а с ы й б у л л а *(һаман шулай озак сузып)*. Юк, берни дә бутамыйм, кырык биштә кайттым.

Л о к м а н. Җүри маташтыра!

А й б у л а т. Башлары бутала башлагандыр инде, сиксән алты яшьтә бит!

Л о к м а н. Җүри маташтырырга да мужыт ул! Вәт карт төлке! ГУЛАГ турында сөйлисе килми!

А й б у л а т. Юктыр, Локман абый!

Л о к м а н. Американнар азат иткән булырга тиеш аны.

А й б у л а т. Илле өчтә кайткан, дидең бит әле, әйеме?

Л о к м а н. Әйе.

*Айбулат тагын сорау яза башлый.*

Н а с ы й б у л л а *(һаман шулай озак маташып).* Пинсе алам мин! Аны бит хәзер атна саен арттырып торалар! Житә, Аллага шөкер.

А й б у л а т *(Локманга борылып).* Чынлап әйтәме ул?

Л о к м а н. Чынлап! Калхузда эшләгән өчен пенсия ала ул! Аның сугыш ветераны буларак пенсиясе юк.

*Айбулат тагын сорау яза.*

Н а с ы й б у л л а *(һаман шулай озак маташып).* Сайлауның берсен дә калдырган юк! Һәрберсенә барам. Минә Путин сайлауларында да катнашып кайттым әле.

*Айбулат борылып Локманга сораулы караш ташлый.*

Л о к м а н. Йөри, йөри ул сайлауларга!

А й б у л а т *(аптырап).* Ничек паспортсыз тавыш бирә соң ул?

Л о к м а н. Әй, авылда сайлау өчен паспорт кирәкми инде!

А й б у л а т. Карагыз әле, ә сез ничек алай Насыйбулла бабайның паспортсыз яшәвен белмәдегез соң?

Л о к м а н. Үзең күреп торасың, ул бит настоящий партизан! Бер сүз дә каерып алып булмый аннан! Үзе не обращался, панимаешь...

А й б у л а т. Не обращался дип, сез миллион төрле документ төзисез бит! Яртысына кешенең паспорт саны кирәк.

Л о к м а н. Әйе шул.

А й б у л а т. Соң шулай булгач, ничек паспорты юк икәнен белмәдегез?

Л о к м а н *(озын паузадан соң).* Яна гына эшли башладым әле мин. Авыл советы рәисе итеп куйгач, бөтен ветераннарны йөреп чыккан идем. Шулчакта Насыйбулла абзый белән дә озак кына сөйләшеп утырдык. Дөрес, ул миңа паспорты юклыгын әйтмәде, ләкин пенсияне калхузда эшләгән өчен генә алганын чамаладым. Бик бәләкәй пенсия ала ул. Күпме үгетләдем шул чакта, районга барып кайтыйк, вәеннәй пенсия ясарбыз, дип! Бармады. Йортны ташлап китәлмыйм, диде. Пенсионерларның шул бит инде ул! Минә күрше урамда сугышта катнашкан бер әби яши. Артиллеристка булган. Пенсияне дә яхшы гына ала. Ә ВТЭКка барып инвалидлык оформлять итсә, тагын да күбрәк алыр иде! Әле өченче көн генә тагын бер кереп чыктым. Юк инде, бармый Казанга! Үрдәк бәбкәләрем чыгасы бар, ди. Нишләтәсең инде аны?!

А й б у л а т. Ә ахыр чиктә ничек беленде соң инде паспорты юк икәне?

Л о к м а н. Лариса Мирзагитовна ни диде соң?

А й б у л а т. Глава авылларга чыгып прием үткәрде дә, шунда Насыйбулла абзый үзе килеп паспорты юк икәнен әйтте, диде. Ике-өч көн эчендә ясап, торжественно вручили, диде.

Л о к м а н. Әйе, шулай булды инде...

А й б у л а т. Хәтер китабы турында сорап караганыгыз юкмы?

Л о к м а н. Сөйләми ул берни дә!

А й б у л а т. Бәлки, сорый белмисездер?

Л о к м а н. Тагын ничек итеп сорыйсың инде аннан?! Мәктәптә Жиңүнең 60 еллыгына альбом әзерләделәр. Башта Насыйбулла бабай янына бала-чага жибәреп карадылар, аннан укытучылар үзләре барды! Алар да буш кул белән кайткач, күчтәнәчләр кыстырып үзем киттем. Чукрак та бит әле ул өстәвенә! Бер нәрсә турында сорыйсың, икенчесе турында сөйләп китә. Бер үк әйберне әйләндереп-тулгандырып, йөзгә төрләндереп сөйли житмәсә... Фотосын да бирмәде хәтта! Юк, ди.

А й б у л а т. Димәк, сез шулай да аның язмышын өйрәнергә тырышып карадыгыз?

Л о к м а н. Карамаган кая ди инде ул!

А й б у л а т. Алайса, әйтегез әле, нишләп Хәтер китабының хәтта ки ике урынында ул үлгән дип язылган икән? Бу ялгышлыкка берәр нинди ачыклык кертә алмадыгызмы?

Л о к м а н. Хәтер китабы кайткач, силсәвиткә чакыртып мин аңа үзе турында язылган юлларны күрсәткән идем.

А й б у л а т. Нәрсә диде?

Л о к м а н. Берни дә әйтмәде! Укы-

гач, борылды да чыкты да китте.

А й б у л а т *(сумкасыннан Хәтер китабын тартып чыгарып актара башлый).* Кая әле ул? Ә, менә! *(Укый.)* Галиуллин Насыйбулла. Уроженец села Калабаш. Мобилизован Красноборским райвоенкоматом. Погиб 21 июля 1943 года. Похоронен в деревне Большая Карповка Советского района Курской области. Каяле икенчесе? Менә! Галиуллин Насыйбулла. Туу елы 1918 дип куелган да, җәя эчендә 1922 дип язылган һәм сорау куелган. Туу урыны Тугзый авылы диелгән монысында. Мобилизован Красноборским райвоенкоматом. Погиб в 1943 году в плену, диелгән. Болар икесе ике кеше түгел микән соң?

Л о к м а н. Юк, бу язмалар икесе дә безнең Насыйбулла карт турында. Без белешеп карадык, Калабашта андый кеше булмаган. Ә Тугзыйга кырык өченче елда чыннан да похоронка килгән булган. Монысын карчыклар сөйләде. Анасы бик нык кайгырды Насыйбулланың, диләр. Нәкъ шул чакта бер оныгы туган булган. Улымның исеме чит җирләрдә аунап ятмасын, дип, шул оныгына Насыйбулла дип исем куштырган. Ул кече Насыйбулла күптән үлгән инде. Ә үлгән дип хәбәре килгәне исән менә.

А й б у л а т. Ник соң шушылар турында язмадыгыз альбомыгызга?

Л о к м а н. Монын нәрсәсен язасың инде?

А й б у л а т. М-м-да...

Л о к м а н. ...Җиңүгә багышланган альбомга Насыйбулла карт турында бер сүз дә кертмәгәннәр, дип, Лариса Мирзагитовнага сөйләмәгез инде.

А й б у л а т. Чукындыгыз инде шул Лариса Мирзагитовнагыз белән! Әйтмәсәм дә булмады!

Л о к м а н. Чукындыртыр да әле ул безне, бигайбиль әстәгъфирулла!

А й б у л а т *(бераз уйланып утырганнан соң).* Өченче көн телевизордан Степан Ковальчук дигән бер украин турында күрсәттеләр. Немецләр боларның авылын басып алгач, яшьләрне көтүе белән җыеп Германиягә озата башлыйлар. Степанны апасы мунча түбәсенә яшереп кала. Шул бер качканнан бүтән якты дөньяга чыкмый инде бу мескен. Энесенең сере ачылыр, дип, апасы кияүгә дә бармый, гомер буе моны карый. Менә шушы көннәрдә апасы да үлгән. Карар кеше калмаган моны. Кая барсын, чыккан инде! Алтмыш өч ел мунча түбәсендә берьялгызы яшәгән! Үзен үзе төрмәгә ябып куйган кебек бит инде бу!.. Насыйбулла бабай да миңа шул Степан кебек. Тик ул мунча түбәсенә түгел, үз эченә бикләнгән. Хәер, әллә ни аермасы юк инде...

*Айбулат Насыйбуллага карап куя, бабайның бер кылы да селкенми.*

*Айбулат тагын сорау яза.*

Н а с ы й б у л л а *(сорауны укыганда).* Улым, бусы ни дигән сүз? *(Айбулат үз язуын укырга үрелә, бабай аның колагына нидер пышылдый. Аннан соң Локман да ишетерлек итеп.)* Ә-ә-ә! Аңладым! Бер хәрефен танымый торам икән!

Л о к м а н *(Айбулатка).* Карале, нәрсә әйтте ул сиңа?

А й б у л а т *(яза-яза).* Әллә тагын, аңламый калдым!

Н а с ы й б у л л а *(һаман шулай озак маташып).* Нигә артыннан йөрмәдең, дип... Нигә кирәк соң ул миңа паспорт? Әнә Локман китереп биргән иде, ята инде хәзер.

*Айбулат тагын сорау язып бирә.*

Л о к м а н. Чыннан да кирәкми инде ана ул паспорт! Авыл җирендә инде, панимешь...

Н а с ы й б у л л а *(һаман шулай озак маташып).* Юк, асрамыйм бернәрсә дә! Дүрт аяклы хайваннардан өйдә песи бар да, ике аяклыларыннан үзем генә. Хатын булса, асрар идем. Берүзем генә булгач, кирәкмәс. Пинсем ашарга җитә, Аллага шөкер. Күп кирәкми бит миңа.

Л о к м а н. Өйләнеп караган иде дә ул, хатынының оныклары кайта җәй көне. Ул бит берүзе генә һәрнәрсәне саклап кына яшәргә өйрәнгән. Бала-чагага тегесе дә кирәк, монысы да. Кызгана бабай байлыкларын! Хатыны, саранлана, диде, яратмады. Аерылыштылар.

*Айбулат тагын нидер язып бирә.*

А й б у л а т. «Әйдә, мәктәпкә сыйланырга киттек», дип яздым әле.

Л о к м а н. Ә-ә-ә!

Н а с ы й б у л л а. Әйдәгез соң. Ашау дигәндә—аяк иләндә!

*Җыенышып чыга башлыйлар.*

Л о к м а н *(Насыйбуллага).* Ачкычны югалттым диган идең бит әле син?!

Н а с ы й б у л л а. Таптым инде мин аны! Пинҗәк кесәсендә булган икән!

Л о к м а н. Вәт карт төлке!

*Чыгып китәләр.*

## III күренеш

*Шунда ук. Төн. Насыйбулла инде йокларга яткан. Әкрен генә тәрәзә шакыйлар. Карт торып тәрәзә янына килә.*

Н а с ы й б у л л а. Айбулат улым, синме бу?

А й б у л а т. Мин, Насыйбулла бабай!

Н а с ы й б у л л а. Хәзер ишекне ачам.

*Насыйбулла торып утны яндыра, ишекне ача. Айбулат керә.*

А й б у л а т. Исәнме, Насыйбулла бабай.

Н а с ы й б у л л а. Исән, улым, исән. Кер әйдә, чишен. *(Стенадагы кадакларда эленеп торган киемнәренә ишарәләп.)* Менә монда эл киемнәреңне. Хәзер чәй эчәрбез. Самавырым кайнар. Туңгансыңдыр төнлә юлда йөреп.

А й б у л а т. Юк, туңмадым. Машинада бит мин.

Н а с ы й б у л л а. Кая соң синең машинаң?

А й б у л а т. Ә мин аны авылга кергәч беренче тыкрыкка куеп калдырдым.

Н а с ы й б у л л а. Яшьләр шаярып тимәсен тагын.

А й б у л а т. Шаярып булмый аның белән, Насыйбулла бабай, сигнализациядә ул. Әз генә тиеп китсәң дә, чучка суйгандагы кебек акыра.

Н а с ы й б у л л а *(чәй әзерләп).* Ярар алайса, утыр әйдә чәй эчәргә. Тапкыр малай булып чыктың әле син, Айбулат улым! Таз икәнсен! Синең белән разведкага барырга була! Син язганны аңламый тордым баштарак! *(Кесәсеннән кәгазь чыгарып.)* Каяле, ни дип язгансың әле? *(Укый.)* «Чукрак картны бик оста уйныйсын, бабай! Мин дә ышана яздым».

А й б у л а т *(көлеп).* Чынлап та ышана яздым шул!

Н а с ы й б у л л а. Карале, ә син минем чукрак түгел икәнне каян сиздең?

А й б у л а т. Соң үзең әйттең бит!

Н а с ы й б у л л а. Кайчан?!

А й б у л а т. Бүген! Бөтенегез дә колакка кычкырмагыз, мин сезгә саңгырау түгел, дидең.

Н а с ы й б у л л а. Шуннан абайладыңмыни?

А й б у л а т. Әйе! Күз карашыңнан да сизендем инде. Аннан соң... Мин аны аңлата да алмыйм... Бавырымның бер чите белән сизеп алдым, димме? Теге мунча түбәсендә качып яткан дезертир турында сөйләгәндә артыграк та уйнап җибәрдең инде. Шул мәхлүк белән чагыштыруым күңеленә тигәне әллә каян сизелеп тора иде! Ә үзең һаман тырыша-тырыша чукрак карт булып кыланасың.

Н а с ы й б у л л а. Улым, мин сиңа менә хәзер үз тормышымны сөйләп бирмәкче булам... Шунда аңларсың, нигә мине ул дезертир белән бер рәткә куярга ярамаганын...

А й б у л а т. Насыйбулла бабай! Син нәрсә?! Әллә үпкәләдеңме?! Мин бит шаярып кына әйттем! Сине сынап карар өчен генә! Синең чукрак түгел икәненә инанасым килгән иде...

*Насыйбулла эндәшми.*

А й б у л а т. Шулай эшләмәгән булсам, мөгаен, син минем колакка: «Төнлә, кеше күрмәгәндә генә кил син миңа, улым»,—дип пышылдамас та идең!

Н а с ы й б у л л а. Локман нилайдныйны сизде бугай анда?! Ни әйтте ул сиңа, дип сорады бит. Ну, син дә таз малай! Әллә тагын, аңламый калдым, диган буласың.

А й б у л а т. Карале, Насыйбулла бабай! Ә нигә син Локман абзый барында сөйләшергә теләмәдең?

Насыйбулла. Ашыкма, улым, сабыр бул. Хәзер анларсың нигә икәнен.

Айбулат. Нәрсә, башлыйбызмы соң инде сөйләшүне?

Насыйбулла. Син гел следователь кебек әйтеп куйдың әле!

Айбулат. Юк ла инде! Следователь бит ул кешене утыртып кую турында уйлый, ә минем аңлыйсым килә.

Насыйбулла. Үзенне дә күрсәтәсен килә инде, әйеме, Айбулат?

Айбулат. Анламадым.

Насыйбулла. Аңлады-ы-ың!!! Синең бөтен язганнарыңда, карагыз Айбулат нинди кыю, башбирмәс, акыллы һәм зирәк, дигән уй ярылып ята. Күлне күккә элеп куйгансың да, унга-сулга карап та тормыйча болгыйсың шашканны! Шулай итеп абаганы чәчәк аттырмакчы буласың. Яшь шул әле син, бик күп нәрсәне белмисең...

Айбулат *(үпкәләбрәк)*. Нәрсәне инде ул, мәсәлән?

Насыйбулла. Абага алмасы, улым,... ачы була ул...

Айбулат. Ничек диден, Насыйбулла бабай? Абага алмасы ачы була? Абага чәчәк тә атмый бит ул, бары әкияттә, хыялда гына күреп була аның чәчәген. Алмасы каян чыга соң аның? Һәм нигә ул ачы?

Насыйбулла. Менә шуны аңлатырга чакырдым да инде мин сине, улым. Шулхәтле гыйбрәтле сабакны кешегә сөйләмичә үзең белән алып китсәң, гөнаһ булыр.

## IV күренеш

*1940 елның яз башы. Төн. Насыйбуллаларның капка төбе. Куышлы уйный-уйный Насыйбулла белән Гөлия килеп керәләр. Насыйбулла ярлы киенгән, Гөлия—хәллерәк. Куыша торгач, Насыйбулла Гөлияне тота.*

Гөлия. Жибәр, хәерсез!

Насыйбулла. Жибәрмим, качасың!

Гөлия. Качмыйм мин.

Насыйбулла. Ә нигә йөгерәсең?

Гөлия. Өйгә ашыгам.

Насыйбулла. Анда кайтып нишлисең төнлә белән?

Гөлия. Әйтимме соң?

Насыйбулла. Әйт, Гөлия!

Гөлия. Йөгереп кайтам да, тизтиз генә киемнәремне салып ыргытып, юрган астына кереп качам! Мендәрне кочаклыйм да, аннан соң... бәхетемнән үләм!

Насыйбулла. Нәрсә-ә-ә-ә?!

Гөлия. Ниһаять, миңа игътибар иттең бит, сукыр!

Насыйбулла. Ә-һә! Каптыңмы, кызый! Әйтәм аны бүген аулагөйдә миннән күзенне алмый утырдың?!

Гөлия. Кем?! Минме?! Үзең син!

Насыйбулла. Йә, ярар, оялма инде, оялма!

*Гөлияне кочаклап үбә.*

Гөлия. Насыйбулла?!

Насыйбулла. Кем тия?

Гөлия. Тияргә маташалар шул, Насыйбулла.

Насыйбулла. Кемнәр?

Гөлия. Кичә әткәй белән әнкәйнең сөйләшкәнен ишетеп тордым.

Насыйбулла. Шуннан?

Гөлия. Әткәй әйтә...

Насыйбулла. Ни ди?

Гөлия. *(...)*

Насыйбулла. Әйт инде, ни диде атаң?!

Гөлия. Тахауга кияүгә бирәм мин аны, ди. Минем Тахауга барасым килми. *(Елый башлый.)*

Насыйбулла *(кукраеп)*. Миңа барасың киләме соң?

Гөлия. *(...)*

Насыйбулла. Барасыңмы миңа, дим?

Гөлия. *(...)*

Насыйбулла. Әллә телеңне йоттыңмы? Бүтән сорамыйм, матри!

Гөлия. Килә, килә, килә!!!

Насыйбулла. Алайса мин армиядән кайту белән өйләнешербез, яме, Гөлия?!

Гөлия. Син армиядән әйләнеп кайтканчы булмам шул инде мин!

Насыйбулла. Ничек инде булмам?

Гөлия. Минем әткәйне белмисең син! Ул бер әйттеме, тешләп өзгән кебек!

Н а с ы й б у л л а. Нишлибез соң, Гөлия?

Г ө л и я. Чү, тавышланма! Әллә кемдер килә инде?

*Беркавем тынланып торалар.*

Г ө л и я. Әйтәм бит, килә кемдер!

Н а с ы й б у л л а. Тахау бит бу, ләгънәт! Бар безнең ишегалдына кереп тор!

Г ө л и я. Нигә?!

Н а с ы й б у л л а. Бар, дигәннәр сиңа!

*Гөлия ишегалдына кереп китә. Зур-зур атлап Тахау керә. Ул заманына күрә бай гына киенгән.*

Н а с ы й б у л л а. Сәлам, Тахау! Кая ашыгасың болай?

Т а х а у. Кая яшердең Гөлияне?

Н а с ы й б у л л а. Гөлияне?! Ул бит ачкыч түгел яшереп куярга.

Т а х а у. Бөгештермә! Әйт тиз бул, кая ул?!

Н а с ы й б у л л а. Нигә соң ул сиңа?

Т а х а у. Син, Насый, кеше өлешенә кермә! Белдеңме?!

Н а с ы й б у л л а. Кемнең өлешенә керәм соң мин?

Т а х а у. Минекенә!

Н а с ы й б у л л а. Ничек алай?!

Т а х а у. Менә шулай! Без Гөлия белән вәгъдәләштек! Арага кермә! Аңладыңмы?!

Н а с ы й б у л л а. Кайчан вәгъдәләштең?! Төшеңдә генә булгандыр ул, Тахау!

Т а х а у. Менә күрсәтәм мин сиңа хәзер төшенне! *(Насыйбулланың якасына үрелеп ябыша.)*

Н а с ы й б у л л а *(Тахауны җайлап кына этеп җибәреп).* Нишлисең син, эт җоны?!

Т а х а у. Әх, син шулаймы әле?! Син шулай, әйеме?!

Н а с ы й б у л л а. Шулай, шулай. Бар, юлыңда бул!

Т а х а у. Күрсәтермен әле мин сиңа юлны! Юлның да ниндиен генә күрсәтермен әле! Белерсең Себернең кайда икәнен!

Н а с ы й б у л л а. Бар, юлыңда бул, дим! *(Тахауны куркытып урынында сикереп куя.)*

Т а х а у *(куркуыннан алга таба сикереп куя).* Күрсәтермен мин сиңа Себер юлын! (Чыгып китә.)

Н а с ы й б у л л а *(әкрен генә).* Гөлия! Гөлия, дим! Чык әйдә.

Г ө л и я *(чыкканда Тахау булып кыланып).* Күрсәтермен мин сиңа Себер юлын!

Н а с ы й б у л л а (йодрыгын күрсәтеп). Тахау сыманнарның даруы шушы инде аның.

Г ө л и я. Вәгъдәләштек, дип алдап тора бит әле тагын, кабахәт!

Н а с ы й б у л л а *(якланып).* Һәй, бәдбәхет!

Г ө л и я. Көлүен көләбез дә, Насыйбулла, чыннан да хат-мазар язып җибәрсә?

Н а с ы й б у л л а. Нинди хат?

Г ө л и я. Нинди булсын инде?! Ярты авылны җыеп алып киттеләр бит инде! Тахау язып ята, дип сөйли кеше. Синең турыда да язар нәрсә табар ул! Килерләр дә алып китәрләр, Аллам сакласын!

Н а с ы й б у л л а. Житешалмаслар.

Г ө л и я. Ник алай дисең?

Н а с ы й б у л л а. Берсекөнгә армиягә китәм мин.

Г ө л и я. Насыйбулла, чынлапмы?

Н а с ы й б у л л а. Чынлап.

Г ө л и я. И Аллам! *(Елый башлый.)* Син дә киткәч, әткәй бирә дә бирә инде мине шул Тахауга.

Н а с ы й б у л л а. Биралмас.

Г ө л и я. Бирмәс! Минем әткәйне белмисең син! Әйтәм ич, бер әйтсә, тешләп өзгән кебек!

Н а с ы й б у л л а. Ә мин нәрсә, әллә тешләп өзәлмыйммы?! Менә тотам да хәзер сине үзебезнең өйгә урлап алып кайтам. Шуның белән вәссәлам!

*Насыйбулла Гөлияне кулларына күтәреп ала.*

Г ө л и я. Син бит берсекөнгә армиягә китәсең?!

Н а с ы й б у л л а. Китмәсә тагын?! Мин кайтканчы бездә яшәрсең. Әни белән.

Г ө л и я. Юк, урламыйсың.

Н а с ы й б у л л а. Әллә синнән сорап торырмын, дисеңме?

Г ө л и я. Сорап торсаң да, тормасаң

да, урламыйсын.

Н а с ы й б у л л а. Ник?

Г ө л и я. Син армиягә киткән көнне үк әткәй бәреп үтерә мине!

Н а с ы й б у л л а. Үтералмас. Әнием бик әйбәт минем. Ул берәүгә дә сина кул тигертмәс. Мин ана ныклап әйтеп куярмын. Әйдә, киттек безгә. *(Гөлияне күтәргән килеш кузгала.)*

Г ө л и я. И Аллам! Иртәгә бөтен авылга ябышып чыккан дигән даным таралыр инде!

Н а с ы й б у л л а. Таралмас! Мин сине урладым, диярмен!

Г ө л и я. Кеше барыбер ябышып чыккан, дип сөйли аны! Ярар инде, нишләрсен? Шулай насыйп булгандыр инде безгә, Насыйбулла. *(Чыгып китәләр.)*

*Бер капчык он күтәреп Тахау керә. Насыйбуллаларнын капка төбендә бер кавем тынланып торганнан сон, эчкә уза. Капчыгын калдырып чыга да учындагы онны килгән юлына сибә-сибә кире китә.*

## V күренеш

*2005 елнын апреле. Насыйбулланын өе. Карт белән Айбулат өстәл янында утыралар.*

Н а с ы й б у л л а. Мулла абзый никахны укып кына бетерде, өч инкывыдышник килеп керде. Күп сөйләшеп тормадылар, икесе ике яктан култыклап алдылар да, өстерәп өйдән алып чыга башладылар. Әнинен: «Кая өстерисез аны?!»—дип аптырап соравына нәчәлникләре: «Белмәмешкә салынып тормагыз, корткычлар! Кибеттән урланган бер капчык он келәтегездә ята»,—дип кенә ырылдады... *(Пауза.)*

А й б у л а т. Ник тынып калдын, Насыйбулла бабай?

Н а с ы й б у л л а. ...Безнен капка төбенә шактый халык—күрше-күлән—жыелган иде. Шунда ник берсе мине яклап бер сүз әйтсен! Аларнын һәрберсе минем карак түгел икәнне белә иде бит! Кем инде йортка килен алып кайткан төндә кибет басып йөрсен?! Юк... Бер сүз дә әйтмәделәр... Әни мина биреп жибәрергә дип бүрек белән душагрейка алып чыккан иде. Инкывыдышниклар бирдермәде, ни палужыны, диделәр. Ә Тахау: «Аристанга кирәк түгел инде болар хәзер»,—дип, шул киемнәрне әнинен кулыннан тартып алды. Хәтта шунда да беркем бер сүз әйтмәде!!!

*Бераз сүзсез утыралар.*

А й б у л а т. Шуннан?

Н а с ы й б у л л а. Шуннан... *(Мыскыллы елмаеп.)* Имеш, суд булды! Илле тугызынчы статья чәпеделәр—бандитизм! Ун елга Себергә, алтын казырга! Мин, беркатлы жүләр, бер яманнын бер яхшысы, дип уйладым үземчә. Имеш тә, ярты Рәсәйне кичәсе бар, юл буе күзәтеп барырмын, анда халык ничек яши икән? Күзәтерсен, бар! Тәрәзәсе дә булмаган Столыпин вагоннарына тутырдылар да бикләп куйдылар. Июль ае иде. Иртәдән кичкә кадәр вагонны кояш кыздыра. Ашарга коры паек кына бирәләр: илле грамм ипи һәм ике йөз грамм тирәсе горбуша балыгы. Ул шыр тоз гына. Кабып йоту белән су сорый башлый, үтереп эчәсе килә. Тел авызга сыймый. Поезд бары тик зур станцияләрдә генә туктый. Конвой башлыгынын кәефе яхшы чакка туры килсә, вагон саен икешәр чиләк су бирәләр. Кырык кешегә! Аны кайнатып эчәргә түземлек тә, мөмкинлек тә юк. Сусаудан жаннар чыга чөнки! Бераздан бикле вагондагы кырык кешенен кырыгында да дизентерия башлана...

А й б у л а т. Кая хәтле алып барды инде ул поезд?

Н а с ы й б у л л а. Владивостокка... Ирексез кешенен күнеле һаман ни дә булса көтә, ниндидер яхшылык булыр дип өметләнә икән ул, улым. Корабка утыртып Магаданга алып китәләр, дигән хәбәр чыккач, дингезне карыйбыз икән әле дип сөенгән идем...

А й б у л а т. Ник, күрә алмадынмыни дингезне?

Н а с ы й б у л л а. Күрдем, Просковья Федоровнаны чыгарганда. Башка вакытта тынчу трюмда консерва банкасы эчендәге килькиләр кебек бардык.

А й б у л а т. Кем соң ул Просковья Федоровна? Сезнең белән хатын-кызлар да бар идемени?

Н а с ы й б у л л а *(көлеп)*. Нинди хатын-кыз булсын ди?! Парашаны шулай атап йөртә идек.

А й б у л а т. Ә-ә-ә!!!

Н а с ы й б у л л а. Аның урынына, улым, Колыма табигатен күзәтеп кинәндек инде! Магаданнан җәяүләп ун көн буе лагерьга кадәр бардык. Кышка кергәч, ул лагерьга сыймый башладык, чөнки яна «халык дошманнарын» китереп кенә торалар. Көннәрдән бер көнне безне эшкә таныш булмаган юл белән алып киттеләр. Утыз градус суык. Өстебездә җүнле кием юк инде, чүпрәк-чапрак шунда. Җил сөякләргә кадәр үтә! Унбиш чакрымлап җәяү баргач, шыр басуда туктаттылар. Шунда башта чокырлар казып баганалар утырттык, шуларга кәлүчи прувылкы урадык. Без үзебез өчен яна лагерь төзибез икән! Җылыныр өчен хәтта учак та ягып булмый. Ни ягасың? Бер генә нәрсә коткара ала. Тик торма! Эшлә дә эшлә! Берзаман барак төзергә материал китерделәр. Материал дигәннәре киндер чатырлар булып чыкты. Шуларны тарттырып куйдык та кырыйларына тыштан кар өйдек. Менә сина барак! Ятарга сәкеләрне ике катлап, урталай ярылган каен бүрәнәләрдән ясадык. Һәр баракка бирәр тимер мичкә бирделәр. Шулардан мич әмәлләдек. Ягып җибәргәч, мичебез кып-кызыл булып кызарды, барак эче әзрәк җылына башлады. Шатланышырга да өлгермәдек, киндер түбәдән тамчы тамарга тотынды. Тышта буран чыккан иде, барак түбәсенә кар яткан да, шул эри икән...

А й б у л а т. Түземле дә соң инде бу адәм баласы!

Н а с ы й б у л л а. Әйе, түземле. Тик кеше күңелендә өмет булса гына яшәргә тели. Нәрсәгә дә булса омтылырга тиеш ул! Ике ел Колыма туңын чокыгач, дөресен генә әйткәндә, өметләрем сүнеп беткән иде инде минем. Хәтта сугышка да җибәрмәделәр бит, кабахәтләр! «Син бит анда беренче көнне үк немецләр ягына качасың, корткыч!»—дип ырылдадылар. Ун елга ук түзә алмам кебек була башлады берзаман. Мин инде үземә кул салу турында уйлый башлаган идем... Ярый әле бәхетемә безнең лагерьга Большой Татаринны китерделәр.

А й б у л а т. Кем соң ул Большой Татарин?

## VI күренеш

*1942 ел башы. Колымадагы лагерьның бер барагы. Төн. Насыйбулла сәкедә йоклап ята. Аның янына Комарик килә.*

К о м а р и к. Эй, Угорь! Харе ухо давить! Вставай! Пахан тебя зовет.

Н а с ы й б у л л а *(йокы аралаш)*. Кто зовет?

К о м а р и к. Пахан! Большой Татарин.

Н а с ы й б у л л а. Какуй такуй бальшуй татарин?

К о м а р и к. Шевели клешнями, там увидишь.

Н а с ы й б у л л а. Ни пайду никуда. Пусть сам придёт. Я тужы татарин. Улак сыер артыннан йөрми.

К о м а р и к *(Насыйбулланың муенына пычак төртеп)*. Ты чё, падло, в пузырёк лезешь?! Недопетрил что ли?! Щас момент на пику посажу, не заметишь, как деревянный бушлат наденешь! *(Насыйбулла торып утыра.)* Вот так-то лучше! Не первый год на пахана осину гну, и не таким рога обламывали. *(Насыйбулланы төрткәләп.)* Давай, стучи копытами!

*Комарик Насыйбулланы Большой Татарин янына алып килә.*

*Большой Татарин ипи белән сало ашап, чәй эчеп утыра.*

К о м а р и к *(Большой Татаринга)*. Слышь, пахан, похоже насчет него пургу не гонят. Никакой он не стопорила, обыкновенный фраер. Да к тому же тоже юрок.

Б о л ь ш о й Т а т а р и н. Харе баланду травить, Комарик! Сядь. На вот, черной полынью побалуйся.

*Комарик утырып чәй эчә башлый.*

Большой Татарин *(Насыйбуллага)*. Юрокмы син?

Насыйбулла. Белмим. Кем сон ул юрок?

Большой Татарин. Татармы син дим?

Насыйбулла. Татар.

Большой Татарин. Исемең ничек?

Насыйбулла. Насыйбулла.

Большой Татарин. Ә нигә Угорь дип йөртәләр?

Насыйбулла. Белмим.

Комарик. Угрюмый потому что.

Большой Татарин. Статьян?

Насыйбулла. Илле тугыз.

Большой Татарин. Срок?

Насыйбулла. Ун ел.

Большой Татарин. На чем погорел?

Насыйбулла. Ничек инде?

Комарик. Базарят, будто бы он ларь бомбанул.

Большой Татарин *(Насыйбуллага)*. Кибет бастыңмыни?

Насыйбулла. Юк.

Большой Татарин. Ә нишләден сон?

Насыйбулла. Берни эшләмәдем.

*Большой Татарин, күз ачып йомганчы торып, Насыйбулланың яңагына сугып җибәрә. Ул атылып барып төшә. Шундук Комарик анын өстенә утырып кыйный башлый.*

Комарик. Пахан—не барбос, с ним не получится фуфло гнать!

Большой Татарин. Җибәр аны, Комарик. *(Насыйбуллага.)* Мин сиңа мент түгел, алдашма мина!

Насыйбулла. Алдашмыйм мин.

Большой Татарин. Карарбыз... Бүген эштә нормаңны тутырдыңмы?

Насыйбулла. Бер ярым норма эшләгән идем.

Большой Татарин. Ә син стахановчы икән?!

Насыйбулла. Нинди стахановчы?! Комлырак урын туры килде дә, ичмасам, тамакны туйдырырмын дип тырышкан идем дә, ярты паек кына бирделәр.

Большой Татарин. Нишләп алай? Бер ярым норма эшләгәч, паек та бер ярым булырга тиеш.

Насыйбулла. Тиеш тә сон... Баканың да койрыгы булырга тиеш...

Большой Татарин. Сорадыңмы сон, ник алай, дип?

Насыйбулла. Юк.

Большой Татарин. Нигә?

Насыйбулла. Ни мәгънәсе бар сон? Ярты паегынны да кире тартып алсалар?!

Большой Татарин. Анысы да хак.

*Большой Татарин, артыннан гына үрелеп, бер кирпеч кара ипи, зур гына кисәк шикәр һәм сало алып өстәлгә куя.*

Большой Татарин. Ал. Болар сиңа.

Насыйбулла. Рәхмәт, кирәкмәс.

Большой Татарин. Ал, дим, сиңа болар!

Насыйбулла. Алмыйм.

Большой Татарин. Нигә?

Насыйбулла. Сиңа бурычлы буласым килми.

Большой Татарин. Ә мин сиңа бурычка бирмим аны, эшләгәнең өчен түлим.

Насыйбулла. Минем сиңа берни дә эшләгәнем юк.

Большой Татарин. Булмаса, булыр.

Насыйбулла. Алайса, ни эшләргә кирәген әйт.

Большой Татарин. Төннәрен суык, минем урынымны җылытырсың.

Насыйбулла. Ничек инде?

Комарик. У тя чё, на чердаке совсем пусто? Королевой зоны будешь, чурка!

Насыйбулла. Барыбер аңлап бетерә алмыйм әле мин?

Большой Татарин. Хатынлыкка алам мин сине, аңгыра!

Насыйбулла. Да пошел ты на хрен!

*Насыйбулла борылып китеп бара, Комарик аны куып тотып аркасына сикерә, аягыннан егып кыйный.*

К о м а р и к. Ты на кого буром прёшь, гнида?! Ты кого посылаешь?! Я те щас будку-то разукрашу, тварь!

Б о л ь ш о й  Т а т а р и н. Брось его, Комарик! Больше порожняк гнать не будем. Не похож он на фраера демисезонного! И на стопорилу тоже. Обыкновенный мужик.

К о м а р и к. Ну, живи, паскуда!

Б о л ь ш о й  Т а т а р и н. Насыйбулла! Кил әле монда, утыр. Хәзер без синең белән чынлап сөйләшәбез.

Н а с ы й б у л л а. Мона кадәрлесе уен идемени?

Б о л ь ш о й  Т а т а р и н. Юк, это был шмон души твоей. Шмон ничек була татарча?

Н а с ы й б у л л а. Нәрсә соң ул шмон?

Б о л ь ш о й  Т а т а р и н. Обыск, проверка.

Н а с ы й б у л л а. Тентү, тикшерү була.

Б о л ь ш о й  Т а т а р и н. Алайса, тикшерүне егетләрчә уздың дип исәплә.

Н а с ы й б у л л а. Рәхмәт инде.

Б о л ь ш о й  Т а т а р и н. Син, Насыйбулла, болай юкка үпкәли торган булма! Иначе у нас с тобой масть канать не будет, а я хочу с тобой якшаться. На хорошего мужика ты похож, татар да әле өстәвенә.

Н а с ы й б у л л а. Карале, син үзебезчә генә сөйләшә алмыйсыңмы? Алайса мин синең сүзләреннән яртысын да аңламыйм.

Б о л ь ш о й  Т а т а р и н. Ә нәрсә әйттем мин аңлашылмый торган?

Н а с ы й б у л л а. Нәрсә ул «масть канать не будет»?

Б о л ь ш о й  Т а т а р и н. Эшләр пешмәс дигән сүз.

Н а с ы й б у л л а. Соң шулай диген! «Якшаться»сы нәрсә?

Б о л ь ш о й  Т а т а р и н. Дус булу.

Н а с ы й б у л л а. Ә нәрсә ул кара әрем?

Б о л ь ш о й  Т а т а р и н. Нинди кара әрем?

Н а с ы й б у л л а. Мин монда килгәч, син дустыңа: «Черной полынью побалуйся»,—дидең.

Б о л ь ш о й  Т а т а р и н. Ә-ә-ә! Чәй!!!

Н а с ы й б у л л а. «Ухо давить» йоклаудыр инде, деревянный бушлат—табут?

Б о л ь ш о й  Т а т а р и н. Әйе.

Н а с ы й б у л л а. Стопорила нәрсә?

Б о л ь ш о й  Т а т а р и н. Нәрсә түгел, кем. Урамда кеше талаучы.

Н а с ы й б у л л а. Ә барбос?

Б о л ь ш о й  Т а т а р и н. Следователь.

Н а с ы й б у л л а. Усак аудару?

Б о л ь ш о й  Т а т а р и н. Нинди усак тагын?

Н а с ы й б у л л а *(Комарикка ишарәләп)*. Менә бит бу, на пахана осину гну, ди.

Б о л ь ш о й  Т а т а р и н. Ә-ә-ә, хезмәт итү инде.

Н а с ы й б у л л а. Тагын «будку разукрашу», диде.

Б о л ь ш о й  Т а т а р и н *(көлеп)*. Чыраенны төям дигән сүз. Син аңла, Насыйбулла, әзрәк башыңны эшләтсәң, безнең халык телен эт пес иткәнче өйрәнергә була. Менә, кара! Әйтик, камерадагы лампочка—солнышко. Ә кояшны болдуха дип йөртәбез. Чөнки төрмәдә ятканда тоткыннар кояшны бик сирәк күрә. Прогулкага алып чыккач, кояшка рәхәтләнәләр, балдеют! *(Шаркылдап көлә.)* Яки менә, мәсәлән, берәр карак квартира басарга бара ди. Ничек иптәшләренә: «Квартира басарга киттем»,—дисен инде ул? Алай дими ул, пошел на скок, ди. Әйтик, квартирадан әйберләр алып чыгып барганда, бу каракны бер кеше күреп калды ди. Ул бит ментларга сөйләргә мөмкин. Шуна күрә карак бу кешене үтерә. Ә малинага кайткач болай дип сөйли: «Ну, я того фраера уговорил и он зажмурился»,—ди. Кызык бит?! *(Көлә.)*

Н а с ы й б у л л а. Кызык түгел.

Б о л ь ш о й  Т а т а р и н. Ә-ә-әй, онытып торам! Син башка камырдан бит әле! Син әле Сталинга хат та язгансыңдыр! Иптәш Сталин, сез белми торгансыздыр, илдә менә шундый хәлләр булып ята бит, дигәнсеңдер. Мине бер гаепсез утыртып куйдылар, дип язгансыңдыр. Минем кебекләр күп монда, дигәнсеңдер. Шулаймы?

Н а с ы й б у л л а *(аптырап)*. Ә син каян беләсең?

Б о л ь ш о й  Т а т а р и н *(кычкырып көлеп)*. Һи-и-и, беркатлы җаннар!!!

Үзегезне кеше итеп тоя башласын өчен сезне тагын күпме изәргә кирәк соң?! *(Лачт итеп төкереп куя.)* Комарик! Бар мозгодуйны чакыр әле, аның әкиятен тыңлыйбыз лутчы!

К о м а р и к. Айн момент! *(Чыгып китә.)*

Н а с ы й б у л л а. Мозгодуе кем инде тагын?

Б о л ь ш о й Т а т а р и н. Тагын бер татар кешесе бар монда, воляда агитатор булып йөргән. Илле сигезенче статья буенча утыртканнар, политический. Низам исемле, без «Не дам» дип йөртәбез инде аны. Көн саен кич белән безгә әкият сөйли.

*Комарик белән Низам керәләр.*

Б о л ь ш о й Т а т а р и н. Сәлам, Низам! Менә таныш бул, бу—Насыйбулла.

Н а с ы й б у л л а. Исәнмесез.

*Насыйбулла Низамга кулын суза, ә тегесе куркып Большой Татаринга карый.*

*Большой Татарин ярый дип ым каккач, Насыйбулла белән кул биреп күрешә.*

Н а с ы й б у л л а *(Комарикка)*. Ә синең исемең ничек?

К о м а р и к. Комарик.

Н а с ы й б у л л а. Юк, үз исемең ничек дим?

К о м а р и к. Чё, пристал, как банный лист? Сказано Комарик, значит, Комарик!

Б о л ь ш о й Т а т а р и н. Тавыш! Әкият тыңлыйбыз хәзер! Башла, Низам.

Н и з а м. Габдулла Тукай. «Кәҗә белән Сарык хикәясе»...

Борын заман бер ир берлән хатын торган,
Тормышлары шактый гына фәкыйрь булган;
Асраганнар бер Кәҗә берлә бер Сарык,
Болар булган берсеннән дә берсе арык.
Әйткән беркөн ире: «Кара монда, хатын!
Үзең яхшы беләсең бит печән хакын;
Китсен бездән чыгып Кәҗә белән Сарык,
Ашап ята бушка гына алар азык».

К о м а р и к. Вот, чурка! Суеп ашаса, ичмасам шунда тамагы туяр иде!

Н и з а м. Комарик, бу бит әкият, художественный вымысел!

Н а с ы й б у л л а. Сарык ите белән пешерелгән бәрәңге шулпасын каплап куйсаң иде ул хәзер, ә?!

Б о л ь ш о й Т а т а р и н. Кеше ите дә ярап куяр иде әле... *(Пауза.)* Низам! Болар белән әкият тыңлап булмый! Бар син урыңга менеп ята тор, мин хәзер.

*Низам хатын-кызларча кокетничать итеп сәкегә менеп китә.*

*Большой Татарин аны арт ягына жинелчә генә сугып озата.*

Б о л ь ш о й Т а т а р и н *(Насыйбуллага ипи, сало, шикәр кисәге биреп)*. Ал, бу сиңа бүген эшләгән өчен тиешле паек.

Н а с ы й б у л л а. Ялгышасың, безгә ипи генә бирәләр.

Б о л ь ш о й Т а т а р и н. Салосы белән шикәре—миннән бүләк. *(Салоны кулында бөтергәләп.)* Хәрам ризык та бит, нишләмәк кирәк?! Ходай үзе кичерсен инде.

Н а с ы й б у л л а *(ризыкларны алырга базмыйча)*. Карале, пахан... Син чынлап әйттеңме соң, әллә шулай шаяртасыңмы?

Б о л ь ш о й Т а т а р и н *(ризыкларны Насыйбуллага сузып)*. Чынлап инде, мә ал!

Н а с ы й б у л л а. Болар турында әйтмим мин...

Б о л ь ш о й Т а т а р и н *(авыз чите белән елмаеп)*. Ә-ә-ә, кеше ите дигәнгә исең киттеме? Курыкма, кеше ашап ятмыйбыз без монда. Мә, Насыйбулла, ал, сиңа болар. Тамагыңны туйдырып йокла әле бүген!

*Насыйбулла сыйларны ала. Ут сүнә.*

## VII күренеш

*Шунда ук. Тагын төн. Насыйбулла шулай ук сәкедә ята. Аның янына Комарик килә.*

К о м а р и к. Насыйбулла, әйдә әкият тыңларга киттек.

Н а с ы й б у л л а. Әкият кайгысы синдә!

К о м а р и к. Әйдә, дим! Пахан чакырды!

*Насыйбулла теләмичә генә урыныннан тора, Комарикка ияреп Большой Татарин янына килә. Низам да шунда. Ул әкиятен сөйли инде.*

Н и з а м. Зөләйха исемле бу патша кызын сорап бөтен тирә-як дәүләтләрдән патша уллары бер-бер артлы килеп кенә тора икән. Ә кыз берсен дә ошатмый ди. Ахыр чиктә атасы аптырап: «Сина нинди ир кирәк соң?»—дигән. «Мин Мисыр патшасына гына кияүгә чыгам»,—дип җавап биргән Зөләйха.

К о м а р и к. Губа не дура!

Н и з а м. Ә беләсеңме ни өчен шулай дигән?

К о м а р и к. Ну, конечно, беләм! Анарда акча да хрена патамушты!

Н и з а м. Юк, Комарик! Хикмәт башкада монда! Зөләйха төшендә күргән була Мисыр патшасын һәм аңа үлеп гашыйк була.

К о м а р и к. Во дает! Төштә күреп тә гашыйк булалармыни?

Н и з а м. Әкият бит инде бу, Комарик!

Б о л ь ш о й  Т а т а р и н. Син, Низам, әйдә читкә китмәле! Дальше ни булган анда?

Н и з а м. Зөләйханың атасы Мисыр патшасына хат язган. Шулай-шулай Кыйтриф...

К о м а р и к. Нәрсә соң ул кыйтриф?

Н и з а м. Нәрсә түгел, кем! Мисыр патшасының исеме шундый булган ул чакта.

К о м а р и к. Кайчан?

Н и з а м. Борын-борын заманда инде, кайчан булсын! Сорау биреп тинтерәтерсең инде хәзер!

Б о л ь ш о й  Т а т а р и н. Комарик, бүлдермәле! Ну, дальше?

Н и з а м. Шулай-шулай Кыйтриф, дип язган Зөләйханың атасы, бик чибәр кызым бар, кыз белән бергә мең дөя, тау-тау алтын-көмеш бирәм, аласыңмы, дигән.

К о м а р и к. Вәт миңа да бирәр патша тужы шундый хат язсын иде, ә?!

Н и з а м. Кыйтрифтән җавап хаты килгән, алам, җибәр, дигән.

К о м а р и к. Ишшу бы!

Н и з а м. Җибәргәннәр Зөләйханы алтыннарын мең дөягә төяп. *(Комарик сызгырып куя.)* Барып җитүен җиткән дә бу, тик ни күзе белән күрсен, Мисыр патшасы Кыйтриф бу кыз төшендә күреп гашыйк булган егет түгел икән.

К о м а р и к. Как түгел? Кем соң ул алайса?

Н а с ы й б у л л а. Комарик, кешегә Аллаһу Тәгалә бер авыз һәм ике колак биргән. Димәк, ул сөйләшкәнгә карaганда ике мәртәбә күбрәк башкаларны тыңларга тиеш. Тик кенә утыр инде әзрәк, ә?!

Н и з а м. Зөләйха Кыйтрифкә буен бирмәгән.

К о м а р и к. А что такое буен бирмәгән?

Н и з а м *(бик каты ачуы чыгып).* Бергә йокламаганнар!

К о м а р и к. Вот сучка!

Н и з а м. Көннәрдән бер көнне Зөләйха базарда йөргәндә сатуга куелган коллар арасында теге төшендәге егетне, ягъни Йосыфны күреп ала да, Кыйтрифкә: «Без моны сатып алыйк»,—ди. Ярар, ди тегесе. Ә сатучы әйтә, бу кол бик шәп, ул кыйбат тора, ди. Күпме? Менә үлчәүнең бер ягына аны бастырабыз, икенче ягына алтын сал! Үлчәү тигезләшсә, алырсың, ди. Кыйтрифнең коллары казнадан алтын ташый башлый, тик үлчәү селкенми дә!

К о м а р и к. Шундый симезмени ул Йосыф?

Н и з а м. Симез түгел лә инде! Нормальный ул. Яшь, бик чибәр, гайрәтле, җитмеш ике тел белә, шуңа хакы кыйбат.

К о м а р и к. Кит инде, кем җитмеш ике телне өйрәнә алсын ди?!

Б а р ы с ы б е р г ә *(ачуланып Комарикка).* Җитте инде, аңгыраланма, әкият бит бу!

Б о л ь ш о й  Т а т а р и н. Дальше ниләр булган анда, Низам?

Н и з а м. Кыскасы, Кыйтриф бөтен булган байлыгын—алтынын, көмешен, сый-ризыкларын, җиләк-җимешләрен, кием-салымнарын китерткән, тик үлчәү тигезләшмәгән. «Бүтән нәрсәм юк»,—дигән Кыйтриф. Сатучы байлыкка карап торган-торган да риза булган.

К о м а р и к. Ишшу бы!

Н и з а м. Кыйтриф белән Зөләйха Йосыфны үзләренең сарайларына алып

кайтканнар. Кайткач Кыйтрифнең башына кайгы төшкән: «Бернәрсәм дә калмады, ничек яшәрбез?»—ди икән. Йосыф казнасын тикшереп карарга киңәш иткән мона. Кыйтриф тикшереп караса, бар байлыгы урынында ди. «Ә ничек алай булды?»—дип сораган Кыйтриф Йосыфтан. Йосыф җавап биргән: «Мин пәйгамбәрләр нәселеннән, нишләсәм дә, кая гына булсам да, Тәңрем минем белән, бу аның эше»,—дигән. Кыйтрифнең бик тә күңеле булган инде, кәнишне! Зөләйханы чакырткан бу. Ана әйткән: «Барыбер балабыз да юк, без бу Йосыфны уллыкка алыйк»,—дигән. Зөләйха риза булган инде, әлбәттә. Тик аның үз уйлары да булган. Йосыф сарайда яши башлагач, почмак саен моны сагалап торып, кочаклап, бәйләнеп йөри башлаган.

К о м а р и к. Шәп бит, ә?! Ну-ну, ә Йосыф?

Н и з а м. Йосыф Зөләйхадан качып йөргән, Тәңрегә ялварган: «Шайтан котырткан бу азгын эштән коткар мине!»—дигән.

К о м а р и к. Вәт придурок!

Н и з а м. Зөләйха төрледән-төрле хәйләләр корган, Йосыфны һаман үзенеке итмәкче булган...

К о м а р и к. Ә ул һаман шулай качып йөргәнме?

Н и з а м. Әйе.

К о м а р и к. Вәт, сарык! Кем инде кочагына үзе шуышып кергән патша кызыннан баш тарта? Хмырь тупорылый!

Н и з а м. Шулай да берсендә Йосыфның сабырлыгы беткән. Ул инде Зөләйханың сүзләренә күнмәкче булган.

К о м а р и к *(зур өмет белән)*. Ну-у!!!

Н и з а м. Ләкин шунда әтисенең: «Нәфесеңне уйнаштан тый»,—дигәнен ишеткән.

К о м а р и к *(ачуыннан лачт итеп төкереп куя)*. Атасын да әйтер идем инде!

Н и з а м. Ахыр чиктә Зөләйха Йосыфка әйткән: «Йә минем әмерләремә буйсынасың, йә гомерең буена зинданга ябып куябыз!»—дигән. Йосыф ана: «Яман эшкә караганда миңа зиндан артыграк»,—дип җавап биргән. Зөләйха төрмә начальнигы белән сөйләшеп Йосыфны яптырып куйган...

Н а с ы й б у л л а. Әкияттә дә эш зиндан белән беткән икән алайса?

Н и з а м. Юк, бетмәде әле әкият, уртасына гына җиттек.

Н а с ы й б у л л а. Зиндан белән бетмәсә дә, барыбер шуңа килеп төртелгән, ябып куйганнар бит әле әнә Йосыфны! Чыга алмый инде ул аннан...

Н и з а м. Ничек чыкмасын?! Чыга! Мисыр патшасы була әле ул, Зөләйхага өйләнә!

К о м а р и к. Әйтәм бит, сарык дип! Кем инде үзен төрмәгә тыккан хатынга өйләнә?

Н а с ы й б у л л а. Әкияттә, бәлки, төрмәдән исән чыгып буладыр, тормышта—белмим...

Б о л ь ш о й  Т а т а р и н. Синең соңгы вакыттагы кәефең ошамый әле миңа, Насыйбулла. Шуның турыда сөйләшергә дип чакырган да идем. В чём проблема?

Н а с ы й б у л л а. Ә син белмисеңме?

Б о л ь ш о й  Т а т а р и н. Юк.

Н а с ы й б у л л а. Як-ягына әйләнеп кара. Берәр яктылык күрәсеңме?

Б о л ь ш о й  Т а т а р и н. Күрәм.

Н а с ы й б у л л а. Кая инде ул синең яктылыгын?

Б о л ь ш о й  Т а т а р и н. Менә Низам, Комарик, син. Сез миңа бу караңгы дөньяны яктыртучылар, яшәүгә ямь өстәүчеләр.

Н а с ы й б у л л а. Яшәү яме мондый булмый ул.

Б о л ь ш о й  Т а т а р и н. Нинди?

Н а с ы й б у л л а *(ачуланып, кулларын җәеп як-ягына күрсәтә)*. Менә мондый!

К о м а р и к. А тебе чё, безнең компания ошамый башлады что ли?

Б о л ь ш о й  Т а т а р и н. Кызмале син, Комарик.

Н а с ы й б у л л а. Бернинди мәгънәсе калмады яшәүнең. Очы-кырые күренми бит бу өметсезлекнең! *(Комарикның маңгаена үзенекен төртеп кычкыра.)* Подохнем мы здесь все!

Б о л ь ш о й  Т а т а р и н *(артыннан бау кисәге чыгарып)*. Һәм син шуңа асылынырга булдың инде. Баулар әзерләп куйгансың...

Н и з а м. Син нәрсә, Насыйбулла?! Мин иптәш Сталинга яздым! Ул безне бу хәлдә калдырмас!

*Большой Татарин белән Комарик көлеп куялар.*

Большой Татарин. Әйт әле безгә, Насыйбулла! Нәрсә өчен утырдың син?

Насыйбулла. Бер гаепсезгә.

Большой Татарин. Ә шулай да ничек монда килеп эләктең?

Насыйбулла. Минеке дә, әкияттәге кебек, хатын-кыз аркасында килеп чыкты инде. Тик мине хатыным утыртмады, көндәшем тырышты. Тахау атлы бер кабахәт җан бар безнең авылда. Ул Гөлиягә кызыгып йөри иде. Гөлиянең әти-әниләре дә Тахау яклы иде, ә ул миңа кияүгә чыкты. Дөресрәге, мин аны урладым.

Комарик. Тебя чё, за это посадили что ли?

Насыйбулла. Себер юлын күрсәтермен әле мин сиңа, дип янап йөри иде Тахау, никах укып утырганда энкывыдышниклар килеп керде. Кибеттән урланган бер капчык онны сезнең келәттән таптык, дип алып та киттеләр.

Комарик. Тебе чё, бер капчык он өчен ун ел впаяли что ли?

Насыйбулла. Әйе! Юк! Мин урламадым ул онны! Тахау кертеп аткан, кабахәт!

Большой Татарин. Ә син, Насыйбулла, беләсеңме соң, бер капчык он өчен илле тугызынчы статья—бандитизм белән ун ел түгел, йөз дә алтмыш икенче статья—кража белән бер ел бирелергә тиеш икәнен?

Насыйбулла. Ничек бер ел?

Большой Татарин. Менә шулай, бер ел. Ләкин сезнең сөйгән Сталиныгыз кушуы буенча яраткан совет судыгыз утыз алтынчы елдан бирле инде йөз дә алтмыш икенче статьяны бөтенләй кулланмый. Ул статьяга туры килгән преступление булса, шундук илле тугызынчы буенча бандитизм чәпиләр дә, ун елга Себергә! Монда халык аз бит! Менә сиңа халык власте, менә сиңа халык суды, менә сиңа якты киләчәк!

*Насыйбулла башын кочып чайкалып утыра башлый, ни әйтергә белми.*

Большой Татарин. Комарик! Сөйләле боларга, нигә Комарик син?

Комарик. Может, не надо, пахан? Не больно-то охота.

Большой Татарин. Сөйлә, сөйлә! Бәлки, әзрәк күзләре ачылыр.

Комарик. Ну, нәрсәсен сөйлисең инде аның? Егерме икенче елгы ачлык вакытында бөтен семьям ачтан үлеп беткән. Миңа өч яшь булган. Кем китергәндер, белмим, Казанга килеп эләккәнмен мин, приютка. Тегендәге тәрбиячеләр төрлечә сорашып караганнар инде. Мин бер генә сорауга җавап бирә алганмын. «Әниең кем исемле?»—дигәч: «Камәр»,—дигәнмен. Тегеләргә нәрсә? Комар, тык комар! Тотканнар да Иван Комарик дип исемләгәннәр мине. Иван булып йөрисем килми, шуна Комарик кына дим танышканда.

Большой Татарин. Нигә кырылган аның семьясы, Насыйбулла?

Насыйбулла. Ачлыктан, ди бит.

Большой Татарин. Ә ачлык нидән килеп чыккан?

Насыйбулла. Корылыктан.

Большой Татарин. Әйе, корылыгы да булды. Ләкин бит ул корылыклар егерме икенче елга кадәр дә булып торган, нишләп соң авыллары белән кырылмаганнар?

Насыйбулла. Белмим.

Большой Татарин. Ә мин беләм! Чөнки сезнең сөйгән совет властыгыз продразверстка дип үз халкын кычкыртып талап бөтен икмәген кырыпсебереп алып бетерде! Запаслык кына түгел, чәчәрлек тә калдырмады! Мин уналты яшьлек малай идем, хәтерлим!!! 1920 елның башында, февраль айлары булгандыр, авылга солдатлар ияртеп бер уполномоченный килде. Халыкны җыеп ультиматум куйды: «Биш мең пот ашлык тапшырырга!» Безнекеләр кешечә аңлатып карадылар моңа: «Дарагуй туариш, дәүләткә икмәк тапшырудан баш тартмыйбыз, тик син сораган хәтле бирә алмыйбыз»,—диделәр. Уполномоченный револьверын болгап котыра башлады. Утызлап кешене—араларында биш-алты хатын-кыз да бар иде—чатнап торган суыкта такта амбарга ябып куйды. Өч көн, өч төн шуларны ашатмыйча-нитмичә катырып тотты! Халык нишләсен, әсирлеккә алынган авылдашларын кызганып икмәк китерә башлады. Ә ул, җир бит, тапшырган бөтен икмәкне—бодай, арыш, арпа, борчак, солыны—бер урынга, кар өстенә бушаттырды. Менә шуннан соң башланды ул ачлык, ә егерме икедә ахыргы чигенә житте...

*Бераз сүзсез утыралар.*

Б о л ь ш о й Т а т а р и н. Насыйбулла! Кеше ите, дигәнемә аптыраган идең... Тугыз бала идек без. Иң элек әти үлде, аннан тугыз баладан башта сигез, аннан жиде, алты, биш, дүрт калдык. Аннан соң иң кече энебез—бер яшьлек Әмиржан... Аның да бүген түгел иртәгә үләсен аңлагач, әни ычкынган... Әмиржанны суеп безгә аш пешергән. Без белмәдек, ашадык... Синең сөйгән совет властың минем әнине акылдан яздырды, үземне кеше ашаучы итте, гаиләсез калдырды, ятимлеккә дучар итте, Насыйбулла!

Н а с ы й б у л л а. Син мина нинди дер яктылык турында сөйләмәкче идең, пахан.

Б о л ь ш о й Т а т а р и н. Ә син үз хәленне Комарикныкы һәм минеке белән чагыштырып кара! Нәрсә, әллә без синнән әзрәк михнәт кичергәнме?! Безнең бу дөньяда беркемебез дә юк, беркем дә көтми безне! Ә синең воляда хатының калган. Ул сине көтәдер бит! Әти-әниләрең исәнме?

Н а с ы й б у л л а. Әни исән.

Б о л ь ш о й Т а т а р и н. Ул да көтәдер! Син аларны кызган, үзеңне түгел! Ай-һай җайлы чишелеш тапкансың син, ә?

Н а с ы й б у л л а. Тагын нинди чишелеш бар соң?

Б о л ь ш о й Т а т а р и н. Исеңдә калдыр, Насыйбулла! Хәтта сине чәйнәп йотсалар да, бу хәлдән чыгуның ике юлы кала әле!

*Комарик хихылдап куя.*

Б о л ь ш о й Т а т а р и н. Низам, теге әкияттәге Йосыф ничә ел ята нарада?

Н и з а м. Унике.

Б о л ь ш о й Т а т а р и н. Ничек чыга?

Н и з а м. Дога кылып Тәңрегә мөрәҗәгать итә һәм Тәңре аның догаларын ишетеп Йосыфны азат итә.

Б о л ь ш о й Т а т а р и н. Ишеттеңме, Насыйбулла! Син үз тормышыңа үзең хуҗа түгел. Совет власте да хуҗа түгел аңа! Бар нәрсә Аллаһы Тәгалә кодрәтендә! Ул сиңа тормыш биргән, ул алырга да тиеш. Үз-үзеңә кул салу—бердән, бик зур җебегәнлек, мескенлек булса, икенчедән, бик олы гөнаһ. Ярамый, Насыйбулла! Башыңнан чыгарып ташла андый уйларыңны. Бу турыда хәтта уйларга да ярамый. Гөнаһ!

Н а с ы й б у л л а. Ә ничек яшәргә соң? Ничек түзәргә?!

Б о л ь ш о й Т а т а р и н. Тешеңне кысып!!! Әйтәм бит, әниең турында уйла, хатының турында! Син аларга кирәк! Һәм тагын шуны бел, үз халкын болай җәберләгән дәүләтнең киләчәге юк! Менә мин әйтте диярсең, СССРның «с» хәрефе дә калмаячак! Без шул көнне күрер өчен булса да яшәргә тиеш!

## VIII күренеш

*Шунда ук. 1942 елның августы.*

Т ө р м ә с а к ч ы с ы т а в ы ш ы. Внимание заключенные! Строиться!

*Насыйбулла, Низам, Комарик, Большой Татарин һәм тагын берничә тоткын сәхнәгә ашыга-ашыга кереп рәт-рәт булып тезелеп басалар.*

Т ө р м ә с а к ч ы с ы т а в ы ш ы. Внимание, заключенные! Родина в опасности! Фашист мечтает нас победить и бросает на фронт все новые и новые орды своих солдат. Партия и советская власть оказывает вам огромное доверие. Вам предоставляется право кровью искупить свою вину за совершенные преступления. Кто хочет на фронт, два шага вперед!

К о м а р и к. Зачесались, краснoперые! Видать хорошо прёт немец, не могут остановить! Смотри-ка, все политические как один вперед шагнули! Бараны, блин!

*Большой Татарин алга ике адым ясый. Бөтенесе аптырап аңа карыйлар. Большой Татарин янына Насыйбулла чыгып баса, аларга Низам да кушыла.*

*Большой Татарин ым кагып Комарикка да чыгарга куша. Комарик та алга ике адым атлый.*

Төрмә сакчысы тавышы. Большой Татарин?! Ты ли это? Не обознался ли я?! Ты же в законе! Даже здесь, в лагере, не работал, а на фронт хочешь?!

Большой Татарин. Надоело лежать на нарах, начальник! На волю охота!

Төрмә сакчысы тавышы. Там не воля, там война!

Большой Татарин. Ну, значит, воевать будем!

Төрмә сакчысы тавышы. Дело, конечно, твое, но предупреждаю тебя, Большой Татарин, и всех остальных тоже, что если с кем по пути или там на фронте осечка выйдет, считайте, сами себе приговор подписали! Расстрел на месте без оправданий!

Комарик. Да, не пугай ты, пуганые мы!

*(Беренче пәрдә тәмам.)*

## ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

### IX күренеш

*1942 ел. Насыйбулла, Низам, Большой Татарин, Комарик һәм тагын берничә тоткын поездда баралар.*

Комарик. Низам, чё задумался? Әйдә, лутчы берәр әкият сөйләле!

Низам. Әкият кайгысы синдә!

Комарик. Ә синдә кукәй кайгы?

Низам. Нинди кукәй тагын?

Комарик. Ну, какой кайгы, аңламасаң!

Низам *(паузадан соң)*. Менә уйлап барам әле мин, бу чукынган Сталин минем дә бит бөтен тормышымны җимерде, тартып алып була торган бар нәрсәмне тартып алды, ә мин Сталин өчен сугышырга барам...

*Комарик сызгырып куя.*

Большой Татарин *(көлемсерәп)*. Авырып китмәгәнсеңдер бит, Низам?

Низам. Утызынчы елны кулак дип әтинең атын, ике сыерын, сарыкларын, хәтта самавырыбызны да талап алып чыгып киткәннәр. Гаиләбезне—әти-әнине, өч сеңлемне—Себергә сөрделәр. Казанда яшәсәм дә, агитатор булсам да, «кулак малае», «халык дошманы» дип, мине дә утыз алтыда хөкем иттеләр. Идеология агуы аңга шулкадәр сеңгән, мин җүләр дә, башкалар кебек, Сталинга хатлар язган булам әле тагын! Сталин илдә булып яткан явызлыкларның берсен дә белми, аңа әйтмиләр, ну, белеп алса, була инде хәлләр, дип ышанып йөрдем. Кайвакыт, әллә контрреволюционерлар Сталинның үзен дә төрмәгә ябып куйдылар микән, дип уйлап куям. Безнең халык беркатлы бит инде ул! Элек тә патша безнең болай яшәгәнне белми, дип ышанганнар бит... Ә менә пахан энесе Әмирҗан турында сөйләгәч, әллә нишләдем... Егерменче еллар ачлыгы чыннан да бит үзебезнең татар большевикларының, башкалардан уздырырга тырышып, Мәскәүнең артын ялап дәүләткә олау-олау икмәк тапшыруыннан килеп чыккан нәрсә! Халык власты шундый буламы?

Большой Татарин. Миләрегез тәмам сыегаеп бетмәгән икән әле үзе!

Комарик. Мин чё-то все равно не допетрил! Син нигә сугышка барырга уйладың соң? Кем йомырканнан тартты?

Низам. Соң илгә дошман бәреп кергәч!

Комарик. А может Гитлер Сталинга караганда лутчы булыр?

Большой Татарин. Комарик, я тебе горбатого лепить не буду, прямо скажу! Совет властыннан башка туган җир бар әле тагын. Ә минем туган җиремне бүген немец таптый. Йөрәккә пычак тыгып куйган кебек! Ничек нарада кызынып ятмак кирәк?! Их, ананны! Дөньяда безнеке кебек тагын бер ил бар

микән? Башта гражданнар сугышында бер-беребезне кырдык. Аннан ачлык оештырып күпме кеше дөмектердек! «Халык дошманнарын» уйлап чыгарып илнең яртысын төрмәгә ябып куйдык. Икенче яртысы саклый! Аптырагач немец изә башлады. Кем генә исән калыр икән сон бу илдә?..

Н а с ы й б у л л а. Ә син үзең ник сугышка барырга уйладың соң, Комарик?

К о м а р и к. Я как пахан! Ә син?

Н а с ы й б у л л а. Мин сугышның беренче көненнән үк доброволец булып китмәкче идем дә, җибәрмәделәр.

## X күренеш

*2005 ел. Насыйбулланың өе. Карт белән Айбулат сөйләшеп утыралар.*

Н а с ы й б у л л а. Безне фронтка алып бара торган поезд беренче станциядә туктагач ук, һәрбер вагоннан диярлек өчәр-дүртәр мәет чыгара башладылар.

А й б у л а т. Ничек инде мәет чыгара башладылар?

Н а с ы й б у л л а. Шулай. Уголовниклар белән политическийларга бүленеш бетте чөнки! Билгеле инде, уголовникларның күбесе Ватанымны саклыйм дип түгел, качып булмас микән, дигән ният белән фронтка барырга ризалашкан. Поезд кузгалып китү белән алар вагон такталарын каера башлаганнар. Ә политическийлар аңлый: әгәр болар качса, беренче станциядә үк бөтен вагонны терәп аталар. Шуннан китә инде сугыш! Блатнойларның берсе дә пычаксыз йөрми аларның, аларга политическийларны кадап үтерү берни дә тормый. Хәер, уголовниклар да шактый кырылды барып җиткәнче.

А й б у л а т. Фронтта ничек кабул иттеләр сезне?

Н а с ы й б у л л а. Оркестр белән түгел инде! Халык дошманнары бит без! Ну, уголовниклар да кимен куймады, кыланып та карадылар, мин сиңа әйтим! Сугыш бара дип тә тормыйлар. Күрәсең, андый кешеләрне берничек тә үзгәртеп булмый торгандыр инде!

А й б у л а т. Ни кыландылар соң алар?

Н а с ы й б у л л а. Алар кыланмаган нәрсә калмады! Йә кәрт уйнаганда талашып китеп берәрсен чәнчеп үтерәләр, йә склад басалар, йә берәр хатынны яки кызны тотып көчлиләр.

А й б у л а т. Насыйбулла бабай, кызык булып китте бит әле миңа! Кызлар белән ничек анда сугышта, ә?

Н а с ы й б у л л а. И-и-и, яшьлек!.. Берсендә ничектер шулай ике көн ял бирделәр. Ерак та түгел зур гына бер авыл бар иде. Комарик шунда барып марҗалар белән дуслашып кайткан. Җыеп алып китте бу безне дә, кунакка чакырдылар, дип. Ну, бардык. Өстәл әзерләгәннәр, самогон күпме эчсәң дә бар. Мин сизенми дә калдым, ничектер пышан-пышан гына егетләр таралышып бетте, без йортта хозяйка белән генә калдык. Самай җиләк чагы бу хатынның, мөлаем гына, бар нәрсәсе дә үз урынында. Мин дә ир бит инде! Кочаклашып үбештек. Бу мине ятагына тарта башлады. Шунда нишләптер күзем тәрәзәгә төште дә, имәнеп киттем! Урамнан Гөлия бара иде! Үзе тәрәзәгә карый. Атылып урамга чыксам, берәү дә юк!

## XI күренеш

*1942 ел. Насыйбуллаларның капка төбе. Төн. Капкадан ерак түгел Тахау коймага терәлеп тора. Уң кулына бияләй кигән. Ашыга-ашыга атлап Гөлия керә.*

Т а х а у *(Гөлиянең юлына каршы төшеп).* Кая ашыгасың болай, Гөлия?

*Гөлия җавап та бирмичә капкадан кереп китмәкче була, тик Тахау аны җибәрми.*

Т а х а у. Йә инде, Гөлия! Мин бит сине сагынып килдем! Әйдә, чын күңелдән бер сөйләшик әле!

Г ө л и я. Кайтып хатыныӊ белән сөйләш!

Т а х а у. Яратмыйм мин аны, Гөлия, әтиләр кушканга гына өйләндем! Мин сине яратам!

Г ө л и я. Ә мин сине күралмыйм!

Т а х а у. Нигә?

Г ө л и я. Әйтсәм дә, аӊламассыӊ шул син, Тахау!

Т а х а у. Ә син аӊлатып кара.

Г ө л и я. Уӊ кулыӊдагы ике бармагыӊ кая?

Т а х а у. Ит чапканда ялгыш өздем.

Г ө л и я. Оят түгелме сиӊа? Бөтен ирләр фронтта, Ватан өчен сугыша, ә син минем өше солдаткаларныӊ канын эчеп ятасыӊ!

Т а х а у. Ире солдатта булган хатын гына солдатка була бит ул, Гөлия. Бурларныӊ хатыннары солдатка булмыйдыр ул!

Г ө л и я. Ә минем ирем солдатта! Сталинградтан хаты килде!

Т а х а у. Шулаймыни? Чыгарганнар әллә?

Г ө л и я. Чыгарганнар шул! Әллә гомер буе төрмәдә утырыр дип уйлаган идеӊме?

Т а х а у *(Гөлиянеӊ алдына тезләнеп).* Гөлия! Барыбер үтерәләр аны сугышта! Кайталмаячак ул кире авылга! Әйдә, миӊа кияүгә чык! Хатынымны аерам! Яратам мин сине, Гөлия! Мин синнән башка яши алмыйм!

Г ө л и я *(Тахауны этеп җибәреп).* Китәле моннан, елан!

*Тахау сикереп торып Гөлияне кочып ала.*

Г ө л и я. Җибәр! Җибәр, дим, кабахәт!

Т а х а у *(Гөлиянеӊ телогрейкасын капшап).* Туктале! Ни бу синеӊ монда?

Г ө л и я. Җибәр, дим, оятсыз! Җир бит!

*Тахау Гөлия телогрейкасыныӊ түш кесәсеннән бер шешә сөт тартып чыгара.*

Т а х а у. Бу ни бу, Гөлия? Син дә иреӊ кебек урлашу юлына бастыӊмыни, ә? Бөтен ил: «Бар нәрсә фронт өчен, бар нәрсә Җиӊү өчен!»—дип көнне-төнне белми тир түккәндә, син колхозны талап ятасыӊмыни әле монда?

Г ө л и я. Би-и-ир!!! Миӊа түгел ул, балага! Сөтем бетте, балам ач!

Т а х а у. Тәк, тәк! Синеӊ дә Себер юлларын күрәсеӊ килдемени?

Г ө л и я. Тахау, кеше бул! Бир сөтемне!

Т а х а у. Синеӊ сөтеӊ түгел ул, колхозныкы!

Г ө л и я *(Тахау алдына тезләнеп).* Тахаветдин! Ялварып сорыйм синнән! Бир инде! Балам ачтан үлә бит! Аныӊ көне буена ашаган ризыгы шул бер шешә сөт бит!

Т а х а у. Әйдә минем белән! Кайтышлый алып кайтып китәрсеӊ сөтеӊне!

*Гөлия сикереп тора да, Тахауныӊ йөзенә төкереп, капкадан кереп китә.*

## XII күренеш

*1943 елныӊ июле, фронт сызыгы. Насыйбулла, Низам, Комарик тәмәке тартып утыралар. Большой Татарин кереп алар янына урнаша.*

Б о л ь ш о й Т а т а р и н. Мать их и в хвост, и в гриву!

Н а с ы й б у л л а. Нәрсә булды, ротный?

Б о л ь ш о й Т а т а р и н. Таӊнан атакага!

К о м а р и к. А чё, первый раз что ли?

Б о л ь ш о й Т а т а р и н. Сарык көтүе урынына да күрми болар безне!

Н а с ы й б у л л а. Нәрсә булды соӊ? Аӊлатып сөйлә әле!

Б о л ь ш о й Т а т а р и н. Таӊнан атакага!

Н а с ы й б у л л а. Анысын ишеттек.

Б о л ь ш о й Т а т а р и н. Бүлдермә! Таӊнан атакага! Бер инеш бар инда, без шуны кичеп, инештән кимендә ярты километр үтеп, шул позицияне сакларга тиеш. Ә инешнеӊ бу ягында—минное поле! Барып та житә алмыйбыз без ул

инешкә! Өстән бомбалар явачак, каршыга пулялар сызгырачак, ә аяк астында миналар шартлаячак!

Н и з а м. Нишләмәк кирәк, без бит сугышта.

Б о л ь ш о й  Т а т а р и н. Әйе, сугышта! Әйе, минем үз Ватанымны фашист корткычларыннан саклыйсым килә! Ләкин болай ангыра сарык кебек белә торып минное поле буенча чабарга мин не подписывался!!!

Н и з а м. Без болай да инде көн саен үлем белән качышлы уйныйбыз.

Б о л ь ш о й  Т а т а р и н. Атакага чапканда пуля тиеп үлсәң, бер хәл! Ә болай белә торып үз-үзенне үтерү—это же тупость, мать твою! Они чё там в штабе, последние мозги пропили?!

*Бераз сүзсез утыралар.*

Н а с ы й б у л л а. Атакага чапмый барыбер бүтән чара юк.

К о м а р и к. Ща, побежал!

Н а с ы й б у л л а. Чапмасак, үзебезнең заградотряд барыбер кырып бетерәчәк. Ә болай мина кырын исән-имин үтеп чыгуын бар.

Б о л ь ш о й  Т а т а р и н. Инешнен теге ягында немец! Анысын да онытма!

Н а с ы й б у л л а. Барыбер бүтән чара юк. *(Ут сүнә.)*

*Ут янганда Большой Татарин, Насыйбулла, Комарик, Низам атакага чабарга әзерләнеп яталар. Бомба шартлаган тавышлар ишетелә.*

Б о л ь ш о й  Т а т а р и н. Артобстрел бетү белән без кузгалабыз, егетләр!

*Бомба шартлаган тавышлар тына. Большой Татарин торып баса.*

Б о л ь ш о й  Т а т а р и н. Рота! Слушай мою команду! Вперед, за родину!

*Берәү дә кузгалмый.*

Б о л ь ш о й  Т а т а р и н. А, ну, подельнички, поднять задницы! Кто останется лежать, самолично в винегрет покрошу, мать вашу за ногу!

*Ул арада миналар шартлаган, аткан тавышлар янадан ишетелә башлый. Комарикнын сикереп торуы була, анын мангаена кыйпылчык тия. Ул йөзен куллары белән каплап Насыйбулла белән Низам өстенә ава. Тегеләр мона бернинди игътибар бирмичә: «Ур-р-ра!!!»—кычкырып Большой Татарин артыннан атакага йөгерәләр. Ут сүнә. Ут янганда сәхнәдә Большой Татарин ята. Ул авыр яраланган. Анын янына Насыйбулла шуышып килә. Анын да җилкәсеннән кан ага.*

Б о л ь ш о й  Т а т а р и н. Бәхил бул, Насыйбулла! Мин дә китәм Комарик артыннан. Низамны күрмәденме?

Н а с ы й б у л л а. Югалыштык ничектер.

Б о л ь ш о й  Т а т а р и н. Житәр инде бу балама, дигәндер Аллаһы Тәгалә. Менә хәзер тегендә баргач та допрос алалар инде. Мать твою! Анда да допрос! Ярар, соңгысы булыр, иншалла. Насыйбулла! Минем сина бер үтенечем бар. Син сугыштан соң минем авылга барып кил, яме. Чуашстандагы Шыгырдан авылыннан мин. «Сәйфетдин Гарифуллин Ватаны өчен сугышканда, атакага чапканда немец пулясыннан үлде»,—диген, яме! Белсеннәр авылдашлар. Мәчеткә кереп хәер бирерсен, минем рухыма дога кылсыннар...

*Большой Татарин тынып кала. Немецлар сөйләшкән тавышлар ишетелә башлый. Насыйбулла Большой Татаринның гәүдәсе артына яшеренеп атышырга әзерләнә. Шунда ул патроннарын санап карарга уйлый.*

Н а с ы й б у л л а. Берәү генә калган.

*Насыйбулла автоматын иж астына төби. Гөлия керә.*

Г ө л и я. Алай итмә, Насыйбулла! Без сине көтәбез бит! *(Чыгып китә.)*

*Низам шуышып керә.*

Н и з а м. Насыйбулла! Син исән икәнсен!

Н а с ы й б у л л а. Жилкәгә пуля тиде.

Н и з а м. Жилкән түзәр! Син беләсенме соң? Без бит синен белән Аллаһы

Тәгалә үпкән кешеләр дияргә була!

Н а с ы й б у л л а. Ни сөйлисең син?

Н и з а м. Батальондагы сигез йөздән артык кешедән без икәү генә исән калдык бит, Насыйбулла!

Н е м е ц  с о л д а т ы  т а в ы ш ы. Хенде хох, русишен швайн!

Н а с ы й б у л л а. Ни ди ул?

Н и з а м. Кулларыңны күтәр, урыс чучкасы, ди.

## XIII күренеш

*2005 ел. Насыйбулланың өе. Карт белән Айбулат сөйләшеп утыралар.*

Н а с ы й б у л л а. Аннан соң поездга төяп Гирманиягә җибәрделәр.

А й б у л а т. Кайсы концлагерьда булдың?

Н а с ы й б у л л а. Берсендә генә булмадым мин. Әллә дүртесендә, әллә бишесендә булырга туры килде. Исемнәре безнеңчә булмагач, истә калмаган инде. Бик хәтерләп торасы да килми, дөресен генә әйткәндә.

А й б у л а т. Анда ниләр күрергә насыйп булды инде?

Н а с ы й б у л л а. Гөлиянең сүзе иде ул. Шулай насыйп булгандыр инде безгә, Насыйбулла, ди торган иде мәрхүмкәем.

А й б у л а т. Ә шулай да концлагерьдагы тормыш турында тәфсилләбрәк сөйлә әле, Насыйбулла бабай.

Н а с ы й б у л л а. Тормышмыни инде ул концлагерьда?! Җан асрау инде ул, тормыш түгел! Ат урынына көне-төне эшлисең дә эшлисең. Бөтен тормыш шул. Ашау начар. Юк, дисәң дә була. Локман хәзер чучкаларын да алай ашатмый. Кутилукка бер бакрач кайнаган су салып бирәләр. Шунда йомырка сарысы хәтле бер бәрәңге йөзеп йөри. Язын-җәен кычыткан турап салалар. Ипи дип бирә торган нәрсәләре оннан түгел. Көрпә белән опилканы кушып пешерелгән бер нәрсәкәй шунда... Ачлыктан китеп бара яздым мин кырык дүрттә! Да тауа ачыктым, ашказаны бөтереп-бөтереп, чыдый алмаслык булып авырта башлады, канлы панус китте! Каян чыккандыр инде ул кадәр? Мин Гирманиягә китергәннән бирле ул чакта чыккан панус кадәр ашамаган идем.

А й б у л а т. Ничек терелдең соң?

Н а с ы й б у л л а. Низам алып калды мине. Алланың рәхмәте, гел аерылмадык без аның белән. Башка концлагерьга күчерсәләр дә, бергә күчерәләр иде. Ул чакта Низам ат җигеп йөри иде, ә без таш ватып төйибез. Ат арбасына салып без эшләгән җиргә әбәт алып килә дә, кайтып киткәндә, шул көнне үлгәннәрне төяп китә. Кайсы көнне, кеше күбрәк кырылса, кат-кат йөрергә туры килә иде аңа. Бер кичтә, каян тапкандыр, Низам бер катилук кайнар майлы шулпа һәм чып-чын ярты кирпеч кара ипи алып килде! Үз күзләремә ышанмый тордым башта! Аннан соң кулыннан тартып алдым да эһ(!) иткәнче ашап та бетердем! Ашап бетергәч кенә, аңыма килеп, читенсенеп Низамга карадым. Ә ул көлә генә. Борчылма, ди. Шушыны ашамасаң ычкына идең син, минем хәл түзәрлек әле, ди. Ярый әле җир йөзендә Тахаулар гына түгел, Низамнар да бар...

А й б у л а т. Чигепләр дә куйгансың инде нужаны!

Н а с ы й б у л л а. Минем нужаның яртысын да белмисең әле син, улым.

## XIV күренеш

*1944 елның көзе. Бүлмәдә өстәл һәм урындык кына. Сәхнә буйлап гестапочы йөренә.*

Г е с т а п о ч ы *(кычкырып)*. Шульц! Кем анда чиратта? Кертегез!

*Насыйбулланы кертеп аталар. Ул идәнгә, гестапочының нәкъ аяк астына килеп егыла.*

Г е с т а п о ч ы (*Насыйбулланы якасыннан күтәреп)*. Тор, русишен швайн!

*Насыйбулланың торуы була, гестапочы аны шундук сугып ега.*

Г е с т а п о ч ы *(кычкырып).* Тор дигәннәр сиңа, урыс чучкасы!

*Насыйбулла торып баса.*

Г е с т а п о ч ы *(акырып һәм Насыйбулланың якасыннан җилтерәтеп).* Ишеттеңме синнән алда кергән бәндәнең акыруларын?! Күрдеңме, нинди хәлдә алып чыгып киттеләр аны?! Ә беләсеңме, кая апкиттеләр аны, ә?! Синнән сорыйм мин!

Н а с ы й б у л л а. Юк.

Г е с т а п о ч ы. Мичкә! Сабын ясарга! Аның кебек кылансаң, сине дә шунда ук җибәрәм! Аңладыңмы!

Н а с ы й б у л л а. Әйе.

Г е с т а п о ч ы *(өстәл янына барып утырып).* Исемең?!

Н а с ы й б у л л а. Насыйбулла.

Г е с т а п о ч ы. Фамилияң?

Н а с ы й б у л л а. Галиуллин.

Г е с т а п о ч ы. Атаңның исеме?

Н а с ы й б у л л а. Гали улы мин.

Г е с т а п о ч ы. Күңелем сизенә, Насыйбулла, синең белән килешербез без, ахрысы. Акыллы мужикка охшагансың. Синнән алдагысы шып-шыр ангыра иде. Нәрсә, килешәбезме?

Н а с ы й б у л л а. Ни тәкъдим итәсез инде.

Г е с т а п о ч ы. Син авызыңны чамалап ач! Сырланып утырырлык җаең юк синең! Йә мин әйткән белән килешәсең, йә... *(Бармагы белән түшәмгә күрсәтә.)* Күрәсеңме әнә теге божраны?

*Насыйбулла башын өскә күтәреп карый, тик җавап бирми.*

Г е с т а п о ч ы. Күрәсеңме, дим мин сиңа?!

Н а с ы й б у л л а. Күрәм.

Г е с т а п о ч ы. Күргәч, бел! Йә мин әйткәнгә күнәсең, йә Шульцны чакырам. Ул әнә шул божрага бау кигертә дә, кулларыңны арттан бәйләп, сине шунда асып куя! Аннан соң сул якка ике йөз мәртәбә бөтерә дә, кирегә бөтерелгәндә резин таяк белән рәхәтләнеп тәя үзеңне! Аннан соң инде син сабын заводына әзер чимал буласың. Белдеңме?!

Н а с ы й б у л л а. Белдем.

Г е с т а п о ч ы. Белсәң, тыңла... Сугыш бетәргә күп калмады. Без хәзер көч җыйдык, мона кадәр ясаган хаталарыбыздан сабак алдык. Күп дигәндә икеөч ай эчендә Мәскәү безнеке булачак. Рейх сиңа бөек ышаныч белдереп дойче зольдатен булырга тәкъдим итә.

Н а с ы й б у л л а. Кем соң ул дуйчы зүлдәтен?

Г е с т а п о ч ы. Немец солдаты! Ангыра!!! Бүлдермә! *(Бераз тынычлана төшеп.)* Сезнең генералыгыз Власов хәзер рейх яклы. Ул Русиядәге большевизмны бәреп төшереп андагы халыкларга азатлык бирергә тели. Син татар икәнсең. Татармы син?!

Н а с ы й б у л л а. Татар.

Г е с т а п о ч ы. Татар булсаң, тыңла! Бөек рейх сиңа азатлык бирергә тели. Власовның «Русская освободительная армия»сендә татар-башкорт легионы бар. Шуның солдаты булып китсәң, син туган иленне большевизмнан азат итүгә үз өлешеңне кертәчәксең. Тамагың һәрчак тук, өстең бөтен булыр. Большевизмны җингәч, без сезгә чын мәгънәсендә милли республика төзергә вәгъдә итәбез. Азат булып, ирекле булып, иркенләп, үзегез теләгәнчә яшәрсез. Йә, ничек, син ризамы?

Н а с ы й б у л л а. *(дәшми)*

Г е с т а п о ч ы *(акырып).* Ризамы дим?!

Н а с ы й б у л л а. Белмим шул. Сез әллә нинди мин аңламый торган нәрсәләр турында сөйлисез.

Г е с т а п о ч ы *(тагын да ныграк акырып).* Карале син, русишен швайн! Син монда үзеңнән герой ясап утырма! Синең бу геройлыгың беркемгә дә кирәк түгел! Әллә син үзегезнекеләргә эләксәң башыңнан сыйпарлар, дип беләсеңме? Син безнең кулда булуың белән бәхетле. Бары тик шуңа күрә генә әле исән син!

Н а с ы й б у л л а. Рәхмәт инде.

Г е с т а п о ч ы *(җанлана төшеп).* Менә монысын дөрес әйтәсең. Йә ничек, куабызмы большевизмны Иделдән?

Н а с ы й б у л л а. Уйларга вакыт бирәсезме?

Г е с т а п о ч ы *(акырып).* Вакыт? Нинди вакыт?! Кем соң син шулхәтле, сиңа вакыт биреп торырга? Әйт тиз бул, ризамы, юкмы?!

Н а с ы й б у л л а. *(...)*

Г е с т а п о ч ы *(һаман шулай акы-*

*рып).* Соңгы мәртәбә сорыйм?!

Н а с ы й б у л л а. *(...)*

Г е с т а п о ч ы. Шульц! Шульц, дим! Әллә йокларга яттыңмы, ялкау сыер! Эшкәрт бу сабын кисәген!

## XV күренеш

*Насыйбулланың өе. Бабай белән Айбулат һаман шулай сөйләшеп утыралар.*

Н а с ы й б у л л а. Утыз-кырык мәртәбә әйләнгәч, анны югалттым. Сабын заводы янында үлгән кешеләрнен гәүдәләрен тау хәтле итеп өеп куйганнар иде. Мине дә шунда илтеп атканнар. Һаман шул Низамга рәхмәт инде, арбасына салып баракка ничектер алып кайталган ул мине. Шул чакта исән калганыма хәзер дә бик ышанып бетә алмыйм. Үзем сиңа сөйләп утырам, үземнең теге чакта авырткан кебек бөтен тәнем сызлый.

А й б у л а т. Низам үзе исән калдымы соң?

Н а с ы й б у л л а. Калалмады шул, бахыр. Азат итәргә бер көн кала атып үтерделәр аны...

А й б у л а т. Менә, Насыйбулла бабай, сугыштан соң батырлар күбәя бит инде ул. Соңгы елларда сүз ирегеннән файдаланып төрле кеше төрле нәрсә яза башлады. Араларында сугышта катнашкан татарларны наданнар, үз халкын кимсетеп яшәгән империяне саклап гомерләрен биргәннәр, дип язучылар да бар?

Н а с ы й б у л л а. Мин, улым, империяне саклыйм, дип сугышмадым. Беркем дә империя өчен дип үлми. Мин туган авылым, әнием, абыйларым, сеңелләрем, Гөлиям өчен сугыштым. Хәер, бүтәннәр өчен җавап бирә алмыйм, төрле кеше булгандыр инде ул чакта да.

А й б у л а т. Ә нигә син татар-башкорт легионына язылмадың? Теге гестапочы әйткәндәй, тамагың тук, өстең бөтен булыр иде. Фронтка барып җиткәч берәр җаен табып үзебезнекеләр янына чыгар идең.

Н а с ы й б у л л а. Шундук атып үтерсеннәр өченме?

А й б у л а т. Ирекле милли республика төзеп бирәбез, дигәч тә кызыкмадыңмы?

Н а с ы й б у л л а. Ә нәрсәсенә кызыгасың аның?

А й б у л а т. Ун-унбиш ел элек суверен республика төзеп карамакчы булдык бит инде. Ә сиңа моны кырык дүрттә үк вәгъдә иткән булганнар. Һәр татар йөрәгендә, бик тирәндә булса да, ирекә омтылыш бар бит инде ул.

Н а с ы й б у л л а. Әллә нинди сораулар бирәсең син, Айбулат! Хәер, сез икенче, яшь буын инде. Белмим, миндә син әйткән мәгънәдә ирекә омтылыш юк иде. Мин 1552 елда ни булганын да җитмеш яшькә җиткәч кенә гәҗиттән укып белдем. Аннан соң ничек инде мин үз илемә басып кереп бөтен нәрсәне кырып, бөтен кешене үтереп йөргән немесләр ягына чыгыйм?! Хәлләре мөшкеләя башлавын да сизенә идек инде. Шулай булмаса, бездән легион ясап маташмаслар иде алар.

А й б у л а т. Суверенитет вәгъдә иткәннәреннән генә әйтәм инде.

Н а с ы й б у л л а *(ачуланып).* Нәрсә соң сез бөтенегез дә сувирин да сувирин! Ни кылдыгыз сувирин булып?! Әйтәм бит, миңа ул сувиринны кырык дүрттә үк тәкъдим иткәннәр иде. Алмадым мин аны!

А й б у л а т. Ләкин бит, Насыйбулла бабай, туган илнең бәйсезлеге турында сүз бара. Аңлыйсыңмы?

Н а с ы й б у л л а. Пычагымамы миңа аның бәйсезлеге! Аңа кадәр, нәрсә, бәйдә идемени ул? Нимес төзеп биргән республика Мәскәү төзегәненнән нәрсәсе белән аерылсын?!

А й б у л а т. Насыйбулла бабай, туктале, кызмале син. Үзең туган авылым, әнием, Гөлиям өчен сугыштым, дисең...

Н а с ы й б у л л а. Әйе шул!

А й б у л а т. Соң алар туган ил бит инде! Татарстан!

Н а с ы й б у л л а. Алар—туган ил, ләкин Татарстан түгел. Чөнки әнигә һәм Гөлиягә сувирин кирәк түгел иде. Аларга минем исән-сау сугыштан әйләнеп кайтуым гына кирәк иде. Аларның минем белән тыныч, үз тормышлары белән

яшисе килә иде. Бары тик шул гына! Ә синен Татарстаныңа сувирин кирәк!

Айбулат. Суверен булса, бәлки...

Насыйбулла. Хикмәт бөтенләй анарда түгел, улым. Беләсенме, нәрсәдә хикмәт?

Айбулат. Нәрсәдә?

Насыйбулла. Үзен уйлап кара. Ни бирде мина ул туган ил нужадан башка?

Айбулат. Бәйсез, азат булса, бирә алыр иде. Үз өен—үз көен!

Насыйбулла. Бирер, көт! Бәйсез булса да, бәйдә булса да, Тахаулар беркая да китми бит! Өч хәрефле оешма да беркая да китми! Ә ул оешма булганда, сувирин дип йөрүләр уен гына ул! Син дә ачуымны китереп сувирин дип утырасын. Теге гестапочы кебек, әйтмәсәм дә булмады! Кирәкми мина берниНди сувирин да, фашизм да, коммунизм да, капитализм да, берсе дә кирәкми! Теләсә кайсы дәүләт—ул кешене изү өчен төзелгән система. Ә минем тынычлап яшисе килә! Аңлыйсыңмы?

Айбулат. Дөрес әйтмисен син, Насыйбулла бабай.

Насыйбулла. Менә сиксән алтыга жит әле, яме, шунда янадан бер сөйләшербез.

Айбулат *(авыз чите белән генә көлеп)*. Ярар сон, алайса. Алга таба ниләр булды инде?

Насыйбулла. Алга табамы? Кырык бишнен апрелендә бомба шартлаган тавышлар безнен концлагерьга да ишетелә башлады. Әһә, без әйтәбез, килеп життеләр безнекеләр! Иртә шатланганбыз. Шул тавышлар килә башлагач, немесләр әсирләрне атарга йөзәрләп кенә алып чыга башлады. Низам белән мина да чират житте. Тагын икебезне бер көтүдә алып чыгып киттеләр. Әллә ни ерак алып бармадылар. Тезеп бастырдылар да, автоматтан сиптерә дә башладылар! Белмим, нишләп алай булгандыр? Әллә куркудан, әллә үлдем, дип уйлап, аңымны югалтып егылдым мин. Төн уртасында уянып киттем. Бар жирем дә исән, бер пуля да тимәгән. Шундук Низам искә төште. Эндәшепэндәшеп карыйм, жавап бирүче юк. Үле гәүдәләр арасыннан эзләп киттем мин моны. Таптым... Йөрәгенә атканнар, кабахәтләр! Аннан-моннан гына чокыр казып, күмеп куйдым Низамны. Мине ике мәртәбә теге дөньядан алып калган кешегә рәхмәтем шул гына булды...

Айбулат. Аннан сон?

Насыйбулла. Тан атып килә иде. Низамны күмеп бетерәм дигәндә генә машина тавышлары килә башлады. Качмакчы булган идем, качар урын юк. Үләнгә салышып, атып үтерелгән әсирләр янына барып яттым. Машиналар килеп житте. Бер күземне әзрәк кенә ачып карасам, немесләр түгел. Безнекеләр дә түгел. Американнар булып чыкты. Батырлыгымны жыеп торып бастым.

Айбулат. Американнар ни диде инде?

Насыйбулла. Берсе урысча сукалый иде әзрәк. Сораштырып маташты да инде, мин ни булганын аңлатып күрсәткәч, үзенекеләренә нидер генә әйткән иде, тегеләр мине кочаклый башладылар. «Рус, Иван, друг, живой»,—диләр. «Гитлер капут, виктория, победа»,—диләр. Шундук ашарга тушункы бирделәр. Кемдер ботинка бирде, кемдер фуражка. Шулай итеп мине американ киемнәренә киендерделәр. Алар белән ике көн йөрдем. Сәвит гаскәрләре белән очрашкач, алар мине үзебезнекеләргә тапшырды.

## XVI күренеш

*1945 елнын мае. Бүлмәдә өстәл һәм урындык кына тора. НКВДчы тегендәмонда йөренә.*

НКВДчы *(кычкырып)*. Казаков! Казаков, дим, твою мать! Йоклап киттенме әллә анда, сыер! Керт тагын берсен!

*Насыйбулланы кертеп аталар. Ул бик нык кыйналган, бер исән жире дә юк.*

НКВДчы. Фамилиян?!

Насыйбулла. Галиуллин.

НКВДчы *(аптырап)*. Галиуллин?! Синмени бу Галиуллин?!

Насыйбулла. Мин идем ачуланмасагыз, гражданин следователь.

НКВДчы. И Галиуллин, Галиул-

лин! Башың бармы синең, юкмы? Чистосердечно сөйләп бирсәң, әллә кайчан беткән иде бит инде бу интегүләрең!

Н а с ы й б у л л а. Нәрсәне?!

Н К В Д ч ы. Ничек икеләтә шпион булып киткәненне инде! Нәрсәне булсын тагын?

Н а с ы й б у л л а. Нинди шпион?

Н К В Д ч ы *(акырып)*. Немец һәм америкaн шпионы, сволочь!

Н а с ы й б у л л а. Гражданин следователь! Мин бернинди шпион да түгел! Мин сезгә соңгы ике елымны ничек, кайда, кем белән үткәрүем турында йөз мәртәбә сөйләдем инде! Һәрбер сүзем дөрес! Ватаным алдында күз яше кебек чиста мин!

Н К В Д ч ы. У-у-у, син нинди сүзләр беләсең икән, Галиуллин! Ләкин бу дөньяда син белмәгән сүзләр, шулай ук син белмәгән нәрсәләр дә бик күп. Сине кислота ваннасына тыгып алганнары бармы? Ә, Галиуллин! Ә артыңа кып-кызыл булып кызган тимер чыбык тыкканнары бармы? Ай, рәхәт ул, Галиуллин! Шашлык исләре чыга, борыннарны кытыклый башлый.

Н а с ы й б у л л а. Шушында үлсәм үләм, ләкин сезнең ул кәгазьләрегезгә мәнге кул куймаячакмын!

Н К В Д ч ы *(ачуыннан ысылдап)*. Су асты көймәсеннән кая китерсең икән соң син?!

*НКВДчы Насыйбулланы бик каты кыйный.*

*Сәхнәдә төрле төстәге утлар уйнап ала. Гөлия керә.*

Г ө л и я. Син, Насыйбулла, күпкә түзгәнне азга гына түз инде. Без сине көтәбез бит! Дөньялар гел болай гына тормас әле! Бәлки, бик күп тә утырмассың, кайтырсың, Алла боерса. Иң мөһиме, исән бит син!

Н а с ы й б у л л а *(читенсенеп)*. Гафу ит мине, Гөлия!

*Гөлия юкка чыга.*

Н К В Д ч ы. Итәрмен менә мин сине! Мин сине шундый итеп гафу итәрмен, бу дөньяга ник туганыңа үкенерсең!

Н а с ы й б у л л а *(көч-хәл белән, НКВДчыдан тәмам туеп)*. Бирегез кәгазьләрегезне!

Н К В Д ч ы *(шатланып)*. Күптән шулай диләр аны!

*Өстәл янына килеп кәгазьләр арасыннан бер папканы эзләп таба.*

*Аны ачып актара башлый.*

Н К В Д ч ы. Бер генә сорау калган, Галиуллин.

Н а с ы й б у л л а. Тагын нинди сорау?

Н К В Д ч ы. Монда синең власовчы һәм немец шпионы буларак заданиең язылган, диверсион эш алып барырга тиеш булгансың икән. Ә менә Америка шпионы буларак нинди задание белән килүең турында бер сүз дә юк.

Н а с ы й б у л л а. Килмәдем мин, кайттым.

Н К В Д ч ы. Анысы не важно! Заданиең нинди?

Н а с ы й б у л л а. Мин каян белим? Язгыгыз инде шунда берәр нәрсә!

Н К В Д ч ы. Мин сезнең бөтенегезгә дә каян задание уйлап табып бетерим?!

Н а с ы й б у л л а. Минем дә башыма бернәрсә дә килми.

Н К В Д ч ы. Ну, ярар. Просто задание дип кенә язам. *(Папкага язып куя.)* Әйдә, кил монда. Куй кулыңны.

*Насыйбулла көч-хәл белән килеп имзасын куя.*

Н К В Д ч ы. Менә булды! Үзеңне дә күпме газаптан коткардың, мине дә! Казаков! Казаков дим, твою мать! Монысын шпионнар янына ябыгыз! Бетте эше.

## XVII күренеш

*Насыйбулланың өе. Карт белән Айбулат сөйләшеп утыралар.*

А й б у л а т. Ничә ел бирделәр инде?

Н а с ы й б у л л а. Егерме биш...

А й б у л а т. Насыйбулла бабай! Менә син нимес төрмәсен дә үткәнсең инде, әйеме, безнекен дә. Әйт әле, кайсысы әйбәтрәк иде?

Н а с ы й б у л л а. Айбулат улым,

төрмәнең аның әйбәте юк инде! Барысы да начар! Тик шулай да, ниместә тәртип күбрәк иде сыман.

А й б у л а т. Ә төрмәдәге тормыш белән иректәге тормыш нәрсәсе белән аерыла?

Н а с ы й б у л л а. Кызык-кызык кына сүзләр ычкындырып куясың син, Айбулат! Нәрсәсе белән аерылсын инде? Ирегең булмау белән аерыла! Хәер... Беләсеңме, Айбулат... Төрмәдә анда тормыш күпкә катлаулырак та, шул ук вакытта күпкә җиңелрәк тә. Анда инде билгеле бер тәртип урнашкан. Әйтик, каршыңа надзиратель килсә, ана биш адым кала син баш киемеңне салырга тиеш. Анардан ике адым киткәч, кияргә була. Иң шәбе, берүзең генә булганда надзиратель белән бөтенләй очрашмавың инде. Чөнки ул бәйдәге эт һәркемгә өргән кебек сиңа барыбер һичьюгы акырып кала. Акырып кына калса әле?!

А й б у л а т. Бусы, аңлавымча, җиңелрәк ягы булды.

Н а с ы й б у л л а. Әйе.

А й б у л а т. Ә катлаулырагы?

Н а с ы й б у л л а. Исән калуы катлаулы. Үзең уйлап кара! Дүрт кешелек вагонкада...

А й б у л а т. Нәрсә соң ул вагонка?

Н а с ы й б у л л а. Ничек дип әйтим? Зэклар ятып йокласын өчен такта-токтадан кадакланган ике катлы караватъ.

А й б у л а т. Ә, аңлашылды.

Н а с ы й б у л л а. Дүрт кешелек вагонкада сигезәр, унар кеше йоклыйбыз. Илле кешелек баракта ике йөзләп зэк җан асрый. Ятып йоклый торган матраслар эченә опилка тутырылган. Ул кандала белән мыжгып тора! Ашау начар. Нык начар! Мине, мәсәлән, үземне ач үлемнән палатна гына коткарып калды.

А й б у л а т. Нинди палатна? Нәрсә соң ул?

Н а с ы й б у л л а. Палатна инде! Палатнаны белмәскә син?! Тимер пычкысының палатнасы!

А й б у л а т. Ә-ә-ә!!!

Н а с ы й б у л л а *(үртәшеп)*. Бә-ә-ә!!!

А й б у л а т. Ә ничек ул сине ач үлемнән коткарып калды?

Н а с ы й б у л л а. Зэкның палуженныйдан артык бернәрсәсе дә булмаска тиеш.

А й б у л а т. Ә нәрсә положено?

Н а с ы й б у л л а. Бернәрсә дә ни палужыно! Тыңла! Шулай берсендә төзелештә эшлибез. Эш вакыты бетте, кайтырга җыена башладык. Карасам, идәндә чәнти бармак хәтле генә палатна сыныгы ята. Кеше күрмәгәндә генә алдым мин моны. Тотсалар, беттең! Ә тотмасалар, бик зур байлык ул! Бәхетемә, шәпләп кенә тентесәләр дә, табалмадылар моны! Мин палатнаны үткенләп, анардан кечкенә генә пычак ясадым. Инструмин! Беләсеңме никадәр кирәк әйбер ул инструмин? Кемнеңдер аяк киемен төзәтергә кирәк, кемгәдер посылка килгән, сало кисәргә кирәк, башкасына тагын нидер. Яшереп куйган җиреннән кеше күрмәгәндә генә алып бирәсең. Теге алып торган кеше бурычлы булып калмый инде, бер кисәк ипи булса да бирә.

А й б у л а т. Ә-ә-ә, алай икән!

Н а с ы й б у л л а. Шулай шул, улым. Кайда да тырышырга кирәк.

А й б у л а т. Насыйбулла бабай! Ә миңа лагерьда утырганда күңелеңә иң нык кереп калган нәрсәне сөйлә әле!

Н а с ы й б у л л а. Лагерьда яткан һәр көнем кичә булган кебек исемдә, улым. Онытып була торган нәрсә түгел ул! Сүз белән дә сөйләп бирә торган нәрсә түгел. Сезгә эләкмәсен инде андый нужалар, Ходаем! Без күргәннәр дә ташып ашкан!

А й б у л а т. Ә шулай да, Насыйбулла бабай?!

Н а с ы й б у л л а. Нәрсә дип әйтим икән соң? Юк, алай аерып алып сөйләрдәй... Ә, юк! Туктале! Мунча төзеттеләр безгә берсендә! Нигә кирәк булгандыр инде ул кыш уртасында урманда мунча, белмим?! Әйтергә онытып торам икән. Кырык бер градус суык булса, эшкә алып чыкмыйлар. Кырык градус кына булса чыгып китәсең инде, кая барасың? Ул көнне шул кырык градус булгандыр, мөгаен. Надзирательләр кемнең ни эшли белгәнен чамалыйлар бит инде. Балта болгый белгән егерме кешене сайлап алдылар. Шулар арасында мин дә бар. Аннан соң тагын егерме кешене сайлап алдылар. Алары бүген-иртәгә үлә, дип йөри торганнар. Барысы да авыру, күбесе картлар. Профессорлар шунда, композиторлар, политическийлар инде. Апкиттеләр безне лагерьдан урманга.

Килеп життек. Икегә бүлеп кара-каршы бастырып тезеп куйдылар безне. Бу якта без, плутниклар, торабыз. Теге якта җыен гарип-гораба, дигәндәй. Тезеп куйдылар да ник апкилгәннәрен әйттеләр. Егерме дүрт сәгать вакыт сезгә, диләр. Шул вакыт эчендә мунча әзер булмаса, сезне дә шушында атып үтерәбез, боларны да, диләр.

Айбулат. Төзедегезме соң?

Насыйбулла. Соң, алдында утыргач?

Айбулат. Әллә чынлап егерме дүрт сәгатьтә төзеп бетердегез?

Насыйбулла. Ә кая барасың?

Айбулат. Димәк, шул кырык кешедән барысы да исән калды?!

Насыйбулла. Юк, бер утызлабы гынадыр. Әле аларның да кул-аяклары өшеп, соныннан гангырина башланып, бармакларын, кул-аякларын кискәләделәр.

Айбулат *(уйга батып).* Алай... Шулай итеп, чәнти бармак хәтле тимер кисәге гомерне саклап калды, диген, ә?

Насыйбулла. Тимер кисәге түгел инде ул, улым. Пычак гомерне саклап кала алмый, ул аны кисә генә ала. Менә төрмә тормышын сораган идең бит? Анда шул мондагы тормыш инде ул, улым. Ләкин анда ул... Ничек дип әйтим?.. Буяуларсыз, шәрә ул анда! Тахаулар да бар анда, Низамнар да. Тахаулар сине бетерергә йөри, Низамнар, үз гомерләрен кызганмыйча, синекен саклап калалар. *(Бераз уйланып утыра.)* Сөйли башласаң күп инде ул, улым. Сиксән алты ел гомерне ничек бер төндә сөйләп бетермәк кирәк?

Айбулат. Авылга кайчан кайттың инде? Егерме бишне үк утырмагансыңдыр бит?

Насыйбулла. Юк, егерме биш үк булмады. Илле өчнең җәендә кайттым мин.

Айбулат. Ә, амнистиягә эләктең, әйеме?

*Насыйбулла килешеп башын селки.*

Айбулат. «Без права выезда» дигән кәгазь бирүләре дөресме соң?

*Насыйбулла тагын килешеп башын селки.*

## XVIII күренеш

*1953 елның җәе. Насыйбулла авылга кайтып төшә. Иң беренче булып аның каршына Тахау очрый.*

Тахау *(Насыйбулланы күреп).* Нәрсә, Насый? Кайттым, дисеңме?

Насыйбулла. Кайттым, Аллага шөкер! Исәнме, Тахау.

Тахау. Зерә кайткансың... Зерә... *(Зур-зур атлап ашыга-ашыга чыгып китә.)*

*Сәхнәгә Гөлия йөгереп керә. Насыйбулла янына килеп житкәч, ул кисәк кенә туктап кала. Беркавем алар бер-берсенә сүзсез генә карашып торалар.*

Гөлия *(илереп).* Насыйбулла!!! *(Насыйбулланың кочагына ташлана.)*

*Бер-берсеннән аерыла алмыйча озак кына кочаклашып торалар.*

*Аннан соң Насыйбулла Гөлияне этеп куя.*

Гөлия *(аптырап).* Нигә алай итәсең, Насыйбулла?

Насыйбулла. *(...)*

Гөлия. Әллә сөйләп тә өлгерделәр инде, Ходаем?!

Насыйбулла. Нине сөйләп? Мин әле Тахаудан башка беркемне дә күрмәдем.

Гөлия. Соң Тахаудан башка кеше сөйләми дә инде аны! *(Жиргә утырып елый башлый.)*

Насыйбулла. Туктале, Гөлия! Аңлатып сөйләле! Миңа кем, нәрсә сөйләргә тиеш иде соң?!

*Гөлия җиргә ятып үк кычкыра-кычкыра елый.*

Насыйбулла. Гөлия! Гөлия! Матурым! Акыллым! Тынычлан әле, әйдә! Ни булды? Кешечә генә аңлатып бир әле?!

Г ө л и я *(тынычлана төшеп торып утыра, жирдәге бер ноктага төбәлеп, мәрткә киткәндәй әкрен генә сөйли башлый).* Сиңа башта ук язмаганга гафу ит инде, Насыйбулла. Авырга узганымны белгәч тә сиңа хат язып җибәрмәкче булган идем, туктап калдым. Бәлки ялгышамдыр, минәйтәм. Аннан соң инде, үзем ныклап инангач, тагын бер язмакчы булган идем, хатны яза да башлаган идем хәтта, тик тагын туктап калдым. Минәйтәм, ат урынына эшлибез, йөртеп бетереп буламы, юкмы әле? Төшсә, сиңа ничек аңлатырмын, дим. Язмадым шулай итеп. Тугач хат язып салган идем...

Н а с ы й б у л л а. Балабыз бармыни безнең, Гөлия?!

Г ө л и я. ...син җавап хатларыңда бу турыда ләм-мим бер сүз язмадың. Алмагансыңдыр син ул хатны, күрәмсең?

Н а с ы й б у л л а. Юк, андый хәбәрле бер хат та алмадым!

Г ө л и я. Анысы соңыннан гына башыма килде шул! Башта аптырадым, аннан соң сине көнләшә, дип уйладым. Үпкәләдем сиңа шуның өчен! И, җүләр дә инде үзем! *(Күз яшьләрен яулык чите белән сөртеп куя.)* Шул үпкәчеллегем белән сиңа бала турында бер сүз әйтмичә коры гына берничә хат та язып җибәрдем әле!

Н а с ы й б у л л а. Кем туды соң, Гөлия?! Кызмы?! Малаймы?!

Г ө л и я. Аннан соң сиңа пахарункы килде. Әни, мескенем, аны алгач гел бетте! Сеңлең малай тапкан чак иде. Улымның исеме чит җирләрдә аунап ятмасын дип, ул балага Насыйбулла дип исем куштырды.

Н а с ы й б у л л а. Гөлия! *(Сикереп тора.)* Нишләп без монда утырабыз соң?! Әйдә, өйгә кайтыйк! Минем дә бит үз баламны күрәсем килә! Ничә яшь инде аңа?! Уникеме?

Г ө л и я. Юк инде ул, Насыйбулла... Утыр...

*Насыйбулла коелып төшә. Башын кочаклап чүгәли.*

Н а с ы й б у л л а. Ни булды?

Г ө л и я. Әмин ышанмадым ул пахарункыга. Шул кара кәгазь килер алдыннан сине төштә күргән идем. Ишегалдына кайтып кергәнсең икән, дим. Гөлия, дисең, иртәгә кара хат китерерләр, шундук ут төртеп яндыр син аны, дисең икән, дим. Берүк әнигә күрсәтә күрмә, дисең. Ни язылган булыр соң ул кара хатта, дип сорыйм. Ялган, дисең син. Шуна күрә ышанмадым мин ул пахарункыга. Әни ышанды. Язганнар бит, ди. Төшемне дә сөйләп карадым, барыбер... Бер ай түзмәде бит! Бер ай! Кырык бишнең язына, синең исән дигән хәбәрең килүгә хәтле яшәсә, бүген дә исән булыр иде әле ул. Синең кайгың алып китте инде аны. Бала кайгысы айһай авыр икән ул, Насыйбулла!

Н а с ы й б у л л а. Балага ни булды?

Г ө л и я. Тахау, кара йөз!

*Насыйбулла сикереп тора.*

Н а с ы й б у л л а *(кулларын Гөлиягә күрсәтеп).* Хәзер үк менә шушы кулларым белән буып үтерәм мин аны!

Г ө л и я *(тыныч кына, әкрен генә, һаман шулай бер ноктага төбәлгән килеш.)* Утыр, Насыйбулла. Тахау шуны гына көтеп йөри ул! Сине яңадан төрмәгә тыгып куяр өчен.

Н а с ы й б у л л а. Мин аның үзен утыртам! Баламны үтергән өчен!

Г ө л и я. Ә ничек дәлиллисең?! Ул бит аны буып үтермәде?

Н а с ы й б у л л а. Ничек үтерде?

Г ө л и я *(һаман шулай тыныч кына).* Сөтем бетте минем нишләптер. Нәбигә бер яшь кенә иде әле ул чакта...

Н а с ы й б у л л а. Малай идемени?! Нәби кушкан идең мәллә?!

Г ө л и я. Савымчылык фермасында эшлим бит инде гомер буе. Кичен кайтканда бер шешә сөт кыстырып кайтам да шуны кайнатып эчертәм нарасыйга. Анысын язган идем бугай инде, Тахау, ит чапканда ялгыш суктым, дигән булып уң кулындагы ике бармагын өздереп атты бит ул сугышка бармас өчен, кара йөз! Нигә шундыйларны утыртмыйлар икән?

Н а с ы й б у л л а. Чөнки алар монда кирәк. Монда алар күбрәк этлек эшли ала.

Г ө л и я. Бәлки, чыннан да шулайдыр... Әйе, белеп алган Тахау. Бригадир бит авылда! Нәчәлник кеше! Кыланганнарын күрсәң син аның! Талап алды шешәмне. Баланың көне буена ашаган

ризыгы шул бер бәләкәй шешә, дип аңлатып карадым башта. Җылап карадым, ялварып карадым, кире талап алмакчы булып карадым, тик булдыра гына алмадым... *(Кычкырып.)* Тәки баланы ачтан үтергәнче сагалап йөрде, кабахәт!!! *(Янәдән җиргә ятып ауный-ауный елый башлый.)* Гафу ит, Насыйбулла! Гафу ит! Саклый алмадым Нәбикәебезне! Барысы да фронт өчен! Барысы да Җиңү өчен! Тахау, әнә, Җиңү өчен безнең улыбызны бирде!

*Насыйбулла Гөлияне күтәреп алып кочаклый, юатырга тырыша.*

*Гөлия үксеп-үксеп елаудан шашыпшашып үбешүгә күчә.*

Г ө л и я **(еш-еш сулап һәм пышылдап)**. Насыйбулла! Насыйбулла!! Насыйбулла!!! Унөч ел бит! Унөч ел! Синме соң бу, Насыйбулла?!

*Насыйбулла тагын Гөлияне читкә этә. Гөлия моңа бөтенләй игътибар итми, һаман аның кочагына керергә тырыша.*

Н а с ы й б у л л а. Туктале, Гөлия! Туктале, дим.

Г ө л и я *(кисәк кенә сикереп торып)*. Нишләп утырабыз соң без монда?! Әйдә, тизрәк өйгә кайтыйк!

Н а с ы й б у л л а. Гөлия, дим, туктале! Тыңлале мине, Гөлия! Минем дә сина әйтәсе бик мөһим сүзем бар иде!

Г ө л и я. Әйт соң, әйт, Насыйбулла! Тыңлыйм!

Н а с ы й б у л л а. Гөлия... Мин аны ничек дип әйтергә дә белмим инде...

Г ө л и я. Ничек бар, шулай әйт!

Н а с ы й б у л л а. Бер сүз белән әйткәндә... Син азат, Гөлия!

Г ө л и я. Ничек инде... азат?!

Н а с ы й б у л л а. Менә шулай, азат...

Г ө л и я. Ни дигән сүз соң инде бу, Насыйбулла?

Н а с ы й б у л л а. Бу, Гөлия, синең минем алда бернинди дә бурычың юк, дигән сүз. Син азат! Нишлисең килә, шуны эшлә. Телисең икән, башкага кияүгә чык.

Г ө л и я. Ни сөйлисең син, Насыйбулла? Каян килде бу сүзләр башыңа? Нигә алай дисең син? Мин сине көтеп күпме хыялланып йөрдем! Насыйбулла кайтыр, дидем, кешечә яши башларбыз, Алла боерса, минәйтәм. Без яшь әле, дим, тагын балалар алып кайтырбыз, дим! Түребез тулып торыр балалар белән, минәйтәм. Ә син ни дисең?! Каян чыккан сүз инде бу?!

Н а с ы й б у л л а. Гөлия... Син әле яшь... Таза... Кияүгә чыгарсың... Балалар алып кайтырсың...

Г ө л и я. Минем синнән бала табасым килә!

Н а с ы й б у л л а *(озын паузадан соң читкә, аска карап)*. Ирлегем калмады инде минем, Гөлия... Бөтен булганын чыгарып бетерделәр...

Г ө л и я *(бераз эндәшми торгач)*. Нишләрсең бит... Бәлки, Алла ярдәме белән терелеп китәрсең әле?

Н а с ы й б у л л а. Ташла инде син мине, Гөлия! Әйтәм бит, кияүгә чык, рәхәтләнеп, тулы тормыш белән яшә. Сугышлар бетте инде хәзер...

Г ө л и я. Миңа синнән башка берәү дә кирәкми, Насыйбулла! Кендекләр береккән инде безнең...

Н а с ы й б у л л а. Өч көндәме?

Г ө л и я. Юк, өч көндә генә түгел. Унөч елда! Моны син үзең дә бик яхшы беләсең! Мин сине үлгән дигән хәбәрең килгәч тә ышанмыйча унөч ел буена кайту белән ташлар өчен көтмәдем! *(Пауза.)* ...Хәтерлисеңме? Теге кичтә син мине нәкъ менә шушы урында куып тоткан идең... *(Пауза.)* Ярый соң, нишләрсең бит?! Шулай насыйп булгандыр инде безгә, Насыйбулла...

## XIX күренеш

*Янәдән Насыйбулланың өе. Бабай белән егет сөйләшеп утыралар.*

А й б у л а т. Кайда эшкә керден инде, Насыйбулла бабай?

Н а с ы й б у л л а. Соң халык дошманы, власовчы, нимес һәм американ ышпиуннарын калхуз персидәтеле итеп куймаслар инде?!

А й б у л а т. Кем итеп куйдылар соң?

Н а с ы й б у л л а. Дубырга, куних итеп.

А й б у л а т. Нигә, әйбәт эш инде?! Мин дә авылда калган булсам, ат караучы булып эшләр идем.

Н а с ы й б у л л а. Мин зарланып әйтмим, әйбәт эш.

А й б у л а т. Шулай итеп пенсиягә хәтле ат карадыңмы?

Н а с ы й б у л л а. Юк, пенсиягә чыкканда авылда бригадир идем инде мин.

А й б у л а т. Карале, ә ничек сина паспортсыз пенсия бирделәр соң?

Н а с ы й б у л л а. Мин каян белим инде аны? «Менә сина, Насыйбулла абзый, фәлән кадәр тиеш»,—диделәр дә, бетте китте шуның белән.

А й б у л а т. Ә үзең паспорт артыннан йөреп карамадыңмы?

Н а с ы й б у л л а. Юк.

А й б у л а т. Нигә?

Н а с ы й б у л л а. Ничек дип әйтим? *(Уйланып тора.)* Башта аның кайгысы гел булмады... Аннан... кирәге булмады.

А й б у л а т. Ничек инде паспортның кирәге булмасын?!

Н а с ы й б у л л а. Ә нәрсәгә кирәк ул?

А й б у л а т. Нәрсәгә дип, менә паспортың булса... *(Уйга кала.)* Сугыш ветераны исемен алыр идең! Пенсияне күбрәк түләрләр иде!

Н а с ы й б у л л а. Кирәкми мина аларның пенсиясе! Галаунай, улым, мина тимәсеннәр алар! Үз гомеремне тынычлап яшәп бетерергә ирек бирсеннәр!

А й б у л а т. Нәрсә, һаман борчыйлармыни әле?!

Н а с ы й б у л л а. Ә аларның туктаганы да юк!

А й б у л а т. Кемнең инде ул аларның?

Н а с ы й б у л л а. Тахауның, мәсәлән.

А й б у л а т. Ә нигә алар дисең?

Н а с ы й б у л л а. Соң Тахау шуларның бәйдәге эте бит инде!

А й б у л а т. Кемнәрнең шуларның?

Н а с ы й б у л л а. Кемнәрнең, кемнәрнең!!! Өч хәрефле оешмадагыларның!

А й б у л а т. Кит инде, Насыйбулла бабай! Монысын арттырып әйтәсең инде!

Н а с ы й б у л л а. Нәрсәне арттырып әйтәм?

А й б у л а т. Тахау КГБда эшли дип, мәсәлән.

Н а с ы й б у л л а. Нишләп арттырып әйтим? Арттырмыйм! Аннан соң, анда эшли, димим мин, аларга эшли, дим. Ул үзе мина шулай диде!

А й б у л а т. Ни диде?

Н а с ы й б у л л а. Син, Насый, иркенгә чыктым дип уйлап ялгыша күрмә, мине синең арттан караштыргалап йөрергә куштылар, диде. Һәр адымың, һәр әйткән сүзең турында барысын да белеп торалар, борчылма, һәрберсен җиткереп торам, диде!

А й б у л а т. Чынлапмыни?!

Н а с ы й б у л л а. Чынлап шул! Әле менә бүген төнлә дә минем тәрәзәдә ут сүнмәгәнен сизгәч, йокламагандыр!

*Кинәт дөбер-шатыр ишеккә кага башлыйлар.*

Н а с ы й б у л л а. Кем бар анда?

Т а х а у т а в ы ш ы. Ач, Насый!

Н а с ы й б у л л а. Нишләп йөрисең төн уртасында?

Т а х а у т а в ы ш ы. Ач! Нинди төн булсын ди? Таң атып килә инде!

*Насыйбулла ишекне ача. Тахау керә.*

Т а х а у. Нишләп утыра монда бу малай?

А й б у л а т. Исәнмесез.

Н а с ы й б у л л а. Ә синең ни эшең бар?

Т а х а у. Беләсеңме кем син, Насыйбулла?!

Н а с ы й б у л л а. Беләм! Элемент!

Т а х а у. Галаунае—безнеке түгел син!

Н а с ы й б у л л а. Син безнеке шул менә, шунысы жәл.

Т а х а у. Бурлар кебек, төнлә белән! Бушаткансыңдыр инде күңелеңне, Насыйбулла, сүккәнсеңдер сәвит властын рәхәтләнеп! *(Айбулатка.)* Сүктеме?

А й б у л а т. Юк.

Т а х а у. Алдашма! Сүкте! Күзләреннән күреп торам, рәхәтләнеп издиваца иткән бу сәвит властыннан! Менә әйт

әле миңа, Насыйбулла! Нишләп безнең хөкүмәтнең бер генә яхшы ягын да күрәсең килми синең?

Н а с ы й б у л л а. Бик нык күрәсем килә! Тырышып-тырышып эзлим гомерем буена! Таба гына алмыйм!

Т а х а у *(Насыйбулланың борын төбендә сул кулының имән бармагын болгап).* Ну, ысматри, Насый! Мин моны болай гына калдырмыйм! Әбизәтелни тиешле җиргә җиткерәм мин моны!

Н а с ы й б у л л а *(кул таягын алып).* Каяле минем такси? Бар әле, ычкын әле моннан яхшы чакта!

Т а х а у *(Тахау артка чигенеп).* Син миңа янама, яме! Җавап бирәсең булыр!

Н а с ы й б у л л а *(кисәк кычкырып).* Тай моннан, дим!

*Тахау абына-сөртенә чыгып китә.*

Н а с ы й б у л л а. Ну, кабахәт кеше дә соң инде! Каян чыга кешедән шулчаклы агу? Алла боерса, ул үлмичә, мин үлмим әле! Башта аны җиргә күмеп куйганнарын үз күзләрем белән күрәм, аннан соң инде тынычланып, дөньялар аз булса да чистарды, дип үземә үлсәм дә ярый.

*Насыйбулла кул таягын кире куеп, урынына килеп утыра.*

Н а с ы й б у л л а. Кызганам да инде мин ул мескенне!

А й б у л а т. Кемне, Тахаунымы?

Н а с ы й б у л л а. Әйе.

А й б у л а т. Ничек инде кызганасың?

Н а с ы й б у л л а. Балаларының да җүне булмады...

А й б у л а т. Оясында ни күрсә, очканында шул булыр...

Н а с ы й б у л л а. Мин әле хыт нужа чигә-чигә булса да дөнья күреп кайттым, ә ул бит авыл көтүлегеннән ерак киткән кеше түгел! Миңа авылдан чыгарга ярамагач, ул да чыкмый инде. Ул югында мин ниләр кырмам?!

А й б у л а т. Чынлап, Тахау авылдан бер дә чыкмаганмыни?!

Н а с ы й б у л л а. Чынлап инде! Әллә син ул Тахауны миңа паспорт алдыртыр иде, дисеңме?

А й б у л а т. Алгансың бит әле менә.

Н а с ы й б у л л а. Локманга рәхмәт инде! Ул йөрде артыннан.

А й б у л а т. Локман?!

Н а с ы й б у л л а. Әйе, Локман.

А й б у л а т. Авыл советы председателеме?

Н а с ы й б у л л а. Әйе.

А й б у л а т. Ә нишләп соң ул миңа бу турыда бер сүз дә әйтмәде? Глава килде дә хәл итте, дигән була.

Н а с ы й б у л л а. Ни дип әйтсен инде, шулай кушкач?

А й б у л а т. Ә син главага приемга бардыңмы соң?

Н а с ы й б у л л а. Кайчан?

А й б у л а т. Паспорт алыр алдыннан.

Н а с ы й б у л л а. Бармадым мин беркая да! Әйтәм бит, Локман йөрде артыннан!

А й б у л а т. Кызык кеше булып чыкты бу Локман!

Н а с ы й б у л л а. У-у-у!!! Син аны белмисең әле! Бик нык кызык кеше ул! Чучкалар асрый. Үзе ашамый, сата. Ашамагач гөнаһасы азрак булыр дип ышана микән инде? Коеп куйган силсәвит персидәтеле инде! Өйләндерде дә инде ул мине.

А й б у л а т. Ә ник ул икенче хатының белән тормадың?

Н а с ы й б у л л а. Әй!

А й б у л а т *(хәйләкәр елмаеп).* Рәт юкмыни?

Н а с ы й б у л л а. Бар, нишләп булмасын?! Кешечә яши башлагач, Гөлиям тәрбияләп торгач, терелдем мин.

А й б у л а т. Кайчан?

Н а с ы й б у л л а. Кайчан дип?.. Кайтканга бер ун ел булгандыр.

А й б у л а т. Ник тагын бер өйләнеп карамыйсың соң? Бәлки, бүтәне ошар. Беткәнмени авылда ялгыз карчыклар?

Н а с ы й б у л л а. Ялгыз карчыклар бүре бугы! Гөлия генә юк шул араларында.

А й б у л а т. Ә-ә-ә... Күптән вафатмы соң Гөлияң?

Н а с ы й б у л л а. Унбиш ел инде. Бәхилләп китте ул мине. «Рәхмәт сиңа, Насыйбулла, рәхәт яшәдем мин синең белән»,—дигән булды мәрхүмкәем. Югыйсә, миңа кияүгә чыккач Гөлиянең атасы кызыннан баш тартты. «Моннан соң минем кызым юк!»—диде. Бер әйтсә, тешләп өзгән кебек ди торган иде Гө-

лия, нәкъ шулай булып чыкты да. Тәки үлгәнче Гөлияне кызы дип танымады. Хатынына да Гөлия белән очрашырга рөхсәт итми иде, качып кына күрешеп йөрделәр. Белеп алса, хатынын эттән алып эткә сала иде мәрхүм... *(Пауза.)* Көтеп ята торгандыр инде Гөлия апаң мине теге дөньяда: «Кайчан килер микән Насыйбуллам?»—ди торгандыр. Бу дөньяда күпме көтте, хәзер теге дөньяда көтә...

Айбулат. Да-а-а, бик зур очерк чыгарга тора әле монда. Жинүнең алтмыш еллыгына багышланган санга ничек шәп итеп язып житештерергә моны? Булдырып булса инде?

Насыйбулла. Анысы өчен борчылмасаң да була, улым. Сиңа барыбер үзең теләгәнчә итеп язарга ирек куймыйлар. Минем турыда Жиңү саныгызда берни дә чыкмаячак.

Айбулат. Ничек инде чыкмаячак? Нигә?

Насыйбулла. Син бит дәүләт гәжитендә эшлисең. Нишләп дәүләт хәтле дәүләт, шулхәтле ялчы тотып, күпме акча түгеп, үз гәжитендә үзен фаш итеп ятсын инде? Уйлап кара!

Айбулат. Юк! Мин барыбер язам, барыбер бастырам!

Насыйбулла. Карарбыз!.. Лаврентий югалды әле нишләптер! Күптән күренгәне юк инде. Тагын нинди этлектә йөри микән?

Айбулат. Кем соң ул Лаврентий?

Насыйбулла. Кем түгел, нәрсә! Минем песи ул.

Айбулат. Лаврентий исемлемени?

Насыйбулла. Әйе.

Айбулат. Ә нигә андый сәер исем куштың?

Насыйбулла. Явыз булганга! Син дә Локман булып утырма инде, бәйләнмә шул исемгә!

Айбулат. Карале, Насыйбулла бабай, Локман димәктән, көндез аның белән бергә килгәч, ник син миңа берни дә сөйләмәдең, төнлә кил, дип пышылдадың? Ул да тыңлап торса ни була?

Насыйбулла. Юкка үткәргәнбез бугай без синең белән бу төнне, Айбулат.

Айбулат. Нигә?

Насыйбулла. Нидербигә! Соң әйтеп торам бит мин сиңа, теләсә кайсы дәүләт—ул кешене изү системасы. Менә шул Локман кебек хөкүмәт кешеләренең кулы белән эшләнә бит инде шул изү, кысу, буу! Әнә, Мөдәррис Әгъләм язган бер шигырендә...

Айбулат. Син Мөдәррис Әгъләмне дә укыйсыңмыни?

Насыйбулла. Нигә укымаска?! «Тышауланган сөю буламыни?» дигән. Ә тышауланган бәхет буламы? Син миннән бүген: «Абага алмасы ачы була, дигәнеңне ничек аңларга?»—дип сораган идең. Менә хәзер аңлатам! Абага чәчәген тапкан кеше бәхетле була бит инде, имеш, гәрчә ул чәчәк әкиятләрдә генә булса да! Ә безнең менә бу Алла каргаган дәүләттә, иманым камил, абаганың чәчәген генә түгел, хәтта шул чәчәктән житешкән алмасын тапсаң да, ул барыбер авызга каба алмаслык ачы булыр иде! Агулы булмаса әле! Чөнки Локман кебек хөкүмәт кешеләре ул абага алмаларын агулап чыгар иде! Кешегә эләгә күрмәсен, бәхетле була күрмәсеннәр тагын дип!

Айбулат. Юк, миңа калса, Локман әйбәт кешедер кебек. Әнә паспорт алып биргән әле сиңа.

Насыйбулла. Ник кирәк миңа мондый дәүләтнең паспорты?! Мин—үзем дәүләт!!!

*Тагын ишек кагалар.*

Насыйбулла. Кем бар анда?

Локман тавышы. Насыйбулла абзый! Ач әле! Мин идем әле бу, Локман.

*Насыйбулла торып Локманны ишек ачып кертә.*

Локман. Исәннәрмесез!

Айбулат. Исәнмесез.

Насыйбулла. Сәлам! Нишләп йөрисең таң бәтәрәеннән? Тахау кереп уяттымыни?

Локман *(тавышын көчәйтә төшеп)*. Ә син каян беләсең?! Хәер, сез бер-берегез турында бөтенесен дә беләсез инде, панимаешь!

Насыйбулла. Соң белмичә?! Сиксән ел вәевәйт ит тә?! Белерсең!

Локман. Айбулат, син ни... Киткән идең бит...

Айбулат. Кире килдем!

Н а с ы й б у л л а. Син, Локман, юк өчен борчылма. Айбулат үзебезнең малай ул.

Л о к м а н. Юк соң, әллә ничек бит... Бездән качып... Берәр ничек комачауладыкмыни без? Алайса, гафу итегез! Без үзебезчә булышырга теләгән идек, понимаешь.

А й б у л а т. Локман абзый, сез чыннан да юк өчен борчылмагыз. *(Исенә төшереп.)* Насыйбулла бабай! Мин бит сине фотога төшерергә онытканмын!

Н а с ы й б у л л а. Әйдә, алайса, менә Локман белән икебезне төшер әле!

Л о к м а н. Юк ла, мин кирәкмим инде анда!

Н а с ы й б у л л а. Әйдә, әйдә! Бас!

*Насыйбулла Локманны терсәгеннән тотып үзе янына тартып китерә.*

*Айбулат башта икесен бергә, аннан соң Насыйбулланың үзен генә бастырып та, утыртып та берничә мәртәбә фотога төшерә.*

А й б у л а т. Газетада бастырырга иң уңышлысын сайлап алам мин аның. *(Тәрәзәгә карап.)* Таң атып беткән икән инде! Китим әле мин. Казанга хәтле кайтасы да бар.

Н а с ы й б у л л а. Ярар, улым! Рәхмәт килүеңә. Әллә ни кунак итеп булмады инде, гаепкә бөкмәссең.

А й б у л а т. Юк ла, нинди гаепләү ди инде ул! Сау бул, Насыйбулла бабай! Сәламәт бул! Озак яшә, тыныч яшә, яме!

Н а с ы й б у л л а. Рәхмәт, улым.

*Кул бирешеп хушлашалар.*

А й б у л а т. Локман абзый, син мине ачуланып калма инде?!

Л о к м а н. Ачуланмыйм. Нишләп ачуланыйм? *(«Шап!» итеп кул бирешәләр.)*

А й б у л а т *(киенә-киенә борын астына көйли).* Без китәбез инде, сез каласыз...

Л о к м а н. Лариса Мирзагитовна нитмәсә генә инде?

## XX күренеш

*Шунда ук, Насыйбулланың өе буш. «Идел таннары» газетасын күтәреп Насыйбулла керә. Ашыкмыйча гына өстәл янына килеп утыра, күзлеген кия. Газета арасыннан хат килеп төшә.*

Н а с ы й б у л л а *(караватта яткан песигә).* Лаврентий! Ишетәсеңме? Айбулат хат язып җибәргән! Ни язды икән, әйдә укып карыйк әле. *(Хатны ача.)* Тә-ә-әк. Исәнме, Насыйбулла бабай, дигән. Сиңа Казаннан кайнар сәламнәр белән Айбулат хат яза, дигән. Лаврентийга да сәлам, дигән! Карале, Лаврентий, сине дә онытмаган бит бу! *(Авыз эченнән генә мыгырданып укый.)* Язам, язам, дигән булган иде, язган язуын, тик бастырмаганнар гына мәкаләсен, шуңа гафу үтенә. Лариса Мирзагитовна ызванийт иткән редакторларына! Соң, аның ызванийт итәсе билгеле иде инде! Тукта, ә монысы нәрсә? «Дөресен генә әйткәндә, Насыйбулла бабай, синең алда без барыбыз да баш иеп гафу үтенергә тиеш, беренче чиратта—дәүләт җитәкчеләре. Ләкин син дөрес әйтәсең, абага алмасы ачы була. Шуңа күрә алар өчен мин синең алда гафу үтенәм. Гафу ит, Насыйбулла бабай!»... Дигән... *(Пауза.)* Лаврентий! Синең дустың Сталин ни әйткән әле? «Дети за отцов не отвечают» дигәнме?

*Насыйбулла күзлеген салып өстәлгә куя.*

*Карават янына барып песине кулына алып утыра да авыз чите белән генә елмаеп куя. Радиодан «День Победы» җыры яңгырый.*

Н а с ы й б у л л а. Нәрсә ди? Паспорт дигән буламы? Ә, Лаврентий?

*(Тәмам.)*



Ирек
Сабиров

## Ә УЙЛАРЫМ—ЗАРЛЫ ҺӘМ АЧЫ...

### Эзлим...

**Илһам тумый. Әллә нәрсә кирәк.
Һәр күргәнен язмый каләмнәр.
Җирдә вакыйгалар тулып ята,
Ә мин сюжет эзлим Галәмнән:**

**Язар азык эзлим. Янәшәмнең
Күрә белмим агын-карасын.
Төнге күкне болыт капласа да
Йолдызларга оча карашым.**

### Татар җыры фестивале

**Куркытмады безне бураннар да,
Наданнардан яуган каһәр дә—
Өч көн шаулап торды татар җыры
Урыс кайнап торган шәһәрдә.
Йөрәгемне назлый даһи моңнар,
Ә уйларым зарлы һәм ачы:
Бер егерме елдан татар җырын
Табылырмы монда җырлаучы?**

### Тарих

**Бүген, имин һәм болытсыз туып
Торган чорда һәрбер иртәбез,
Без, тарихны китаплардан укып,
Ничек җиңел фикер йөртәбез:**

**Имеш, борынгылар җәфаланган
Узмыш таба алмый язмыштан;
Хакимнәр дә камил булмаганнар:
Тегесе юньсез, монысы ялгышкан...**

Ирек САБИРОВ (1950)—*шагыйрь; "Манзара", "Аваз", "Апрель" һ.б. шигырь китаплары авторы. Чиләбе өлкәсенең Еманжелинск (Яман Елга) шәһәрендә яши.*

Күрә торып ычкындырылган бит
Теге мөмкинлекләр, бу форсат...
...Чорлар, ханнар, ерак бабаларны
Сүгеп, тәнкыйтьләве—бик ансат.

Ә үзебез? Әнә, кайный дөнья!
Уйлап кына кара син бары:
Күпме гөнаһ, күпме ялгышлыклар
Кыла бүгенге көн ханнары!

Болгар. Алтын Урда. Явыз Иван,
Ленин, Гитлер, тагын ары кит—
Кайтмас булып узып киткән көн дә—
Ул кичәге бүген бары тик.

Терсәкне дә тешләп була—ләкин
Кабатланмый тарих яңадан;
Болгарларга кайтып булмагандай,
Кайтып булмый узган таңга да.

Шигърият һәм гакыл исән чакта,
Корып егылганчы соңгы гөл,
Бүгенгене камил итү кирәк,
Бүгенгене... Әле соң түгел!

## Юлда

*Т.-гә*

Йөрүзәнне узам. Юл кырында
Бар мәһабәт текә бер кыя:
Таш кальгадай үзе, ә башында—
Наратлардан купшы такыя.

Шул кыяга кемдер әллә гарьдән,
Әллә иләсләнеп шат яздан,
Адәм менәлмәслек биеклектә:
"Бәхетле бул, бәгърем,"—дип язган.

Шушы җөмлә актарыплар ташлый
Һәр юлчының фикер-хисләрен.
Минем дә шул—йөрәк сызлап куйды:
"Нишләдең син, бәгърем, нишләдең?.."

Гаеплемен: бәхет бирәлмадым.
Хәзер каршы алам һәр таңны:
"Кичер мине, бәгърем,"—диеп, әмма
Беләм: инде соң һәм караңгы...

## Миңа җиткән...

Тынгы белми адәм: арттырмакчы
Ил данын һәм... илдә үз данын:
Бер мактаулы исем алыр өчен
Кемдер сата хәтта вөҗданын.

Ул коткыга гамьсез минем хисем,
Карап торам шуңа гел читтән:
Ирек Нәгыйм улы дигән исем
Бу тормышта миңа бик җиткән.

Миңа җитә, шигъри юлларыма
Төгәл булып кучсә уй очым,
"Мин әйтергә теләгәнне әйткән,"—
Дип укыса һәрбер укучым...

## Казанга кайтам

Кайтмам диеп чыгып киткән идем,
Капчыгымны салып җилкәмә...
Тамырларым тартып газаплады:
Мин Казанга кайтам иртәгә.

Минем җырны моннан ишетмидер
Бишбалта да, Яңа Бистә дә.
Бер кычкырып җырлап килим әле:
Мин Казанга кайтам иртәгә.

Бәлки әле минем тавышым да
Моңнар өстәр кичке азанга.
Фани эшләремне читкә ташлап,
Мин иртәгә кайтам Казанга...

## Бәһа

Мин үземне зур зат диеп саный алмыйм,
Үз-үземә бераз көлемсерәп карыйм,
Мәҗлесләрдә савыт тотып сөрән салмыйм;
Түрдән түгел, бусагадан урын сайлыйм.

Юк, юк,—шыңшып, елап, мескенләнеп йөрмим,
Тик, чынлап та, үз бәямне үлчи белмим.
Әгәр халкым күңелендә калса эзем,
Соң булса да, искә алыр милләтем, дим.

## Табигать

Болыннарга чыгам яңгырдан соң:
Тәнгә-җанга ләззәт вә сихәт.
Әй, тыңлагыз, кала әсирләре:
Табигатьтә бөтен хакыйкать!

Җәйге алан камиллеккә өнди—
Читтә торсын үгет-нәсихәт...
Әй, сәяси уйнаш ялчылары,
Табигатьтә бөтен хакыйкать!

Туган халкым! Бәхетемне таптым
Синең белән генә мин фәкать...
Әй, адашып арган йөрәккәем!
Табигатьтә икән хакыйкать...

## Шигырь язам

Шигыремне камил итәр өчен
Бер сүз җитми,—җигеп бөтен көчем,
Барлык белемемне күзаллыйм.
Бер төгәл сүз кирәк: табигатьтә
Бар ул, беләм,—ләкин табалмыйм.

Менә, таптым, диеп, куеп карыйм
Шигъри юлга—моңы бозыла.
Ә йөрәктә язылмаган җырлар
Кайнап, ярдан ашып, узына:

Сүзгә сусап, ярлырга тора
Касыйдәләр, газәл, мөнәҗәт...
Бердәнбер сүз... төннәр буе эзлим...
Нинди авыр газап...
Һәм ләззәт!..

## Сөю

Кайчак пыскып уза гомер,
Янмый сүнә сөюләр;
Сәбәбен дә аңламаслык:
Кем туң йөрәк, кем юләр?

Кайчак исә, күкрәп килсә,
Мәхәббәт тиң яшенгә...
Кайтсын яшьлек, бергә яшьник,
Хисләреңне яшермә.

Үкенечкә калыр, назлы
Тойгылар булса харап...
Янма бушка, гомер кыска,
Сөю күпкә кыскарак.

## Алар һәм без

Борынзаман шагыйрьләре, имеш,
Нинди даһи, нинди асыллар;
Римлыларны гына укып кара:
Горацийлар, Тибулл, Катуллар...
Ләкин шанлы исемнәрне ятлап,
Шаккатма син ятка, якташым:
Бездә Горацийлар булмагандай,
Римның да бит юктыр Такташы...

## Кемгә хат языйм?

Чиктән ашты вакыт тизләнеше:
Иртән—бәби туе, кич—ясин...
Уй-хисләрем кайный. Кемгә сөйлим,
Бер утырып кемгә хат языйм?

Телсез дөнья! Тамга, ымнар чоры.
Яхшымы бу, белмим, яманмы?
Кире кайтмас шигъри дәвер булып
Артта калган хатлар заманы.

Әңгәмәдәш тапмаганнан шашып
(Кем елмаер безгә, кем елар?),
Йөрәгемне талый, эчтән ашый
Ялкынсынган фикер-тойгылар.

Дуслар, дисәм,—ниятләре фани
Ихтыяҗлар белән чикләнгән;
Һәрберсенең йөзе битараф та,
Һәммәсенең җаны бикләнгән.

...Гыйнвар көртләрендә әллә кояш,
Әллә узган гасыр чагыла?
...Кышкы төннәр буе хатлар язам
Мин үземнең малай чагыма.

♣



Рашат
Низами

## БОМЖ

ХИКӘЯ

Ничек болай булды соң әле бу?

Түбәнгә таба ничекләр тәгәрәде, шушындый аяныч хәлләргә кайчан, ничек, ни рәвешле килеп төште соң ул? Язмышның кара тамгасымы бу? Юкса, болай дөрес яшәде, рәнжеш алырлык гөнаһ-фәләннәргә дә кереп батмады кебек...

Соңгы көннәрдә әнә шундыйрак сораулар аны кигәвендәй бертуктаусыз игәүләп тора, әрсез-талымсыз бер кортсыман, җанын кимерә. Алай гына да түгел, авыр таш кебек, бөтен җилкәсен басып тора. Шунлыктандыр, соңгы вакытларда гәүдәсе дә сорау билгеседәй алга иелеп төште аның.

Хәлбуки, бу сорауларның җавабын белә, бик яхшы белә ул. Тик моны кемгә сөйлисең дә, кемнәргә ничегрәк итеп аңлатасың... Кычкырып көләчәкләр, "җебегән!" дип, хурлыклы тамга сугарга да күп сорамаслар...

Намусың каршында сөйләп, үз-үзеңне күпмедер юатсаң гына инде. Бәлки, әзрәк кенә тәүбә дигән нәрсә килеп чыгар. Үзеңә дә, башкаларга да гыйбрәт өчен.

Менә бит язмыш: һич тә көтмәгән-уйламаганда тиктомалдан диярлек сукбай хәлендә бер ялгызы урамда утырып калды... Ә бит бомжлык кыйссасы, искә төшерсәң, мажаралы кинолардан да болайрак килеп чыкты...

...Бик күп һөнәрләр остасы Таһирҗан, заводта байтак еллар эшләгәннән соң, ниһаять, тугыз катлы йорттан үзенә фатир алды, гаиләсен сөендерде. Әмма аны тора-бара бер нәрсә харап итте: йөз төрле сәбәпләр аркасында соңгы елларда кинәт кенә аракы белән дуслашып китте ул, аракыга бил бөкте. Үзе генә белгән "картинка" менә болайрак һәм игезәк көннәр кебек гел бер төслерәк килеп чыга иде: кичләрен стакан төбенә төшкәнче гөрләтеп эчәсең, ә инде иртән... үтереп баш авырта, чыдар әмәл юк. Кемдер әйтмешли, ашказанында шүрәлеләр утын кисә...

Иртәгесенме? Иртәгесен башкаенда бер генә уй бөтерелә, дөресрәге, бораулый: ничекләр итеп баш төзәтергә икән дә, ничекләр итеп шушы тоныкт-карангы дөньядан якты га чыгасы? Моның өчен ул кайчакларны теләсә ни эшләргә, хәтта җир читенә китәргә дә риза. Ләкин анда аны

Рашат НИЗАМИ (1950) — *язучы. "Кызыл җәй", "Яшьлеккә хат", "Тормыш трамвае" китаплары авторы. Казанда яши.*

көтеп торучы бар микән соң? Вәт кайда мәсьәлә!

Шулай да кайчакларны әллә каян гына дөньяның рәхим-шәфкатьләре елмаеп куя аңа. Менә бүген дә...

Таһирҗан, иртә таңнан үк торып, өйләрендәге чүп чиләгенә үрелде. Урамга, һавага, кояш астына чыгарга бер сәбәп, гап-гади сылтау инде. Баскычлардан төшеп, туп-туры ишегалдына тәпиләде. Чү! Гөнаһ шомлыгы дияргәме моны: нәкъ аның каршыннан, аяк астыннан диярлек, юлын аркылы кисеп, кара мәче узып китте...

Имәнеп китәргә ашыкмады ул. "Төкерәмсәнә төрле ырымнарга, исем дә китми",—дип үзен-үзе юатырга азаплануы иде. Шулай да, кара мәченең күләгәсен ярым-җете күзләре белән якынча шәйләп өлгергән иде. Адымнарына ныклык бирергә тырышып, атлый бирде.

Таһирҗан эре панель шакмаклардан салынган тугыз катлы гадәти бер йортта яши иде. Анлаганнар өчен мәгълүм ки, йорт—җитмешенче еллар җимеше. Хәзер инде бүтәнчәрәк манзаралар: тимер рәшәткәләр белән урап алынган, өч төрле кирпечтән эшләнгән, плиткалар белән тышланган "элитный дом"нар китте әнә. Менә алар каршысындарак та бар шундый йортларның берсе...

Анда инде бүтәнчәрәк кешеләр, ягъни бүгенге замана байлары, хәллерәк кешеләр яшәп ята. Боларның акча-мазасы да күп, теләк-мөмкинлекләре дә зурдан.

Яңа көн үзенә ниләр китерәсен белсә икән Таһирҗан!

Чүплек савытларына таба якынайды. Квадрат рәвешендәге дәү тимер ящикләр рәтендә ишек-бусага, такта-плинтус, плитә һәм измә, гәҗит калдыклары өем-өем оешып ята иде. Зурдан кубып, "теге"ләр евроремонт ясаган, күрәсең...

Әлеге буталчык сурәтләрне күздән кичереп тә өлгермәде, шулвакыт чүп-чар, ремонт калдыклары белән дыңгычлап тутырылган тимер тартмаларның берсендә, чикерткә сайрагандай итеп, телефонга охшаш бер аваз чылтырады!

Мондый хәл, мондый тамаша кино-әкиятләрдә генә булырга мөмкин ләбаса...

Әллә берәр "инопланетянин" төшеп утырганмы бирегә? Ә шулай да күңел алгысына, чүп чиләген бер кырыйга этәргән куллары "космос"тан килгән авазларга таба үрелә. Әллә саташамы, колагына әнә шулай ялгыш ишетеләме соң?

Ни булса булыр, кармаланып, чүп-чарларны аралап, үзенең табышына таба якынайды. Тиз генә табылмый да, каһәр! Замана чире—евроремонт белән мавыгучылар ялгыш "ташлап" калдырган бер-бер хикмәт бу, һичшиксез.

Кичәге "күңел бәйрәме"ннән соң Таһирҗанның күңеле коргаксыган, башы чатнаган чак иде шул. Әх, булса икән калтырча йөрәкнең уртасына бер чәркә аракы! Дөньясы түгәрәкләнеп китәр иде. Кулдагы чүп чиләге нәрсә ул—әһәмиятсез бер йомры кисәге.

Иртәдән әнә шундый чуалчык уйлар белән, бер йотым һавага сусап, авырсынып, ә шулай да ниндидер могҗизага ышанып чыккан иде ул үзләренең ишегалдына...

Ә могҗиза дигәнең аны, чыннан да, көтеп кенә торган икән.

Чүплек савытларының берсеннән, чыр-чыр килеп, телефон тавышы ишетелү—гайре табигый хәл түгел, коеп куйган чынбарлык иде... Комарланып, ике куллап актарына торгач, чүп-чар арасында чикылдап утырган кесә телефонын ансат кына эзләп тапты. Куанычыннан, хәзинәгә юлыккан юлбасардай, чак кына кычкырып җибәрмәде! Ломбардкамы? Туп-туры ломбардка...

Юк! Ашыкмый торсын әле. Кем кемгә шалтырата икән? Табылдыгына янә бер комарлык белән ике куллап ябышты, томанлы фантазиясе уйный башлаган иде аның.

Кнопкага басу белән, телефоннан яңгыраган беренче сүзләр колагына үтеп керде, ниһаять:

—Алло-алло! Виктор Аминович!

—Я вас слушаю... Здравствуйте!..

Таһирҗан минуты-секунды белән рольгә кереп бара иде инде.

Шулай бер-берсенә хәерле көн теләгәннән соң ничектер татарчага күчтеләр.

—Хөрмәтле шеф, бүген нинди заданиеләр кушасыз?

Исемен дә оныта язган Таһирҗан, алдын-артын да уйлап тормастан, мәсьәләне үзе өчен "иң авырткан" җирдән элэктереп алды. Җавабы кыска, үзенә калса, таләпчән дә иде:

—Ике капчык цемент, ике ярты, бер ящик сыра... Барасы адресмы? Языгыз, бакча адресы... Анда сезне, ни-теге... Таһирҗан каршылар. Точка!

Үзенең артистларча оста уйнавыннан ирнең авызы коймактай җәелде. Ашар-эчәр ризыкларны күз алдына китерүдән төкереген ләззәт белән йотып куйды. Бөтенесе—бушка, халявага, чит хисапка... Күктән төшкән бәхет булачак бу! Иң мөһиме—баш төзәләчәк, бакчадагы кирпеч-цемент эшләре дә алга китәчәк, боерган булса...

Ир башы белән сабыйларча куанып, әнә шулай ихластан шатланган, фикер йөрткән иде шул чакларда.

Таһирҗанның тавышын, ныклы сөйләшүен чын-чынлап хуҗаныкы дип кабул иттеләр, ахрысы. Ул бит аларны чынлап та дачасына, шәһәрдән егерме чакрым читтәге бакчасына чакырган иде. Адресы төгәл әйтелгән. Килерләр, "ә" дигәндә "җә" дип тордылар, көчләп әйттермәде ич...

***

Әйе, ике сәгать чамасы дигәндә Таһирҗанның бакча-дачасына килеп тә җитте теге гаярь егетләр... Хәзер, кайта төшеп уйласаң, искитмәле хәлләр иде бит бу: аны аракы һәм затлы колбаса белән бик һәйбәтләп сыйладылар. Баштарак. Аннары... аннары инде аяк-кулларын бәйләп, этә-төртә машина фургонына кертеп салдылар... Калганын инде ул юнләп хәтерләми дә. Детективларда әйтелгәнчә, аны билгесез юнәлештә каядыр алып киттеләр. Шулай да бер нәрсә хәтерендә: баштарак кәефе шактый күтәренке рухта иде аның. Аннары—томан, томан... караңгылык... Алар бергә кушылып, җай гына чайкала, алар белән бергә Таһирҗанның да тәне-гәүдәсе чайкала...

Әллә каян килеп чыккан менә шушы хәерсез көннән соң ул чын мәгънәсендә колга, урысчалатып әйтсәк, "рабсила"га әйләнде дә куйды. Кирпеч коймалар белән уратылган алагаем иркен, икенче бер дөньяга килеп эләкте. Биек коймалар артында—чыршы-нарат, каен-усак ише агачларның колач-колач ябалдашлары. Алар иректә, ирек һавасын сулап яшиләр. Ә ул—капкында. Капкынга эләккән бүре аягын чәйнәп өзеп кача, диләр. Биредә андый мөмкинлек юк. Ачу килгәндә бары янак итләреңне генә чәйни аласың. Сактагыларның бөркет күзе һәр кыймылдаганыңны, хәрәкәтеңне күреп-белеп тора. Хәтта милиция киемендәгеләр дә күренгәләп ала бирелә...

Шөкер, ярый әле кыйнамадылар, аяк-кулларын имгәтмәделәр. Ә моның өчен яхшы "дисциплина", тырышлык белән түләргә кирәк. Хәер, аның эшчән, хезмәттән бүтәнне белмәгән аяк-куллары төзелеш өчен бик тә кирәк, бик тә мөһим булган шул. Араларыннан Артем исемле берәү әнә карышырга, тыңламаска тырышып караган иде, башына капчык киертеп, аны да бик тиз акылга утырттылар.

Чынбарлык ачы иде: коллыкка урлап киткәннәр икән аны...

Ул хәзер беркем дә түгел. Тормыштагы бөтен хокуклары бер мизгел эчендә диярлек төтендәй юкка чыкты. Тор. Эшлә. Аша. Ят. Көннең көнендә әнә шул хәлләр кабатлана.

Көннәрнең берендә урман почмагында күке кычкырды. Сискәндерми, ләкин моңайта, уйландыра. Кемнәрнең гомерен яисә өенә әйләнеп кайтыр көннәрен санады икән ул? Җавап юк.

Көн арты көн измә ясау, кирпеч салу, ишек-тәрәзә борысларын көйләү, такта-бүрәнә юну эшләренә китә.

Әйтерең бармы, утар-биләмә хуҗалары яңа байларча яши. Урман тикле урман эчендә ярымагачтан, ярымкирпечтән хан сараедай бина салып яталар. Хәзер бу—әллә кайлардан килеп кергән ят бер сүз белән "коттедж" дип атала бугай.

***

Озын җәйләр узып, күкеләр тавышы тынып, урмандагы агачлар яфрагын койды.

Вак-төякләрне исәпләмәгәндә, төзелеш эшләре ахыргача түгәрәкләнде. Хәзергәчә аңлап бетерә алганы юк, ни могҗиза булгандыр: көннәрнең берендә күзләрен кара тасма белән бәйләп, үзләре белгән яшертен юллар белән, Таһирҗан дигән эш атын туган шәһәренә кайтарып та ташладылар. Үзенең тоткынлык тарихын берәүгә дә берничек тә берни сөйләмәскә дигән катгый кисәтү белән, билгеле.

Каты куллы шома бу егетләрнең әйткәнен тыңламасаң, антыңны бозсаң, ни-нәрсә буласы тел төпләреннән бик тә мәгънәле аңлашыла иде. Алга таба яшисең килсә, телеңне читлектә тот, янәсе...

Ә яшисе килә иде шул, шайтан алгыры!

Күзләрен каплап торган кара тасманы чишеп җибәргәндә... төс-кыяфәте, марка-фәләне билгесез булган машинадан җилләр искән иде инде. Шәһәр читендәге ялан кыр уртасыннан шәһәргә таба тәпиләргә туры килде. Ашыгып, ярым куркып, ярым кабаланып.

Саташкан бер зат сыман, менә үз йортына, фатирына, гаиләсенә кайтып барышы аның. Урмандагы теге тоткынлыктан соң шау-шулы урамнар да, дөбердәп чапкан трамвайлар да ничектер сәер тоелды. Шәһәрдә яңарак пәйда булган кызыл автобуслар, котырган үгездәй ярсып, менә-менә өстенә ташланыр да сытып китәр шикелле иде. Ә кешеләр, кешеләр? Алар бар да бәхетле, тук чырайлы түгелме соң? Таһирҗан гына...

Ниһаять, әнә, үз йорты. Таныш почмаклар, тротуар, чокыр-чакырлы асфальт, балконнардагы ярымачык тәрәзәләр... Чү, әнә, аларның тәрәзәсеннән, очынырдай булып, нindiдер ак яулык тирбәнә түгелме? Ак ситсы кисәге—сугыш-орышларда җиңелү билгесе... Юк-юк, Таһирҗанның тормыш сынаулары каршында ак флаг күтәрергә уйлаганы да юк.

Ниндидер бер эчке тоем белән кесәләрен капшагандай итте. Ләкин анда ни фатир ачкычы, ни паспорт-документлары юклыгын аңлап, бу гамәленнән кире чигенде.

Менә... кара дермантин белән тышланган таныш ишек. Бердәнбер сыеныр урыны шушы бит аның. Менә күрерсез, эчүен дә ташлар. Тормыш кадерен белеп, гаиләсен борчымый гына яши дә башлар. Күңелендәге шушы хыялый уйларның чынлыгына ышаныч өстәргә тырышып, кыңгырау төймәсенә басты.

Тынлык... Бер минут чамасы әлеге тынлык аңа сәгатьтән артык тоелды бугай. Ишекнең теге ягыннан кемнендер атлап килгәне ишетелде, анда кечкенә күзлек тәрәзеннән күзәткәнен дә чамалап була иде. Бераздан гына

тимер тоткалы ишек яртылаш чамасы диярлек ачылды. Ул анда тораташ кыяфәтле хатынын күрермен дигән иде. Ә ишек артында...

Ишек артында—таныш түгел томсыз гына бер ирнең пеләш башы шәйләнде. Таһиржан, үз күзләренә үзе ышанмыйча, бер мәлгә телсез-өнсез калган иде. Шул арада теге бәндә аның аяк астына, берничә йөзлек ташлады. "Менә сиңа... фатирың өчен акча. Рәхмәт әйт тә, бүтәнчә бирегә аяк атлыйсы булма!"

Ишек "шалт" итеп ябылганда: "Паспортың яндырылган, эзләп йөрисе булма!"—дигән сүзләр генә колагына кереп калды. Шулай итеп, язмыш аңа янәдән кара мөһер сукты.

Беркатлы, ышанучан кеше буларак, Таһиржан боларны бик авырдан кичерде. Элек-электән мажаралар эзләргә яраткан хатыны түзмәгән, саткан аны, бүтән кешегә алмаштырган әнә. Чеп-чиста, ап-ачык хыянәт. Моны ничек йотып җибәрмәк кирәк?

Фәкать аракы белән коендырыргадыр, бәлки... Акрынлап тагын эчүчелеккә сабышты ул. Азнакайда яшәп яткан әти-әнисе янына кайтып егылмакчы иде, бу уеннан да кире кайтты. Бигрәкләр оят бит, ничек кайтып күзләренә күренерсен...

Менә шулай сукбай хәленә төште ул. Такыр кесәдә һәм күнелдә ямьсез бушлык. Ә бушлыкны, мәгълүм булганча, нәрсә беләндер тутырырга кирәк. Дөрес анысы, бәи-карчыклар сыман, шешә җыюлар белән мавыкмады ул. Хәер сорашу сукмагына да басмады. Җае чыкканда, кара эшләрдә бил бөгеп, тамак ялына азмы-күпме акча юнәтергә тырышты.

Аңа бу чоңгылдан ничек тә үрмәләп чыгарга кирәк иде. Тик ничек итеп? Менә шушы сорау эчен яндыра, бавырын көйдерә. Кышын канализация торбалары тирәсенә елышуны күнеле берничек тә кабул итә алмас кебек.

Ниһаять, аңында ап-ачык бер фикер оешты: дачадагы бакчасына барырга, андагы хәлләрне ачыкларга... Анысын да югалтмаган булса, тәбәнәк йортында кечерәк кенә моржа чыгарыр, ике куллап янәдән балта эшенә тотыныр...

Таһиржанның чүп савытлары рәтеннән узып барышы иде. Яшерен-батырын түгел, биредәге сукмакларны да еш таптарга туры килгәләде аңа. Анда, һич югы дигәндә дә, нәрсәкәйдер табыла, кайчак шуның белән юанасың... Әмма бу юлы...

Хикмәти Хода түгел диген син моны: иң кырыйдагы чүплек савыты эченнән, үч иткәндәй, нәкъ теге чактагы итеп, кесә телефоны чылтырый иде!

Алыргамы, алмаскамы икән?

Авызы пешкән өреп кабар, диләр. Тарих ике тапкыр кабатланмый, дигәнне дә ишеткәне бар аның. Өреп кабасы булды, ахрысы: сукбай Таһиржанның куллары, кабаттан чүп-чарны арчып, кесә телефонына үрелде...

## ИКЕ КӨТҮЧЕ

Авылның Хабрай кушаматлы атаклы көтүчесе Хәбибрахман аягын сындырган, менәтерә! Кайда, ничек диген әле—атлап барган җиреннән гап-гади бер түмгәккә сөрлегеп ләбаса... Алтмышынчы еллар азагы бу.

Алтмыш моржалы кечерәк кенә бу авылда утыз баш сыер, унсигез чамасы башмак тана, илледән артык сарык һәм бәрәннәр исәпләнә. Яз якасыннан инде менә җәйнең кочагына атлап керәбез дигәндә генә шушындый күнелсез хәлнең килеп чыгуы җиргә, мал-туарга ябышып яткан халыкны пошаманга салды.

Шулай булмый ни, дүрт аяклы малларның туймас тамагын кояш нуры яисә тыкрык чирәме белән генә томалап куярмын димә. Аннан килеп, ни әйтсәң дә, Хабрай үз кеше: мал башына еллык акчаны утыз тәңкәдән артыгын сорамый. Мең дә тугыз йөз җитмешенче еллар уртасы өчен бик тә таман акча инде бу. Югыйсә, читтән килгәннәр әнә бәяне алтмышка кадәр күтәрмәк булып әтәчләнә, сатулаша...

***

Авылның бәхетенә күрә, бу четерекле мәсьәлә бер көн дигәндә хәл ителде дә куйды!

Яңа көтүчене фәрештәләр күктән төшерделәр диярсең... Егерме биш яшьләр тирәсендәге ярпач гәүдәле, табак битле, эчкәресеннән балкып торган мөлаем бер егет кеше. Күп сөйләшми, сатулашмый, үз табигатенә йомылганрак адәм баласына охшаган. Моның исә асылда егет үзе генә белгән җитди сәбәпләре бар иде, билгеле. Хәер, бу хакта сүз соңрак...

Менә авылның һәр иртәсендә, таң әтәчләрен дә уздырып, чыбыркы шартлый! "Уяныгыз, йоклап ятмагыз!"—дигән сүзләрне әйтә кебек ул. Чат саен сыер-сарыклар мөгрәшә. Сакалбай кәҗәләр, гадәтенчә, койма-рәшәткәгә ышкылып уза. Иртәдән кузгалып көтү куган халыкның җаны тыныч: иншалла, мал-туарлар урман һәм болынның сусыл, яшел киңлекләрендә туклыкка кинәнәчәк...

Габдрахман атлы яңа көтүченең дә дөньясы түгәрәк. Өй борынча кунып яши башлады. Кичен—авыл ашы, кайчагында тавык шулпасы да эләккәли үзенә. Күн сумкасында һәрвакыт әбәдкә дигән ипи-сөт, яшел суган, тәгәрәп пешкән каты йомырка булыр. Ана иптәшкә, көтүне кулда тотар өчен йорт саен берәр малай-шалай яисә чират хуҗасы ияреп чыга.

Инде менә чын дөресен әйтергә дә вакыт җитте бугай. Армия хезмәтендә бик зур бәхетсезлеккә дучар булды Габдрахман. Чик саклау гаскәрләрен элек-электән күпме мактап килсәләр дә, хәтта анда да юньле тәртип юк икән. Кулына автомат тотып, Кытай-Совет чикләрен саклады ул. Үзенә күрә күңеленә хуш килердәй матур көннәре, якты өметләр дә юк түгел иде. Ләкин...

Казармадагы төрмә тәртипләре, яшь солдатларны кыерсыту, төнлә уятып җәберләү, бәдрәф чистартырга мәҗбүр итүләр тәмам чыгырыннан чыгарды бу таза егетне. Ата-ана назын күрмичә, әбисе тәрбиясендә генә үскән ятим малай яман гадәтләрне җаны-тәне белән һич кенә дә кабул итә алмады.

Берсендә... сары чәчле бәйләнчек сержантны, бер селтәнү белән, казарма идәненә көлтәдәй егып салды ул! Хакыйкать эзләп кылган шушы гамәле бик тә кыйммәткә төште ул чакта. Аяк-кулларын сөлге белән бәйләп, офицерлар гына су коена торган бассейнга аягүрә ялангач бастырып куйдылар аны. Җир астыннан бәреп чыккан чишмә суы коточкыч салкын иде. Менә шунда, автомат белән саклап, өч сәгать буе боздай салкын суда бастырып тоттылар татар егетен...

Өшеде, туңды, калтыранды ул, тәне-гәүдәсе буйлап тора-бара секунд саен салкын "кырмыскалар" йөгереште. Су салкыны акрынлап җелекләренә, сөякләренә хәтле үтеп керде, бөтен күзәнәкләрен изеп ташлады аның. Моның нәтиҗәсе бик аянычлы булып чыкты: Ходай биргән сәламәтлеген югалтмаса да, Табигать бүләк иткән иң кыйммәтле хәзинәсен—ирлеген югалтып, мәхәббәт-гыйшык эшләренә аның инде бернинди дә теләге, маһирлыгы калмаган иде.

Бу серне һичкемгә дә әйтергә, уртаклашырга ярамый, билгеле. Бу серне берәү дә белергә тиеш түгел иде. Ахыр чиктә, кимсенеп яшәмәсен өчен. Егетнең уйлары, инануы әнә шушы хакыйкатьне үзләштереп өлгерде, ныклы бер карарга килде. Иң яхшысы—ялгызлык, ялгызлык, үз эчеңә кереп

бикләнү... Бәлки, тора-бара күк капусы аның хөрмәтенә бер ачылыр әле... Хәзергә сабыр итәргә, Аллаһ кушканны үтәп яшәргә кирәктер...

Шуңа да ул ерактагы туган авылыннан, шәһәрдә вакытлыча фатирга кергән яшь хатынынннан да аңлы рәвештә качып китте, ялгызак җанына сыеныр почмак, яшәр урын эзләде.

Менә күрәсез, ул аны уңышлы гына тапты да шикелле.

Кечкенәдән тальян гармунга мөкиббән булганлыктан, Габдрахманның җыр-моңга маһирлеге бирелә, урман-тугайлар, гөнаһсыз табигать кочагында өр-яңача бәреп чыкты лабаса! Ул ике бармак юанлыгы кура-камышлардан курай, әйе, чып-чын курай ясарга һәвәсләнеп китте. Тора-бара иртәдән иртүк чыбыркы шартлатуларның да хаҗәте бетте: курай тавышы ишетелдеме, авыл кешеләре иртәдән үк капка төбенә чыгып баса; маллар исә, моңлы курай көенә җай гына тирбәлеп, болын-урманнарга таба юнәлә...

Әнә шулай тиз арада яратып, үз итеп өлгерделәр Габдрахманны авылда. Исем-фәләнне кыскартырга күнеккәнлектән, бик күпләр Гапти дип кенә эндәштеләр үзенә.

Ләкин, җәйнең кыл уртасында, әллә каян гына җыелыш дигән нәрсәкәй калкып чыкты авыл клубында...

***

Утызынчы еллар бурасыннан калган бу калтырча клуб әле һаман да халыкка хезмәт итә иде. Кырмыскадай мәш килеп, авылның сау-сәламәт халкы клубның агач эскәмияләренә җыйналышканнар әнә.

Хикмәт шунда: аягы төзәлеп, инде ничә дистә еллар авылның төп көтүчесе саналган Хабрай үзенең хокукларын дәгъвалый башлаган икән. Бердән, түшәмгә карап тик ята торган ялкаулар затыннан түгел; икенчедән, дөнья булгач, аны акча-фәлән яклары да кытыкламый түгелләр. Абруе да бар: бывший фронтовик, аракы эчәргә дисәң егылып китми. Урман-кырларның да һәр почмагын география картасыдай яттан белә диярлек.

Мәсьәләне хәл итү өчен кичкырын менә шушы клубка җыйналдылар да инде. Алтмышны узган Хабрай ага әле нык, таза, күркәм күренә—куе кара чәче көмештәй чал төсмерләр белән аралашкан булса да, сакал-чигә тирәләре пөхтәләп кырылган, аякларын өстерәми генә туры атлый, башын-ияген ишегалды әтәчедәй югары күтәрә төшкән. Бу хәлиткеч минутларда як-ягына каранырга вакыты да юк шикелле аның.

Бригадир Хәсәнша белән туп-туры сәхнәгә, төсе качкан комач җәелгән өстәл янына уздылар. Фәлсәфи-хикмәтле итеп бераз гына тын утырдылар, аннары бригадир кеше сүз алды:

—Иптәшләр! Бүген без көн тәртибендәге мөһим бер мәсьәләне хәл итәргә җыйналдык. Күреп торасыз, көтүчебез Хәбибрахман агай ныклап аякка басты. Аның үзе эшенә көтүче булып кире кайтасы килә... Безнең хәзергә действующий (бу сүзне урысчалатып әйтә бит, малай актыгы!) көтүчебез бар, менә шуңа күрә мәсьәләне уртага салып сөйләшик, хәл итик бергәләп...

Залда хәзергә шау-шу сизелми, гаҗәеп бер тынлык. Һәммәсе ни булыр икән дип көтәләр, бригадирның сүзен тыңлыйлар.

—Безнең бригада икенче ел инде рәттән колхоз идарәсенең күчмә вымпелына лаек. Көтү мәшәкатьләреннән безне азат иткәнгә күрә, бу вымпелда хөрмәтлебез Хәбибрахман агайның да өлеше зур. Колхоз идарәсе һәм авылдашлар исеменнән без аңа иң әлек рәхмәтләребезне җиткерик булмаса...

Әйбәт кенә кул чаптылар. Хабрай, билгеле ки, әлеге мактау сүзләрен сары май урынына йотып куйды. Аның күңеле мәтәлчек ата бугай. Яңа көтүче Гапти генә ут эчендә яна иде: аның язмышы ничегрәк хәл ителер

дә, алга таба ничегрәк яшиселәр булыр?.

Бригадир сүзен дәвам итә:

—Ә хәзер авылыбызның мал-туарларын көтү турында Хәбибрахман ага белән безнең яңа килешү төзүен сорасак, ничек булыр, авылдашлар?..

Залда шау-шу, карга көтүедәй үзара сөйләшү купты! Нәкъ шул чакта Хәбибрахман ага, нидер әйтмәк булып, урыныннан күтәрелде. Бригадир шундук:

—Менә хәзер ул үзе әйтер,—диде дә сәхнәдән ераклаша төште.

Өстәл артында Хабрай ялгызы калды. Күзләрен хәйләкәр кысып куюы һәм башактай сары мыеклары астыннан көлемсерәп карап торуына караганда, аңардан шактый мут сүзләр чыгачагына шик юк иде.

—Авылдашлар!—ди Хабрай, тамак төбеннән чыккан көчле тавыш белән сүз башлап. Үзе колакка катырак булганга күрә, башкалар да начар ишетә дип уйлый иде ул.—Җир кешеләре, мине онытмаган өчен рәхмәт сезгә!

Бу урында ул, яр буендагы балыкчыдай, залда утырганнарга яңа бер караш ташларга да онытмады.

—Үзегез беләсез, январ суыгында мин сугыштан ырматиз белән кайттым. Духтырлар күп йөрергә кушмады. Ә карчык әйтә, күбрәк йөр, ди. Карчык кайнар мунча якты һәм солы суына утыртты мине... Карчык минем беткәнче акыллы, бер стакан салып бирде дә әйтә бу: бар, йөр, ди. Йөреп киттем тәки. Әнә шулай сезнең көтүче булып киттем мин. Егерме елдан артык сезнең малларны көтәм, авылдашлар. Йә, әйтегез, кайсыгызның миннән начар көтүче дип зарланганы бар? Әллә алай түгелме, ә?!.

Абзый бу урында уң кулын колагына якын китерде. Кем инде, узган ел минем сыерларны начар көттең, дип аңа карата зар сүзләре әйтер икән? Көтүчене ачуландырсаң, кайчакларны сөтсез утыруың да бик ихтимал лабаса.

Хәйләкәр-шома Хабрай дилбегә очын яңадан үз кулына эләктереп алды:

—Күрденме, энем Хәсәнша, һәммәсе канәгать, ә син нәрсәдер сөйләнгән буласың...

Хабрай залдагыларның аз гына тынычлануын көтте һәм, уйларына батып, янә чын-чынлап сөйләп китте:

—Син, Хәсәнша, өч-дүрт ярдәмчең белән дә көтү эшләренә җитешмәс идең. Кайчакта урман ешлыгындагы сыерны дүрт-биш адымнан да күрмисең. Ярый әле Сарбаем бар. Ул булмаса, шул тиклем дә көтү артыннан чабарга шайтан үзе дә өлгермәс иде!..

Бу урында залдагылар янә бер кат рәхәтләнеп көлештеләр.

—Сезгә, бәлки, көлке көлкесендер, ә миңа алай түгел; сезнең сарык һәм сыерларыгыз хәтта төшләремә керә, туганнар...

Моңга бирелгән Хабрай туктап калды, ничектер сәхнәдән төшмәкче булып калкынды. Ләкин шушы хәтле халык җыелганда үз сүзен әйтеп каласы килә иде аның.

—Күптәннән әйтәсем килеп җөри... Менә нәрсә, авылдашлар... Егерме ел эчендә шуңа ышындым, мал-туар үзенең хуҗасына тәмам охшый икән ул! Җәмәгать! Менә алыйк безнең Гөлбикәне. Аның моңлы тавышы нинди икәнлеген кайсыгыз гына белми икән! Вәт шул, мин көткән елларны дүрт сыеры булды аның, берсенең дә тавышы иртәнге азан авазларыннан ким түгел иде... Дөрес сөйлимме мин?..

—Дөрес, дөрес! Әйдә, сөйләп бетер...

Хабрайның уй-фикер ташы кызганнан-кыза барды:

—Яки менә Һадиятне алыйк. Син бередәме, Һадият дус? Сезнең сыер бит тамак ертып кычкыра һәм аның Гөлбикә сыеры белән дуслыгы да

яшерен-батырын түгел. Ике тавышка көйли башласалармы... түзеп кенә тор менә! Тәмам авыл ахирәтләре. Колакка каты булсам да, ишеткәлим үзләрен...

—Ха-ха-ха!

Залдагылар тагын буылып көлә.

—Әйе, мал иясенә охшаган шул... Менә син, Хөҗҗәт яшьти, бер почмакта яшь егетләрдәй тыенкы гына утырасың болай. Сыерларыңның авырлыгы—уртача. Син үзең дә бер уртача кеше. Әйтик, фронттан дүрт-биш орден белән кайттың. Мактанып йөргәнең юк. Сыерың да тыйнак, үзең дә тыйнак бер кеше...

—Кичәгенәк син Хөҗҗәттә сыйланып чыктың, шуңа күрә мактау сүзләрең җәл түгел,—дип, арадан берәү гәпкә кушылды.

Хабрай моны ишеттеме-юкмы—аңламассың, ул үзенең сөйләвен белде:

—Яки менә ялгыз хатын Сәрбинәне генә алыйк... Сыеры салмак, тыңлаучан, әмма берәр кигәвен тешләдеме—йөгәннән ычкына! "Ә" дигәнче барлык көтүне болгатып бетерә. Сүгенергә, фактически, мине Сәрбинәнең сыеры гына өйрәтте. Сәрбинә хуҗабикә—алты бала анасы, ә үзе һаман да яшь танадай кылана түгелме?

—Үз башыңа сөйләнәсең, картлач,—диде Сәрбинә үпкәләгәндәй итеп.

...Ике ай буе кешеләр вә табигать белән юньләп аралашмаган Хабрайның сөйләр сүзе бетәрлек түгел иде, ахрысы.

—Менә шулай, хөрмәтле авылдашлар! Ә син, Гайнетдин туган, дөресен әйткән өчен миңа үпкәләмә! Синең комсызлыгың сыерыңа да күчкән. Үләң тезләреннән житәрлек, ә синең Карлыгачың гел читтән умыртырга ярата...

—Ха-ха-ха!..

Шулвакытны залда көтелмәгән хәл булып алды. Каян килеп чыккандыр да, ничекләр шулай осталык белән кылангандыр: сәхнә түренә этләргә генә хас житезлек белән көтүче Хабрайның Сарбае йөгереп менде дә, бер гаепсез бәндә сыман, арт аякларына чүгәләп утырды. Йолдыз бөртегедәй жемелдәп торган күзләре нәрсәдер әйтергә тели иде шикелле.

Аның нәрсә әйтергә теләгәнен Хабрай халыкка бик тиз аңлатып, "тәржемә" итеп бирде:


—Менә, күрәсезме, минем файдага тагын бер тавыш өстәлә, туганнар! Сез бит минем Сарбаемны калжа белән юньләп сыйламасагыз да, сөттән, сөяк-санактан мәхрүм иткәнегез юк... Рәхмәт әйтергә менгән ул сезгә...

***

Жыелыш менә шулай житди дә, кызыклы да узды. Талашу-кычкырынулар, тарткалашу әлләни булмады кебек. Нәтижә шул: Хабрай белән Гаптинең икесен дә көзгә кадәр тәгаенләп, жәй буе бергә көтү көтсеннәр дип, кояш астына жибәрделәр.

Хакы-бәясе ничек булды дисезме? Монысын инде авылдашларыннан яисә көтүчеләрнең үзләреннән сорарга кирәк... Ә Гапти нишләде дисезме? Аның көтүче сумкасында һәрвакыт китаплар булды. Китапханәдән дә, кешеләрдән дә ала иде ул бу китапларны. Аның шәхси фажигасен хәзергә берәү дә белмәде. Көзен, инде көтү-жәйләү эшләре тәмамлангач, аның исәбе—яхшы врачларга күренү иде. Күкрәп торган бу егеткә бер-бер дару, им тапмый калмастыр алар...

♣



# КҮҢЕЛ АЗАТЛЫГЫ

(Ә. ЕНИКИ ТУРЫНДА КАЛӘМДӘШЛӘРЕ)

**Әхсән Баянов:**

—Минем өчен таянырлык рәтле кеше иде ул. Үзе дә мине шулай санагандыр дип уйларга җөрьәт итәм. Чөнки "Юлчы" дигән җыентыгының титул битенә шул хакта язган иде. Халык өчен ул исән чагында ук тере классик булды. Гәрчә аның да иҗат юлы шома гына була алмады. Тәнкыйтьчеләрнең тискәре мөнәсәбәтенә түзеп яшәде ул. "Рәшә" повесте чыккач, "Кояшлы язны рәшә капламасын" (К. Фәсиев) дигән мәкаләдән соң тискәре мөнәсәбәт аеруча көчәеп китте. Авторитар тәнкыйтьнең бертуктаусыз изүенә карамастан, кеше үз мәсләген үзгәртмәде. Үтә кызыл әсәрләргә таба борылмады.

Ул "иҗат азатлыгы" дигән сүзләрне еш кабатлый иде. Мина карата да әйткән сүзләрен хәтерлим. "Дөньяны үзең күргәнчә тасвирлау хокукы". Бик тырышсалар да, аны шул хокуктан мәхрүм итә алмадылар.

Ә. Еникинең барлык уңышлары әхлакый ныклык белән анлатыладыр дип уйлыйм. Элек классик булган кебек, ул хәзер дә тере булып кала. Теге вакытта ук язылган шедеврларын укып карагыз. Аларда җанга кагылышсыз бер генә җөмлә, бер генә сүз дә таба алмассыз. Чөнки аның иҗаты чит тәэсирләрдән азат. Яза башлаганда ук ул чиста күңелле кешеләрне сайлаган.

Татарстанның халык язучысы Әмирхан Еники милләтебезгә барыннан да элек әнә шушы сыйфатлары белән кадерле. Какшамас иманы белән зур ул, бөек ул!

***

**Туфан Миңнуллин:**

—Сүзне үземнән башлыйм әле.

"Канкай углы Бәхтияр" драмасын язганда патшабикә Екатерина II белән граф Потемкин диалогын язарга кирәк иде. Әллә ничә вариант язып карадым—үземне канәгатьләндермәде. Авыл апасы белән авыл агаеның сөйләшүе килә дә чыга. Бик озак азаплангач кына үз дигәнемә ирештем шикелле.

Әмирхан ага Еники турында уйланганда әлеге вакыйганың искә төшүе очраклы түгел. Безнең бик күп әсәрләребездә әдәби осталык нык аксый. Югыйсә барысы да урынында кебек, ләкин нидер житеп бетми. Нидер дигәнем—әйтәсе фикерне төгәл, саллы һәм, иң әһәмиятлесе, нәзакәтле, нәфис итеп әйтә белү осталыгыдыр.

Әмирхан Еники дә бит без язган, без кулланган сүзләрдән төзи җөмләләрен. Нигә аны укып сокланабыз да, кайберләребез язганның өч-дүрт җөмләсен укуга

ук күнел кайта? Унмаган хатынның оешып бетмәгән коймагын ашап интеккән кебек.

Мөхәррирләрдән ишеткәнем бар: Әмирхан Еники редакцияләргә китергән кульязмаларын басылып чыгар көнгәчә төзәтә, камилләштерә иде, диләр. Димәк, Әмирхан ага үз иҗатына олы хөрмәт һәм җаваплылык белән караган.

Әйе, ул үз иҗатының гына түгел, тулаем татар әдәбиятының затлылыгын билгеләүче язучы иде.



*Әмирхан Еники һәм Туфан Миңнуллин Мәскәү Кремленең Георгий залында, СССР язучыларының VIII съездында.*

***

**Нажар НӘҖМИ:**

— Әмирхан Еники минем өчен — тере классик, матур сүз остасы. Әйтер идем, ул проза белән яза торган шагыйрь. Аның әсәрләре — кеше йөрәгенә ята торган әсәрләр. Моңа ул табигате белән нечкә күңелле, кешелекле булуы белән ирешә. Шул яклап ул миңа өлкән дус та, остаз да.

*1994*

***

**Рабит БАТУЛЛА:**

—Әмирхан Еники язучы гына түгел, ул—әдип. Ул—акыл иясе, Ана теле сагында торучы, халкы-милләте турында киеренке уйланучы, халыкның азатлыгы өчен көрәшүче, шул көрәшнең ысулы итеп әдәбият мәйданына чыккан баһадир. Әмирхан Еники гомере буе шул гамәлдә булды.

...Соңгы 30-40 ел эчендә язылган чәчмә әсәрләрдә шигырьдә булган затлылык сирәк очрый. Әмма Әмирхан Еники әсәрләрендә бу сыйфат аерым урын тота. Аның әсәрләрен син кайта-кайта укыйсың, укыган саен яңа нәрсә ачасың. Әдипнең серле кинаясе сиңа, Сим-Сим ачкан серле ишек кебек ачылып китә. Шигырьгә тиң хикәя әнә шулай берничә катламнан торырга тиештер инде ул.

...Хәсән Туфан, Фатих Әмирхан турында: "Әдәбият ханы—Әмирхан" дип язган иде. Әмирхан Еники турында мин дә шул сүзләрне кабатлыйм: Әдәбият ханы—Әмирхан!

***

**Равил Фәйзуллин:**

—Әмирхан ага гомере буе үз гамәленә үзе хуҗа булган зат. Сабыр-тыйнак кына, кабаланмыйча, очар биеклекләрне анык белеп, узгынчы сәяси-конъюнктур хәрәкәтләрдә буталмыйча, талантының кодрәтен, шәхес буларак үз дәрәҗәсен белеп яшәде, иҗат итте. Бу очракта чыгышы ягыннан мәгълүм ыру-токымнан, затлы нәселдән булуы да шактый ук әһәмиятле булса кирәк.

Һәр иҗатчы, телиме-теләмиме, таныймы-танымыймы, ул—барыбер Вакыт галиҗәнаплары белән алышка чыккан зат. Чарасызлыкны, Вакыт кодрәтенә беркемнең, бернәрсәнең дә каршы торалмаганын белсә дә, Иҗатчы, Вакытның «ялына ябышып булса да», хезмәтләре белән Ана үз исеме белән мөһер суга... Киләчәктә Идел-Урал тирәлегендә XX гасырның төрки прозасы турында сүз чыкса, иң беренчеләрдән булып Ә. Еники исеме телгә алыначак. Иҗаты һәм яшәү рәвеше белән килер буыннарга, бигрәк тә каләм ияләренә, бик тә кирәк әхлакый

сабаклар да бирде Әмирхан агабыз. Шуларның берсе (гәрчә аксиома кебек мәгълүм булса да)—язучы нинди генә заманда, нинди генә шартларда яшәп иҗат итсә дә, вөҗданына тугры калып, көндәлек мәшәкатьләрдән өстен торып, тормыш дөреслеген язарга тиеш.

Бу—Аның язучылык кредосы иде, күпләр өчен өлге булыр сыйфаты. Тагын икенче бер гыйбрәтле сабак-нәтиҗә: хикәяләү, тасвирлау шигырь рухы белән сугарылмаса, чәчмә әсәр шигъри телле булмаса, чын проза әсәре юк ул. Әмирхан Еники—прозаның шагыйре ул.

Әмирхан Еники исән чагында данда коенып, иҗатына тиереннән артыгын алган (андыйлар да булды!) язучы түгел. Чын бәһасе киләчәктә алыначак әдип ул. Әмирхан учагы әле дөрли генә башлады.

***

**Марсель Галиев:**

—Әдәбиятта асыл бәя язучы мирасының күләменә, күплегенә карап түгел, ә чын сәнгати әсәрләренең сыйфат дәрәҗәсен күзаллап, татар әдәби теленең бөеклеген раслаган, милләтнең гореф-гадәте, гаме аша әрнүен дә, омтылыш-кичерешләрен дә югары кимәлдә тасвирлап, рухи хәзинә тудыра алганнарга бирелергә тиеш. Мондый бөек затларыбызның берсе—Әмирхан Еники.

***

**Мансур Вәли-Барҗылы:**

—Әмирхан Еникине мин татар халкының иң зур әдибе дип саныйм.

Аның әсәрләренең гаҗәеп дәрәҗәдәге фәлсәфи тирәнлеге, әдәби-эстетик яктан үтә камиллеге, аларда милли рухның һәм милли психологиянең гаять нечкә һәм матур чагылышы, тормыш күренешләренең бик тә масштаблылары һәм типиклары сайлап алыну һәм тасвирлану, әсәрләрнең халык моңнарына якын дәрәҗәдә музыкаль янгырашы һәм әдәбият-сәнгать әсәрләре өчен хәлиткеч кимәлдә мөһим булган тагын башка асыл сыйфатлар безгә Әмирхан Еники иҗатына әнә шундый иң югары бәһане кую мөмкинлеге бирә.



*Татар һәм башкорт мәдәниятенең күренекле әһелләре (уңнан сулга) Әмирхан Еники, Мостай Кәрим, Нәҗип Җиһанов.*

***

**Рэдиф Гаташ**

*Әмирхан ага Еникигә*

*Бала итте бугай—шаштырды шатлык:*
*Аксакал белән түбәтәй алмаштык!*

*—Сезгә, яшькә, килешер, ди, укалы,*
*Ә миңа—бизәксез, гади булганы.*

*...Чын алтын күз! Уфада—туй дәвамы:*
*Сиксән биш яшь—морза әдип бәйрәме!*

*Гасырлардан мирас акыл сүзендә,*
*Татарның язмышы—моңы күзендә.*

*"Әйтелмәгән васыять»ләрен әйттеме,*
*Тарих төпкеленә уйны дәштеме?—*

*Илле яшьлек йөрәкне кыстым учка:*
*Очар кебек, әверелеп хәтер-кошка.*

*—«Сөт калыр, Ватан китәр»... Шул—кызганыч.*
*Әмма исән рухта Өмет, Ышаныч.*

*Инде кыйбла җуймыйча барырсызмы?*
*Шул "изге сөт, кан"ның сез варисымы?*

*...Мин дә хәзер чал чәчле ир бугай ла,*
*Олы гамьнән читтәмен күк шулай да.*

*Гаҗәпмени—уй ташып, калсам шашып?—*
*Аксакал белән түбәтәй алмашып...*

*1994*



*Әмирхан Еники Чуашстанда татар әдәбияты көннәрен ачу тантанасында чыгыш ясый. 1984 ел.*

# ӘДИП БӘХЕТЕ

Әмирхан Еники... Матур әдәбият сөючеләрнең күнел төпкелләренә бик тә тирән үтеп керә алу тылсымына ия булган олы талант иясе, нечкә психолог, зур философ, гаять тормышчан һәм шул ук вакытта югары сәнгать дәрәҗәсендәге үлемсез әсәрләр тудырган мәшһүр әдип! Ә. Еники турында замандашлары язган сүзләрне генә искә төшерик: “Сирәк талант” (Ф. Хөсни), “Күңел карурманнарының былбылы” (И. Юзеев), “Сихри дөнья” (Р. Мостафин), “Рухи матурлык җырчысы” (Ф. Сафиуллина), “Иллюстрациядән—проблемага” (И. Нуруллин), “Вөжданына тугры әдип” (Р. Фәйзуллин), “Тынгысызлык” (Р. Мөхәммәдиев), “Халык күңеленә юл” (Манс. Вәлиев)...

Әдипкә 85 яшь тулу уңаеннан “Казан утлары” журналында (1994 ел, 3 сан) аның белән әңгәмә үткәрелгән. Әнә шул әңгәмәдә Ә. Еники үзе турында болай дип яза:

“—Мин гомерем буе рухи азатлыкка һәм фикри хөрлеккә сусап яшәгән кеше. Әмма яшәвем 8 яшьтән алып 80 яшькә кадәр тоталитар система шартларында узды... Аның кадерле дип әйтерлек чагы булырга мөмкинме?! Әлбәттә, юк!.. **Тик кайчандыр күргән бик матур төшләр генә узган гомернең кадерле бер мизгеле булып искә төшкәли...**”

Игътибар итегез: үтелгән 85 ел гомердән бары тик үзенең төшләрен генә әдип иң кадерлесе дип билгели! Бу хәл үзе үк кеше өчен бик тә тетрәндергеч күренеш түгелме!? Әйе, без хәзер сокланып укый торган әдәби әсәрләр алар, мөгаен, әнә шундый тетрәндергеч җан газапларының—рухи гарасатларның—кадерле җимешләре булып тугандыр. Әнә шуңа күрә аларның тәэсир көче бик тә зурдыр!

Ә бит ул гарасатлар озын гомер юлында бик тә күп булган...Озын-озак гомер юлында...

Әмирхан Еники 1909 елның 2 мартында хәзерге Башкортстанга кергән Благовар районы Яңа Каргалы авылында дөньяга килә. Шунысы кызыклы: әдипнең шәҗәрәсе бик күптәнге морзалар нәселенә барып тоташа. 1980 елларда күренекле әдәбият тәнкыйтьчесе Фәрваз Миңнуллин әдип тудырган әдәби геройларны бер сүз, бер төшенчә белән билгеләгән иде—затлылык. Әмирхан Еникинең ерак тарих төпкелләреннән килгән нәселе, нәсел каны уйнавы иҗатта әнә шундый затлы геройларны тудыручы хәлиткеч орлыкларны салгандыр дип уйларга нигез бар бирелә.

Аның әтисе Нигъмәтҗан—житез хәрәкәтле, ачык күңелле, җор сүзле, уен-көлке яратучан кеше була. Ул матур гына җырлаган да, гармун да уйнаган, оста гына биегән дә. Әнисе Бибихәдичә исә—сабыр холыклы, акыллы хатын булган. Ул 22дә үзеннән яшьрәк Нигъмәтҗанга кияүгә чыга. Ләкин гаиләнең баладан бәхете булмый. Тугыз бала бер-бер артлы туып, күпмедер үскәч, йә кызамыктан, йә чәчәктән, йә эч авыруыннан үлеп баралар. Унынчы бала булып дөньяга Әмирхан килә. Аның исән-сау үсүен теләп, нәзерләр әйтеп, гаилә яшь ярымлык бала белән 1910 елда сәүдә үзәгенә әверелгән Дәүләкәнгә күчә. Әмирханга ике яшь вакытта энесе Илдархан туа. Шуңа күрә туганнары арасында аларны “ике бөртек” дип йөртәләр.

Дим буенда урнашкан Дәүләкәнгә күчеп килгәч, булачак әдипнең әтисе сәүдә эшенә керешеп китә. Моңа бер этәргеч—Дәүләкәндә шактый гына “купичләр” яши. Шушы төбәктә Әмирханның балачагы һәм яшүсмер еллары үтә. Кечкенәдән үк ул ямьле Димнең хозур табигатен, ягымлы кешеләрен күреп үсә. Белемне мәчет каршындагы мәдрәсәдә ала башлый. Анда парталар булмый билгеле, шуңа күрә тәбәнәк өстәл артына җәелгән киезгә тезләнеп, белем алалар. Хәлфәләре дә читтән килгән коръәнхафиз—бик усал һәм кансыз кеше була. (Әдипнең “Коръәнхафиз” дигән бик тә тирән социаль һәм этик эчтәлекле хикәясен искә төшерегез.) Икенче елны белем алганда дини гыйлем белән беррәттән тел, хисап, җәгърәфия кебек дөньяви фәннәр дә кертелә башлый. 1922 елдан балалар укырга совет мәктәбенә

йөри. Ләкин ата-ана теләге белән алар кичләрен мәчеткә барып, дин сабагы да укып кайта. Хәтта кайбер көннәрдә мендәрләрен кыстырып барып, шунда йоклап та калалар. Монда киезгә сузылып яткач малайларны жен, пәри, албасты, абзар иясе, мәчет өрәге, яшь кыз кыяфәтендәге юха елан, падишаһлар, шаһзадәләр, хан кызлары турында сөйләнгән вакыйгалар бик тә кызыксындыра.

Дәүләкәннен үзәгендә бай гына китапханә була. Әмирхан анда еш йөри. Аннары кайбер сәүдәгәр, приказчикларның өйләрендә сакланган "Ялт-йолт", "Ак юл", "Сөембикә", "Аң", "Шура" журналларын сорап алып, укыштыргалый. Тагын әби-бабасы йортында сакланып калган, ләкин таушалып беткән "Тутыйнамә", «Бакырган», «Бәдавам», «Бүз егет», «Каһарман катыйль» китапларын кулга төшереп, аңлый алганнарын укый. Инкыйлабтан соң Уфада чыккан «Белем», Мәскәүдә нәшер ителгән «Кечкенә иптәшләр»не дә ярата ул.

Әмирхан кече яшьтән үк тормышка игътибарлы, күзәтүчән малай була. Аны аеруча кызыксындырганы—кымыз эчәргә килүчеләр. Кымызчылар арасында бер җәйне Нәгыймә Таҗдарова (1957 елда әдип анын турында китап та яза) белән Нури Сакаев, Маһирә Мирвәлиева белән Шакир Шамильский да була. Икенче бер җәйне—Казаннан Галимҗан Нигъмәти һәм Гомәр Гали хатыннары белән. 1924 елда—Мәҗит Гафури, Шәриф һәм Сәгыйть Сүнчәләйләр... Әмирханның әдәбият белән «җенләнә» башлаган елларында ук шундый күренекле сәнгать әһелләрен, галимнәрне, әдипләрне күрүе—бәхет эше, әлбәттә.

Яшүсмер чагында ук югарыда саналган әнә шул талант ияләрен якыннан күрү, хәтта алар белән аралашып алу Әмирханда иҗади ялкын кабызгандыр, талант иясенә һәм талант башкара алган бөек могҗизага соклану, әсәрләнү тудыргандыр. Һәм Әмирхан сәнгать мәктәбенә укырга керү теләге белән 1925 елда Казанга килә, башта китап кибетенә курьер булып эшкә урнаша. Ул иҗатка килгән 1926-1927 еллар әдәби процесста аеруча катлаулы һәм каршылыклы чор. Әлеге елларда әдәбият мәйданында Ф. Әмирхан, Г. Ибраһимов, Ж. Вәлиди, Г. Рәхим, Г. Сәгъди, С. Җәләл, Ф. Сәйфи-Казанлы, Ф. Бурнаш, К. Тинчурин, Ш. Усманов, Һ. Такташ, К. Нәҗми, Г. Толымбай, Г. Гали, Г. Кутуй, Х. Туфан кебек танылган әдипләр иҗат итә. Алар инде яна әдәби юнәлешкә йөз тоталар. Белгәнебезчә, егерменче еллар ахырында әдәби процесс кискен борылыш кичерә. Ә. Еники дә, шул вакыйгаларның тере шаһите буларак, С. Җәләл һәм Ченәкәйне «чистарту», С. Габәши, Г. Кашшаф, Д. Фәтхине ТАППтан чыгару, Һ. Такташны кисәтү, Ф. Бурнашка гаеп тагу, Г. Кутуйны «әдәбияттан читләштерү» процессларын үз күзләре белән күрә. Үзе дә каләм тибрәтә башлый һәм «Озын көй тынлаганда» (1926), «Дус кеше» (1928), «Яз башы» (1929) дигән хикәя һәм повестьларын иҗат итә. Әнә шул әсәрләре белән ул әдәбият мәйданына кереп китә.

Ә. Еники үзе әйтмешли, «иҗади ашкыну һәм эзләнүләренең житлекмәгән үрнәкләре» янына иҗтимагый-сәяси тормыш каршылыклары, әдәбият-сәнгатьнең үзендә барган кискен борылышлар кушылу аны шактый вакыт иҗади эштән читләштерә. 1927 елда ул Донбасстагы наданлыкны бетерү курсларында укыта, 1928 елның көзендә Казанга кайтып, мех фабрикасында тирене сортларга аерып тора башлый. Анда 1932 елга кадәр эшли. Ләкин күнелен белем алу теләге тырнап тора. Шул елларда Казанда хезмәтне фәнни оештыру институты оеша. Ә. Еники аны уңышлы гына тәмамлый. 1934-41 елларда ул кинофикация трестында инструктор, Үзбәкстанның Маргелан шәһәрендәге мәктәпләрнең берсендә укытучы булып эшли.

1941 елда башланып киткән сугыш... Бу елларда ул үзенең «Бала», «Ана һәм кыз», «Бер генә сәгатькә», «Ялгыз каз», «Мәк чәчәге» дигән хикәяләрен иҗат итә. Әлеге хикәяләре белән ул Язучылар берлегенә кабул ителә, әсәрләре аерым китап булып басылып чыга.

Әдип иҗатының беренче дәверендә барлыкка килгән хикәя һәм очерклар чынбарлыкны чагылдыру ягыннан уртак сыйфатларга ия иде. Бу елларда язучыларның күбесе үз әсәрләрендә фронттагы һәм тылдагы батырлыкларны сурәтләүгә—күбрәк вакыйгаларның тышкы ягына—йөз тотты. Ә. Еники әсәрләрендә исә дәһшәтле сугыш турыдан-туры үзе түгел, ә аның кеше күңелендә калдырган

эзе, тудырган хисләре тасвирланды. Ә. Еники бу темага яңа төсмерләр алып килде, сугыш һәм тормыш, яшәү һәм үлем, дәһшәт һәм матурлык фәлсәфәсен сәнгать дәрәҗәсенә күтәрде.

Ә. Еники иҗатында солдат образын ачу төрле яссылыкта бара: башта, сугыш әле башланган гына вакытта, солдат Зариф («Бала»), аннары бердәнбер улын көтеп ятучы ананың соңгы өмете булган Хәсән («Ана һәм кыз»), туган йортына бер генә сәгатькә кайта алган Гомәр («Бер генә сәгатькә»), штраф ротасы повары Иван («Ялгыз каз»), әсәрдә бөтенләй исеме күрсәтелмәгән Солдат («Мәк чәчәге»), иң куркыныч бәрелештә коралсыз калган Василий, Талип, Хәким («Кунакчыл дошман»), сөйгәне Таһирәнең җырын ишетүдән шатлык кичереп, якты дөньядан китеп баручы солдат егет («Кем җырлады?») һ.б. Сугыш шартлары аларны бер омтылыш, теләк белән яшәргә мәҗбүр итә. Алар туган илләренең, якыннарының, туганнарының, кардәшләренең тынычлыгы, иминлеге өчен көрәшәләр. Гәрчә, кылган гамәлләре, үтисе бурычлары солдатларны фронт сызыгы белән бәйләп торса да, күңел түрләрендә аларны аңлаган, яраткан, үз иткән, сагынып көткән кешеләр яши.

Еники иҗатында сугыш темасының яктыртылуы уңаеннан шуны басым ясап әйтергә кирәк: соңга таба рус әдәбиятында Ю. Бондарев, В. Кондратьев, үзебездә Х. Камалов һәм рус телле язучы Т. Гыйниятуллин көчәйтеп, үстереп җибәрәчәк яңа бер юнәлешнең тәүге үсентеләре бездә нәкъ менә аның—Әмирхан Еникинең—югарыда без сүз алып барган хикәяләрендә күренгән икән! Аларда сугыш Кеше күңеле, Кеше йөрәге аша—Кешегә хас булган барча хис-кичерешләр белән сурәтләнә.

Сугыштан соңгы чорда Ә. Еники иҗатының үзәгенә фаҗигаләр, югалтуларның кайтавазын чагылдыручы проблема буларак ялгызлык килеп керә. Шул исемдәге хикәядә әлеге проблема кеше язмышы, өмете, рухи дөньясы белән бәйләнештә, характер сыйфатларын ачу чарасы буларак тагын да калкурак чагылдыра.

Сугыш елларында бердәнбер кызын, ирен югалтып, «Бөреле» совхозына үзенең җәнлекләре белән килеп эшкә урнашкан Тамара Сергеевнаның кичергән газапларыннан тиз генә котыла алмавы сурәтләнә. Автор аны «көзге чәчәк, тагын берничә ел—һәм ул сабагында шиңәчәк»?—ди.

Әсәрдә укучы күңелен тетрәткән бер вакыйга бәян ителә. Бәлки таяныч булыр дип Тамара Сергеевна үзеннән күпкә яшьрәк булган, чибәр егет Петя Котовны сайлый. Әмма үз учагын мәхәббәткә нигезләп корырга хыялланган Тамара Сергеевнаның изге хисләрен Петя Котов бәяләп бетерми. Хәтта хезмәттәшләренең тупас шаяртуына да кушылып, үз хатынын түбәнсетә. Тамара Сергеевна аны кеше итәргә тели. Җитәкчелек белән сөйләшеп, Ленинградка укырга җибәрә. Ләкин тәкәббер егет инде кире әйләнеп кайтмый, бары хат кына җибәрә. Әлбәттә, Тамара Сергеевнада бу хыянәтне аңларлык акыл һәм кичерерлек ихтыяр көче дә бар. Ләкин биредә автор аның хисләр дөньясын аерып күрсәтә, ягъни героиньдагы рухи дөньяның матурлыгын ача.

Ә. Еникинең 1948 елда ук язылып, уналты ел дәвамында басылмый яткырылган «Тауларга карап» хикәясен алыйк. Әсәрдәге Локман карт ил өстенә килгән һәртөрле авырлыкларны халык белән бергәләп үз җилкәсендә күтәрә, чыныккан характер иясе булып күз алдына бастырыла. Хикәядә автор героеның киеренке драматик хисләрен, борчылуларын, тынгысыз уйларын сурәтли. Локман карт күңелендәге газаплы уйланулар оныгы Батырҗанның сугышта үлеп калуы турында хәбәр алынганнан соң тагын да көчәеп китә.

Локман карт өчен тауларга карау үткәнне барлау, киләчәкне фаразлауга тиң. Карт озын тормыш юлы кичкән. Ләкин ул күреп тора: аның гомере өзелү белән нәселе дә бетә икән! Ике Герман сугышы улын һәм оныгын алып киткән. Әмма хикәя беткәндә генә автор Локман картка сөенеч бүләк итә. Аның йортына оныгы Батырҗанның сугышта бергә кушылган хатыны Сания бала күтәреп кайтып керә. Бу бик тә көтелгән, тансык баланың исеме дә теләсә нинди түгел—Газизҗан. Ул—Батырҗанның улы, оныкның баласы, нәселне дәвам иттерергә тиешле газиз бала! Хикәянең «Әйе, күләгәләр шуып үтә, тормыш бетми, һаман, һаман дәвам итә», дип тәмамлануы бездә рухи күтәренкелек тудыра, халыкның, милләтнең киләчәгенә өмет уята.

Сугыштан кайткач, Ә.Еники башта «Совет әдәбияты» журналында әдәби хезмәткәр, аннары Татарстан радио комитетында әдәби тапшырулар редакторы булып эшли. 1950-52 елларда Казан авиация техникумында татар теле укытып алганнан соң ул 1953 елдан әдәби иҗат эшенә күчә.

Озак еллар дәвамында «Тауларга карап» хикәясенең басылмый торуы әдипне уйландыра. Житмәсә, илленче елларда татар әдәбиятында повесть жанры активлашып китә. Күрәсең, шул да тәэсир иткәндер—1952 елда Ә. Еникинең беренче күләмле әсәре булган«Рәхмәт, иптәшләр!» повесте дөнья күрә. Повестьта ферма мөдире Нургалинең эчке дөньясы, аның авыл Советы сессиясендә отчет бирүе һәм эштәге кайбер кимчелекләре тәнкыйть ителә. Нургали бергә эшләүче иптәшләренә шикләнеп карый, аларның үзенә яхшылык теләүләренә ышанмый.

Алга таба язылган повестьларында Ә. Еники сюжет корының төрле мөмкинлекләреннән файдалана. Аның «Рәхмәт, иптәшләр!», «Вөждан», «Гөләндәм туташ хатирәсе» повестьларында тармакланган сюжет белән очрашсак, «Саз чәчәге», «Йөрәк сере», «Рәшә» әсәрләрендә параллель сюжет корылышына тап булабыз. Параллельлек принцибына корылган сюжет «Саз чәчәге», «Рәшә», «Йөрәк сере» повестьларында геройның фикерен контрастлыкта ачу мөмкинлеге тудыра. «Саз чәчәге» повестенда Шакир Мостафинның беренче һәм икенче хатыны Мәрьям белән Нажия, Мәрьямнең әнисе белән Майпәрвәз капма-каршы куела. Шул ук үзенчәлеккә «Рәшә» повестенда да юлыгабыз. Әсәрнең төп герое Зөфәр бертуган абыйсы Зариф белән чагыштырылса, төп геройны ачу өчен Рәшидә һәм Гамбәр образлары капма-каршы куела. Сюжет корылышындагы параллельлек принцибы Ә. Еникинең «Йөрәк сере» повестенда аеруча ачык күренә.



*Әмирхан Еники укучылары белән.*

«Йөрәк сере» һәм «Гөләндәм туташ хатирәсе» повестьларының төп геройлары— нечкә күңелле, хис белән яшәүче кызлар. Әмма аларның уйлары гаять төрле. Дөрес, кайбер очракта ике кыз өчен уртак сыйфатларны да табабыз: икесе дә сабыр, итагатьле, яшь һәм тәҗрибәсез. Аларны бер теләк берләштерә—бәхетле булырга, мәхәббәткә, саф хисләргә нигезләнгән гаилә төзергә. Ике герой да Ә. Еникинең эстетик идеалына туры килерлек, затлы хатын-кызлар. Һәрхәлдә, аларны шулай бәһаләүче тәнкыйтьче Ф. Миннуллин белән килешәсе килә.

Ә. Еникинең психологик сатирасы да җәмгыятьтәге тискәре күренешләргә җавап рәвешендә барлыкка килгән. Әдипнең «Саз чәчәге» повесте хакында беренчеләрдән булып фикер әйтеп чыккан И.Нуруллин да шул юнәлештә уйлана: «Ә.Еникинең «Саз чәчәге» повесте да, проблематик әсәр буларак, тормыштагы хәл ителергә тиешле мәсьәләләргә прожектор утын юнәлтә, уйланырга, фикер йөртергә мәҗбүр итә»,—ди ул. Димәк, һәр нәрсәдәге кебек, Ә.Еники иҗатындагы сатирик пафос та тормыш ихтыяҗы тарафыннан тудырыла. Автор, «Саз чәчәге» повестен язып, совет чынбарлыгындагы житди кимчелекләрне күләмле жанр канвасында сатирик фаш итә.

Повесть партия райкомының икенче секретаре Шакир Мостафинны урыныннан «төгәрәтүләре» белән башланып китә. Әсәр чишелештән башлана һәм чишелеш белән тәмамлана. Ләкин чишелешнең әле повесть ахырында да тәмамланмавы тормыш агымының бертуктаусыз хәрәкәттә икәнлегенә ишарә ясый. Вакыйгалар барышында автор әйтергә теләгән идея тәмам ачыкланырга, әсәрне сатирик пафос белән тәмам сугарырга өлгерә. Шакир Мостафин образына хас типик сыйфатларны

ачу өчен автор параллельлек алымыннан файдалана, ягъни бирдә төп геройның тормышы ике чорга, ике тормышка бәйләп ачыла. Беренчесе—Чирмешән чоры. Шакир Мостафин Чирмешәндә райком секретаре булып эшләгән вакытта хатыны Мәрьям һәм өч яшьлек кызы, авариягә очрап, һәлак була. Шуны исәпкә алып, Мостафинны Камышлыга райкомның икенче секретаре итеп күчерәләр. Шакир Мостафинның көннәрдән бер көнне саклык кассасында эшләүче Нажиягә күзе төшә. Үзеннән күпкә яшь бу кыз аның күңел дөньясыннан кайгы-хәсрәтне куып чыгарыр кебек тоела.

Ә. Еники шулай итеп безне Байгузиннар гаиләсе белән (фамилиягә игътибар итегез: бай—гузин!) таныштыра башлый. Майпәрвәз ханымның карашлары, позициясе гаиләдә ныгып өлгергән. «Майпәрвәз ханым еш кына: ирне көлдергән дә хатын, бөлдергән дә хатын,—дип әйтергә ярата торган иде». Дөнья көтә башлагач та Майпәрвәз ирен үзе теләгән якка бора: милиционерлык эшен ташлатып, аны дәүләткә тире, йон, йомырка җыючы конторага агент итеп урнаштыра.

Майпәрвәз кызы Нажиягә дә Мостафин белән вәгъдәләшкән вакыттан башлап ук үз тәҗрибәсен тапшыра башлый: «Беренче кичтән ук ирне үзенә ефәк жепләр белән бәйли белергә кирәк,—ди иде ул, пышылдап кына». Майпәрвәз ханымның тормыш принцибы ачык, төгәл һәм шул ук вакытта куркыныч, чирканыч та. Ләкин ул барысын алдан уйлаган, шуңа күрә Майпәрвәз ханым күрсәткән юл максатка ирешү өчен иң кыска һәм уңышлы булып чыга.

Шакирның эчке уйларын ачу өчен Ә. Еники аның үткәне белән бүгенгесен параллель куеп тасвирлый. Беренче хатыны Мәрьямнең тыйнаклыгы һәм яшь хатын Нажиянең «ефәк жепләр» белән бәйләве арасында аерма гаять зур. Икенче чагыштыру Майпәрвәз белән беренче хатыны Мәрьямнең әнисе арасында үткәрелә. Мәрьямнең әнисе Мостафин күңелендә оялчан, әдәпле, тыйнак, эшчән карчык булып сакланып калган. «Ә менә бу акшарлы битенә елмаю каткан «әби»... Пылау белән сыйлар, җимеш суы белән сыйлар, ике сүзнең берендә «Шакир!» дип дәшер, әмма әрсез-хәйләкәр карашыннан: «Менә без сиңа нинди кызыбызны бирдек, кадеребезне бел!»—дигән горур кисәтү сизелеп торыр».

Үзе тап булган даирә Мостафинны кызыксындыра, акрынлап җәлеп итә, саз кебек үзенә суыра. Майпәрвәзләр йогынтысының үзенчәлеге, мәкерле ягы шунда, алар үзләренең һәр адымын яхшылык билгесе астында, кияүгә күрсәтергә тиешле табигый илтифат дип эшлиләр, ягъни аны үз якларына яхшылык, «кадер-хөрмәт белән аударырга тырышалар».

Мостафин исә кыен хәлдә... Бер яктан, ул—партия вәкиле, ана хезмәт итә. Әмма гаилә эчендәге көч тә Мостафинны үз тәэсиренә буйсындыра бара. Агымга каршы тора алмаган Шакир җиңелергә мәҗбүр. Рухи тотрыксызлык, ихтыяр көченең җитенкерәмәве аның киләчәктәге язмышын хәл итә. Шулай итеп Шакир Мостафинның үзен дә сазлык суырып ала, аның яшәү рәвешенең бик нык үзгәрүенә китерә.

Рухи һәм әхлакый сыйфатлар бик тә көчсезләнеп, бары тик матди мәнфәгатьләр генә өстен чыккан бүгенге көн, безнең кыргый капитализм еллары өчен Ә. Еникинең бу повесте никадәр актуаль яңгырый! Ә бит әсәр моннан ярты гасыр элек язылган!

Салкын акылга һәм хәйләгә таянып яшәүче образ Ә. Еникинең «Рәшә» повестендә дә килеп керә.

Повестьның төп герое Зөфәр Сабитов—яшәү принципларын алдан билгеләп куйган, бай, коммерция эшләренә маһир, икейөзле, максатчан зат. Аның һәр ясаган адымы уйланган, тормыш, яшәү принцибы анык билгеләнгән: «...агым уңаена агарга... заманга аркылы килүдән сакланырга... һәрвакыт уяу, тыйнак, мыштым булырга кирәк».

Ә. Еники "икейөзлелек" дигән масканың асылын әлеге әсәрдә төп герой булган Зөфәр образы аша ача. «Ул—реалист, анынча, баш исән булу гына чын бәхет түгел әле. Исән калган баш ничек яшәр—менә хикмәт нәрсәдә. Ә ул моның серен белә иде: бәхет—үзең теләгәнчә яшәү, бәхет—матди һәм рухи бәйсезлек ул!».

Зөфәрнең караклыгын, бармаклары үзенә таба кәкре икәнлеген күпләр белә,

ләкин заводта ана бер генә кеше—заводның кадрлар бүлеге мөдире булып эшли башлаган сынар куллы майор Симаков кына каршы төшә. Ул һәрьяктан Зөфәргә капма-каршы сурәтләнә: Зөфәр хәтәр елларда тылда ОРС начальнигы булып тыныч кына яшәп ятканда, Симаков сугыш кырында бер кулын югалтып кайта. Шуңа күрә ул Зөфәрнең кем икәнлеген тиз танып алса да, бары тик «Тыл күсесе! Халуй!»—дип атаудан ерак китә алмый.

Әлбәттә, Зөфәр эшләгән кыек эшләрне фаш итү, ачып салу җиңел түгел. Сынар куллы майор гына андыйларны җиңә алмый. Әсәрдә автор «сынар кул» детальнә күп мәгънә салган, ул Зөфәргә каршы кешеләрнең көчсез, ялгыз булуларына ишарә ясый.

Зөфәрнең күргән төше аша үз героеның киләчәген дә автор символ ярдәмендә алдан билгеләп куйган. «Тип-тигез очсыз-кырыйсыз дала, ялтырап яткан күл күренә, ... күпме генә барсаң да теге күлгә барып җитә алмыйсың. Чөнки ул юк, ул рәшә генә, коры далада алдап-котыртып уйнаклаган эссе шәүлә генә». Әлеге очсыз-кырыйсыз дала күренеше әсәрдәге төп образның күңел бушлыгын бик тәэсирле итеп күрсәтә.

Зөфәрнең чын уйларын, планнарын, мәкерле фикерләрен ачык күрсәтү өчен автор тарафыннан артистка Рәшидәнең саф, керсез күңеле алына. Кызның эчке дөньясын ачу—Зөфәрнең рухи түбәнлеген күрсәтү булып аңлашыла. Алар аерым-аерым кешеләр генә түгел, бәлки рухи яктан һич тә бербөтенне тәшкил итә алмастай затлар икән! Әсәр дәвамында шушы хакыйкатьне аңлау Рәшидәгә күңел җиңеллеге китерә. Зөфәр дә үзенчә нәтиҗә ясый—Рәшидә, никадәр матур, нәзакәтле булмасын, ана тормыш юлдашы була алмый. Үтә рационалист Зөфәр белән романтик Рәшидә—бер-берсен инкарь итүчеләр! Зөфәрнең сайлаган кәләше—Гамбәр туташ. Анда Сабитов өчен кулай сыйфат бар. Ул—күндәмлек. Зөфәренә «хуҗам!» дигәндәй карап торган Гамбәргә өйләнешүләренең беренче көненнән үк ул шаяртып, «сина, орчыгым, башыңны түбән иеп кенә тору килешә!»—дип куя. Гомумиләштереп әйтсәк, Ә. Еники геройлары өчен күндәмлек, буйсыну, баш ию аларның тискәре сыйфатлары буларак бирелә.

Ә. Еники иҗатында өлкән буын вәкилләрен сурәтләү зур урын алып тора. Автор, әлбәттә, аларга зур идея-эстетик бурыч йөкли. Өлкән буын яшьләр өчен һәр яктан үрнәк булырга, үткән тормыштагы уңай тәҗрибәне, рухи байлыкны югалтмыйча, алга таба дәвам иттерелүен кайгыртып яшәргә тиешләр. Чыннан да, туган җирдән, аның рухи тәҗрибәсеннән, традицияләреннән аерылуны язучы хәзерге тормышның әхлаксызлыгын күрсәтә торган күренеш дип бәяли. Локман картның фәлсәфи уйланулары («Тауларга карап»), Акъәбинең гаилә бөтенлеге турындагы хыяллары, милли тәрбия бирү теләге («Әйтелмәгән васыять»), Кларанын бабасы сагынып сөйләгән туган яклары («Туган туфрак»), Рамазан картның мәхәббәттәге тугрылыгы («Картлар») фонында һ.б. яшь һәм урта буыннарның кайбер вәкилләре шактый төссезләнеп кала.

«Әйтелмәгән васыять» хикәясендә Акъәби хәлсезләнеп түшәккә яткан сәгатеннән алып сурәтләнә. Сабыр холыклы, тыйнак бу карчык гомеренең соңгы көннәрен туып-үскән җиреннән аерылып, Уфадагы балалары карамагында яшәргә мәҗбүр.

Ул—гомере буе хәләл көче белән көн күргән киң күңелле кеше. Акъәби озын гомер юлы үтеп, зур тәҗрибә туплаган, халыкның акыл-зиһенен үзенә сеңдергән, илгә укымышлы балалар үстереп биргән. Алар ирешкән биеклектә үз өлешен аңлаган сурәттә дә, ул шәхси рәхәтлеккә дәгъва итмәстән, аларның илгә, халыкка хезмәтеннән канәгатьлек хисе кичереп яши. Анда ата-баба җиренә, тәрбияләп үстергән халкына, туган теленә, сакланып калган гореф-гадәтләренә, мәдәни байлыкка карата сакчыл, ихтирамлы караш тәрбияләү турында васыять әйтеп калдыру теләге көчле. Ләкин балалары Акъәбинең тавышсыз-тынсыз, аерым бүлмәдә ятуын артыграк күрәләр, берсе дә аны борчыган эч серләре белән кызыксынмый, хәтта хәл белүләре дә коры, формаль генә килеп чыга. Үзләренчә, алар карчыкка авыруын җиңелрәк кичерергә ярдәм итәләр сыман. Әмма иң мөһиме—аның җанын дәвалау ягын онытала алар. Нәтиҗәдә Акъәбинең борынгыдан килгән, яшьләр өчен әһәмиятле, киләчәкнең нигез ныклыгы өчен җирлек булырлык кыйммәтле

васыяте үзе белән бергә җир куенына китә.

Әсәргә берничә эпизодик персонаж кертелгән. Әмма алар әсәр тукымасында бик әһәмиятле урын тота. Әгәр хикәя үзәгендә торган Акъәби һәм аның балалары арасында аңлашылмаучылык тууын күзәткән булсак, характерлар бәрелешенә игътибар итсәк, әсәргә кертелгән ярдәмче образлар—Миңлебай карт, Гарифә, Сәетгали, шагыйрь—Акъәбинең теләктәшләре, аның уйларын хуплаучы, сайлаган юлының хаклыгына ышанучы, халыкчан традицияләрнең үсеш алачагына инанучы образлар буларак биреләләр. Балалар белән мөнәсәбәттәге контрастлык һәм ярдәмче образларның аңа карата теләктәшлеге Акъәби образының типик сыйфатлары ачылуын тәэмин итә, шуның ярдәмендә күтәрелгән мәсьәләнең әһәмияте үткенәйтә.

Хикәянең эпилогында Акъәбинең авылда калган сандыгын алып килү күрсәтелә. Балалар өчен бу искергән, кирәкмәс әйбер кебек. Шулай да сандыктагы башка әйберләр арасында кызы Гөлбикәне хәситә кызыксындыра, Суфиян улы Геннадийның күзе исә камчыга төшә. Авторның биредә барлык истәлек-реликвияләр арасыннан камчыга аерым тукталуы да очраклы хәл түгел. Камчы, бер яктан, заман рухын чагылдырса, икенче яктан, кешеләрнең кайсы якка текәлебрәк каравын, аларның сайлаган кыйблаларын билгеләргә ярдәм итә. Хикәядә камчыга салынган төп мәгънә—явызлык, әшәкелек сыйфатларының күрсәткече ул. Бу детальгә салынган мәгънә соңыннан башка әсәрләргә дә күчә. «Корьәнхафиз» хикәясендә камчы тотып торучы Хафиз сурәтләнә. Хикәя, беренче карашка, уку-укыту мохите, мәдрәсә тормышы, аның эчке тәртипләре, хәлфә һәм шәкертләр арасындагы мөнәсәбәтләрне ачуга багышлана. Ләкин бу—хикәянең бары тик өске катламы, ә төп фикер исә аскы катламда ята. Корьәнхафиз—изге сүзләрне яттан сөйләп йөргән адәм шул ук вакытта кансыз да, явыз да була ала икән! Һәм икейөзле сатлык та! Менә бу мәгънә дә актуаль түгел дип кем әйтә ала?! Югары дәрәҗә биләгән коммунистларның тиз арада икенче битлек киеп алуларын һәм яңа дәрт белән халыкның, җәмгыятьнең канын суыра башлауларын бик тә яхшы хәтерләтә бит бу күренешләр!

Моны, әлбәттә, шул чор хакимияте дә бик яхшы аңлый иде. Чөнки күп меңләгән җитәкчеләрнең, түрәләрнең бик күбесе нәкъ әнә шундый Корьәнхафиз кебек адәмнәр иде бит алар. Үзләренең ныклы иманнары булмаган, халыкка һәм илгә хезмәт итүне олы максат итеп куймаган, бары тик заманга җайлашып, заманча сөйләп үзләренә мөмкин кадәр күбрәк файда табарга тырышкан кешеләр иде алар. Ә. Еники үз әсәрләре белән әнә шундый типларны фаш итте. Әнә шуңа күрә ул коммунистларга һәм совет дәүләтенә карата күпмедер дәрәҗәдә оппозициядә булды. Шуңа күрә аны партия өлкә комитеты бер дә яратмады. Ә. Еники Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясен дә бик соңлап алды.

Әйе, Ә. Еники хикәяләрендә еш кына очракта повесть жанрына лаеклы, тирән һәм киң мәгънәле күренешләр яктыртыла. "Шаяру" хикәясендә, мәсәлән, әдип геройларын пароход палубасында сурәтли. Тук тормыштан, "ирекkә чыккан" Диләрә ханымның эчке дөньясы, кешеләргә булган чын мөнәсәбәте гадәти бер яулык ярдәмендә ачып салына биредә. Яулык—бу очракта мәхәббәт, сөю-сөелү символы. Диләрәнең дә сөеләсе, мәхәббәт татыйсы килә. Ул кайчандыр әлеге мөмкинлектән баш тарткан, тормышын үзеннән күпкә өлкән кеше белән бәйләгән. Хәзер, башка кешеләр өлешенә кереп булса да, аның әлеге хисне татыйсы килә. Пароходта кайтучы студент егетнең сөйгәненә дигән бүләген—яулыгын—җәдәштә алдап үзенә ала ул. Әгәр булдырса, әлеге яшь егетнең мәхәббәтен дә үзенеке итәр иде. Ләкин бу мөмкин түгел... Диләрә ханым—карт ир белән яшь егет арасында калган бәхетсез хатын. Бу—хатын өчен фаҗига. Диләрә ханым тоя башлаган әлеге бәхетсезлек Ә. Еникидә сәнгать чаралары ярдәмендә тирәннән ачыла.

Ә. Еники иҗатының тагын бик әһәмиятле үзенчәлеге бар: ул—милли рухка, милли моңга бай образлар тудыру остасы. Әдип халык характерының һәм яшәешенең еракттан килүче әхлакый нигезләрен үзе үткән юл, анда очраган кешеләрнең типик сыйфатларын гомумиләштерү һәм индивидуальләштерү аша ачып сала. Татар һәм башкорт халыкларында яшәп килгән изге йолалар, гореф-гадәт, традицияләрнең мәңгеләштергән символы буларак Ә. Еники "Җиз кыңгырау" хикәясен иҗат итә. Хикәя авторның үткәнгә сәяхәтен хәтерләтә. Әсәрнең өске катламында татар туе

ритуалы, этнографик картиналар, хозур табигать күренешләре, гаять кунакчыл кешеләр тасвирлана. Жиз кынгырау моны лейтмотив булып затлы хисләр янгырашын тәшкил итә Бу аһән төп герой Әхтәм күнелендә ныграк сакланып калган. Вакыйганын башында ук ишетелгән әлеге сагышлы көйгә Нигъмәтулла үзенең жыры белән кушылып китә һәм аның сагышы бөтен сәяхәтнең симфониясе булып янгырый.

Ә.Еники үзе музыка сәнгатеннән ерак торган кебек тоелса да, ул турыдан-туры жыр, музыка, уен кораллары, аларның кеше яшәешендә тоткан урыны, кеше күнеленә ясаган тәэсире турында еш яза.

Ә. Еники прозасында сәнгатьчә сурәтләү ысуллары да нигездә эчке дөньяны, рухи халәтне ачуга юнәлтелгән. Шул якны ачуда язучы сайлаган ин үтемле чараларның тагын берсе—табигать тасвирлары. Анын прозасында пейзажнын роле көчле һәм автор ана олы идея-эстетик бурыч йөкли. Әдип әсәрләрендә кеше һәм табигать арасындагы мөнәсәбәт тирән, эчке бәйләнештә бирелә. Бер яктан, пейзажны сурәтләү, икенче яктан, типик халәтне тасвирлау кеше характерын ачуда кулланылган ике параллель алым гына түгел, ә бәлки бер алымнын, синтезлашканербөтеннен ике ягы, ике юнәлеше булып тора. Бу үзенчәлекне язучынын «Төнге тамчылар», «Тынычлану» хикәяләрендә ачык күреп була. «Апрель киче. Юеш, жылы, томанлы. Карангы, тын урамнарда тып-тып тамчы тама». «Төнге тамчылар» хикәясе әнә шундый юллар белән башланып китә. Әлеге әсәрдә кеше характерын, гомумән, кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрне ачуда пейзаж әһәмиятле урын тота.

Ә. Еникинең «Тынычлану» хикәясендә дә табигать—эмоциональ халәт тудыру чарасы. Хикәядә ул төп герой Гасыйм Сәләховичнын эчке дөньясы, кәефе, кичерешләре белән тыгыз бәйләнештә бирелә. «...Көне... Иртәнге сәгатьтән үк бөркү эсселек үзен шул чаклы сиздерә башлар икән? Гажәп! Хәтта төне дә жинеллек китермәде, суынырга өлгермәгән таш йортлардан, таш урамнардан, тузан исен анкытып, һаман бөркелеп торды бу китмәскә килгән эсселек... Менә өч атна инде янгыр тамганы юк.

Гасыйм Сәләхович кин караватынын читенә таянып, күзләрен дә ачарга иренеп, тик кенә утыра. Әллә ялкаулыктан, әллә хәлсезлектән? Икесе дә бардыр, ахрысы....». Күрүебезчә, басынкы авыр һава Гасыйм Сәләховичнын эчке дөньясына күчә, «борчый, кәефен боза, куркытып та куя».

Ә. Еники кеше күнелендә туган газаплы кичерешләргә тәнгәл килерлек күренешләрне табигатьнең үзеннән эзләп таба, анын герой жанына ясаган тәэсирен сурәтли. Гасыйм Сәләхович күнелендә туган хафа, көчсезлек табигатьтә дә күзәтелә: әмма әлеге эсселек геройны һәрдаим озатып бара сыман. Гасыйм Сәләхович, бөркү һавадан котыла алмаган сыман һәр адымда борчыган йөрәгенә дә дәва таба алмый. Авыр, басынкы көннәр аны таушата, хәлсезләндерә.

Һәр туган көн Гасыйм Сәләховичка яна авырлыклар гына алып килә. Анын өчен ин якын булган кешесе—хатыны Рәмзия—иренен хәленә битарафлык күрсәтеп, больницага кереп ята. «Әйе, сәер халык бу хатыннар женесе, ике төпле, юк, өч төпле чемодан кебек, ниләр генә ятмыйдыр анын төпләрендә. Кайчагында шундый көтелмәгән берәр әкәмәт китереп чыгара, шаккатудан тәмам телсез каласын». Һәрхәлдә, хатыны Рәмзияне шундыйлар рәтенә кертеп караса да, Гасыйм Сәләхович ана иялəнгән, шуна күрә анын капризлары белән дә килешергә мәжбүр. Язучы үз героен гаиләнең тар кысаларында гына тасвирламый, башкарган эшләре, кылган гамәлләре аны кинрәк мәйданга чыгара. Әмма тормышында бердәнбер күнел юанычы булган фән өлкәсе дә ана жан тынычлыгы алып килми. Чөнки кайчандыр яклаган диссертациясе яна буын вәкилләре ирешкән уңышлар янында төссезләнгән. Бүгенге көн югарылыгында фикерләү—анын өчен хәл итә алмаслык бурыч.

Төп геройның антиподы булган Идеал Шәйхиев образы исә анын фән өлкәсендәге дәрәжәсен билгеләүче бер үлчәү буларак та кабул ителә. Тормышта үз урынын тапкан Идеал, табигый, остазы Гасыйм Сәләховичка караганда фәндә зуррак уңышка ирешә. Идеал—исеменнән үк күренгәнчә, үзен югары бәяли, һавалы кеше. Ул әсәрдә мөһим роль үти, төп геройнын чын хәлен ачыклаучы образ булып тора. Язучы чын фән кешесен, галимлек сыйфатларына ия билгеле бер тип тудыра.

Ләкин укучының симпатиясе, барыбер, карт галим ягында. Гасыйм Сәләховичның әсәр ахырындагы үлемен әдәбият галиме Ф. Ганиева «үлеме дә физик үлемнән бигрәк әнә шул рухи үлем булып, яшәү өчен көрәшмәү нәтиҗәсе булып кабул ителә»,—дип билгеләп үтте. Тәнкыйтьче, дөрестән дә, тагын бер кат рухи якның өстен чыгуына басым ясый. Төп герой теләк-омтылышларының нәтиҗәсе буларак «гомер буе теләгән, омтылган тынычлыгы аңа әнә шулай, ялгызлык, аңлаша алмау, битарафлык булып килгән».

Әмирхан Еники әсәрләрен укыганда аларның әдәби, сәнгати яктан үтә дә таләпчән рухта язылган булуына, аларның эстетик камиллегенә сокланасың! Аларда бит бер генә артык сүз дә, бер генә артык деталь дә юк. Әнә шуңа күрә әсәрләрнең тәэсир көче бик зур да инде!

Әдип иҗаты уңаеннан тагын бер җитди фикер телгә килә. Русның зур хикәячесе А. П. Чеховның һәр хикәясе диярлек киногa төшерелгән. Безнең Ә. Еникиебез дә нәкъ аның дәрәҗәсендә (әйе, без моны һич курыкмыйча әйтәбез) торган әсәрләр авторы бит! Ни өчен соң аларга нигезләнеп нәфис фильм булмаса, инде һич югы, телефильм төшерелми?! Ни өчен без аның әсәрләренең кыйммәтен аңламыйбыз?! Безнеңчә, бу—тулаем милли мәдәният алдында хәл итүне сорап торган актуаль мәсьәлә.

Ә. Еникинең повесть һәм хикәя жанрында ювелирдай оста булуы безнең әдәбиятта инде бәхәссез хакыйкать дип санала. Әмма биредә шуны гына өстәп әйтәсе килә. Аның әдип буларак көче, иҗатчы буларак зурлыгы һич тә оригиналь чагыштырулар куллануда түгел, шаккатарлык телбизәкләр табуда да түгел, мавыктыргыч сюжет ясиә вакыйгада да түгел аның көче. Әмирхан Еники үз әсәрләрендә тормышның, кешеләр яшәешенең гаять тә тирән мәгънәле күренешләрен зур психологик нечкәлек белән тасвирлап бирә ала. Ул укучыга бик тә гыйбрәтле, бик тә тәэсирле фәлсәфи сабак бирә. Әгәр дә без Еники әсәрләрен аларның бар булган мәгънәви һәм хисси хасиятендә дөнья укучыларына җиткерә алсак, ул чагында Еники әсәрләре, һичшиксез, иң зур бәягә лаек булырлар иде! Татар әдәбиятының дөнья күләмендә бик матур бер чагылышы булыр иде ул!

Ә. Еники иҗади эзләнүләренең бер этабы 70-80 нче елларга туры килә. Бу чорда ул үзенең шәхси тормыш тәҗрибәсенә, үткәненә бәйле уйлануларын укучыларга җиткерү максатыннан мемуар-автобиографик жанрга мөрәҗәгать итә.

Ә. Еникинең «Соңгы китаб»ы үзәгенә әдип тормышының тарих белән, әйләнә-тирәдәге кешеләр, гомум хәрәкәт белән күп төрле алыш-бирешен, элемтәләрен мөмкин кадәр тулырак, бөтен катлаулылыгында ачу бурычы куелган. Эссе жанрына якын торучы бу әсәрдә авторны чал тарих битләрен актарып, үз башыннан кичкән хәл-вакыйгаларны яңартып чыгу гына канәгатьләндерми, биредә үткән көннәргә, күренешләргә бүгенге көн югарылыгыннан торып карарга, бәяләргә тырышу да, кешеләрнең тормыштагы урынын, социаль кыйммәтен тарих бизмәнендә үлчәү дә сизелеп тора.

Укучы күз алдында әдип чордашларыннан тулы бер галерея пәйда була. Аларның һәммәсендә үзгә холык-сыйфат, кабатланмас язмыш.

Менә аның Фатих Әмирхан белән очрашуы.

“Китап магазинына барганда-кайтканда еш кына Ленин бакчасы аша үтеп йөри идем. Көннәрдән бер көнне менә шул бакча аша үтеп барам. Көз ахыры, агачлар инде шәрә, бакча юлларына сары яфраклар түшәлгән. Тын-буш юлларның берсеннән ак сакаллы кечерәк бер бабай тәгәрмәчле креслоны артыннан әкрен генә этәреп килә. Креслода пенсне кигән бер кеше утыра... Каршыма килеп җитмәс борын ук мин ниндидер бер күңел сизенүе белән креслодагы кешенең Фатих Әмирхан икәнен танып алдым: “Йа Хода!”—дидем ирексездән эчемнән генә һәм шунда ук адымнарымны әкренәйттем...”

Күрәсезме, бу өзек үзе бер аерым хикәя сыман мавыгып, бирелеп укыла. Чөнки әдип үзе дә аны җаны-тәне белән рухланып, шул күренеш алып килгән хис-кичерешләрдән тәмам тәэсирләнеп яза. Әнә шулар барысы да төгәл булып укучы йөрәгенә күчә. Оста әдип каләме үз йөрәген безнеке белән нечкә тоташтыра.

Менә ул мәшһүр Галимҗан Ибраһимов янәшәсендә Ялтада... Ә бераздан мондый

юллар: "Әгәр мин 1955 елда партия Үзәк Комитетына Галимҗан Ибраһимовның эшен янадан карауны үтенеп хат язганмын икән, әнә шул 1937 елда әдипне үз күзем белән күрү мина ул хатны тәвәккәлләп язарга, һичшиксез, ярдәм иткәндер дип уйлыйм".

Халыкка хезмәт итүнең Фатих Әмирханнар, Галимҗан Ибраһимовлар күрсәткән үрнәген Әмирхан Еники да яхшы үзләштергән. Ул тормыш көрәшләрендә кешелек һәм язучылык иманын ныгыткан. Китапның бер битендәге менә мондый юллар ул процессның нинди каршылыклар аша узуына мисал бирә. "Иҗат эше минем өчен башта ук шәхси эш, өзлексез уйлану белән бәйле **күңел** һәм **намус эше** иде. Мин бары үзем белгәнне, үзем ышанганны гына язарга тиеш дип уйлый идем. Ләкин бер бәхәс чыкканда мина әйттеләр: син үзең белгәнне, үзең уйлаганны эчеңдә калдыр, ә безгә без таләп иткәнне яз!—диделәр. Әмма үз күңелеңдә тумаганны заказ буенча гына язу?—Юк, мин моны аңлый да, кабул да итә алмый идем…"

Кешене икегә аеруга—аны икейөзле итүгә этәрүче көчнең анатомиясе биредә ничек ачык һәм типик чагыла! Әйе, мондый омтылышның безнең җәмгыятьтә шактый көчәеп киткән чорлары булды. Без эчтән берне уйлап, тыштан икенче төрле сөйләргә дә өйрәнеп бетә яздык. Ләкин ул чагында да халыкның, кешелекнең иман ныклыгын саклаучылар булды. Саф күңелле, нык-таза иманлы, көчле рухлы кешеләр булды. Рухи тормышыбыз көрәшчеләре булды! "Соңгы китап" әнә шундый көрәшчеләрнең күңел көндәлеге дә ул.

1980 нче еллардан башлап Ә. Еникинең публицистик мәкаләләре тупланган җыентыклары да дөнья күрә башлый. «Хәтердәге төеннәр» (1983) дигән мәкаләләр, очерклар һәм истәлекләр җыентыгы әдипнең әдәбият, сәнгать, тормыш мәсьәләләре хакында уйлануларын туплаган чыганак.

1990 нчы елларда һәм үз гомеренең соңгы елларына кадәр әдип газета-журнал битләрендә тормыш, яшәеш, үткәнебез, бүгенгебез һәм киләчәгебез турындагы, заманның актуаль мәсьәләләрен яктырткан мәкаләләрен бастырып торды. Шуларның нәтиҗәсе буларак 1996 елда аның тарихи-хронологик нигездә язылган соңгы җыентыгы "Кояш баер алдыннан" дигән китабы дөнья күрде. Биредә Ә. Еники бик итагатьле генә итеп үзе үткән елларга борылып карый, төрле җитәкчеләрнең ил белән идарә итү чорына объектив бәя бирергә омтыла. Рәсәй күләмендәге вакыйгалардан соң, Татарстан, аның бәйсезлеге мәсьәләләре күтәрелә. Язучы ил тормышындагы вакыйгалар турында җитәкчеләрнең, халыкның ана мөнәсәбәте турында да тәфсилләп яза. Гомумән алганда, "Кояш баер алдыннан"—безнең өчен гаять кыйммәтле чыганак.

Ә. Еники безнең арабыздан 2000 елның февраль аенда китеп барды… Үзе әйтмешли, әдәбиятны "күңел һәм намус эше" дип санап ул газиз милләте өчен гаять кыйммәтле рухи, әхлакый, фәлсәфи һәм эстетик хәзинә булган үлемсез әсәрләр иҗат итеп калдырды. Халыкның, бигрәк тә милләтнең яшәве, алга таба үсеше кыен булган елларда да, "томанлы" елларда да милләткә һәм аерым-аерым кешеләргә яшәүдә ышанычлы юлны югалтмаска булышырдай, җирдәге Намус һәм Гаделлек маякларын күрсәткән, әнә шуларны раслаган гүзәл әсәрләр язды ул. Шул ук вакытта алар, ул әсәрләр, үтә милли һәм халыкчан әсәрләр иде. Татар укучысының күңеленә бик тә ятышлы, халык җырлары кебек бик тә кадерле әсәрләр иде алар.

Әнә шуңа күрә үткән гасыр ахырында Әмирхан Еникигә "Халык язучысы" дигән исем бирелү Гаделлекнең һәм Әмирхан Еникины яклаучы, яратучы меңләгән кешеләрнең җиңүе, тантанасы булып кабул ителде.

Дөресендә дә, чын-чыннан халык язучысы иде бит ул безнең Әмирхан агабыз!

**Әлфия МОТЫЙГУЛЛИНА,**

*Татар дәүләт гуманитар педагогика университеты доценты.*

# ҖИЗ КЫҢГЫРАУ
# ТАТАРНЫ АЛГА ДӘШСЕН!

1999 елның 5 октябре. Чехов базары, "Мир" кинотеатры яныннан үтеп, "түрәи" гаиләләр гомер кичергән, ләкин тарихка *ул* яшәгәнгә кереп калачак йортка якынаям. Күңелдә шик-шөбһә бар. Әңгәмә кора алырбызмы? Аксакалның фикерләү куәсе хәзер ни чама икән?.. Юкка курыкканмын. Әмирхан ага Еники һаман да әле фәһемле, ушлы һәм кырыс-принципиаль гәптәш икән. Һич кенә дә "Соңгы китаб"ын инде 14 ел элек үк язган, ярты ел элек туксанын тутырган кап-карт бабай димәссең! *("Тәфсилле әңгәмә"без "Идел"нең 2000 елгы 4нче санында басылды.)*

"Чын татар язучысы бервакытта да татар милләтенең киләчәге турында уйланудан, борчылудан туктамады"—бер соравыма җавап итеп шулай диде бөегебез. Ләкин хәтәр елларда бу гамьне теләсә кем белән уртаклашып булмаган, ул үзе исә Бакый Урманче, Нәкый Исәнбәт, Әхмәт Фәйзи, Ибраһим Нуруллин, Фатих Хөсни, Нури Арсланов, Сибгат Хәкимгә бик ышанган, алар белән тәмам ачылып сөйләшкән.

Сүз татар тарихына күчкәч, мондый фикер әйтте аксакалыбыз: "Безнең тарихта иң фаҗигале язмышка дучар ителгән кеше—Сөембикә! Аны кулындагы сабый ханы белән Явыз Иванга әсирлеккә биреп җибәрүне Казан түрәләренең иң хурлыклы җинаятьләре дияр идем мин".

Акъәби турындагы соравыма җавап мондый булды: "Әйтелмәгән васыять"нең вакыйгасын һәм кешеләрен башкорт итеп язуның төп сәбәбе—татар итеп язсам, үтмәс, бастырып булмас дип шикләнүдән иде. Ә башкорт итеп язгач, ничектер җинел генә үтте әсәр... Әмма "Әйтелмәгән васыять" башкорт телендә дөньяга 20 елдан соң гына чыга алды. Моның сәбәбен аңлау бик читен иде..." Башкорт халкына тагын бер әдәби героен бүләк итте әле Әмирхан ага. Мәшһүр "Йөрәк сере"ндә Зөһрәгә бәхет Бәхетгәрәй атлы гаҗәеп бер башкорт егете булып килә.

Әмирхан агабызны соңгы тапкыр 2000 елның 20 гыйнварында күрдем мин. Әдип диванда чалкан ята иде. Күрешергә дип кулын да яткан килеш кенә сузды. Нык кына авырып китүен, чире ни икәнен белмәвен ничектер дулкынланып, хисләнеп сөйләде ул. Инде дүрт-биш ел элек үк "Үлем мине ни сәбәптер куркытмый", "Без әзер, без тыныч", дип язса да, беркадәр әсәрләнгән, гаҗәпләнгән-аптыраган шикелле тоелды ул миңа. Күзләре дә ничектер бик тере елтырый иде. Әйтерсең лә үлем түшәгендә 91 яшьлек Әмирхан түгел, бәләкәй Әмир ята—тансык, кадерле, бераз иркә дә. Алар 11 баладан ике төпчек малай—Әмирхан абый белән энесе Илдархан гына исән калганнар бит. Шуңа күрә бөтен кардәш-ыру аларны "ике бөртек" дип атап йөрткән, өсләрендә кан калтырап, саклап үстергән. Икесен бергә кунакка да җибәрмәгәннәр хәтта... Әмирхан абый хәзер гүяки әнә шул үтә кадерле "ике бөртек"нең инде соңгысы да бөтенләйгә юкка чыгачак бит дип борчыла иде...

Ә минә иркә язучы булу тәтеми ана.

1979 елда Актерлар йортында үткән юбилее бик тә истә. Әмма бу бәйрәмдә катнаша алуымның могҗизага тиң эш булуын 21 еллап вакыт үткәч, юбилей комиссиясенең рәисе Аяз Гыйләҗев белән сөйләшкәннән соң гына белдем мин. Болай дип аңлатты ул:

—Язучылар союзына обкомнан ахылдап-ухылдап Гариф Ахунов кайтып

керде һәм, мине читкәрәк тартып, “Аяз! Вәлиев[1] Еникинен юбилеен үткәрмәскә кушты!”—диде. Мин шаккаттым, бик каты ачуым чыкты, һәм мин Туфан Миңнуллин янына кереп киттем. Туфан ул чакта Союзның партоешма секретаре иде. Һәм әйттем: “Әгәр дә Еникинен житмеш еллыгын үткәрмәсәк, халык күзенә ничек күренербез?!”—дидем. Туфан—кызу кеше, шундук ярсып-дулап обкомга китеп барды... Ул жинеләеп кайтып керде һәм: “Рөхсәт бирделәр!”—диде...

Аяз абыйның әйтүенчә, Әмирхан ага юбилей президиумына бик тә-бик тә Нәкый Исәнбәт белән Хәсән Туфанны утыртырга теләгән, әмма бу кадәр үк “крамола”га юл куймаганнар.

Эчке энергиясе шулкадәр дә зур булган мондый юбилей кичәсен мина бүтән беркайчан да күрергә туры килмәде. Башланудан күп алда ук шыгрым тулган, әллә нихәтле кеше басып та торган залның һавасын әйтерсен лә протест биодулкыннары айкый иде. Нәрсәгә протестмы? Куштан язучыларга бөтен шартлар булдырылып та, Әмирхан Еники, Нурихан Фәттах, Аяз Гыйләжев кебек ихлас каләмле жете талантларга киртә арты киртә куелуына, яраткан язучыбызнын һаман да әле үз ижатына гадел бәһане ала алмавына. Милли аны саулар исә чын милли язучыбызны олылау аша татарның ул чактагы хәленнән, илдәге милли сәясәттән ризасызлыкларын да чагылдырмакчы иде кебек. Яшьләр аеруча кыбырсып йөрде. Мансур Вәлиев, Аяз абыйның доклад текстына Еники ижатының милли аслын ачкан шундый-шундый сүзләрне кертәсе иде бит дип өзгәләнеп утырды-утырды да, бер заман юкка чыкты. Унмы-унбишме минуттан ул, еактан ук балкып, елмаеп килде һәм “Булды!” диде.

Кичә рәсми-сүрән генә ачылып, Әмирхан абый сәхнәгә чакырылгач, янымда утырган Зөлфәт мина: “Әйдә, басабыз!”—дип пышылдады. Без урындыкларны шыгырдатып торып баскач, житәкче әһелләр аптырап безгә текәлде. Ул заманда бит жыелыш-фәләннен шәрәфле президиумы итеп Үзәк комитет политбюросын сайлаганда гына басалар иде әле. Без арттан дүртенчеме-бишенчеме рәттә утыра идек. Менә дөбер-шатыр бездән арттагылар да торып басты. Кул чабулы бу кайнар ихтирам дулкыны арткы стенага терәлеп сүнеп калмады, ничектер бездән алга сикереп, тиз арада беренче рәткә кадәр йөгереп үтте. Нишләсен, президиумдагы рәсми әһелләр дә торып басып, Еники атлы әдипне алкышларга мәжбүр булдылар...

Бусы мина 2000 елда Гариф Ахунов сөйләгәннәрдән:

—1966 елны Әмирхан аганын “Салават күпере” дигән хикәяләр жыентыгы басылып чыкты (аңа әдипнен “Бер генә сәгатькә”, “Кем жырлады?”, “Тауларга карап”, “Матурлык”, “Әйтелмәгән васыять” кебек бөтен татар әдәбияты тарихында да иң-иң әйбәтләрдән саналырлык әсәрләре кергән—Р.Ю.). Язучылар союзы аны Тукай бүләгенә тәкъдим итте. Әмирхан аганың бүләкне аласына берәү дә шикләнмәде. Союзнын рәисе Мирсәй Әмир хәтта “Бүләкне сина бирәбез, табын әзерлә!”—дип тә әйткән булган. Әмирхан агага бүләк тәтемәде. Обкомда анын турында: “Олы юлдан бармый”, дигәннәр...

Бөек әдипкә Тукай озак “тәтеми” әле. Уллары тиярлек язучылардан Шәүкәт Галиев алып—12 ел, Марс Шабаев белән Диас Вәлиев алып—8 ел, Равил Фәйзуллин алып 6 ел үткәч кенә аны да, ниһаять, лаек дип табалар. 75 яшендә!

Олы житәкчеләр катнашында Камал театрында юбилей үткәрү, шәп фатирга тиенү гомеренең соңгы елларында гына насыйп булды абзабызга. Заманалар үзгәргәч, әдәбияттагы олы юлнын башка турдан үткәнлеге хакимнәргә дә мәгълүм булгач.

—Яшьләрнен “Азатлык!” дип оран салуларын да, Татарстанның яшел-кызыл төстәге флагын да мин тыныч кабул иттем,—диде Әмирхан ага.—Аларнын вакыты житкән иде. Милли азатлык хәрәкәте бөтен Рәсәйне басып киткән иде инде. Бездә исә ул хәрәкәтнен башкалардан иртәрәк башлануы да аңлашылса кирәк. “Вак” милләтләр арасында иң эресе, көрәшкә иң әзере без идек бит!

[1] М.Ф. Вәлиев ул чакта – партия өлкә комитетының идеология буенча секретаре.

Мондый сүз дә әйтте мина Әмирхан ага:


—Бәйсезлек өчен кулга корал тотып көрәшүнең корбаннары күп, нәтиҗәсе юк диярлек. Кайда тулы мөстәкыйльлек, чын бәйсезлек? Күп мәсьәләләр, кабул ителмәгән дога шикелле, һавада асылынып кала. Мисаллары—Карабах, Абхазия, Чечня... Тулы бәйсезлек өчен көрәшүгә караганда безгә хокукларыбызның булган кадәресен саклап калу һәм арттыру өчен, Рәсәйдә чын федерализм өчен көрәшү кулайрак түгел микән?—Көчсезлек, мескенлек галәмәте эзләмик моннан. 1999 ел бит әле бу, хокукларыбызның хәзергедән күп мулрак чагы. Әмирхан агабыз болай дип тә әйткән кеше: "...Әмма күпме генә вакыт узмасын, агрессия—агрессия булып кала, ә шуның корбаны булган халык үзенең мөстәкыйльлеген кайтару хокукын беркайчан да югалтмый" *(Татар мәсьәләсе. Идел, 1990, № 10).*

Элекке хакимнәргә җайлашмаган-яраклашмаган кебек, бөек әдип яңаларына да мөкиббән китмәде, кирәк булганда тәнкыйть сүзен дә кистереп әйтә белде. Хәтта Татарстан президенты М. Шәймиев тә әнә, әдипнең туры сүзле булуы турында сөйләгәндә, "Мин моны үз җилкәмдә тойдым",—дигән иде.

2004 елны Татарстан китап нәшриятында Еникинең 5 томлык "Әсәрләр"е чыкты. (Кызганыч ки, төзүчесе, Әмирхан агайның соңгы, өченче хатыны, Ш. Мәрҗани оныгының кызы Наҗия Ильясова исеме китапта кара рам эчендә бирелгән иде.) Татар хәреф таныганда һич искермәячәк томнар бу! Инде, озакка сузмыйча, Әмирхан ага турындагы истәлекләр китабын да чыгарасы иде бит!

* * *

Әмирхан абыйга биргән иң беренче соравым ул үзе "хикәя-истәлек" дип атаган мәшһүр әсәренең "герое" турында иде. Әдипне үз иткән бер генә кеше дә белми калмастыр аны—14 яшьлек хыялый үсмерне туй буласы Абзан авылына җилдереп алып барган сары атның дугасында "зың-зин, зың-зин" килеп чыңлаган җиз кыңгырауны. Әсәрнең исеме дә "Җиз кыңгырау" бит. Берәр ничек сакланып калып, таба алсак, нинди кыйммәтле әдәби ядкарь буласы иде кана бу кыңгырау!



*Әмирхан Еники үзенең эш бүлмәсендә хатыны Наҗия ханым белән.*

Табып булыр да кебек. Мин аның эзенә төштем бугай инде. Әүвәл менә бу өзекне укып алыйк әле: "Минем китаплар шүрлегендә тавыш-өнсез генә җиз кыңгырау тора. Ул шул Абзан туена, Нигъмәтулла абзыкайның сары ат башында, кара дугага тагылып барган кыңгырау икән, аны мина күп еллардан соң Мәдинә җиңгәчәй биргән иде..." Моны Әмирхан ага үзе үк язган. Кайда язганмы? Әллә кайда түгел, шул "Җиз кыңгырау"да ук язган. Ягъни 1966 елны.

Инде әңгәмәдән алда бирелгән юлларга да күз салыйк. "Аның эш бүлмәсенә керү белән, әле студент чакларымда ук күрергә хыялланган әйбер турында сорадым. Исән микән ул?.. Исән икән, әле дә, әдип 33 ел элек язганча, китап шүрлегендә тора икән! Юкса ул вакыт эчендә шүрлек кенә түгел, фатир да алышынган инде...

Ана үрелгән чакта Әмирхан аганың күзләре кысыла төште, кулы да чак кына калтырап куйды. Тегесе дә, сөенеп, аваз салды. Бераздан агаебыз аны берничә кат селкеп тә алды әле. Түрәләр йортының биек түшәмле иркен бүлмәсе кыңгырау чыңына күмелде".

Кыңгырауны эзләгән булып уен уйнап алган өчен укучылардан гафу үтенәм. Ачу килгәннән бу. Яһүд һәм урыс зыялылары бөекләрен халыкка таныта беләләр әнә. Юбилей үткәрү осталыкларына да таң калырлык. Житмәгән бөеклек детальләрен бар итеп, матур-матур мифлар да тудыргалыйлар кебек хәтта ки. Без исә булганын да эзләмәскә, күз алдында ятканын да күрмәскә мөмкинбез. Шулкадәр дә хисси, хатирәи куәткә, мәгънәви егәргә ия бу жиз кыңгырау шулай онытылып ятарга тиеш идеме соң, йә?

"Ул туйга катнашкан кешеләрнен бик күбесе—кода бабайлар, Хөбәйдулла кода, Нигъмәтулла абзыкай—күптән бу дөньяда юк инде...

Әйе, дөньяда бөтен нәрсә искерә, туза, үзгәрә, тик менә жиз кыңгырау, ни хикмәттер, һич кенә дә бер үзгәрми. Чак кына кагылдың исә, нәкъ теге вакыттагы шикелле, көмештәй саф, нечкә, дәртле тавышы белән бүлмәне яңгыратып жибәрә. Һәм күз ачып йомганчы мине ундүрт яшьлек чагыма—үземә урын таба алмыйча гел борчылып йөргән, нидер сизенеп көткән иртә яшьлегемә кайтара да куя. Барысын-барысын да үтә бер ачыклык белән терелтә ул минем хыялымда..."

Әңгәмәдән соңгы текстка да күз салыйк әле: "Жиз кыңгырау исә, күпме гомердән соң киштәдән төшеп, янә Еникиләргә хезмәт итеп алган. Әмирхан абыйның соңгы көннәрендә аның белән янәшә булган ул. Нажия апа башка бүлмәдә чакта кирәге чыкса, Әмирхан абый аны кыңгырау шалтыратып дәшкән..."

Хәзер менә Әмирхан агай да, Нажия апа да юк инде...

Жиз кыңгырауны алда ни көтә? Якын яки ерак оныклар кулында гади бер уенчыкка әйләнеп калып, бөтенләйгә югалмасмы ул?

Аптырагач, Тукай музеена да мөрәжәгать итеп караган идем. Илтифат итмәделәр.

Юк, авазлы-жанлы бу ядкарьнең урыны музейда түгелдер. Хикмәтле чыңы белән язучыларның съездларын, әдәби ел йомгакларын, идарә утырышларын ачып жибәрергә тиештер ул, бәлки?

Ләкин әдәби кысага гына сыя микән ул? Татарның бөек әдибе, чын милли язучы рухын сеңдергән жиз кыңгырау тулаем татар халкы өчен дә кыйммәтле ядкарь ләбаса. Аннан, Әмирхан ага үзе дә, Нигъмәтулла абыйсы да (әтисенең энесе)—татар тарихына ялганган затлар бит, сынмаган-сатылмаган "чабаталы" морзалар нәселеннән алар.

Быел җәй "Жиз кыңгырау"да тасвирланган хәлләргә 85 ел тула. Хәзерге көннән торып карасаң, туйга бару вакыйгасында бар да символик мәгънәгә ия сыман. Татарның тарихи юлдашы булган ярсу ат. Алга омтылган, жилкенгән-иләсләнгән татар морзалары. Үсмер морзаны матур озын гомер, данлы-шанлы киләчәк көтә. Жиз кыңгырау исә—ашкынып татар туена, татарның матур киләчәгенә бару символы кебек. Бәс шулай икән, безнең күңелләрне жилкендереп, рухландырып торгаласын әле ул. Татар конгрессларын ачсын, яңа заман дугаларында чайкалып, Сабан туйларында, суверенитет бәйрәмнәрендә бу борынгы да, яңа да Казаныбызга дәртле моңын сибеп, киләчәккә дәшсен. Татарны гел алга әйдәп торсын!

**Рәфикъ ЮНЫС.**
2009 ел, гыйнвар


*Бу документ Әмирхан аганың кызы Резеда кулында сакланган архивында иде. Матбугатта бастыру өчен әзерләнгән мәкаләнең кульязма нөсхәсе булса кирәк ул. Ләкин аның ни Башкортстанда, ни Татарстанда басылуы яки кемнең дә булса кулына килеп керүе безгә нәмәгълүм. Машинкадан (компьютердан) чыккан өч нөсхәсе дә ниндидер кабинетларда тузланып ятмый микән?*

*Мәкалә 1991 елда язылган булса кирәк. Аны бер генә сүзен дә кыскартмыйча басабыз.*

# ТИГЕЗЛЕК АША ТАТУЛЫККА

Татар-башкорт мөнәсәбәтләренә тулы ачыклык кертер вакыт җитте, минемчә... Моңарчы без бу мөнәсәбәтләрнең елдан-ел бозыла баруын күреп, ишетеп торсак та һәм шуңа кәефебез бик кырылса да, ике арадагы “дуслык” хакына сүз әйтүдән тыелып килдек. Аннары күршеләр эшенә тыгылу булмасын дип тә үтә саклык күрсәтергә тырыштык. Әмма ләкин менә мин шул күрше җирләрдә туып-үскән, шуның һавасын сулаган, суын эчкән татар язучысы буларак, Башкортстанда яшәүче татарларның бүгенге хәле һәм киләчәк язмышы турында күптән үк уйланып, борчылып килүемне әйтмичә кала алмыйм. Менә минем хакым бардыр дип уйлыйм.

Сүзне мәгълүм нәрсәләрдән башлыйк: Башкортстан—күп милләтле республика. Ләкин аның 90 проценты чамасы халкын өч милләт—урыс, татар, башкорт тәшкил итә. Сан ягыннан урыслар беренче, татарлар икенче, башкортлар өченче урында. Татарлар белән башкортлар төрки халык, диннәре бер, телләре бик якын. Мостай Кәрим Казанга бер килүендә бу ике халыкны бер төптән үсеп чыккан куш каенга охшаткан иде. Моңа бик җиңел ышанырга була; бик борын заманнарга кермичә, соңгы 4-5 гасырны гына алганда да татарлар белән башкортлар бер үк җирләрдә аралашып, кәсеп итешеп, кызлар да бирешеп яшәп киләләр. Сугыш-кырылыш түгел, татулык хөкем сөргән алар арасында. Шулай да алар, чыгышлары буенча төркидән саналсалар да, икесе—ике халык. Моны истән чыгармаска кирәк. Әмма ни кызганыч, борыннан яшәп килгән татулык соңгы елларда анлавы читен дошманлыкка әйләнә. Дөресрәге, кемнәрдер әйләндерергә тырыша. Ике халыкның да абсолют күпчелегендә бер-берсенә дошманлык булмаска тиеш. Мәсәлән, мин үскән Этколда (хәзерге Дәүләкәндә) башкортлар белән татарлар бер үк урамнарда күршеләр булып яшәделәр, иллә-мәгәр алар арасында дошманлык түгел, бернинди җитдирәк низагы да булмый торган иде. Һәр ике халык та борыннан килгән гореф-гадәтләрен саклап, тыныч кына яши бирәләр, бер үк мәчеткә йөриләр, бәйрәмнәрдә бер-берсенә кунакка йөрешәләр иде.



Бер урамдагы күршеләр арасында булмаган дошманлыкнын бер-берсеннән ерак утырган татар-башкорт авыллары арасында булуы мөмкинме, нәрсә житми, нәрсә бүлешәселәре бар аларнын? Жир-су бүлешәселәре юк лабаса!..

Әмма ясалма рәвештә тудырылган милли антагонизм шулай да бар. Бу антагонизм бигрәк тә бер ише башкорт укымышлыларынын татарга карата мөнәсәбәтләрендә ачык күренә башлады. Күптән моны сизеп килә идек инде, ләкин вакытлы гына чирдер, бер үтәр әле дип ышана идек. Мәгәр ул үтү түгел, отыры көчәя генә барды. Ахырда бөтенләй милли шовинизм төсен алды—аеруча башкортнын шәһәр яшьләрендә... Һәм бу аяныч хәлнен төп гаепчесе—Башкортстаннын партия житәкчелеге дияр идем мин. Сонгы 15-20 ел эчендә башкортны татарга каршы кую, татарны төрлечә чикләү-кысу, хәтта аны йотарга тырышу Башкортстан житәкчеләренен рәсми сәясәтенә әйләнде. Жан исәбен алганда татарларны авылы-авылы белән башкорт итеп язу, татар мәктәпләренә көчләп башкорт телен кертү, татарларны үз телендәге матбугаттан, китаптан аеру—болар барсы да житәкчелектә утыручыларнын инициативасы белән ачыктан-ачык эшләнә башлады. Моны инде Совет шартларында бөтен бер халыкка карата үткәрелгән геноцид димичә мөмкин түгел.

Мондый сәясәтне анлау өчен бер нәрсәне истә тотарга кирәк. Башкорт борынгы халык булса да, яшь милләт, Россия дәүләтенә "ирекле" кушылса да "ак патша" кулыннан милли мохтарият алалмады. Бары революциядән сон гына ул, Зәки Вәлиди аркасында, күп милләтләрдән элегрәк автономия алуга иреште. Табигый инде, үз исемендәге республикада ул тизрәк үсәргә, күтәрелергә, бары үзе генә төп хужа булып танылырга тиеш иде. Әмма ни өчен анын бу омтылышы татарга каршы юнәтелде сон?

Мәгълүм булганча, ин башта татар-башкорт жөмһүриятен төзү күздә тотыла. Тиешле карары да чыгарыла, проектлары да эшләнә, ләкин төрле сәбәпләр нәтижәсендә бербөтен жөмһүрият урынына аерым-аерым башкорт һәм татар республикалары төзелә. Һәм менә шул чакта ук инде ике халык арасын киләчәктә бозачак хәтәр орлык салынып кала да. Мин моны Мәскәү тарафыннан татар халкына карата үткәрелгән мәкерле сәясәтнен нәтижәсе дип карыйм. Чынлап та, Идел—Урал арасындагы зур бер регионда тоташ яшәп килгән татар халкын кыл урталай бүлеп, ике якка аерып кую шуны раслый түгелме?!.. Арада тар гына елга, ә язмышларда нинди зур аерма! Нәтижәдә без бөтен бер милләт булып яшәү мөмкинлеген югалттык.

Бәлки татарны болай аерып кую башкорт файдасына булгандыр?.. Юк, киресенчә түгел микән, чөнки республикада татарнын бернечә йөз менгә күбрәк булуы чын башкортнын гел эчен пошырып, саруын кайнатып торучы сәбәпләрнен берсе булса кирәк. Ике тәкә башы бер казанга сыймый дигәндәй, башкортнын татарны һаман да күпсенүе, анарга гел генә каныгуы да башлыча әнә шул "тарлыктан" кыбырсыну аркасында киләдер дә, ахрысы. Сонгы вакытлардагы ямьсез күренешләр дә шуны раслый, минемчә.

Кайчагында уйлап куям: Зәки Вәлидинен башкорт халкын үз жирендә күпчелек итәр өчен "Кече Башкортстан" төзеп, башкаласын да Стәрлетамакта ясавы дөресрәк булмады микән?!..Асылда бит башкортларнын төп массасы "Кече Башкортстан"га кергән жирләрдә тупланып яши дә. Исемендә "кече" дигән сүз булса да, ул шактый зур һәм табигате белән гаять бай территорияне—Жанүби Уралны, Ирәндек, Сакмар, Ашказар, Акидел (урта агымына чаклы), Дим буйларын эченә алган. Монда татарлар булса да—азчылык. Ә Уфа тирәсе торгыны татар, Уфа үзе дә татар каласы, инде анардан көнбатышка табан китсән, Ыкка кадәр тоташ татар авыллары тезелеп утырган... Боларны Башкортстанга кертеп, нигә әле ике халыкны буташтырырга, башкортнын милли бөтенлегенә куркыныч тудырырга? Шулай уйламады микән үзе дә типтәрдән чыккан Зәки әфәнде?!..

Хәер, бу хакта башкалар да уйлаган булырга тиеш. Чөнки Татарстанны игълан иткән декретнын махсус искәрмәсендә Бәләбәй һәм Бөре өязләренен

кайсы республикага керү мәсьәләсен соңрак халыктан сорап хәл итәргә диелгән иде. Ләкин кызганычка каршы, Ленин кул куйган декретның шушы искәрмәсе гамәлдә үтәлмәде, халыктан сорап тормыйча гына үзәк карары белән ул өязләр Башкортстан составында калдырылды.

Әнә шулай туа хәзерге Башкортстан... Республика зур, бай, милли составы бик чуар, мәгәр моңарчы алар бер үк җир-суларда ничек яшәгән булсалар, шулай яшәргә дә тиешләр. Башкортның азрак, татарның күбрәк булуы да әле ул чакта нindидер бер гайре табигый хәлдән саналмаган. Яна туган уртак республиканы бергәләп җитәкләү, аякка бастыру да беренче нәүбәттә алар өстенә төшкән. Тик шуны әйтергә кирәк, татарлар башкортка караганда һәр җәһәттән алгарак киткәнгә күрә, республика тормышында да алар зуррак урын тоталар. Җитәкче органнарның күбесендә татар коммунистлары утыра, мәгариф һәм мәдәният өлкәсендәге эшләрне дә башлыча татарлар алып бара. Республиканың гамәлдәге теле дә ул чакта татар теле—гәзит-журналлар, китаплар да татарча чыгалар, йөзләгән башкорт авылларында балаларны да татар мөгаллим һәм мөгаллимәләре татарча укыталар. Моның өчен рәхмәт әйтүче булгандырмы—белмим, ләкин татарның ул хезмәтен башкортны "татарлаштыру" дип аңлатырга тырышулар соңгы вакытларда еш ишетелә башлады. Бу, әлбәттә, чеп-чи ялган. Татар бит башкорт арасына читтән миссионер булып килмәгән, ул да бит шул ук илнең бик күптәнге үз кешесе... Үзендә барын тугандаш халыкка риясыз бирүче генә... Көчләп-җылатып чукындыру, ә чукынмаганнарын качып китәргә мәҗбүр итү түгел ич бу!.. Башкорт үзенең җирләрендә һәмишә искечә хөр-иркен яши биргән.

Әмма башкорт исемен йөрткән республика, иртәме-соңмы, башкортлашырга тиеш иде, билгеле. Башы аның автономия алган көннән үк башлана. Ә инде егерменче елларга кергәч, бигрәк тә башкортның үз әдәби теле гамәлгә куелгач, башкортлашу аеруча көчәя. Бу унай белән шуны әйтү дә урынлы булыр: башкортның үз әдәби телен булдырырга омтылуын Галимҗан Ибраһимов Казаннан торып бик нык яклап чыга. Аннары башкорт телендә әлифба төзү, дәреслекләр чыгаруда да Уфаның үзендәге татар укымышлылары якыннан катнашалар... Әлбәттә, башкортлашу бик законлы табигый күренеш иде. Һәрбер автономия алган республикада ул шулай куелган, шулай бара да. Ни дәрәҗәдә ул дөрес, гадел бара—бусы икенче мәсьәлә.

Һәм Башкортстан шартларында әнә шул "икенче мәсьәлә" озакламый беренче урынга чыга да инде. Ягъни башкортлашу процессы көчәя барган саен татар халкының хокук һәм мөмкинлекләре чикләнә бара. Бу хәл үзен бигрәк тә культура өлкәсендә ачык күрсәтә: бөтен матбугат әкренләп башкорт теленә күчеп бетә—татар телендә бары бер гәзитә генә торып кала. Татар телендә китап чыгару да туктала. (Татар әдип, шагыйрьләре башкорт теленә күчәргә мәҗбүр була.) Театрда да шул ук хәл—күпчелеге татар артистларыннан торган Уфа театры башкортча гына уйный башлый.

Хәлбуки, Башкортстанның ул чактагы Конституциясендә татар теле дә башкортныкы белән беррәттән дәүләт теле булып саналган. Шулай булгач, һәр ике халыкның да милли культурасы бер үк хокуклар белән файдаланып, янәшә яшәргә һәм тәрәккый итәргә тиешләр иде.

Ул чагында татар культурасы башкортныкына үсәргә ирек бирмәс иде, диючеләр булыр. Мин үзем моңа ышана алмыйм, чөнки башкорт халкының милли аңы бик көчле, теле бик бай, фольклор иҗаты да гаять бай, саф үзенчә яшәргә һичшиксез кодрәтеннән килер иде. Миңа калса, үзләренең асыл нигезләрендә яшәгән ике якын культура бер-берсен бары тик баетыр гына иде. Бу минем күптәнге карашым... Мәгәр бер халыкның мәдәниятен икенче халыкның мәдәни ихтыяҗларын чикләү исәбенә үстерергә тырышу—бу инде, йомшак итеп әйткәндә, әдәпкә сыймый торган нәрсә. Ә миллионнан артык татарны кая куясың?.. Ул әнә яши, үрчи, картлары урынына үсеп җитә яшьләре. Республика туган көннән

алып, анын тормышында бик актив катнашып килә. Татар күче кермәгән бер генә хезмәт тармагы да юктыр, мөгаен. Ләкин милләт буларак анын нинди хокуклары бар, милли ихтияжларын теләгәнчә үти аламы ул?.. Һәр милләт кешесенә җитди ачылыр һәм үсәр өчен мәйдан кирәктер бит инде... Һәм менә күчле чишмә үзенә юл эзләгәндәй татарлар да башкортлаштыру процессына тартыла башлыйлар. Язучы буласы килгәне башкортча язарга тотына, фәндә эшләргә теләүчесе—башкорт галиме булып китә, житәкчелеккә үрмәләүчеләр—гүя чын ихластан башкорт патриотына әйләнә... Озакламый бу "башкортлашу"нын тагын бер гаҗәеп ягы күзгә ташлана: татардан чыккан кайбер кешеләр ансат кына башкорт булып китә; янә килеп, башкорт тарихын баету максаты белән татар мирасына әкренләп керү башлана. Совет чорындагы милли сәясәттә алдау, ялган, фальсификация һәр халыкта да бик күп булды, бу шаукымнан татар-башкорт та, билгеле, читтә калмады. Мирас мәсьәләсе, әлбәттә, катлаулы мәсьәлә, аны бары тарихи дөреслектән чыгып кына хәл итәргә мөмкин—бу исә галимнәр эше. Шуна күрә мин бәхәссез ике мисал китерү белән генә чикләнәм: берсе анын, бик күптәнгесе—татарнын милли шагыйре, үз гомерендә бер авыз башкортча язмаган Мәҗит Гафурины башкорт классигы дип игълан итү; икенчесе, сонгы вакыттагысы—татар халкынын күнелендә күптән кадерле урын алган, татар драматургиясенен классик гәүһәре булып саналган "Галиябану"ны башкорт драматургиясе үрнәге итеп тану... Йә, әдәбият тарихы белән күпме-азмы таныш кем генә бу ялганнар белән килешә алыр икән? Ә бит бер ялган икенче ялганны тудыра, һәм ул бервакытта да халыкларны якынайтмый, читләштерә генә.

Шулай ук мин бер милләттән икенче милләткә күчүнен дә бик четерекле бер мәсьәлә булуын яхшы анлыйм. Бигрәк тә татар белән башкортка килгәндә, икесенен берсе булып аталуы бик җинел. Алар арасында аралаш никахлар да аз булмаган—шул сәбәпле катыш канлы татарны да, башкортны да күп табып булыр иде. Шуна күрә минем шәхсән беркемне дә милләтен алыштырган ул дип атап күрсәтәсем килми. Хакым да юк, белмим дә... Тик шуны гына әйтә алам, чын башкорт хәзерге заманнын яна "башкортына" ни өчендер өнәмичә, шикләнеп карый, ә татар аны һаман да үзенеке итеп саный—моны минем күзәткәнем бар.

Гадәттә, милләтне билгеләү һәркемнен үз эше диләр. Мәгәр мондый караш белән килешүе читен. Чөнки кеше үзенен чын милләтен белеп торган хәлдә икенче милләткә күчә икән, ул шунын белән бергә ата-бабаларын да, туган һәм туачак балаларын да күчерә. Мона анын хаккы бармы? Мина калса, кеше төп тамырыннан аерылмаска тиеш. Милли чыгышны саклау—кешенен халкы алдындагы намус бурычы дияр идем мин.

Әмма бу очракта милләтне алмаштыруның халыклар арасындагы мөнәсәбәткә тәэсире нинди—иң мөһиме әнә шунда. Ике халыкнын үзара мөнәсәбәтен яхшыртамы ул, әллә киресенчә начарлатамы? Бу унай белән мина бер кешенен исемен шулай да атарга туры килә.

Сүз Мидхәт Закир улы Шакиров турында. Мәгълүм булганча, Башкортстан шартларында партия өлкә комитетынын беренче секретаре йә урыс, йә башкорт булырга тиеш—башкортнын чыны табылмаса, ялганы да ярый... Ә унбиш ел буена республика башында диктатор дәрәҗәсендәге беренче кеше булып утырган Шакиров асылда кем?.. Чын башкортмы ул? Атасы Закир абзый революциягә чаклы Казаннын "Мөхәммәдия" мәдрәсәсендә укыткан халфә. Анын Казандагы баласы һәм туганнары, белгән кешеләрнен әйтүенә караганда, татар булып йөргәннәр. Хәер, Закир абзыйнын нәселендә дә башкорт каны булуы бик ихтимал. Шулай булган тәкъдирдә дә мин анын улы Мидхәт Шакировны ялган башкорт дияр идем. Ин элек гамәленә карап. Нәкъ менә анын вакытында республиканы башкортлаштыру сылтавы белән татар халкын төрлечә кысу-чикләү яман көчәйде. (Мисал өчен татар мәктәпләренә башкорт телен көчләп кертүне искә төшерү дә житә.) Анын вакытында бер иште башкорт яшьләрендә милли шовинизм тышка бәреп чыкты. Ниһаять, татар-башкорт арасын тәмам бозылып бетүгә китереп

житкерде.

Ни өчен Шакировка республиканың төп бер халкына карата мондый геноцид дип атарлык сәясәтне үткәрү кирәк булды соң? Чөнки үзе чын башкорт булмагач, "җилкәбездә һәмишә татар утыра" дип зарланган башкортны тынычландырыр өчен, шул рәвешчә үзенең хакимлеген саклар өчен кирәк булган ул аңа... Инсафлы чын башкорт моны эшләмәс иде, әлбәттә...

Ситуация хәзер шундый ки, ямьсез ызгыш гүя мал бүлешә алмаган ике бер туган арасында бара. Килештереп булачакмы аларны?

***

Башкортстан үзенең суверенитетын игълан итте. Ул Россия Федерациясе һәм Советлар Союзы составында калачак. Статусы үзгәрәчәкме—ул кадәресен ачык кына белмим. Һәрхәлдә, хокуклары артырга, мөстәкыйльлеге киңәергә тиеш. Менә шушы яңа шартларда республикадагы миллионнан артык татар халкының да язмышы янадан каралырга тиештер дип уйлыйм. Аны искечә калдыру һич мөмкин түгел—кала икән, ике халык арасында туган хәзерге кискен каршылык та сакланачак. Республиканың тынычлыгы һәм иминлеге өчен бу хәвефле хәлдән, әлбәттә, чыгу кирәк.

Татар-башкорт мөнәсәбәтләрен янадан караганда түбәндәгеләрне истә тоту зарур:

Беренчедән, татар белән башкортны аерып торган этник ызан югалмаска тиеш. Милләт тормышы, гаилә тормышы кебек үк, үзенең тәртип-низамнары, гореф-гадәтләре белән яши. Якынлык никадәр зур булса да, һәркайсы милли үзенчәлекләрен барыбер саклый. Димәк, башкортның—башкорт, татарның татар булып калуы табигый күренеш. Шулай булып килгән ул, һәм шулай булып дәвам итәргә дә тиеш.


Икенчедән, бер республика шартларында яшәүче бу ике аерым халык, әлбәттә, бер үк хокук һәм мөмкинлекләр белән файдаланырга тиештер инде. Сан ягыннан рустан кала икенче урында торган татар халкының моңа тарихи, икътисади һәм мораль яктан да һичшиксез хакы бар. Әгәр Идел-Урал арасын бөтен бер регион итеп алсак, шушы зур аралыкта башкорт һәм татарлар Ислам динен кабул иткән заманнардан бирле яшәп килделәр.(Ибне Фазлан сәяхәте шуны раслый түгелме?!) Инде Казан ханлыгы бетерелгәннән соңгы заманны алсак та, татарларның золымнан качып, Идел-Кама буйларыннан Уралга табан күченә башлауларына да 3-4 гасыр вакыт үтеп киткән... Шуңа күрә дә бит инде Октябрь революциясеннән соң бу зур регионны башта Идел-Урал штаты, аннары Татар-башкорт җөмһүрияте итү турында проектлар төзелә, карарлар чыгарыла. Соңыннан бер урынына ике республика төзелгән икән, халыклар бит һаман шул ук утырган җирләрендә калганнар. Шулай булгач, Башкортстан эчендәге татар халкы да башкортның үзе кебек үк төп халыктан саналырга тиеш. Аңа "килмешәк" дип карау асла дөрес булмаячак.

Инде мәсьәләнең икътисади ягына килсәк, монда һичбер төрле бәхәскә урын да юк, минемчә. Җитмеш ел буена татар халкының Башкортстан хәзинәсенә тир түгеп керткән өлеше берәүнекеннән дә, артык булмаса, һич тә ким түгел. Башкортстанны яшәткән төп көчләрнең берсе ул, димәк, бирү генә түгел, үз ихтыяҗларын таләп итәргә дә аның хакы бар.

Мораль (яки юридик) яктан килеп карасак та сүз һаман шул ук хокук мәсьәләсенә килеп терәлә: чынлап та татарның үз телендә балаларын укытырга, үз телендә язарга, китап, гәзит, журналларын чыгарырга, кыскасы, башкорт үзе файдаланган барлык мөмкинлекләр белән дә файдаланырга хакы юкмыни? Ике арадагы низагның нигезендә шул хокуклар тигезсезлеге ята түгелме соң?!

Үзеннән-үзе аңлашылса кирәк, бу гаделсезлекне бетерүнең чарасы бер генә—ул да булса милли хокукларны тигезләү... Законлы рәвештә, Конституциягә кертеп: мәсәлән, Башкортстанның элеккеге Конституцияләрендә дәүләт теле булып,

башкортныкы белән беррәттән, татарныкы да санала иде. Бу бик дөрес булган, һәм аны янадан кайтарырга кирәк, чөнки бер-берсенә бик якын ике төп халыкнын хокукларын тигезләү белән бергә, ул аларнын мөстәкыйльлеген дә саклаячак. Сүз дә бит асылда нәкъ менә башкортның да, татарнын да милли мөстәкыйльлеген, бөтенлеген саклау турында бара. Һәм мона бары хокуклар тигезлеге аша гына ирешеп булачак. Шул чагында гына ике халык арасында чын татулык та сакланачак.



Иманым камил ки, туган ягым иркен Башкортстан шартларында ике халыкның да үзенчә тормышы һәм саф үз мәдәнияте бер-берсен кызыксындырып, сокландырып янәшә бик матур яшәячәк. Берсен алга чыгару өчен икенчесен тыеп торунын кирәге булмачак. Башкорт халкынын рухи байлыгы житәрлек, ижади көчләре бик нык үсте, ул мәдәниятен үзе дәвам иттерү генә түгел, алдынгы мәдәниятләр дәрәжәсенә күтәрә алачак. Әдәбиятынын һәм сәнгатенең дөнья мәйданына чыккан үрнәкләрен без хәзер үк инде күреп торабыз.

Татар мәдәниятенә килсәк, мәгълүм ки, анын тамыры тирән, тарихы бай. Башкортстаннын күп төбәкләрендә, аеруча Уфанын үзендә, бу мәдәниятнен чәчәк аткан чаклары да булды. (Мәшһүр мәктәп-мәдрәсәләрен искә төшерү дә житә.) Ирексездән бетеп торган шушы мәдәниятне янадан тергезергә кирәк. Сусап көтеп торган халкы бар, ижади көчләре дә бик тиз үсеп чыгачак.

Йә, монардан кемгә зарар?.. Һәрхәлдә, башкорт мәдәниятенә берәр төрле зарары тияр дип борчылырлык сәбәп юк, минемчә... Киресенчә, бер үк жирләрдә яшәүче ике якын халыкнын саф үзләренчә мәдәниятләре бер-берсенә үрнәк булып, тәжрибә уртаклашып торырлар дип ышанасы килә. Мәсәлән, башкорт әдипләренен әсәрләрен татарчага, татарларныкын башкортчага тәржемә итеп чыгару мөмкин булыр иде. Ике әдәбиятнын да укучылары артыр гына иде.

***

Мин читтән торып язучы... Ихтимал, Башкортстандагы чын хәлне белеп тә бетермимдер, бу язганнарымда төгәлсезлекләр дә, бәхәсле урыннар да күптер. Ләкин мин, мөмкин кадәр битарафлык саклап, мәсьәләне үзем анлаганча яктыртырга тырыштым. Аръягы—укучылар хөкемендә.

Тик минем белән килешсәләр-килешмәсәләр дә аларнын бер нәрсәдә шикшөбһәләре булмасын иде: мин бары изге нияттән чыгып, үземә якын-кадерле ике халык өчен дә хөрлек, мөстәкыйльлек, тигезлек, татулык—һәм шул нигездә алар арасында гомерлек тынычлык белән иминлек булуын телим. Монысы белән, иншалла, килешерсез дип ышанам.

**Әмирхан ЕНИКИ**

# “ФАКТЛАР ДӘФТӘРЕ”ННӘН

* * *

...Урта Россиядә татарлар шактый күп булып, алар бер аймак булып утырганнар. Аларны рус патшалары чукындыру юлы белән йотарга тырышканнар, ә чукынмаганнарын төрлечә җәберләгәннәр, кысканнар. Екатерина Икенче Россияне губерналарга бүлгәндә, татарлар тоташ бер масса булып утырмасын өчен, аларны төрле губерналарга кертеп бүлгәләгән: бер өлеше—Тамбовка, икенчесе—Пензага, өченчесе—Рязаньга һәм башка губерналарга кергәннәр...

* * *

Хәким Сәлимҗанов сөйләде:

—Бер вакытны театр алдында Такташ мине очратып, миннән бик ялварып 3 тәнкә акча сорады. “Нигә ул сиңа?”—дигәч, “Ач йөрим, ашаганым юк”,—диде. Минем кесәмдә 5 сумлык акчам бар иде, шуны чыгардым. Менә, мин әйтәм, бар акчам шушы, вакларга кирәк”. “Юк, син ваклап торма, барсын да бир”,—диде Такташ, чак еламыйча.—Мин сиңа тиздән кайтарырмын”. Шулай итеп, 5 тәнкәне алып китте. Берничә көннән бу миңа бурычны китерде, 10 сумлык акча чыгара. Мин әйтәм, минем сдача юк бит, дим. “Ә син барсын да ал, барыбер мин синнән бурычка тагын сорармын әле”,—ди Такташ.

Такташның акчага шулай бик тилмергән чаклары еш була иде.

* * *

Исмәгыйль Усманов белән сөйләшү (5 февраль, 77 ел)

Исмәгыйль Усманов 1926 елдан 1930 елга кадәр Салих Сәйдәш белән якыннан аралаша, дуслашып та китә. Миңа түбәндәгеләрне сөйләде.

...Салихка иң зур йогынты ясаган кеше—ул да булса Кәрим Тинчурин иде. Кәрим абый аңа, төрле әсәрләргә музыка язган чагында, бик күп нәрсәләрне төшендерә, аңлата иде. Шулай ук Вәлиев—Сульваның да тәэсире зур булды (ул елларда Сульва, режиссер буларак, күп кенә музыкаль әсәрләрне сәхнәгә куйды). Дөрес, ул шактый дорфа кеше иде, әмма Салихны эшләтә белә иде.

Сугыштан соң да Салихның рухы бик төшенке иде. Очрашкан чакларда: “Хәлең ничек, Салих?”—дип сорасаң: “Хәлем читен минем, Исмәгыйль, читен!”—дия торган иде. “Нидән алай соң?”—дигәч, “Үзем гаепле”,—дип кенә әйтеп куя иде.

* * *

Хәсән Туфанның бәйрәмен үткәреп җибәрдек. (Аңа 70 яшь тулды.) Башта комиссия (мин шуның бер члены идем) аның бәйрәмен зур итеп, Татарстанда гына түгел, бөтен илгә ишетелерлек итеп үткәрергә уйлаган иде. Барлык күрше һәм тугандаш республикалардан кунаклар чакырырга исәп бар иде. Моның өчен бер мең ярым сум акча кирәк булды. Ләкин бәйрәм көне килеп житкәнчегә кадәр безгә бу акчаны бирмәделәр. Нәтиҗәдә күп җирдән кунаклар чакырылмыйча калды, бары Мәскәү белән Уфадан гына килделәр...

Бәйрәмне уйлаганча зур итеп булмады, ләкин ул матур, җылы гына узып китте. Татар шагыйренә тагын ни кирәк?!.

* * *

Үзбәкстан язучысы А. Якубов үзбәк халкының фаҗигасен сөйләде. Үзбәкстанны бары мамык игүгә күчереп бетерү бик зур бәла-казалар китергән икән. Агулы химикатлар куллану аркасында төрле яман авырулар таралган. Гарип балалар табу күбәйгән. Хатыннар 30 яшендә карчыкка әйләнәләр икән. Бу бәхетсезлекләргә һәм авыр шартларга түзә алмыйча, 270 үзбәк хатыны үзләрен яндырып үтергәннәр.

**Әмирхан ЕНИКИ.**

# "МИННӘН "МАТУРЛЫК" КАЛА..."

## ӘДИПНЕҢ ТӨРЛЕ КӘГАЗЬ КИСӘКЛӘРЕНӘ ЯЗЫЛГАН УЙ-ФИКЕРЛӘРЕ

Язарга кирәк, язмыйча булмый. Әйтәләр иде, он ашап өйрәнгән эт, мәхлүкъ, тегермән ташын яламыйча торалмый дип,—шунын шикелле мин дә.

"Без үзебез татар, ләкин жир биләүдә башкорт булып исәпләнәбез..." Моны мина Хәсән Сарьян әткәйдән ишеттек дип сөйләгән иде.

Кеше тук булса, көн дә аны каезлап тормасалар, ул бик рәхәтләнеп коллыкка да иярләшә.

Кызганычка каршы, без демократиядән бик ерак торабыз әле. Хосусый милеккә дә юл ачылганы юк. Гомуми коррупция хөкем сөрә. Власть тирәсендә яңа номенклатура оеша. Байлык шулар кулына күчә. Ә бөлгенлек, хәерчелек көннән-көн көчәя. Мәдәният иң авыр шартларда яшәргә мәжбүр.

Мәдәният әлифбадан башлана. Халыкның 100 проценты булмаса да, 80—90 %ы ана телендә укый-яза белергә тиеш. Шул нигездә милли әдәбият, милли сәнгать үсә...

Безнең гаять хәтәр хәлдә калган туган телебез белән милли мәдәниятебезне терелтү өчен безгә тулы мөстәкыйльлек кирәк. Хосусый милек аша гомуми муллыкка, байлыкка ирешү кирәк. Ә бу демократия шартларында гына булуы мөмкин.

80—90 процент татарлар яшәгән районнарда хакимият эшләрен татарча йөртергә кирәк. 20нче елларда шулай булган.

Закон, указларны татар телендә язып, аннары русчага тәрҗемә итәргә кирәк. Киресенчә түгел.

Пленумда әйтелде: баланы ата-ана теләгән телдә укыту—милли телләр зарарына булачак.

Мал иясенә ошый: язучы теләсә-теләмәсә дә, анын үз табигате әсәренең жаны булып тора.

Мин һәртөрле тантаналарга иярләшә алмадым, мин трибунадан иркен-кыю сөйләргә өйрәнә алмадым.

Миннән "Әйтелмәгән васыять" кала, "Матурлык" кала, ниһаять, "Тынычлану" кала. Шуларны искә төшерүчеләр "Кем иде соң ул Әмирхан Еники?"—дип бәлки бер эчләреннән генә уйланып куярлар. Минем беркемгә бернинди дәгъвам юк. Булса да, мин аларны калдырып китәм—дөньяныкы дөньяда калырга тиеш. Мина дәгъвалары булганнарына баш иеп, ярлыкау сорыйм.

Нурихан
Фәттах

# БЕРЕНЧЕ ШИГЫРЬ КҮК БАЛАЧАК...

ИСТӘЛЕКЛӘР

## 27. Уразы

Яңавыл киң үзәннең калкулык төшенә урнашкан. Тимер юл буендагы элеватордан бер чакрым чамасы таш юл белән төньякка китсәң, әлеге калкулык чак кына, өч-дүрт метр чамасы гына түбәнәя. Аста икенче тигезлек башлана. Тигезлектән төньяктагы калкулыкларга, тауларга орынып, Бүә агып ята. Тигезлектә—болыннар, әрәмәләр. Язгы ташу вакытларында болыннарны, әрәмәләрне су басарга мөмкин.

Янтыкка турыдан түгел, Уразы аша кайтканда без тимер юлны аркылы чыгабыз да, элеватор яныннан үтәбез дә, төньякка таба китәбез һәм әлеге калкулык читенә барып житәбез. Агач өйләре, тар, баткак урамнары белән Яңавыл артта кала. Каршыда исә гажәеп күренеш ачыла. Чак кына аста, түбәндә—болыннар, әрәмәләр җәелеп ята. Болыннарлан, әрәмәләрдән арырак, еракта артык биек булмаган калкулыклар калкып утыра. Сулгарак борылып карасаң, еракта томанланып. яшәреп-күгәреп Сакат таулары күренә, уң якка карасаң, тагын да томанлырак, сихрирәк булып Шүрәле як таулары күренә. Туп-туры төньякта исә—Уразы ягы. Уразы янында гына кабарып шәрә таулар күренә. Каршыда, нәкъ бер тау өстендә ямь-яшел булып, шәрә басулар арасында аерылып, нарат урманы үсеп утыра. Елның теләсә кайсы вакытында да ямь-яшел. Безнең якта нарат бик сирәк очрый. Монда исә—бөтен бер урман. Кайчандыр анда, тау башында бер карт нарат кына моңаеп утыра иде. Әлеге урман менә шул бер нарат балалары. Мин ул “балалар”ның бик кечкенә чагын хәтерлим. Күрәсең, изге санап, ул наратларны беркем кисмәгән. Тора-бара алар үстеләр, калын, зур урман булды. Хәзер инде карт наратны яшь наратлар күмеп киттеләр.

Яңавылдан Уразы ягына карап барганда, ачык җиргә килеп чыгу белән еракта, иң элек менә шул кызгылт балчыклы тау башында утырган дүрткел нарат урманы күренә. Бу—Уразы.

Авыл Бүәнең аргы ягында. Бүәгә кечкенә елга килеп кушылган төшкә урнашкан. Яңавыл якта якында гына Бүә буе болыннары, Бүә суы авыл бакчалары яныннан ук агып ята. Табигатьнең монда иң матур, иң гүзәл җирләре. Һәр язны монда сабан туйлары була. Җәй көне Янавылдан пионер лагере килә. Бер елны, сугыш вакытында мин дә шундый лагерьда булдым. Торуын без Уразы клубында тордык. Ашау-эчү шунда булды. Якындагы Бүә буе болыннарына кумәкләшеп походка йөрдек, балык тоттык, җиләк, карагат җыйдык. Сугыш елларында Сажидә Сөләйманова да Уразыда торган, ахрысы. Ул да истәлекләрендә Бүәне, Бүә буе болыннарын сагынып искә төшерә. Уразы турысындагы Бүә үзе бер әкият. Яр буйларының авылга якын өлеше таллык, арырак китсәң, балан, шомырт. Ара-тирә печәнле акланнар. Суы да, болыны да, җиләк-җимеше дә якында гына. Әлегрәк /малай чакта/ мин Уразы халкыннан да бәхетле халык юктыр дөньяда дип уйлый торган идем. Бигрәк тә Бүә очы кешеләре. Капканы ачасың да, йөгереп туп-туры Бүәгә су керергә төшәсең яисә балык каптырасың. Бозауны, сыерны да каядыр еракка куып йөрисе юк—якында

*Ахыры. Башы 2008 елның 10нчы санында.*

гына болыны. Карагат та ерак түгел. Чыгасын да жыеп кирәсен.

Күчтәвыл кебек, Пулат, Янавыл, Янтык кебек Уразы да минем хәтердә мәнге сеңеп калды. Минем күзне ачкан, мине тәрбияләшкән тәэсирләр ул Уразы тәэсирләре. Күңелемдә, хәтер күгендә аерым-аерым булып Янавыл, Янтык яшәгән кебек,—анда минә шул кызгылт таулары, шәрә ярлары һәм тау башындагы нарат урманы белән Уразы дөньясы да бар.

Уразыга без Янтыктан Яңавылга барганда яисә киресенчә Яңавылдан Янтыкка кайтканда гына кагылып узабыз. Ләкин минем өчен Уразы юл өстендәге авыл буларак кына якын түгел. Уразыда безнең туганнар бар. Инәкәйнең сеңлесе Галимә утыз дүртенче елда, ахрысы, шушында килен булып төшә. Без аны Чибәрттәй дибез. Чибәрттәйнең кияве—Кәрим. Анысы безнең өчен "жизнәй" яисә "Уразы жизнәй". Чибәрттәй яшь чагында шат күңелле, шук-шаян иде. Аның үзенә генә хас сөйләшү стиле бар, үзенчә ул шаяртырга, көлдерергә ярата. Жизнәй—озын буйлы, чандыр, жирән чәчле. Әкрен сөйләшә, әкрен кыймылдый. Ачуы килсә кычкырып жибәрә, Сугыш елларында әле аның әтәсе, инәсе дә исән иде. Жизнәйнең әтәсен без "кода бабай", инәсен—"кодагый әби" дибез. Кода бабай чепи күзле, жирән төстәге кәжә сакаллы. Кайчан барма, ишек төбендәге жан сәкедә ак киез өстендә йә ятып торыр, йә утырып торыр. Кодагый әби гел мич янында, түрсике янында. Мичкә яга, аш-су пешерә. Шулай хәтердә калган. Уразылар районда иң беренчеләрдән булып колхоз төзегәннәр. Кемнәрдер авылдан аерылып, Ар Уразы ягындагы ниндидер чишмә буенда яна авыл корганнар да, шуны "Юлбаш" дип атаганнар. Ләкин төп авылдан күченергә теләүчеләр күп булмаган. Юлбаш авылы таркалган. Соңыннан Уразы колхозы "Юлбаш" дип атала башлаган. Тирә-якны совхозга әйләндергәнче Уразылар "Юлбаш" булып йөрделәр. Безнең якта иң беренче булып, ахрысы, Уразыда жимеш бакчасы утыртканнар. Чишмәле чокыр буенда көньяк тау битендәге ул бакчаны мин бик яхшы хәтерлим. Анда алма, кура-җиләк, карагат бар иде. Шунда ук кортбакча да бар иде. Заманында Уразы бакчасы бөтен тирә-якка дан тотты. Янтыктагы Нуркай бакчасы Уразыныкыннан соңрак үсеп китте, ахрысы. Хәер, хикмәт аның кайсы беренче, кайсы икенче булуында да түгел. Сугышка кадәр, сугыш вакытында, хәтта аннан соң да бездәге җиләк-җимеш, алма бакчалары шаулап-гөрләп торды. Уразының атаклы яшелчә бакчасы да бар иде. Алмасын, жимешен дә, яшелчәсен дә, баланын да элек хезмәт көненә колхозчыларга тараттылар. Базарга илтеп сатарга да житә иде. Ул вакытта әле урлашу, этләшү, үзенә алып калырга тырышу юк. Яисә юк дәрәжәсендә. Безнең Чибәрттәй күбрәк минә шул жимеш бакчасында эшләде. Гел алдынгы булды, макталды. Жизнәй атлы эштә йөрде, ат та карады, бригадир да булды. Сугышка кадәрге Уразы минем өчен гел бәйрәм булып, җиләк-җимешләре, болыннары белән торып калган.

Без, әйткәнемчә, Яңавылга барганда Уразыга сугылып узабыз. Безнең өчен Уразының тагын бер унай ягы бар. Жизнәйләрнең өе авыл читендә генә. Тәрәзәләреннән Янтык юлы күренеп кенә тора. Күтәренеп Яңавылга базарга барасың булса, кайчагында кичтән Уразыга барып кунасың да, иртән иртүк торып китәсең. Кайсы вакытта барсаң да аларның ишеге ачык. Сине һәрвакыт якты йөз белән каршылыйлар, ашатып-эчертеп, түргә урын жәеп бирәләр.

Сугыш башлану белән муллык кимеде, бәйрәмнәр, сабан туйлары тынып калды. Жизнине сугышка алдылар. Ул чакта без Яңавылда мәктәп ишек алдында торадыриек. Жизнәй безгә килеп кунды. Әле дә күз алдында: өстендә озын кайры тун. Гадәттәгечә, күп сөйләшми. Капчыклар күтәреп кайгылы йөз белән ишектән чыгып киткәндә мин аңа "Жизнәй, немесләрне жиңеп кайт",—дидем. Бу теге нәкъ китаплардагыча, кинолардагыча булды. Соңыннан үзем оялып куйдым. Хатын-кыз жылаша, кайгылы йөзләр. Жизнәй, ахрысы, берни эндәшмәде. Сугыштан ул яраланып кайтты. Кулбашында бик озак снаряд кыйпылчыгы йөрде.

Сугыштан соң озак еллар авылда тормыш җайланмады. Нәкъ минә шул авыр елларда кеше эчәргә күнегә башлады. Безнең жизнәй дә әз эчмәде аракыны. Бригадир, ат караучы булган чагында өйрәнде бугай ул аңа. Магазиннарга иң кирәкле товар кайтмаса да, мичкәле аракыга кытлык булмады. Аракыны ул елларда чүмечләп үз шешәнә тутырып саттылар.

Бервакыт Уразыда минем күз алдында шундый хәл булды. Кода бабай кайсыдыр балага бер ярты литрлы шешә бирә дә, аракы алып кайтырга дип магазинга жибәрә.

Теге бала аракыны алып кайта. Кичкә таба ата белән ул аракы эчәргә утыралар. Стаканга салсалар, аракы ак түгел, шәмәхә кара төсендә. Жизнәй аптырап китә. Иснәп карый, аракы. Ләкин нишләп соң бу әллә нинди төстә? Сатучы алдап җибәргәнме әллә? Ата белән ул тиргәшеп, әйткәләшеп китәләр. Соңыннан беленә: күзе бик үк яхшы күрмәгән кода бабай укучы балаларның кара ясап йөрткән шешәләрен биреп җибәргән икән аракыга дип. Эчәргәме, эчмәскәме мондый аракыны? Өстәл янында алар озак кына кычкырышып утырдылар. Шулай да ахыр чиктә эчәргә булдылар. Эчтеләр. Язу карасы кушылган аракыдан ул вакытта аларга берни булмады. Булуы соңрак булды. Соңгы елларда жизнәй бик бетерешге. Мин аның нәрсә белән авырганын ныклап белмим дә. Корыды-кипте, тамагыннан үтми башлады. Аның диагнозын белүнең кирәге дә юк, минемчә. Аракыны су урынына эчте һәм шуның белән китеп тә барды. Чагыштырмача яшьләй китте.

Картлар да үлеп беттеләр. Чибәрттәй балалары белән берүзе торып калды. Рамил дигән олы малае яшьтән үк читкә китте, бер кызы Вайжады ягына кияүгә китте. Икенче бер кызы авылдагы бер исерекбашка чыкты. Янында калган төпчек улы Казанда элемтә техникумын тәмамлады, шулай ук читкә китте. Берничә ел буена Чибәрттәй ялгыз өйдә үзе генә торып ятты. Бакчасына бәрәңге утыртты, мал асраган булды. Аннан соң балалары янына барып кышлый башлады.

1985 елда мин ул якларда соңгы мәртәбә булдым. Янтык белән Яңавыл арасындагы юлны хәзер ындыр арттан салганнар. Элекке Чибәрттәйләр яныннан үтә торган зур юл томаланып калган. Өй ялгыз. Тирә-якны чүп үләне баскан. Өй янындагы тупыл сынган. Һәркайда ташландык, күңелсез.

Уразы янындагы Бүәгә, болыннарга карарлык та түгел. Аяк атлаган саен җир өстендә теләсә нинди техника калдыгы—әле бер тәгәрмәч, әле покрышка, бетон багана, чуалган чыбык төргәкләре аунап чта. Бүәгә якын башында юл буенда Уразының коелы чишмәсе бар иде. Нәкъ шуның янына күчмә авыл корып җибәргәннәр. Кая карама, тракторлар, вагоннар, электр чыбыклары. Җир өстен дуңгыз абзарындагы кебек сазга әйләндергәннәр. Вагоннарга зур итеп кызылга ак белән русча лозунглар язып элгәннәр. Болыннарны, әрәмәләрне, Бүәне мыскыл иткән кебек. Элекке сихри Бүә Казандагы Болак сыман пычрак канализациягә әйләнгән.

Уразының кичләрен, шат-көләч кешеләрен, кызарып пешкән җиләкләрен, алмаларын татыган кешегә бу кадәр мәхшәргә ышанасы да килми. Ләкин ышанмыйча мөмкин түгел. Без бит коммунизмга барабыз—бәхетле киләчәккә. Болыннар, әрәмәләр өстеннән тимер-тимер гәүдәләрен сузып күккә ашкан баганаларга да, офык күкне каплап утырган салмак чыбыкка да, хәтта юлга аркылы җыландай сузылып яткан тимер, алюминий чыбыкка да сүз әйтергә ярамый. Якты-бәхетле киләчәк шул үзе түгел микән...

## 28. Күршеләр

Янтыкта Нуртдин картның уң ягында Хәерланам карт урыны булган. Нуртдин дә, Хәерланам да Вәрәш очка Түбән очтан күчеп утырганнар. Хәерланамны без бал бабай дип, корткасын—баләби дип йөрттек. Бал бабайның беренче хатынынннан биш-алты малае булган. Беренчесе үлгәч, икенче хатын алган. Икенчесеннән шулай ук алты-җиде бала булган. Без шул балаларның яшьрәкләре белән уйнап үстек.

Бал бабайны мин бик аз беләм. Озын буйлы, киндер ыштан-күлмәк кигән, киез эшләпәле, чабаталы бер карт булып истә калган. Аның чыршы башына менгезеп бәйләп куелган умарталары күп иде. Умарта тоташ агачтан чукып ясала. Шундый ук буш умарталар бал бабайның амбарында, амбар тышында да булыр иде. Бал суыртыр вакытны без түземсезлек белән көтеп алабыз. Бал бабай бал суырткан көн күрше-тирәдә үзенә бер бәйрәм була. Бал бабайның бал суыртырга җыенуын күреп алдыларммы, олылар алдан ук күршеләргә кермәскә дип ныгытып куялар. Ләкин без, аларның сүзен тыңламыйча, борыннарны сузып, чебен кебек бал исе килгән җиргә җыелабыз. Бал бабай безгә яңа гына умартадан алынган бал тоттыра. Кәрәзле бал. Кучтәнәч итеп, " ятимнәр өлеше" дип. Баләби берәр агач кубәтә белән өйгә дә кертеп бирә. Бу күптәнге гадәт. Кортчы юмарт булса, күрше-күләннән, ятимнәрдән кызганмаса, аның кортлары да тырышып эшлиләр, балы да күп була. Монысы күптәнге ышану.

Яна суырткан балны күп ашап булмый. Жылы, сыек бал шундук тамакка тия, "ачы" була башлый. Бервакыт шулай Казаннан кайткач ниндидер йомыш белән Вайжадыга киттем. Вайжадыда безнен авылдаш, яшьтәш кортбакчада эшли. Бу мине үзе эшләгән кортбакчага алып китте, яна бал белән сыйламакчы булды. Жәйге матур көн. Кортлар көне буе эштә. Бөтен тирә-як гү итеп тора, бал исе килә. Әдеһәм бер умартадан тулы рам алды да, балын аерды. Шуннан бу стакан тутырып бал бирде. Үзе дә эчте, мин дә эчтем. Икебез дә шундук йокыга киттек. Бу хәл иртәнге якта булды. Жәйге озын көндә кичкә кадәр берни белми йоклаганбыз. Яна бал ашап үлүчеләр турында да ишеткән бар.

Күрше бал бабай шундый юмарт карт булып хәтердә калган. Анын безне бал белән сыйлавы сугышка кадәрге елларда булды. Бал бабайлар артында, бездән өченче йорт—Мәхмүтжан бабайлар йорты. Мәхмүтжан бабай бал бабайнын беренче хатынынnan туган икенче малае. Бал бабайнын беренче хатынынnan туган барлык уллары өйләнеп, башкаланып чыкканнар. Икесе Вәрәш очта—чишмә аша гына. Бу очны сугыштан сон Бушкилде дип атадылар. Бу исем әле дә онытылып бетмәгән. Кемне әйтәсен дип сорасан, "теге Бушкилде фәләнне", диләр.

Мәхмүтжан бабайнын теге ягында—Бәлкә бабайлар, алар янында—Гали. Ул да Хәерламаннын беренче хатынынnan туган малае. Ин кечесе. Хатыны Хәмдия. Сугышка китте дә, юк та булды. Авылнын Гыйльмулла бабайлар тыкрыгында бал бабайнын тагын бер улы бар. Анысы ин олысы. Балта остасы. Тегерменче. Мин белгәндә анын бөтен гомере дигәндәй тегермәндә үтте. Бүә арьягында, авылдан бер чакрым чамасы арырак елга буенда колхознын су тегермәне бар иде. Шунда ук якында гына колхознын сыер, сарык фермасы урнашкан. Бал бабайнын олы улы—"Шәкерт бабай" шунда тегермән тарттырды, тегермәннен барлык кирәк-яракларын үзе эшләде.

Безнен бер өй аша күршебез Мәхмүтжан бабай да балта остасы. Без аны Урта бабай дип йөртәбез. Сугышка кадәр үк безгә каршыда гына, елга буенда ат фермасы салдылар. Ферманы ул чактагы типовой проект буенча эшләделәр, ахрысы. Башка авыллардан килеп, экскурсия белән безнен ферманы карап йөргәннәре истә калган. Ферма биек, иркен. Уртада кин коридор, коридорнын ике ягында да араннар, араннарга каршы—тәрәзәләр. Стена буйлап ике якта да тар аралык сузыла. Ат янына арттан да, алдан да килеп була. Идәннәре сайгак. Коридорнын ике ягында канау сыман колашалар. Сыеклык агар өчен. Заманына күрә—"механизация".

Менә шул ферманы Урта бабайлар эшләде.

Ферма янында гына, чишмә аша, уч төбедәй матур бер ярымутрауда тимерлек бар Шул тимерлек, ягъни тимерче алачыгы янында Урта бабайнын мастерское булды. Колхозда, бригадада нинди агач эше бар—барысын да ул эшләде. Кыш булса, ватылган чана төзәтү, яна чана ясау, жәй булса—арба, кәрәндәс төзәтү, тәгәрмәч бөгү, тугым, күчәр ясау—барысы да анын эше. Якында гына, елга яры буенда анын чана табаны бөгә торган куышы бар. Еш кына ул анда мичкә ягып, кыздырып, юнылган агачны " пешерергә" куя.

Авылда машина-трактор күбәеп, атлар-арбалар ялга чыккачы Урта бабай шунда ал-ял белми үзенен мастерскоенда эшләде. Арбага-чанага тәмам мохтажлык беткәч, дөресрәге, арба-чананын, атнын кирәге калмагач, мастерскойдагы барлык коралларын үз өенә алып кайтты. Тимерлек тә, мастерской да әкренләп юкка чыкты.

Шунысы нык истә калган: анын һәр коралы үз урынында булыр, кайралган, үткерләнгән булыр. Балтасы чәч ала торган пәке кебек. Пычкы, ышкылары, өтергеләре шулай ук ялт итеп тора. Аларга ул беркемне кагылдырмый. Анын гадәттә кораллары ике пар була, берсе—үзе өчен, берсе башкалар өчен. Балта эшеннән башка ул тагын итек баса, тире или. Анын гомумән белмәгән эше юк. Олы малае Мөхәмәтнур да, Закир дә әтәләре кебек теләсә нинди эшкә оста булдылар.

Бала-чаганын ярты гомере күршедә үтә. Без дә күршеләргә еш керә торган идек. Казанда укыган, торган елларда да, авылга кайту белән ин элек мин күршеләргә керәм. Урта бабай белән без озак кына сөйләшеп утырабыз. Ул Казан хәлләрен сорый, мин аннан үзем кызыксынган нәрсәләрне сөйләтәм. Күбрәк ул үзенен бала вакытларын, күргән-белгәннәрен, ишеткәннәрен сөйли. Бервакыт әйтте: әтәйләр элек көмеш чыга торган жирне белгәннәр, диде. Ләкин кайда булган ул жир—әйтә алмады.

1961 елның язы бик иртә килде. 30 апрельдә, ял көнне, иртән иртүк Урта бабай безгә килеп керде. Бигрәк күңелле, әйдә, Бүә буйга барабыз, диде бу. Әйдә, дидем. Хуҗалык эшләре бар иде—олы кеше үзе кергәч, тиз генә җыендым да киттек Бүә буена. Ул миңа туфаннан исән калган кешеләрнең йортларын күрсәтмәкче булды.

Бу турыда аның элек тә сөйләгәне бар иде. Бик борынгы кешеләрне—безнең ниндидер бабайларны туфан харап иткән, имеш. Урта бабай моны берничә мәртәбә сөйләде. Инәкәй дә, яшәби дә сөйли торганнар иде. Туфан харап иткән, туфаннан котылып калган изгеләр турында алардан башкалар да сөйли торган иде. Билал җизнәйдән дә ишеткән бар. Аннан соң Уразыда Чибәрттәйләрнең күршесендә бер карт бар иде. Нәби абзый диләр. Бер кышны Уразыга баргач мин моның янына кердем. Илленче еллар. Озынча, зур, такыр баш, ак сакал-мыек. Эре гәүдәле бер карт. Минем белән бу дөньяның ничек яралуы турында бәхәс башлап җибәрде. Сез әйтәсез—Алла юк, дисез, Алла булмагач бу дөнья ничек барлыкка килгән, иң элек нәрсә булган? Шундыйрак фәлсәфә. Минем иң укымышлы чак. Нәби бабайның дини фәлсәфәсенә дә, без туфаннан калган халык дигәненә дә минем әз генә дә исем китмәде. Бала вакытта да, үскәч тә мин мондый сүзләргә әкияткә караган кебек карадым. Күрәсең, дини китаплардан укыганнардыр да, шуны кабатлыйлардыр дип уйладым.

Бүә буена барганда да Урта бабай юл буена шундый әкиятләр сөйләп барды. “Әтәй сөйли торганые” дип ул Казанның ничек алынуы турында да, туфан турында да сөйләде. Җил-давыл калыккан да, имеш, туфан чыккан, шәһәрләрне җир йоткан, бөтен нәрсә җир астында күмелеп калган. Җиргә тимер шеш төртеп карадың исә, шыкы-шыкы иткән тавыш ишетелә, имеш. Казып карадың исә, җиз комганмы анда, табакмы, тасмы чыга икән. Ләкин теләсә кемгә чыкмый икән. Ятим балага гына ишетелә икән шыкы-шыкы килгән тавыш.

Көн матур, кояш кыздыра. Тирә-якта кошлар сайрый. Елга буйлап, басулар, әрәмәләр аша Очлы тауга кадәр барып җиттек. Очлы тауның иң биек җирендә шәрә яр-кыя янына килеп, түбәнгә карап тордык. Агачлар яңа яфрак яра башлаган. Язгы ташу әле кайтып җитмәгән. Бүә ярларына тулып ага. Еракта ялтырап күлләр күренә. Аста, урман арасында шат тавышлар ишетелә. Кояшлы көнгә сөенеп, авылдан яшь-җилкенчәк күңел ачарга килгән.

Мин Урта бабайның туфаннан исән калган кешеләрнең өйләрен күрсәтермен дигән сүзенә әз генә дә ышанмадым. Очлы тау янына килеп җиткәч, ул үзенең вәгъдәсен оныткандыр инде дип уйладым. Ләкин бу алай булып чыкмады. Урта бабай менә тау кырыеннан эчкәрәк, урман арасынарак алып китте. Шул чагында мин чыннан да ниндидер түгәрәк чокырлар, дөресрәге, батынкы җирләр күреп алдым. Чокырлар тигез булып тезелгән, бер үк зурлыкта, бер үк тирәнлектә. Күпме булгандыр—әйтә алмыйм. Санамаганмын. Унлап-унбишләп булыр. Моны чыннан да кемнәрдер элек җиргә казып кергән куыш урыннары дип уйларга була. Чокырлар өстендә юан-юан юкәләр үсеп утыра. Тау астында гына чишмә агып ята. Изгеләр чишмәсе.

Мин бик нык аптыраршта калдым. Бала вакытта ук ишетеп үскән әкият чын булып тоела башлады. Тик шулай да әле чокырсыман бу басынкы урыннарның һичшиксез баз өйләр булуына ышанып җитә алмадым. Бу берәр төрле геологик күренеш булырга да мөмкин. Якындагы чишмә шуңа ишарәли. Чокырлар булган төштә җир астында известь ташлары булса, җир асты сулары ул ташларны әкренләп юа һәм шул рәвешчә җир өстендә батынкы урыннар барлыкка килә икән. Казан тирәсендә калку урыннарда шундый чокырлар—батынкы урыннар бар. Газетада бу турыда геологлар бер язып та чыкканнар иде. Ни генә булмасын, археологлардан башка мона дөрес җавап бирүе кыенрак.

Шулай да хикмәт анда түгел. Хикмәт шунда: туфан турындагы истәлекләр, имеш-мимешләр, күрәсең, дини китаплардан укылган әкият булмаска тиеш. Якындагы чишмәнең Изгеләр чишмәсе дип аталуы да тиккә генә түгел. Бу турыда мин соңыннан гына ныклап торып уйлана башладым. Хәер, уйлана башлауның башы шул көнне булды, ахрысы.

## 29. Бәлкә бабай

Бәлкә бабай гомер буе фермада ат карады. Өе фермадан якын гына, каршыда, тау башында гына. Фермага ул төннен теләсә кайсы вакытында төшеп менә. Атларга печән сала, су бирә, сонга калып кайткан атларны урнаштыра. Иртән иртүк, таң тишегеннән торып, пеләмәннәй айгыр өчен яшел печән чабып алып кайта, эшкә китәсе атларга башак болгата. Кайчан карама, ул анда. Үзе күренә, йә тавышы ишетелә. Атларга, камыт-ыңгырчакка, бау-шуга, арба-чанага—барысына да ул баш. Аннан сорамыйча, аның рөхсәтеннән башка берни алып булмый. Безнең генә түгел, хәтта олылар да, бригадир да иң элек аның сүзенә колак сала. Кечкенә буйлы, таза, нык. Кыска итеп, таза итеп кырылган сакал-мыек. Билдә киндер альяпкыч. Тавыш көр. Кайчагында аның тавышы бөтен очка ишетелеп тора. Бәлкә бабайның хатыны Камиләттәй шулай ук кычкырып сөйләшә. Шат күңелле, киң күңелле. Аларның Муллаханы бездән олырак булды. Үсә төшкәч, сугыш елларында, ахрысы, ФЗОга алынды. Бер китүдән кайтмады, кайдадыр Уфада төпләнеп калды.

Ат тотарга, ат җигәргә, атка атланырга, кыскасы, атның телен аңларга без менә шул Бәлкә бабайлар янында буталып өйрәндек. Печән чабарга, кибән башына сәнәк белән печән биреп торырга, көлтә ташырга һәм шуның ише ирләр эшенә безне әлеге дә баягы Бәлкә бабайлар, Вәли бабайлар өйрәтте. Вәли бабай дигәне безнең кордаш Назирнең әтәсе була. Сугыш елларында ул безнең дүртенче бригаданың бригадиры булды. Аларны сугышка алмадылар. Армия хезмәте өчен алар инде карт иде. Ләкин колхоз эшен ул елларда тулысынча менә шул картлар күтәрде.

Урта бабайлар, Бәлкә бабайлар, Вәли бабайлар безнең өчен яхшы күрше дә булдылар. Күрше генә түгел, күрәсең, ата да булганнардыр. Бала вакытта ятимлек үзен бик сиздерә, ир баланың ничек тә ирләр янында буласы, аларның җылы карашын тоясы, яхшы сүзен ишетәсе килә. Урта бабай ваксырга, чәпчергә ярата, Бәлкә бабай кычкырынырга ярата. Вәли бабай кычкырмый да, чәпчеми дә—тыныч, ягымлы. Һәркемнең үз холкы. Шулай да мин аларның безне берәр ничек кыерсытканын, күңелне кырганын хәтерләмим.

Без генә түгел, олылар да берәр йомышлары булса күршеләргә керәләр. Үтечкә дип берәр нәрсә алып торалар, кайчагында берәр нәрсә турында киңәшергә дип керәләр. Ир кешенең киңәше һәрвакыт төпле була. Яшәби шулай еш кына "Вәли абзый белән киңәштем әле", "Мәхмүтҗан бабагыз белән киңәштем әле" дияргә ярата торган иде. Алай-болай безнең турыда күршеләрдән берәр авыр сүз ишетсәләр, безнең өчен ул иң зур җәза, иң зур кайгы була. Инде берәрсе безнең турыда берәр яхшы сүз әйтә икән, шундый яхшы сүз безнекеләрнең колагына чалынып кала икән, өйгә алар сөенеп кайталар, кайту белән ишеткәннәрен сөйләп безне дә куандыралар.

Без үскәндә безнең якның атаклы бер кешесе—Миннегали бар иде. Аның атаклылыгы шунда—ул дивана. Тумыштан. Чын дивана. Ул үзе безнең якныкы түгел. Каяндыр Көектәнме, Истәктәнме. Көек тә, Истәк тә Янавылның көнчыгышындагы, кире яктагы авыллар. Шулай да Миннегали нишләптер күбрәк безнең якта тоткарлана, тоткарланган саен Камиләттәйләрдә куна. Аларда мунча керә дә, ял итә дә, янадан чыгып китә. Беркайда ул озаклап тормый. Ничектер бер елны чирләп киткәч кенә Камиләттәйләрдә озаклап яткан бугай.

Миннегалине тирә якта белмәгән кеше юк. Аның исеме халык теленә шул кадәр нык кереп урнашкан, "Миннегали" сүзе үзе генә дә кайчагында бик күп нәрсә аңлата ала. Яшь чагында ул армиягә каралырга барган. Мона чишенергә кушканнар. Бу чишенгән һәм, күрәсең, бик нык куркып, шул килеш урамга чыгып йөгергән. Бу хәл әле революциягә кадәр үк булган. Шул көннән башлап, имеш, аның үзләре ягына кайтып күренгәне дә юк ди. Йөри-йөри безнең Буә аръягына килеп чыккан.

Казанда укып йөргәндә авылга кайткач, бер мәртәбә ындыр артта очраттым мин моны. Кыскарак буйлы, җинел гәүдәле, кытайныкы кебек сирәк сакал-мыеклы. Өстендә иске-москы. Катлап-катлап кигән. Башында бүрек сыман бер нәрсә. Аякта берни юк. Җәй көне иде. Аны хәтта кыш көне дә яланаяк йөри дип сөйлиләр. Аркасында капчык, кулында таяк. Иң тәэсирлесе таяк, ахрысы. Таяк башына төрле тасма, чүпрәк-чапрак бәйләнгән, чәйнүк капкачы һәм тагын шундый шалтырамаклар

тагылган. Кемдә нәрсә күреп кызыга, шуны сорап ала икән дә, таяк башына тагып куя икән, ошамаса соңыннан берәрсенә бүләк итеп бирә икән.

Ул гадәттә ят кешеләр белән, үзе яратмаган кешеләр белән очрашмаска тырыша. Кайберәүләрне бик ерактан читләтеп үтә, өенә дә, үзенә дә якын килми. Яшь чагында безнең чибәрттәй—инәкәйнең сенлесе Галимә шаяртып: "Миннегали, мине кияүгә аласынмы?"—дигән имеш. Шуннан ул безнең өйне читләтеп уза торган булган, безнекеләр белән сөйләшмәгән.

Мине күргәч, бу туктады. Ике куллап таягына таянды да, ысылдау сыман тавыш чыгарып, сызгырына башлады. Үзе минем белән сөйләшә, үзе мина карамый. Ничектер кырын күзен генә төшереп ала. Ул минем Казанда укыганны белә бугай, мине, күрәсең дөньяда иң бай кеше дип уйлый. Бер "чары" сорады бу. Акчаны ул берлек, өчлек, бишлек дип атамый, чары, яшел, җәнгәр дип атый. Унлык булса "кызыл", "чары" берлек була. Бирдем мин моңа "чары"ны. Диваналарга хәер бирсәң, савабы күп була, диләр иде олылар. Соңыннан Камиләттәйләргә әйткән Миннегали: "Вәҗидәләрнең Казаннан кайткан уллары акыллы икән"—дигән.

Миннегалидән башка безнең якта тагын бер дивана бар иде. Монысы хатын-кыз. Исеме Миннурый. Карт кыз. Каяндыр Казан ягыннан килеп чыккан да, калган безнең якта. Миннурый шыр дивана түгел, ушлырак, ислерәк. Юан гына гәүдәле. Аркасында һәрвакыт капчык булыр, яулыгы әбиләрчә чигәсенә төшереп бәйләнгән, аягында чабата. Бөтен байлыгы шул. Ул да авылдан авылга йөри, күңеленә хуш килгән кешеләрдә кунып, ял итеп чыга да, бик ашыгыч эше бар сыман янә каядыр китеп бара. Шунда ул бик кызганыч итеп Казанның алынуы турында бәет укыган иде.

Миннурый да күбесенчә Камиләттәйләрдә туктала торган иде. Бәлкә бабай фермада чагында кычкырынырга яратса да, Камиләттәй кебек үк шәфкатьле, миһербанлы кеше булган, күрәсең.

## 30. Беренче шигырь

Мин аны өченче класста укыганда яздым. Кыш көне иде. Көн салкын, кояшлы. Укудан соң, ахрысы, мәктәптән чаңгы алдым да, чыршылыкка чаңгы шуарга киттем. Ул чакта чаңгыны хәзергесе кебек магазинда сатмыйлар, чаңгы бары мәктәптә генә була. Физкультура кабинетында. Физкультура дәресләрендә бөтен класс белән чаңгыда йөрисең. Чаңгыны укудан соң да биреп торалар. Биргәндә әйтәләр: фәлән сәгатькә китереп житкер, диләр Фәлән вакытка кадәр шуасың, ләкин чаңгыны тиз генә тапшырасы килми. Күбрәк, озаграк шуарга тырышасың. Сонлап килсәң, сине көтеп торган укытучыдан эләгә, билгеле. Анысына гына түзәсең. Чаңгы шуу шундый күңелле! Дөньяда гел чаңгы гына шуып торыр идең кебек.



*Булачак әдипкә әле 18 яшь.*

Очынып, җинеләеп кар өстеннән шуышып барасың. Жир өстендә, кояш нурында ак кар бөртекләре жемелдәшә. Янда гына тун яшел, авыр чыршылар утырып кала. Чыршы ботакларына мендәр-мендәр кар эләгеп калган. Таяк белән суктың исә, ботак өстендәге кар тузанланып, шуып коела да, лыпылдап шундук кар өстенә барып төшә. Ак кар, яшел урман, зәңгәр күк һәм алсу-саргылт кояш. Никадәр ачык, саф, нәфис төсләр. Бер-берсенә охшамаган сихри төсләр.

Кызурак барсаң, битеңә салкын жил бәрә. Салкын жилдән битең, тәнең, кул-аякларың кайнарланган кебек була. Инде егылмый-нитми таудан да шуып төшә алсаң, куанычың эченә сыймый. Егылып карга чумсаң да борын салындырып тормыйсың. Йомшак карга егылуның да үз рәхәте бар.

Ачыгып, күшегеп кич өйгә кайттым да, жылы мич башына менеп утырдым да, көндезге тәэсирләрне шигырь итеп яздым. Беренче шигырь. Башын "Кыш" дип куйдым. Икенче көнне дәфтәр битеннән конверт ясап, конвертны пешкән бәрәнге белән ябештереп, шигырьне "Октябрь юлы"на, район газетасына жибәрдем. Кемнең дә булса шигырь язарга кушканын, киңәш иткәнен хәтерләмим.

Өченче класста булгач, күрәсен, дәреслекләрдә укыган берәр шигырь тәэсир иткәндер. Шуннан соң менә илле елга якын язу-сызу белән көн күреп яткан көнем.

Шигырьнең эчтәлеге инде онытылган. Хәер, аның исеме генә шигырь булгандыр. Ул, күрәсен, үз телен, туган телен ярдәмендә хисләрне, кичерешләрне ак кәгазьгә төшерүнең беренче үрнәге генә булгандыр. Беренче шигырьдән соң икенчесе, өченчесе дә язылды. "Кыш" турындагы шигырьләрдән соң яз, җәй, көз турындагы шигырьләр барлыкка килде. Бер-ике шигыремне 1944 елда "Совет әдәбияты" журналында бастылар, шул ук елны район газетасында "Ленин яшь" дигән шигырь дә басылды. Бер башлагач, инде туктамадым. Минем бу эшемне олылар, укытучылар да күреп алдылар, яшьтәшләр дә күрде. Язган нәрсәләремне мин беркемгә дә күрсәтмәскә тырыштым. Ләкин шигырь шуның өчен дә шигырь инде ул—аны кемдер күрергә, укырга тиеш, сине мактарга тиеш.

Бала вакытта мин күп яздым. Үземчә күп яздым. Җырлар, хикәяләр, әкиятләр, пьесалар яздым. Җиденчедә укыганда "Пионерская правда"дан бер пьеса тәрҗемә иттем дә, шуны укучылар алдында уйнадык. Декорациясен дә үзем эшләдем. Режиссеры кем булгандыр—хәтерләмим.

Нәрсә язам, барысын да диярлек редакцияләргә җибәрәм.—"Яшь ленинчы"га, "Пионер каләме"нә. "Ялкын" ул чакта "Пионер каләме" дип атала иде. Редакцияләрдән һәрвакыт җавап килә. Хатта һәрвакыт "эшләнеп җитмәгән, баса алмыйбыз" кебек сүзләр була. Кәеф кырыла. Бернничә көн кайгыга батып йөрисең дә, янадан каләмгә тотынасың. Яхшырак язарга кирәк, теләсә нинди редакция берсүзсез басарлык итеп язарга кирәк!—Минем өчен төп максат һәрвакыт шул булды.

Стена газеталарын, кулдан язылган журналларны гел мин чыгардым. Рәсемнәрен ясадым, башларын бизәдем. Андый газета-журналларда шигырь бернинди каршылыксыз "басыла". Берәр юбилей-фәлән булдымы, берәрсе тәкъдим иттеме, шундук шигырь әвәләп бирәсең.

Без үскәндә концертлар да еш була торган иде. Концертларда мин үз шигырьләремне укыйм. Тугызда, унда укыганда без концерт куярга, спектакль уйнарга хәтта күрше авылларга барып йөрдек. Күршедәге Эткенәвылга, мари авылы Шүдиккә барып йөргәннәр истә калган.

Безнең бала вакыт, үсмер вакыт авыр, катлаулы, михнәтле чорга туры килде. Шулай да мин уйлап куям: бүгенге заман балаларына караганда бәхетлерәк булганбыз без! Радио юк дәрәҗәсендә, телевизор юк, магнитофоннар, шалтыр-шолтыр дискылар-фәләннәр юк. Кино сирәк була. Өстәвенә, акча юк, теш арасына кыстырыр нәрсәсе юк. Барысы да киләчәктә булачак! Шуңа да тырыштык без. Китереп биргәнне, сатып алганны көтеп ятмадык. Эшен эшләргә дә, хыялланырга да, шигырен язарга, артист булырга да вакыт табылды.

Безнең сабый чак, безнең үсмер чак гомумән беренче шигырь сыманрак булды. Ул шигырьдә ритм да, рифма да бик үк төгәл булмагандыр, ләкин анда тирән мәгънә булган. Без тормыштан, табигатьтән аерылмаганбыз. Ач-ялангач һәм ятим булсак та без җиргә, күккә, суга якынрак булганбыз. Без чебиләнгән ялан аяклар белән язгы кар суларын ерып йөрдек, яңа ачылган тау кашларында ябагалан әвәләнгән туплар белән уйнадык. Кайнар тузанлы юлдан тузан туздырып узыша-узыша без зәңгәр офыкларга, кичке кояшларга карап йөгердек. Болында, хуш исле чичкәләр арасында җиләк җыйдык, чикерткәләр тоттык, кошлар сайравына хәйран калып, төпсез күккә карап яттык.

Юк, үкенмим.

Тирән күк, болытлар, болыт арасыннан чыккан кояш нурлары миндә һәрвакыт чиксез бер соклану һәм сагыш тудыра. Бер җәйне Бүә буенда, Зыярат тавына якын җирдә, үзебезнең дүртенче бригада җирендә сука сөргәндә атны туктаттым да, сабан өстенә чалкан ятып болытларга карап шигырь яздым. Болыт турында, яңгыр турында. Белмим, бәлки ул бер кылану гына булгандыр, ләкин анда мине күрердәй беркем юк иде. Бары Җирәнкәй генә, аптырап, зур башын борып әледән-әле миңа карап алды. Шуннан соң да мин бер җәйне Бүә буенда, әрәмәләр арасында блокнот белән карандаш белән йөрдем. Үзебезнең якның тауларыннан, әрәмәләреннән, чокыр-чакырларыннан матуррак, тәэсирлерәк берни юктыр кебек тоелды миңа. Очлы тауда, Очлы тау астында һәрвакыт нindидер илаһи бер сер саклана кебек.

Дөнья никтер иң әүвәл шунда яралгандыр да, Очлы тау, урманнар, болыннар шул турыда белгәнгә күрә, шулай олы, серле һәм мәһабәт булып күренәләрдер сыман.

Минем ул блокнотта минә шул зәңгәрсу таулар да, эссе көндә куе күләгә ташлаган имән куаклары да бар. Чыршылар да, үзебезнең чыршылык та бар. Жилсез вакытта да моңлы шаулап, олы, мәһабәт булып утырган чыршы дөньядагы барлык агачлардан шигърирәк.

Яисә малай чакта сезнең жыйнаулашып, көтү булып куян куып йөргәнегез бармы? Көз көне жир туңгач? Әле кар яумаган. Басуда моңаеп кипкән әремнәр, ирен яргычлар утыра. Яннан гына телен салындырып акбай чаба. Кинәт алда яфрагын койган шәрә куак арасыннан соргылт куян килеп чыга. Күргән кеше күрә, күрмәгәне күрми. Барысы да чәрелдәп, котырып "Әнә! әнә! Куян!" дип кычкыра. Һайһаулап бөтен көтү Акбае-ние белән куян артыннан ыргыла. Акбай алгарак чыга, чиный-чиный чаба. Куян бездән тоттырамени, жүләр! Көек-жылга чокырының икенче ягына барып чыга да, безне үчекләгән сыман ялт-йолт каранып көтеп торгандай итә дә, куаклар, үләннәр арасына кереп юк та була. Безгә бары аның куак төбендәге оясын күрү генә насыйп була. Куе үлән арасын шомартып бетергән. Шунда ук эре "чикләвекләрен" салып калдырган. Чит-чите коры үләннәр белән капланган куян оясын күрү дә үзе бер бәхет, үзе бер могжиза.

Сезнең, билгеле, Бүәне дә күргәнегез юк. Аның ташлы, комлы яр буенда, тез тиңентен суга кереп, балык каптырганыгыз да юк. Бүә ул бер урында салмак, тыныч ага, ярлары куркыныч, яшькелт суы тирән. Икенче бер урында ул югарыдан төшкән шарламак сыман, шаулап, тавышланып ага. Янтык янындагы кичү турында Бүә киңәеп, берничә тармакка бүленә. Иң зур тармагында су һәрвакыт кызу ага. Төбендә катлам-катлам ташлар күренеп ята. Геологик чор.

Безнең якның басуларында да геологик чорлар очрый. Сөргәндә, тырматканда шомарып беткән соргылт яшен ташларына тап буласың. Кашлак жирләрдә бары диңгез, елга буйларында гына була торган вак, шома, түгәрәк ташлар очрый. Жирне бераз казысаң, шулай ук яр буе ташлары килеп чыга яисә көтмәгәндә сап-сары комлыкка юлыгасың. Миллион еллар элек безнең якта диңгез шаулаган яисә бозлавык чорында безнең басуларда иләмсез зур боз кисәкләре яткан.

Бездә чишмәләрнең исәбе-хисабы юк. Янда гына, Вәрәш очында—салкын чишмә. Мин аны үземне белә башлаганнан башлап беләм кебек. Суы саф, салкын. Туктаусыз челтерәп ага да ага. Калкулык куенынннан чыга да киң чокыр төбеннән түбән агып китә. Салкын чишмә калкулыгы өстендә чыршылар. Тоташ чыршылар. Чишмә яныннан югарыга караганда чыршылар бик биек булып күренә. Чыршылар арасында зәп-зәңгәр күк.

Печәнлектә—Пешәлек чишмәсе. Чыккан жирендә кызгылт-аксыл таш катламнары күренеп тора. Су шул катламнар арасыннан кысылып, сытылып чыга. Аңа шунда берәрсе юкә кабыгыннан колаша куя. Чишмәләр Сакат тавында да, Очлы тауда да бар. Очлы тауның урта бер жиреннән чыккан чишмәне изгеләр чишмәсе дибез. Аның суын эчкән һәркем чишмәгә көмеш тәнкә ташларга тиеш. Йоласы шулай. Бәлки бу берәр төрле бик борынгы йоланың калдыгы гынадыр? Эчкән саен кем инде чишмәгә көмеш тәнкә ташлап торсын? Бигрәк тә безнең заманда !

Житмеш ничәнчедер елны без хатыным Руфина белән минем туган якка, Кучтәвылга кайттык. Тимергали абый безне мотоциклга утыртып төрле жиргә йөртте. Миннән бигрәк Руфинага күрсәтү өчен. Кучтәвылны мин беләм. Бүә аръягын, Очлы тауларны, Сакат тауларын күргән кешегә Кучтәвылның берниндн кызыгы юк. Ләкин Кучтәвылның Бәрдәшә чишмәсен күреп мин шаккаттым. Минем аны күргәнем юк иде. Без бәләкәй чакта безне, күрәсең, ул якка жибәрмәскә тырышканнар. Тәбәнәк кенә калкулыкның батынкы төшеннән югарыга таба ургылып су бәреп тора. Салкын чишмә сыман, Пешәлек чишмәсе, Изгеләр чишмәсе сыман челтерәп акмый—бәреп, ургылып чыга, күп булып, көчле булып чыга. Мондый могжизадан аерылып, күзне алып булмый. Бәрдәшә чишмәсе кешедә илаһи дәрт, омтылыш һәм соклану хисе тудыра.

Чишмәләр, таулар белән бергә туган якның юкәләрен дә искә төшермәсәм, алар мина үпкәләрләр сыман. Безнең Сакат тавы, Очлы тау тоташ юкә урманнары белән капланган. Юкә йомшак, нәфис, шигъри агач. Юкә чәчкә аткан чакта аның хуш исе бөтен дөньяга тарала. Кояшлы көннәрдә юкә урманы гү-ү итеп тора. Бал

кортлары ашыгып бал җыялар.

Авылга кайткан саен мин урманнарда, әрәмәләрдә, чишмә буйларында йөрим. Үзем генә. Уйланып, күккә, болытларга карап, битне талгын җилгә куеп. Олы Пешәлек чокыры башланган җирдә, Таш амбар чокыры дигән сүз миндә һәрвакыт сорау тудыра. Анда беркайчан бернинди таш амбар булмаган. Ишеткәнем юк. Таш амбар чокыры турында шундый риваять сөйләнә. Шундагы юан чыршыга, имеш, бастырык юанлыгы җылан уралган. Җылан кешеләрне ашый торган булган. Бер вакыт кара болыт чыккан да, әлеге җыланны чыршысы-ние белән күтәреп алып киткән. Болыт чыршыны, имеш, төбе-тамыры белән йолкып алган. Каян килгән бу риваять, кем уйлап чыгарган аны?

Аннары шул чокыр буенда, калкулык битендә тип-тигез булып киң генә юл сыман нәрсә сузыла. Нинди тигез эзләр алар? Кайчандыр Марстан кешеләр төшкәнме безнең басуларга, әллә, киресенчә, безнең җирдән күккә ракеталар күтәрелгәнме? Ләкин ул җирләрне безнең бабайлар моннан йөз ел чамасы элек кенә ачканнар бит.

Менә шунда утраусыман кечкенә калкулыкта кояш кыздырганда рәхәтләнеп сузылып үлән арасында ятканым бар. Күк аяз, җир өсте җылы, йомшак. Үлән сабаклары буйлап вак бөҗәкләр йөгереп йөри. Туктаусыз чикерткәләр чәкелди. “Менә шунда ятар идем мин. Мәңгегә. Туган җирдә” дип уйлаганым бар. Аннан соң Салкын чишмә өстендәге калкулыкта, Кортбакча җирендә дә үземә мәңгелек урын сайлап хыялланганым бар. Минем өстә таш торачак, ташка "Бу дөньяда мин дә булдым” дигән сүзләр язылган, имеш.

Беләм, сабыйларча хыял. Җәйге көндә басу өстендә тирбәлгән рәшәдәй йөгәнсез, тотрыксыз хыял. Беләм, чынбарлык безнең ише хыялыйларны яратып җиткерми. Ләкин шунсы да хак: без барыбер җирдә яшәдек. Егылсак та, абынсак та торып бастык, йөгереп киттек. Без сокланып җирне яраттык, җирнен-күкнең, чишмәләрнең гүзәллеген яраттык. Безнең яратуны, безнең әрнүләрне, күз яшьләрен оныту мөмкин түгел. Сабый чакның шигърияten, иртәнге якта күгәрчен гөрләвен һәм коеп яуган яшенле яңгырларны онытып булмаган кебек, оныту мөмкин түгел.

## 31. Беренче мәхәббәт

Беренче мәхәббәт. Беренче ярату. Беренче шигырь чын шигырь булмаган кебек, беренче мәхәббәтне дә чын мәхәббәт дип әйтеп булмыйдыр, күрәсең. Беренче мәхәббәт, беренче ярату... Тумыштан бирелгән чир шикелле, әледән-әле искә төшеп, эчне тырнап, бимазалап тора.

Мин әле дә аның исемен авыз тутырып әйтергә, акка кара белән язарга кыенсынам. Ул исемдә сихри көч бар. Мин аны яраттым дип әйтә алмыйм, ошады дип кенә дә әйтәсем килми. Беренчеме, икенчеме класста укыганда минем ана күзем төште. Аның янында мин үземне уңайсыз сизәм. Аның нурлы йөзенә, пәрдәле йөзенә тутырып карарга куркам сыман. Ләкин ул якында булганда миңа һәрвакыт күңелле. Аңа бары читтән генә, үзе сиңа карамаганда гына карарга була кебек. Аның тавышын ишетсәм мин тетрәнеп китәм, ялгыш кына аның белән күзгә-күз очрашам икән, никтер оялам, кызарып чыгам.

Кичләрен аларның өе яныннан узганда шундый рәхәт! Кич, караңгыда алар ягына курыкмыйча карый алам. Читтән авылга кайтып кергәндә иң элек шулар ягына күз ташлыйм. Анда мине һәрвакыт үзенә тартып торучы ниндидер көч бар кебек.

Ул инде күптән кияүдә. Балалары бар, балаларының балалары бар. Авылда чакта мин әле дә алар яныннан тыныч кына, гамьсез генә үтеп китә алмыйм. Кайчагында без болай гына очрашабыз, исәнлек-саулык сорашабыз һәм тизрәк аерылып китәргә тырышабыз.

Аны белмим, мин үзем шулай. Урамнан узганда, чыршылыктан узып барганда кайчагында мин аның бакчага, ишегалга чыккан чагын күреп калам. Нинди генә киемдә, нинди генә хәлдә булмасын, ул һәрвакыт серле һәм күркәм.

Шигырь язарга өйрәтмәгән кебек, безне яратырга да өйрәтмәделәр. Без ничектер барысына да үзебез өйрәндек. Белсәк тә, белмәсәк тә, яндык-көйдек, авыз-борын канаттык. Алны-артны карамыйчарак барганда, таеп китеп, хәтта бозлы суга да барып төштек. Барысы да булды. Әрнү дә, сагыш та, үкенү дә, бәхеттән исереп күккә ашулар да. Канаты сынган кош кебек җирдә аунап, бәргәләнеп ятулар да.

"Беренче мәхәббәт" бер генә булмады.

Унны бетергән елны көтмәгәндә шундый бер "мәхәббәт" булып алды. Июль ае, ахрысы. Җәйнең җылы, матур чагы. Мәктәп ишегалдына Зәкия килеп керде. Зәкия—Җобанай кызы. Яңавылның Эткенәвыл ягын шулай Җобанай диләр. Элек аерым авыл булган. Хәзер инде Янавыл белән кушылып, Ходайбирдин урамына әйләнеп калган.

Зәкия миннән өч-дүрт яшькә олырак. Мәктәпне дә элегрәк бетергән. Казанга китеп, университетның тарих-филология факультетына укырга кергән. Мин унны бетергән елны ул өченче курсны бетереп кайткан иде. Ак йөзле, чибәр, елмаеп кына сөйләшә.

Килеп керде бу. Мине күрде дә, күптәнге дусты кебек, якын итеп сөйләшә дә башлады. Мин аны элек тә белә идем, ләкин олырак булганга алар безгә буй җитмәстәй чибәрләр булып тоела торганнар иде. Бу юлы без ничектер җинел генә якынаеп киттек кебек. Ул миңа Казан турында, университет турында, язучылар, артистлар турында сөйли. Исем китеп тыңлыйм. Мин бит үзем быел университетка, Зәкия укыган факультетка барырга җыенам. Зәкия мине дәртләндерә, имтиханнардан курыкма, анда шигырь язучыларны бик теләп алалар, ди. Хәтта шунысы да булды, ничектер җай туры китереп ул миңа "Синең тавышың Фәхри Насретдинов тавышына охшаган", диде. Фәхри Насретдиновны мин ишетеп тә белмим. Хәер, аны шул ишетеп-тыңлап белергә кирәк тә инде. Ләкин мин аны беренче мәртәбә шул Зәкия авызыннан ишеттем бугай.

Үземнең Фәхри Насретдиновка охшавыма артык исем китмәсә дә, Зәкия белән очрашулардан, сөйләшүләрдән соң минем тәмам йокым качты. Мин инде хәзер Казан, университет дип түгел, бары Зәкия дип кенә хыялланам. Ул да, билгеле, сизми калмагандыр. Ара якынайганнан якыная, тик барыбер уртада биек койма кала бирә. Көн дә шулай очрашабыз, сөйләшәбез. Беркөнне җыенып без Бүә буйга карагатка киттек. Хәзер инде мин сөйлим. Бүә буйның Янавыл ягындагы әрәмәләрен, сазлыкларын мин биш бармагымны белгән кебек беләм. Ул көнне без бидрәләрне тутырып карагат җыйдык. Иң ахырда Бүәнең кичүгә якын бер аулак төшенә килеп су кердек.

Булды андый хәлләр. Мин инде үземне чын-чынлап бәхетле итеп сизә башладым. Дөрес, бәхетнең мөмкинлегенә әле бик үк ышанып та житә алмыйм. Шулай да мин исерек кебек—әйле-шәйле. Ул арада миңа Казанга китәргә вакыт та житте. Зәкиягә әле иртәрәк. Ул мине Янавылдан озатып җибәрергә, Казанга баргач очрашырга сүз бирде.

Казанга китәргә бер көн кала, ахрысы, артык кыюланып, әрсезләнеп мин Зәкияләрнең өенә киттем. Никтер күренми башлады ул соңгы көннәрдә. Капкаларын ачып кына кергән идем, каршыма Зәкиянең әтәсе килеп җитте. Йөзе усал. Бу мине куалап чыгаргандай чыгарды. Зәкиянең инәсе дә, туганнары да юк, әтәсе белән икәүдән-икәү генә торып яталар. Соңыннан беленде—соңгы көннәрдә бу кызын өйдән чыгармаган, минем белән очрашудан тыйган икән.

Шулай да Зәкия мине озатырга килде. Минем янадан күнел күтәрелеп китте. Кайчагында үзенне бәхетле итеп тою өчен әлләни күп тә кирәкми бит. Казанга бәхет эзләп барсам да, мин инде күпмедер дәрәҗәдә бәхетле идем.

Казанда мин тарих-филология факультетының татар бүлегенә кердем. Геология факультеты бинасының болындай бер бүлмәсендә торырга урын бирделәр. Укулар башланып, бераз җайлашкач, мин беркөнне Зәкияне эзләп киттем. Ул шәһәр читендәге икенче бер тулай торакта тора булырга тиеш. Адресын беләм, юлны беләм. Таптым. Зәкия мине гадәттәгечә бик ягымлы йөз белән каршы алды. Бүлмәләре кечкенә, җыйнак. Без барлыгы иллеләп кеше торабыз бер бүлмәдә, болар—дүртәү. Чишенгәндә әйтте бу пышылдап кына: "Татар бүлегендә укыганынны әйтмә, физматта укыйм дип әйт"—диде.

Мин берни җавап кайтара алмадым. Өскә кинәт салкын су койгандай булды. Ул кичне мин Зәкия белән дә, аның бүлмәдәш кызлары белән дә рәтләп берни сөйләшмәдем. Әдәп саклап бераз гына утырдым да, авыр, газаплы бер тойгы белән үзебезгә кайтып киттем. Шуннан соң беркайчан Зәкияләр бүлмәсенә аяк басмадым.

## 32. Җир

Борынгы кеше җирне анага тиңләгән. Ана кебек үк җир тудыручы һәм туйдыручы исәпләнелгән. Җирнең тудыручы һәм туйдыручы булуы турындагы фикер миллион еллар буенча кеше аңында сакланып калган. Шул нигездә кешенең җиргә, яшәүгә, үлемгә карата булган карашлары, ышанычлары формалашкан. Җиргә кагылышлы һәр эш-хәрәкәт җир-ананың тынычлыгын боза дип уйланылган. Шуңа күрә җирнең күңелен күрү өчен ана багышлап корбан биргәннәр, хәер-садака биргәннәр. Бу бигрәк тә язгы кыр эшләре башланыр алдыннан булган. Җирне сөрү, җиргә орлык чәчү, уруның изгелеген кеше бер генә минутка да исеннән чыгармаган. Ашарга утырган саен—иртә дә, кич тә кеше җиргә, тауга, калкулыкларга үз табыныннан өлеш чыгара торган булган.

Монысы—этнография. Җирнең тарихы да бар. Бай һәм куркыныч тарихы бар. Үзара сугышлар, талашлар, яулап алулар, халыкларның, авыл-шәһәрләрнең юкка чыгуы, кырылуы, яндырылуы. Барысы да җир өчен. Җир ул изге ана гына түгел, иң кадерле, иң җайлы яшәү урыны да. Җир кешене туйдыра. Җир кешене яшәтә һәм ана үзен хуҗа итеп, хаким итеп тоярга тулы мөмкинлек бирә.

Авыл кешесе элек үзен җирдән башка күз алдына китермәгән дә. Җирсез кеше—беткән кеше, йортсыз, хокуксыз кеше. Янтык басуларын, әйткәнемчә, һәркем үзе ачкан. Басулар, болыннар, әрәмәләр кешегә икеләтә-өчләтә якын, кадерле булган. Шуңа күрә дә ул аңа теше-тырнагы белән ябышып яткан. Шуңа күрә дә ул үз җирен башкаларга бирергә дә теләмәгән. Элегрәк бер карыш җир өчен дә, болын, әрәмә өчен дә күрше белән күрше, авыл белән авыл арасында ызгыш-талашлар, хәтта балта-пычак күтәреп кан коюлар булган.

Игенченең җиргә карата булган мәңгелек һәм даими карашы колхозлашу елларында үзгәрә башлады. "Минеке" урынына "безнеке" өскә чыкты. "Минеке" фәлсәфәсеннән баш тартырга теләмәгән бик күп аңгыралар җирсез дә, башсыз да калдылар. Аларны, тирес урынына ашлама итеп, меңәрләп, йөз меңәрләп, миллионлап җир куенына тутырдылар. Бала вакытта без моны күреп-белеп, ишетеп үстек.

"Безнеке" өскә чыкты. "Безнеке" белән бергә авылларда исән калган һәртөрле ялкаулар, икеле-микелеләр, яраклашучылар һәм сукырлар өскә чыкты. Күпмедер вакытка"безнеке" тантана итте.

Ләкин "безнеке" җиңүче булганда да чынлыкта аның күңелендә "минеке" шайтаны калды. Мин белгәндә инде авылда, колхозда "безнеке" фәлсәфәсе шактый көчле иде. Басулар—безнеке, болыннар—безнеке, урманнар—безнеке. Чишмәләр, елгалар—шулай ук безнеке. "Безнеке" ул чикләре билгеле булмаган таркау-тарау нәрсә түгел. "Безнеке"нең чикләре ап-ачык. Яңа Уртавылның яисә Янтыкның дүрт ягындагы барлык җирләр—"Очкын" колхозыныкы. Колхозда дүрт бригада. Һәр бригаданың үз җирләре, үз басулары, үз болыннары. Һәр бригада бер "мин" булып үз җирен эшкәртә—сөрә, чәчә, ура, суга.

Сугышка кадәр, утызынчы-кырыгынчы елларда колхозчылар чын-чынлап дәртләнеп, тырышып эшләделәр. Һич югы ул вакытта миңа, минем кебекләргә шулай тоелды. Билгеле, ул чакта да ялкаулар, салгашучылар, читкә каеручылар булгандыр. Ләкин күпчелек бердәм һәм эшчән булды. Сугыш еллары авыл халкын тагын да ныграк туплый төште. Китапларда, газитләрдә языла торган коллективизм аны югары ноктасына җитте.

Төзәтеп булмаслык үзгәрешләр сугыштан соң, җиңүдән соң башланды. Җирдә туган, җирдә аунап үскән, көн-төн ашлык үстерү белән шөгыльләнгән кеше, ниһаять, үзенең кол икәнлегенә төшенде. Кол тырышып эшләсен өчен тамагы туярлык булса да аның ашарына-эчәренә биргәннәр. Сугыштан соңгы колхоз игенченең җанын асрарлык та туйдыра алмады. Күз алдында җирнең кадере китте, җирнең кыйммәте, изгелеге юкка чыкты.

Колхозлашу елларында Янтыкның Нуримөхәммәт яисә Нуркай дигән кешесе Бүә буеннан төпләп карагат алып кайта, Бәләкәй тау астында, чишмәле бер калкулык буенда җиләк-җимеш бакчасына нигез сала. Элегрәк безнең якларда җиләк, карагат бакчасы белән беркем кызыксынмый—җиләге дә, карагаты да барысы да аяк астында гына чөнки. Кайсы әрәмәгә кермә,—кура җиләк, карагат, чикләвек. Нуркай карт

әкренләп сортлы карагатлар, җиләкләр, алмалар утырта. Моның өчен ерактагы авылларга барып йөри. Елдан-ел бакча зурая, бакча бөтен авылның, бөтен тирә-якның горурлыгына әверелә. Бакчада баштарак Нуркай карт үзенең корткасы белән генә эшли, сонга таба колхоз аерым бакчачылар бригадасы оештыра. Ул елларда шундый ук бакчалар күрше Уразыда, "Юлдаш" колхозында була. Сугыштан соң Вәрәштә, башка авылларда да җиләк-җимеш бакчалары барлыкка килә. Нуркай карт бакча үстереп кенә калмый—Янтыкның бер очыннан икенче очына тал утыртып чыга. Нуркай карт үлгәч тә бакчаны онытмыйлар. Бакча җире елдан-ел кинәя, эшчеләре арта, язгы-көзге эшләрдә механизация кулланыла башлый. Бакча ел да зур табыш бирә. Нуркай бакчасы тәэсирендә, ярдәмендә авылда өй янында кешеләрнең үз бакчалары барлыкка килә.

Алтмышынчы-җитмешенче елларга кадәр әлеге бакчалар шулай шаулап-гөрләп утырдылар да, әкренләп сүнә башладылар. Иң элек Уразы бакчасы корыды, аннан Вәрәш бакчасының рәте китте. Иң ныгы, иң зурысы Янтык бакчасы иде. Аның да кызыгы калмады. Иң күңелсезе шул, җиләк-имеш бакчалары белән бергә тирә-якта күп кенә кортбакчалар юкка чыкты. Илленче елларда бөтен илдә урман утырту башланды. "Көндәлек" урман утырту ул һәр елны була. Урманчылар әле берәр кашлак урынга, әле шунда берәр чокыр буена агач утыртып куялар. Күпмедер вакыттан соң ямьләнеп урман күтәрелә башлый, үсеп китә. Илленче елларда утыртылган урман башкачарак булды. Кемдер исбат иткән—бөтен ил буенча урман утыртып чыксаң, басуларны коры җилләрдән саклап булачак һәм игеннәр, имеш, каерылып уңачак.

Урманның кешегә һәрьяклап файдасы булуы күптән мәгълүм. Ләкин урман утыртып кына ашлык үстереп булуына мин элек тә ышанмадым, хәзер дә ышанмыйм. Бөтенләй урмансыз-нисез тип-тигез далада моның, бәлки, әзме-күпме файдасы бардыр. Әммә болай да урманлы, әрәмәле һәм таулы-ташлы безнең якта урман утыртуның игенчелеккә сукыр бер тиен дә файдасы булмады дип уйлыйм.

Бездә, әйткәнемчә урман үстереп түгел, урман ачып, урман яндырып иген иккәннәр.

Ни булса булды—утырттылар бездә урманны. Ярты километр, бер километр чамасы аралыкларга туп-туры итеп тар гына урман утырттылар. Безнең Пулат якта яна агач утыртылган җирдә элек Озын әрәмә, Түгәрәк әрәмә, Бәләкәй әрәмә дип аталган чикләвек әрәмәләре бар иде. Әрәмәләр төпләнде. Янәсе, элеккечә җир ачалар. Хәзер шунда төньяктан көньякка таба тар гына каенлык сузыла.

Авылга кайткач, бала вакытта чикләвек җыйган әрәмәләрне сагынып, Пулат якка барып чыгам да, басу уртасына салып куелган нindидер мәгънәсез коймага барып төртелгән кебек, шул каенлыкка барып төртеләм. Каенлык арасы шыр ачык. Монда һәрвакыт җил сызгырып тора. Усал җилләрне ничек итеп тотадыр ул каенлык, һич аңлый алмыйм. Минем өчен каен утын буларак кына яхшы. Дөрес, каенның миллеге, себеркесе дә була, тузы да була. Ләкин урман каены шыксыз, күләгәсез. Каенга кош та кунмый. Кемнәргәдер ияреп безнең шагыйрьләр каенны мактасалар да, безнең халык беркайчан каенны якын күрмәгән. "Каен" белән "кайгы" тиңдәш мәгънәле сүз итеп каралган. Каенны элек ишегалга кертмәгәннәр. Янтыкта безнең ишегалда, чыршылар арасында бер каен кысылып үскән иде. Мин югында инәкәй түзмәгән, шул каенны кисеп ташлаган.

Әрәмәләрне төпләү берничә ел буена дәвам итте. Авылга кайчан кайтма, әле бер әрәмә төпләнгән, әле икенчесе төпләнгән. Кайткан саен йөрәк кысылып куя. Без чикләвек, шомырт, балан, җиләк җыйган әрәмәләр шулай күз алдында юкка чыкты. Элекке кеше аларны юкка гына калдырмаган булган—тирә-як матур булсын өчен, балаларга чикләвек, шомырт-балан җыярга мөмкинлек булсын өчен калдырган. Колхоз-совхоз әлеге әрәмәләрне төпләп күпме файда алгандыр, әйтә алмыйм. Ләкин зыянын әйтергә була. Әрәмәләрне генә түгел, авыл кешесенең—балаларның, карт-корының шатлыгын, күңел куанычын да төпләгәннәр алар. Балалар хәзер авылда җиләккә, чикләвеккә йөрмиләр, магазиннан алып кайтканны көтеп яталар. Өйдә. Телевизор каршында. Хәлсез атларга булышка тракторлар, автомашиналар күпләп кайта башлагач без ул чакта сөенеп бетә алмадык. Болай булгач эшләр китә җайга! Тракторлар, автомашиналар белән бергә авылга электр, радио керә башлады, телевизор килде. Авылда кемнәрдер өмет иткән культуралы тормыш башланды.

Аерым алып караганда, тракторы да, башкасы да яхшы нәрсәләр. Ләкин конкрет авылга, кешегә, аеруча жиргә, табигатькә кагылышлы рәвештә алганда, яңалыкның кире яклары да аз булмады.

Телевизор баганасын Сакат тавы өстенә утыртып куйдылар. Тимер багана янында урман киселде. Монысы әле анын әлләни түгел. Ерактан караганда ул тимер багана бөтен Сакат тавының, бөтен тирә-якның күренешен ямьсезләп тора. Берничә елдан безнең якларда да нефть чыгара башладылар. Нефтьчеләр килү белән жирнең асты өскә әйләнә башлады. Ачык басулар өстеннән, карурманнар, калкулыклар өстеннән озын-озын атлап шөкәтсез бетон баганалар тезелеп китте. Салмак чыбыкларын салындырып, тимер көянтәләрен жәеп утырган жирнең өстен теләсә каян атлап чыгып, табигатьне, яшеллекне, гүзәллекне челтәрләп бетерделәр. Болыннарда, юл буйларында ауган бетон баганаларга, өзелгән, укмашып беткән чыбык төргәкләренә, резин, тимер, пыяла калдыкларына хәзер инде беркем игътибар итми.

Янавылдан Янтыкка, Янтыктан Пулат, Вайжады, Байсар якларына кин юл салынды. Юл яхшы, такыр, туры. Машиналар батып ятарлык түгел. Авыл уртасына да юл салдылар. Монысы да начар түгел. Ләкин юл салганда бульдозерлар туп-туры авыл уртасындагы, урман читендәге калкулыкларны, чишмә буйларын уртага, юлга төртеп кенә төшерделәр. Өске катламы болай да юка гына булган жирнең өсте шәрәләнеп калды. Кызыл балчык катламы астыннан кайбер төштә моннан миллион еллар элек формалашкан таш катламнары килеп чыкты. Язын-көзен һәм жәйге яңгыр вакытларында яна яралар өстеннән шаулап су ага. Ләкин жир ярасы, шәрә чокыр-чакыр беркемне кызыксындырмый.

Сиксәненче еллар башында, ахрысы, сугару дигән нәрсә турында сүз китте. Сугару белән кеше гомер-гомергә шөгелләнгән. Кайбер жирләрдә бары сугару ысулы белән генә иген игәләр. Безнең якта да, югарыдан килгән күрсәтмә нигезендә, сугару эше башлана. Безнең очта, Олы Пешәлек белән Бәләкәй Пешәлек арасында елганы буып, буа ясамакчы булалар. Буа бик биек, киң итеп өелә. Буа уртасына, артык суны агызу өчен, гидротехник жайланма ясала. Буаның ике ягыннан да басулар башлана. Басулар тигез түгел—буадан ераклаша барган саен үргә таба күтәрелә бара. Ике яктагы басуның да жирләре әрлән балчыгы кебек, ягъни уңдырышсыз. Проектта каралганча, буадан ике якка да сугару торбалары сузылырга тиеш була. Проектчылар безнең Пешәлек янына килеп тә карамаганнардыр, күрәсең. Мәскәүдә йә Ленинградта торып сызгалап биргәннәрдер. Эшчеләре ерактагы Әрмәнстаннан килгән әрмәннәр була.

Буага, шул тирәдәге яр буйларын кимереп, зур-зур машиналар белән балчык өйделәр. Буа урынында элек бер гектар чамасы уңдырышлы түбән жир бар иде. Анда иң корылыклы елларда да каерылып ашлык үсте. Шул уңдырышлы үзәнне тракторлар изеп, автол, солидол түгеп, берни үсмәс хәлгә китерделәр. Анда—Буа артында төрле ватык техника, трослар, кабельләр аунап калды. Басуга сузыласы торбалар сузылмады. Алар да шунда өем-өем булып тутыгып ята. Эшчеләр исә эшләдек дип отчет бирделәр, кесә тутырып акча алдылар да, алардан жилләр исте.

Файдасы ни? Жәй көне буада балалар су керәләр, су өстендә казлар, үрдәкләр йөзеп йөри. Пулат якка яна торба сузганнар, ахрысы—буадан килгән су белән анда бер су сиптергеч көне буе клевер басуына су сиптерә. Бер елны буа ерылып киткән. Аны төзәткәннәр. Буадагы су акрынлап саега бара, чөнки төпкә ләм утыра. Бу балчык буа ярты миллион чамасына төшкән. Кем түләр ул ярты миллионны? Жир түләмәячәк—ансы көн кебек ачык. Нефтьнең ничек чыкканын мин беренче мәртәбә Күчтәвыл басуында, Бәрдәшә чишмәсен карарга баргач күрдем. Басу уртасында, калкулык битендә кара майга буялып беткән тимер насосның тимер чыбыгы жиргә батырылган торба эченә төшә дә менә, төшә дә менә. Шунда ук электр моторы эшләп утыра. Жир өстеннән каядыр еракка торба сузылган. Насос жирнең канын суыра. Кан кап-кара, майлы—елкылдап тора. Шул кадәр тирәннән кара май, кара кан суырып чыгару үзе бер могжиза. Ләкин могжизаның тирә-ягы карарлык та түгел. Кап-кара, пычрак. Үләннәр кап-кара, чичкәләр кап-кара, жир өсте кап-кара. Язгы-көзге сулар белән шул түбән агып төшә, чишмәләргә, елгаларга әләгә. Бер биолог әйтте—жиргә төшкән нефть табы үзеннән үзе утыз елсыз бирми, диде.

Без гомергә гашыйк булган, безне иркәләп, саклап, туйдырып үстергән Буә

буйларын хәзер танырлык та түгел. Бүә суы кайчагында пычрак канализация суын хәтерләтә. Бүәдә хәзер су керүче күренми. Бүәне астан Карман турысында бетон белән буып куйдылар, ГРЭС төзеделәр. Су күтәрелде. Болыннар, әрәмәләр су астында калды. Безнең Очлы тау буендагы болыннарга чаклы күтәрелгән диләр. Очлы тау астындагы кичү турысында калкурак урында Яңавылның аэропортыннан килеп, "безнеке" булмаган нindидер чит кешеләр дачалар корганнар. Анда алар этләр белән, каравылчылар белән яшәп яталар ди, дачага, имеш, вертолет белән генә киләләр ди. Сугыш елларында немец оккупациясе турында куркып, шомланып сөйләгән кебек, авыл халкы шул турыда зур сер итеп сөйли.

Кайткан саен авылда зур үзгәрешләр күреп таң каласың. Һәр үзгәреш, һәр яңалык күңелдә тирән эз калдыра. Элегрәк мин тышка чыгып елга аръягындагы чыршылыкка карап утырырга ярата торган идем. Анда һәрвакыт бала-чага чыр-чуы ишетелә. Безнең Бушкилде очында гына да алар унлап-унбишләп. Безнең малай чактагы кебек алар да качышлы уйныйлар, кычкыралар, бер-берсен хәрәмләшүдә гаепләп, чәте-чәте тиргәшеп алалар. Кайчагында берәрсенең җылаган тавышы ишетелеп китә. Кызык. Күңелле. Җаның-тәнең белән ял итеп, рухланып утырасың. Шул чагында туган җир—баш өстендәге болытлар, ерактагы күксел Очлы тау шәүләсе, чикерткәләр сайравы исткиткеч якын булып тоела.

Житмешенче елларда балалар чыр-чуы ишетелми башлады. Кош кунмаган агачтан да шыксызрак берни юк. Балалар тавышы ишетелмәсә бөтен тирә-як шулай тоела башлый. Шыксызлык, бушлык эчне тырный, күңелне кимерә. Артыннан үкчәнә басып шау-шулы балалар килмәгәч, дөньяда яшисе килми башлый.

Нефтьчеләр безнең яннан гына, җир астыннан, елга аша юан торба суздылар. Безнең ындыр артта гына Кортбакча янындагы җирдә трансформатор будкасы корылды. Нефть торбасына янәшә генә югары көчәнешле электр линиясе үтә. Безнең чыршылыктагы өйдән ике йөз-өч йөз метр чамасы ераклыкта бер елны таштан-бетоннан нindидер корылма сала башладылар. 1984 елны кайткач, мин Агай әрәмәсе чокыр буйларын карап кайтканда әлеге корылмага читтән генә күз ташлап үттем. Янына барасым килмәде. Совхозның машина-трактор мастерскойлары шунда күчәчәк имеш. Авылдан, әрәмәдән, чишмәләрдән чак кына читкәрәк салырга беркемнең башына килмәгән. Хәер, аның планын да Янтыкның үзендә түгел, Уфада яисә Мәскәүдә ясаган булырга мөмкиннәр.

Бер елдан соң инәкәйнең елын уздырырга кайттым. Кайтсам, тагын яңалык. Безнең яннан гына уза торган нефть торбасы шартлаган да, җир өстенә нефть бәреп чыккан. Кара кан ызаннар, буразналар буйлап түбән таба агып килгән, безнең яндагы чокырга ук килеп җиткән. Ярый әле вакытында күреп-сизеп алганнар—нефть чишмәсенең юлын бүлү өчен Салкын чишмә чокырын буганнар. Ашык-пошык. Бульдозерлар белән. Яшел чирәм каплаган меңәр еллык яр өстен ерттырганнар да, аска этеп төшергәннәр. Якындагы төз, юан чыршыларны кисеп аударганнар. Салкын чишмә чокырында—без уйнап үскән, бозау куып, чыбык-чабык җыеп үскән, үзебезнең өйнең ашалып беткән идән такталары кебек, өй янындагы сукмаклар кебек үк якын һәм кадерле булган чокыр эчендә ямьсез, иләмсез, котсыз буа хасил булган. Буа алдында нефть таплары белән пычранган яшькелт су җыелып ята. Буага тимер торбалар салып калдырганнар, үзле, юеш балчык күбеп, яргаланып беткән.

Буа артындагы салкын чишмә—ничә еллар буе көн-төн челтерәп, сөйләнеп яткан шигъри чишмәбез мәңге тынып калган. Юк, бөтенләй үк тынмаган. Саркып, күз яшьләре кебек, тамчылап тора. Коесына бидрә тыгып чумырып алалар да, икенче бидрә алганчы тонганын көтеп торалар. Сахрадагы кебек, ком чүлендәге кебек.

Нуркай карт сыман мин дә Салкын чишмә буйларына алтмышынчы елларда таллар утыртып чыккан идем. Таллар яхшы гына үсеп китте. Ләкин чишмә чокыры елдан-ел тирәнәйде. Яр ишелеп, җир җимерелеп, чишмәләр коруын инде без утырткан тал тамырлары гына тотып торырлык түгел. Җиргә булган барлык хокукларыннан, диненнән, өмет һәм ышанычыннан мәхрүм кеше, әйтерсең, карт анасыннан ярсып-ярсып үч ала. Җир хәзер "минеке" дә түгел, "безнеке" дә түгел. Ләкин, карт булса да, тапталган, мәсхәрәләнгән булса да, безне һаман җир тудыра, җир туйдыра. Безнең башка анабыз юк. Була да алмый.

*26 апрель, 1988 ел.*

Гомәр
Бәширов

# КҮҢЕЛ ДӘФТӘРЕ

Бу арада һаман да үлемнәр, авырулар турында язарга туры килә. Менә тагын берсе хакында язмыйча узып булмый.

Г. Әпсәләмов декабрь ахырында бер төркем иптәшләр белән Пермь өлкәсенә атналык уздырырга киткән иде. Шунда ана инсульт булып кичәдә егылып калды. Моннан врачлар, профессорлар барды, тегендә дә шулай ук ярдәм оештырдылар. Ниһаять, берникадәр вакыттан соң аны самолет белән Казанга алып кайтып шифаханәгә салдылар.

Шул рәвешчә ул мескен бик кыен хәлләрне кичерде. Әле хәзер инде берәр атнадан бирле бераз аңына килде, кеше таный башлады һәм хәтта торып утыра башлады, диләр.

Иң начар ягы шунда: кайбер мещан тибындагы кешеләр, бигрәк тә, аның якыннары Әпсәләмовның бу авыруын башкалардан күрәләр. Ягъни, язучылар аның "Ак чәчәкләр"ен бик каты тәнкыйть иткәннәр. Нилектән? Чөнки Әпсәләмовның шөһрәтеннән көнләшкәннәр. Шуның нәтиҗәсендә Г. Әпсәләмов бик авыр кичереш уздырган. Ул "урынсыз" тәнкыйтьне күтәрә алмаган.

Бөтенесе юк нәрсә. Бердән, Әпсәләмовның шөһрәтенә бер кем дә кызыкмый. Чөнки язучыларның һәммәсенә дә кәгазь җитәрлек. Язалар икән, һәммәсенең китабы чыгып тора. Әпсәләмовның шөһрәте берәүгә дә күләгә төшерә алмый. Чөнки ул үз урынында, бүтән язучылар үз урыннарында. Әйтик, Расихның яисә Фатих Хөснинең, Мәрсәй Әмирнең яисә Ибраһим Газиның берсенең дә Г. Әпсәләмов урынында буласы килми. Чөнки аларның да, бүтәннәрнең дә әдәбиятта бик матур һәм бик һәйбәт үз урыннары бар.

*29 гыйнвар, 1966.*

## ӨЧЕНЧЕ ДӘФТӘР

(1966 ЕЛНЫҢ МАРТЫНДА БАШЛАНДЫ)

*Ни сәбәпле уң яктан яза башладым?*
*Хәзер картая төшкәч, нигәдер*
*бала һәм яшь вакытта язган*
*шушы хәрефләр җанга якынрак*
*тоела башлады. Болар күңелемдәгене*
*тулырак, матуррак, дөресрәк*
*әйтергә сәләтле кебек сизәм*[1].

Менә өченче дәфтәремне башлыйм. Беренчесен һәм икенчесен башлаганда киләчәк турында әлләни фикер йөртмәгән идем. Бик гади генә итеп үземне шатландырган һәм борчыган вакыйгалар турында, әлләни тирәнгә китмичә, бик гади генә итеп язып барырмын дип уйлаган идем. Ул шулай булды да. Хәзер мина инде, кызганычка

[1] Өченче дәфтәр тулысынча гарәп графикасында язылган. *(Зөфәр Бәширов искәрмәсе.)*

*Дәвамы. Башы 2008 елның 11нче санында.*

каршы, 65 булып китте. Телисеңме, теләмисеңме гомернең ахыргы өлешенә керелгән. Димәк, "итәк-жиненне җыебрак" йөрергә кирәк. Чөнки табигать синең белән һич исәпләшеп тормастан, һәрвакыттагыча үз кагыйдәләре белән эш итәчәк. Синең үләсең киләме, юкмы, язасы әсәрләрең бармы, юкмы, боларда аның эше юк. Аның "үз туксаны туксан".

Ә мин әле чын иҗат тормышын менә хәзер генә башлыйм кебек. Минем язасы әсәрләрем язылганнарыннан күбрәк! Кая ул! Әле мин чын-чыннан менә хәзер генә яза башладым шикелле. Мин үземдә иге дә чиге дә булмаган иҗат мөмкинлеге сизәм. Әгәр мин күңелемдә тупланган иҗат дәртен ахырына кадәр халыкка бирә алмыйча китеп барсам, мине тудырган, тәрбияләгән, миңа иҗат дәрте биргән сөекле халкыма бурычлы булып китәрмен, минем күңелем тыныч булмас, мин хәтта кабердә ятканда да бик кайгырырмын, борчылырмын. Чөнки мин үземне халкыма һәм илемә файда китерүче кеше, кирәкле кеше дип саныйм.

Димәк? Димәк, бер генә минутны да әрәм итмичә язарга кирәк!

**13 март, 1966.**

Кичә Аккош күлендә берүзем кичке концерт тыңлап утырдым. Радиодан халык көйләрен бирделәр. Тынынны да алмыйча сокланып тыңларлык, күзеңнән яшьләр китерә торганнары күп. Мәсәлән, мин "Гөлҗамал"ны, "Кара урман"ны тагын бик күпләрне һич тә тыныч кына тыңлый алмыйм.

"Халык" дигәч хәзерге яшьләр күбесенчә авыл халкын күз алдына китерә: салам түбәле өйләр, кайры тун, арыш ипие, чабата, наданлык... Ләкин шундый шартларда яшәүче шушы халык (дөрес, авыл халкы гына түгел, шәһәрен дә кушып) нинди гаҗәеп музыка иҗат иткән! Ул көйнең сүзләре нинди!

*Шәмдәлләрдә генә утлар яңа, Гөлҗамал,*
*Җиткән кызлар киндер җеп эрлиләр.*
*Энҗе дә мәрҗән кызларның кулбавы,*
*Авыр җан сөйгәннәрнең булмавы.*

Ачык кына булып күз алдына килеп баса: менә кызлар аулак өйдә җеп эрлиләр, җырлап утыралар. Шәмдәлләрдә утлар яна. Нәрсә турында җырлыйлар? Мәхәббәт турында. Кызларның сөясе, сөеләсе килә. Ләкин җан "сөйгәннәр"ең менә шунда янда гына түгел, бәлки ул бөтенләй юктыр да әле. Ләкин ул "җан сөйгән" һичшиксез булырга тиеш, һичшиксез! Чөнки аны җан тели, чөнки ансыз тормыш итеп булмый, тормыш үзе мәхәббәт дигән сүз!

Менә шул мәхәббәтне сагынып, шуны көтеп, зарыгып җырлый кызлар.

Ләкин бу көйдә шулкадәр моң, шулкадәр өзелеп-өзелеп китә торган, йөрәкне, күңелләрне чиртеп-чиртеп, сызлатып ала торган сагыш авазлары янгырый ки, ул мәхәббәт инде бер тапкыр булгандыр, тәгаен булгандыр дигән уй килә (чөнки мәхәббәтне үзе татып карамаган кеше улкадәр моң бирә алмас иде). Әйе, ул мәхәббәт кабынган да сүнгәндер, әнә шул сүнгән яки сүнә башлаган мәхәббәтне сагынып җырлый торгандыр. Менә мин "Гөлҗамал"ны тыңлыйм да (шулай ук башка шундый катлаулы көйләрне дә) хәйран калам. Анда бит опера ариясына салырга гаҗәеп борылышлар бар! Анда бит халыкның моңы, нечкә күңел тибрәнешләрен бик тирән итеп, искиткеч дәрәҗәдә үтемле итеп, йөрәккә үткәреп әйтеп бирә торган ифрат тирән һәм камил эшләнгән моң бар! Син аны кайда гына җырлама, ничек кенә җырлама, дөньяның кайсы гына почмагында җырлап күрсәтмә, ул үзенең халәтен югалтмаячак, ул татар халкының үткәндәге моңы икәнлеген һәрвакыт ап-ачык итеп әйтеп бирәчәк.

Мондый көйләр бит меңләп! Шундый сокландыргыч көйләрне, халык музыкасын шул "надан", салам түбәле халык чыгарган, консерваторияләрдә белем алмаган халык арасыннан борынлап чыккан халык вәкилләре иҗат иткән бит! Хәзерге композиторлар, кайвакыт ничә еллар югары уку йортларында белем алуларына карамастан, андый сокландыргыч һәм мин әйтер идем, сәмави моңны бирүгә ирешә алмыйлар.

Менә шулай булгач, халыкның шушы табигый талантына ничек сокланмыйсың? Аның ул бөек иҗат батырлыгы, үзен мәңгеләштереп калдырган гаҗәеп моңнары каршында ничек баш имисең?

Һәм мин сокланам, мин рәхәтләнеп тирән ихтирам белән баш иям. Алай гына түгел, мин халкым белән, халкымның шушы талантлы, эшлекле, намуслы, батыр булуы белән горурланам. Шушы халыкның улы булуым белән дә горурланам. Шушы үземне тудырган халыкка чын күңелдән хезмәт итәм, аны тагын да күтәрәсем, тугандаш халыклар арасында аны тагын да күренеклерәк итәсем килә.

Әмма мина "алай ярамый", диләр. Үз халкымның фәлән-фәлән яклары белән горурлану ул масаюга алып бара, ул бүтән халыкларны кимсетү була, диләр. Халыклар дуслыгына зарар китерү, алай горурланмаска, гомумән, һәммә халыклар да бик һәйбәт, һәммәсе өчен дә берьюлы горурланырга кирәк, диләр.

Минемчә, кеше үз халкын никадәр ныграк яратса, үз халкы белән никадәр көчлерәк горурланса, андый кеше башка халыкларны да шулкадәр тирәнрәк һәм ныграк ярата. Милли горурлык белән халыклар дуслыгы арасында бернинди каршылык та юк, бәлки алар берсенә-берсе өстәлеп, нур өстенә нур гына булалар.

Киресенчә булганда без космополитлар гына тәрбияләячәкбез. Менә анын нәтиҗәсе күз алдында инде. Яшьләр һаман аза баралар. Алар аракы эчәләр, сугышалар, яшь кызларны бозалар. Хәзер гыйффәт саклау искелек калдыгы булып исәпләнә. Фәлән мәктәптә гыйффәтен саклаган кызлар бик аз гына процент тәшкил итә—8ме, тугызмы процент кына! Котычкыч хәл!



*Гомәр Бәширов (сулдан), композитор Җ. Фәйзи, ТКН директоры С. Вәлиди һәм композитор З. Хәбибуллин (утырган). 1954 ел.*

**30 апрель, 1966.**

Ә. Еникинең минем "Намус" турында фикерен ишеткәнем юк иде. Ул мондый фикер әйтте.

Дөрес, докладчы "Намус" романыннан бик отышлы үрнәкләр китерде. Роман аңа лаек та. Ләкин докладчы әйткәнчә, "Намус" романының кыйммәте халыкның сугыш вакытындагы патриотик хисләрен, сугыш вакытында фидакяр эшләрен югары художество чаралары ярдәмендә күрсәтүдә генә түгел. Ул үзенең әдәби кыйммәте белән, бик отышлы табылган детальләре белән кадерле. Колхоз эшендә, дөрес, аның геройлары фидакяр эшлиләр. Ләкин байтак еллар узганнан соң мин романның эшкә багышланган урыннарын оныттым инде, алар истә сакланмаган. Ә менә кем әле теге карчык? (читтән Хәдичә икәнлеген исенә төшерәләр). Әйе, Хәдичәнең намаз укуы һич тә онытылмый. Әйе. Без динне инкяр иткәнлектән түгел, юк. Намаз монда бер форма гына. Шул намаз уку аша Гомәр агай кешенең рухи тибрәнүен (юк, алай димәде шикелле), кешенең рухының бик нечкә тибрәнешләрен матур итеп, истә калырлык итеп бирә алды.

Яисә менә Нәфисәнең Иделдә су коену эпизоды. Ул да зур осталык һәм талант белән язылган. Менә шундыйлар күп һәм "Намус" романы шулары белән кадерле дә.

**5 июнь, 1966.**

Шушы арада Тукай юбилеен уздырып йөрдек.

Башта мин бу юбилейга берникадәр скептик караштa идем. Минем аңа хакым да бар иде шикелле, чөнки Г.Тукай юбилеена хас хәзерлек булмады. Әйтергә оят булса да, монда язмыйча булмый инде. Бөтен Советлар Союзында шулкадәр шөһрәт казанган, аз дигәндә берничә буын Азия һәм Ауропа язучыларының (үзбәк, кыргыз, казакъ, каракалпак, төркмән, башкорт, нугай, чуаш, әзәрбәйҗан, таҗик), гомумән төрки телдә язучы һәрбер язучының иҗатына, алай гына да түгел, барлык шул әдәбиятларның реалистик юлга басуларына ярдәм иткән, аларга юл күрсәткән бөек кешенең 80 еллыгы бик зур күләмдә, бик тантаналы рәвештә узарга тиеш дип безнең уйларга хакыбыз бар иде. Ләкин аңа акчаны бик аз бирделәр. Ул акчага Союздан килгән барлык өлкән язучыларны кунакханәдә урнаштырырга, Иделдә йөртергә, тагын әллә ниләр эшләргә кирәк иде. Без ояла-ояла Казакъстаннан Сабит Мукановны, Башкортстаннан Сәйфи Кудашны, Үзбәкстаннан Гафур Голәмне, Каракалпактан, Әзәрбәйҗаннан, Чуашстаннан, Маридан, Башкорстан, Удмуртия, Мәскәүдән тагын бик күп зур язучыларны кабул итәргә тиеш булдык. Шуның өстенә аларны Тукай-Кырлайга да алып барырга кирәк иде.

Менә шундый хәл. Комиссиянең рәисе булган Министрлар Советы рәисенең ярдәмчесе Ярмөхәммәтова: "Ул нинди эш, каян шулкадәр акча табыйк, Мәскәү безгә акча бирми",—дип бик күп нәрсәләрне җимереп ташлады. Кунакларга хөрмәт тә, игътибар да җитәрлек булмады. Тукайның берәр генә булса да китабы чыкмады. Мәскәү газитләрендә аның турында житди язучыларның мәкаләләре басылмады.

Безне 300 ел буена рус патшасы басып яткан, 300 ел буена коллыкта яшәткән. Менә без инде коллыктан, рухани коллыктан һаман да чыга алмыйбыз. Без һаман да Тукайның бөеклеген, аның зуррак тантанага лаек булуын һаман да раслый алмыйбыз. Безнең җитәкчеләребезнең һәрбер сүзеннән, һәрбер гамәленнән әнә шул коллык, Мәскәүгә каршы әйтә алмау, ягъни аннан Тукайның юбилеена аз-маз гына акча сораудан куркудан гыйбарәт булды.



*Гомәр Бәширов (сулдан) һәм Нәкый Исәнбәт (уңда) Бакый Урманчеда кунакта. Казан 1988 ел.*

Хәлбуки, Тукай хөкүмәтнең акча түгүенә һич мохтаҗ түгел. Аның әсәрләре бөтен дөнья күләмендә һәм бездә 115 тән артык мәртәбә басылып чыккан. Тукай әнә шул исәпкә дә үз юбилеен ун мәртәбә кызыграк итеп уздыра алыр иде.

**3 июль, 1966.**

Без моннан бер атна чамасы элек Казанга кайтып яши башлаган идек инде. Әле бүген якшәмбе көн итеп кышка хәзерлекне тәмамларга Аккош күленә килдек.

Мин 19нда Карловы Варыга китәм. Шуңа кадәр эшем бик күп. Алар арасында иң әһәмиятлесе—яңа әсәремнең язылган өлешен машинкада бастырып "Казан утлары"на тапшыру. Аның калган өлешен курорттан кайткач тәмамлап бирермен дип уйлыйм.

Бу дәфтәргә дә бик күп язасы нәрсәләр бар. Мәсәлән, мин сентябрь башында Бакуда булдым. Аңа кадәр Тукай юбилее вакытында бездә Гафур Голәм, Сәйфи Кудаш, Сабит Муканов булдылар. Алар белән әңгәмәне ничек язмыйсың?

Һәммәсен дә язарга кирәк. Ләкин менә бүген аңа мөмкинлек юк. Мин алар турында курорттан кайткач һәм әлеге әсәремне тәмамлагач язармын инде. Чөнки аңа кадәр минем вакытым булмастыр шикелле.

Миңа Хәсән турында күбрәк язарга кирәк дигән фикер башка килде. Чөнки мин аның турында хәзер шактый ук күп беләм. Без бик якын яшибез, күрше генә.

Хәсән, минемчә, хәзерге шагыйрьләрнең иң талантлыларыннан берсе. Шуның өстенә аның тормышы бик катлаулы. Ул бит үлемгә хөкем ителгән кеше. Үлемгә хөкем ителгәннән соң ул бер камерага эләккән. Ул барып кергәндә камерада караңгы икән. Кемдер ана дәшкән:

—Ә, иптәш, сез дә Айга озатылачак кешемени? Русча: "А, товарищ, вы тоже на Луну?"

Шушы сүзләрне ишеткәч Туфан, "Кара әле, монда да кеше тавышы ишетелә, һәм ул кеше нинди шигъри сүзләр әйтә. Димәк, әле бөтен дөньяда караңгы түгел икән..." дип уйлаган. Ягъни, үлемгә хөкем ителгән кеше дә шундый юмор белән сөйләшә ала икән, димәк, әле өметне бөтенләй үк өзеп бетермәскә мөмкин икән дигән фикергә килгән, аның күңеле аз гына булса да күтәрелгән.

Менә шундый хәлләр ишетә торгач, шундый фикергә килдем: теге яңа романда

("Хәерле иртә") язучыны Хәсән итәргә кирәк. Нинди һәйбәт һәм кызык материал! Бу образны кертү белән берьюлы бик күп нәрсә отарга мөмкин. Бердән, ул культ вакытын ачарга ярдәм итәчәк. Икенчедән, безнең әдәбиятта язучы образы юк диярлек. Менә Хәсән ана бик лаеклы.

Өченчедән, мин Хәсәннең рухани тормышын яхшы беләм дип уйлыйм. Димәк, аны һәйбәт бирергә мөмкин булачак.

Шунын өстенә, анын романтикасы бар.

Хәсән август башында Мәскәү янындагы Монино дигән санаторийга киткән иде. Аннан бик сәер, һәм борчый һәм дулкынландыра торган кечкенә генә хат җибәргән. Хәтта шигыре дә бар. Мин ул турыда язмыйча, бу дәфтәргә ул җибәргән шигырьне кушымта итеп куям. Менә ул: кечкенә генә кәгазьгә гарәп хәрефләре белән һәйбәт кәгазьгә вак кына итеп язылган. Һәм яшел кара белән! Нәкъ шулай. Мин аны белә башлаганнан бирле бүтән кара белән түгел, нәкъ менә шул яшел кара белән вак кына итеп яза.[2]

Нигә бу хатында ул шулкадәр өзгәләнә? Кайткач сөйләшеп карадым. Әнә шул әлеге дә баягы аны борчыган мәсьәлә инде: теге халык бу халыкны изә. Шуна каршы әлләни эшләп булмый. Ул шуна борчыла.

Шундый бер закон физикада да бар шикелле: материяга күпме көч куелса, ул шундый ук көчне каршы куя.

Милли мәсьәләдә дә шулай ук. Никадәр басымны көчәйтсәләр, басымга каршылык та шулкадәр ук күбәя.

Рус шовинизмы хәзер көчәйгәннән-көчәя бара. Ләкин шуна каршы милләтчелек тә башын күтәрә. Шовинизм никадәр көчәйсә, милләтчелек тә шулай ук каршылыкны көчәйтә бара. Бу—закон. Марксизм законы.

**9 октябрь, 1966.**

Кичә төнге унда Сәйфи Кудаш белән телефонда сөйләштем. Безнеңчә 10, аларча 12 дигән сүз бит инде ул. Бик унайсызлансам да Сәйфи бик тиз тынычландырды:

—Шул синең белән сөйләшергә булгандыр күрәсең, бүген йокларга ятмаган идек әле,—диде.

Шуннан киттек сөйләшеп. Мина Галимҗан Ибраһимовның "Галия" мәдрәсәсендә укыту чорыннан кайбер мәгълүматләр кирәк иде. Сүз кузгалуга Сәйфи үзенең авыру икәнен дә онытты, ярты төн булуын да—һәммәсен дә онытты. Нәкъ элекке "Галия" мохитенә кереп китте дә, шул санаулы минутлар эчендә бик күп нәрсәләр сөйләп бирде. "Галия" мәдрәсәсе 13 ел яшәве дәверендә 20гә якын язучы, 20дән артык редактор, күпмедер врач, күпмедер агроном һ.б. биргән. Анда укыган 100 кешенең 45 соңыннан коммунист булганнар. Өфегә Колчак һөҗүм иткән вакытта 45 "Галия" шәкерте үзләре теләп Совет властен якларга киткәннәр. Һәм башкалар.

Шунысы куандыра, бу абзый, яше шактый ук һәм авыру булуына карамастан, әдәбият дигәндә һәммәсен оныта да тормыш һәм эшкә башы-аягы белән чума.

Минемчә шул картаймый да аны.

**23 декабрь, 1966.**

Бүген кич белән радиода русча минем беренче татар совет шигърияten башлап җибәрүчеләр турында чыгышым булды. Ул чыгышның эчтәлеге болай ярыйсы гына иде. Мин анда моннан 50 ел элек әдәбиятта беренче урынны тоткан совет шагыйрьләренең, берничә җөмлә белән генә булса да, портретларын һәм иҗатларының үзенчәлеген әйтергә тырыштым. Ләкин...

Ләкин... Мин картайганмын икән бит! Менә шуны беренче мәртәбә диярлек бүген аңладым. Миннән картлар тавышы ишетелә. Тәмам эштән чыккан, әлсерәгән карт дип үк әйтмәс идем, шулай да...

Шулай да бу картка радиога чыгып, шундый сүлпән тавыш белән ялкынлы революционер шагыйрьләр турында сөйләргә кирәк идеме икән? Ай-хай!..

Мин бит үземчә бик тырышып, ялкынлы итеп... дип үк әйтмәс идем, әмма эчке бер дулкынлану белән сөйләгән идем! Бактың исә, ул монда бик ваемсыз, әйдә ярар инде... дигән кебек ишетелә икән бит!

Сабак булсын сиңа, сабак булсын!

**24 декабрь, 1966.**

Әле берничә сәгать кенә элек Арчадан кайтып төштем. Үземнең туган-үскән ягым. 50 елдан бирле очрашмаган яшьтәшләр, авылдашлар белән очраштым. Мәсәлән,

[2] Кызганычка каршы, дәфтәр эчендә Хәсән Туфанның ул шигыре язылган кәгазь табылмады.

Шәйди белән, Иван Матвеевич белән. Мин онытқан һәм бик әһәмиятле төрле хәлләрне сөйләделәр. Болар миңа әлеге әсәремне язарга һичшиксез ярдәм итәргә тиешләр.

Болай тыштан караганда бөтенесе үз урынында. Өйдә исән-сау торганнар. Үзем сау-сәламәт йөреп кайттым. Тагы ни кирәк?

Әмма безнең халыкка өйдәге тынычлык кына җитми бит, ул гына аз бит.

Менә чылтыраттылар. Мәскәүдән бер-ике язучы кайтты. Аларны Мәскәүдәге иптәшләр Г. Ибраһимовның 80 еллыгы уңае белән башланган тантана алдыннан шул турыда истәлекләр һәм докладлар ясау өчен үзләре чакырып алганнар иде. Бу иптәшләрнең чыгышы шул зур бәйрәмгә әзерлек, шуңа бер кереш кебегрәк бер чара булырга тиеш иде.

Әмма ни булган?

Җыелыш башланыр алдыннан бу җыелышны уздырырга рөхсәт итмәгәннәр.

—Ул нинди җыелыш? Нигә татар телендә генә? Нигә сез русча сөйләшмисез? Бәйнәлмиләл телдә сөйләргә кирәк,—дигәннәр...

Г. Ибраһимов болай да бик җәберләнгән әдип бит инде. Татарның ул классик язучысы, бер генә үпкә белән сулавына карамастан, монда үләсен белә торып Пләтән төрмәсенә ябылган, шунда салкын сарайда үлгән иде бит!

**12 февраль, 1967.**

Хәзер бөтен кеше йоклый инде. Мин генә уяу. Минем хәлемне белүче, һаман кайгыртучы, минем иң нечкә хисләремне, бөтен борчуларымны һәммәсен дә белеп торучы Кәримә генә йокламый. Әйе, бөтен дөньяда без икәү генә йокламыйбыз. Ул күрше бүлмәдә ята, әмма мин белеп торам, ул әле йокламый. Мин аз гына "шыгырдап" куямы, йөткерәмме, борчылып марш атлап йөримме, ул һәммәсен дә сизеп ята, һәм минем өчен борчыла. "Нигә йокламый икән?" дип уйлый. Менә бит нинди нечкә нәрсә!

Бүген мин телевидениедә Әмирхан Еники турында сөйләдем. Үземә үк ошамады. Мин үземне бик үк тыныч тотмадым. Андагы кешеләр "алай түгел, менә болай" фәлән-төгән дип сөйлисе нәрсәне, тегеләй дә болай да әлләничә мәртәбә үзгәрттеләр. Тыныч кына сөйлисе урында ниндидер коры бер чыгыш килеп чыкты, Әмирхан Еники турында минем бик җылы итеп сөйлисем килгән иде. Кызганычка каршы, мин теләгәнчә килеп чыкмады. Ниндидер коры чыгыш булды. Җитмәсә, ахырын, мин әйтәсе сүзнең ахырын кисеп ташларга туры килде. Чөнки анда Мәскәү башлаган икән. Гадәттәгечә, Мәскәү бернәрсә белән дә исәпләшми, үз тапшырулары башланганда мондагыларны рәхимсез рәвештә кисеп ташлый. Нәрсә ул аңа ниндидер татарларның чыгышы. Менә шулай. Мин бүген үземнән һич канәгать түгел. Миңа җитдирәк, тынычрак булырга кирәк иде.

**10 апрель, 1967ел.**

Язучыларның IV съездында булдык. Аннан байтак вакыт элек кайттык. Менә бүген шуның йомгаклау җыелышы булды.

Сөйләсәм дә сөйләдем, сөйлисем дә килмәде. Чөнки съезд гомумән яхшы тәэсир калдырмады, дөресен язмыйча булмый. Алдан сайлап куйган кешеләр генә сөйләде, язучылар күбесе үз фикерләрен әйтә алмадылар.

Мине нәрсә борчый? Мин 40 елга якын партия стажы булган карт язучы бит инде. Безгә, ягъни гомумән язучыларга ышанырга кирәк иде инде. Без, гомумән, совет властена каршы кешеләр түгел лабаса! Без үзебезнең кешеләр, без партиянең иң ышанычлы карт гвардиясе. Әмма безгә дә ышанмыйлар бит! Менә нәрсәдә фаҗига. Нигә шулкадәр формаль юлга басарга? Нигә язучының шәхси тойгыларын кысарга? Без бит үзебез яулап алган шушы властька каршы берни дә эшләмәячәкбез. Бу көн кебек ачык мәсьәлә. Ләкин шуңа карамастан нигәдер чиклиләр, нигәдер кысалар. Һич кирәкмәгәнгә!

Безгә ияреп барган кешеләр милли мәсьәләләр турында, тел турында, гомумән Союздагы кимчелекләр турында сөйләргә кирәкми диделәр. Үз өегезгә кайткач, тәнкыйть итәрсез, монда тәнкыйть белән шөгыльләнергә кирәкми, уңай яклар турында гына сөйләргә кирәк дип кисәттеләр.

**9 июнь, 1967.**

*Ахыры киләсе санда.*

Тәфкил
Вафин

# МӘКРУҺЛАР

## Мәхәббәтнең кабатлануы

1866 елнын декабре. Зәмһәрир суыгы булуга карамастан, төн урталарында Янгилдегә Иске Чәчкаб авылыннан Мөхәммәтсабит йортына ишан Габделлатыйф Алкин килеп төшә (анын урыслардан качып йөргән чагы). Мөхәммәтсабитнын әтисе Шәрәфетдин, шакылдату тавышын ишетеп, капканы чыгып ача. Шәрәфетдин бабай сакта тора. Ул ишек алдында берничә сәгать буе йөри, жылынып чыгарга да керми. Ишан хәзрәт, Янгилдедә эшне тиз тотып, яктырганчы Тәтеш өязенен Ташкичү авылында борып житү турында уйлый. Анда аны Мөхәммәтша көтә. Мөхәммәтшанын урыс хөкүмәте тарафыннан Себергә жибәрелүчеләрнен чираттагы этап исемлегенә эләгүен Алкин ана шәхсән үзе житкерергә һәм кинәшләрен бирергә тели. Мөхәммәтсабит, Барыш волостендагы Кыртапа авылына барып, мөселманлыкка кайткан Сөләйманга ишан хәзрәттән бер кәгазь тапшырырга тиеш була. Сөләйманга Барыш волостена кергән татар-мәкруһ авылларынын вәкилләр жыелышын жыеп, күрше өязләрдәге мәкруһларнын хәлен бәян итү йөкләнә. Кәгазьдә шулай ук Тәтеш өязенә кергән мәкруһ авылларында яшәүчеләрне тынычландыру нияте белән бәян ителгән берничә яхшы хәбәр дә житкерелә. Шуларнын берсендә патша хөкүмәтенен, чиркәү руханиларынын даими рәвештә мөселман диненен тиздән бетәчәге турында тәкрарлап торуларына карамастан, Казан губернасында яна мәчетләр калкып чыгуы, шул исәптән Казаннын үзегендә 12 мәчет эшләп килүе, берничә яна мәчет төзелә башлавы, ә купец Д. Б. Усмановнын, хакимияттән рөхсәт алып, хәтта Тихвин бистәсендә дә мәчет төзетә башлавы бәян ителә. (Архиерейнын эчке эшләр министрына язган хатында болай диелә: «Казан шәһәренен Тихвин бистәсендәге чиркәүләр янында мәчетләрнен үрчеп чыгуын Тихвин чиркәүләрен мыскыллау һәм кимсетү дип анларга кирәк». Хакимиятьне тагын бер нәрсә тынычсызлый, ул—мөселманнарынын Россия башкаласы Петербургта да мәчет төзү буенча өлгерлек күрсәтүләре. Бер белешмәдә Петербургтагы хәлләр турында болай дип әйтелә: «Постройка мечети в столице важный признак преуспеваемости мусульманства в России. Теперь уже недолго ждать, когда вдоль Невы будут раздаваться звуки азана, «Аллах акбар», т. е. «Аллах велик».)

Габделлатыйф Алкин Тәтеш өязе мәкруһларына юллаган кәгазьдә бәгырьләргә сары май булып яткан түбәндәге сүзләр дә була, Мөхәммәтсабит аны урысча да укып күрсәтә: “Многих русских приводило в уныние факты возврата крещенных татар в прежнюю веру”.

Кыртапа—хәзерге Татарстаннын Кама Тамагы районында, Коры Үләмә елгасы буенда урнашкан авыл. Анда яшәгән, тирә-як мәкруһлар ихтирамына лаек булган Сөләйман һәм Габделлатыйф Алкин—күптәнге танышлар. Сөләйман минем Мөхәммәтсабит бабам белән дә яхшы таныш була. Аларны бабамнын

*Дәвамы. Башы 2008 елның 11нче санында.*

Акхуҗадагы дусларыннан берсе Әбраретдин Рәхмәтуллин таныштыра. Чөнки Сөләйманның хатыны—Акхуҗадан, ул һәм Әбраретдин—бертуганнар. Сөләйман абзый хатыны Миңлегайшә белән дүрт бала—дүрт малай һәм бер кыз үстерә. Кызлары Миңлегөл төпчек балалары була.

Мөхәммәтсабит Сөләйман һәм аның гаиләсе белән тиз арада дуслашып китә, алар фикердәшләргә әвереләләр. Сөләйманның уллары Мөхәммәтсабит белән Кыртапа мәкруһлары арасында эшчәнлек җәелдерәләр. Барып-килеп йөрү өчен ара шактый ерак булса да, Мөхәммәтсабит бабай Сөләйманның балаларына кичләрен яшерен рәвештә дәресләр бирә. Миңлегөл дә абыйлары белән бергә укырга-язарга өйрәнә. Ул абыйларына караганда дәресне тизрәк тә үзләштерә, сәләтлерәк була. Сөләйман да балалары белән бергә язу танырга өйрәнә. Мөхәммәтсабит аша Алкиннан алган язуларны Миңлегөлгә күчертеп яздыралар. Миңлегөлне гаиләдә, иркәләп, Миңнүс дип йөртәләр, аны яраталар. Ул үткен кыз булып үсә. Үсмер яшенә җиткәч, аңа Моңлы гөл дип тә эндәшәләр.

Мөхәммәтсабитның тәүлекнең кайсы вакыты булуга карамастан Янгилде авылыннан чыгып китүе авылдашлары, бигрәк тә урыс күршеләре тарафыннан башка авылда яшәгән сөяркәләре янына бару дип бәяләнә. Шуңа күрә аның өйдә булмавы хакимият өчен куркыныч тоелмый. Бу хәл турында архиепископ Антоний губернаторга болай дип җиткерә: “Иван Иванов (Шәрәфетдин) о сыне Василии отзывается как о негодяе, развратнике, шатающимся по деревням неизвестно для чего и как вышедший из повиновенья.” ТР МА.—Ф. 1.—Тасв. 3.—Сакл. бер. 228.—Б. 44.) Әтисенә шулай дип аңлату отышлырак була.

Чынлыкта Сабитның төп вазифасы башка волостьларда, хәтта өязләрдә яшәүче мәкруһлар белән очрашудан, мәкруһларны дөнья хәлләре белән таныштырудан, мөселманнарның үз диннәренә кайтуын оештырудан гыйбарәт була.

Мөхәммәтсабит күп вакытын Кыртапа авылында, Сөләйман гаиләсендә уздыра. Сөләйман һәм аның уллары Мөхәммәтсабитны үз итәләр, аңа ияләшәләр. Мөхәммәтсабитның Янгилде авылындагы шәхси хуҗалыгы шактый зурлардан исәпләнә: 25ләп оя умартасы, ике сыеры, берничә аты була. Олыгаюы сәбәпле, Шәрәфетдингә хуҗалыкта эшләү кыенлаша. Мөхәммәтсабитның улы Мөхәммәтсадыйкка әле ундүрт тирәсе, кызлары Мәхүпкамал белән Миңлекамал да авыр физик хезмәт өчен яшьрәк булалар. Хуҗалыкны алып барырлык кеше әбиебез Мәхүпҗамал гына була. Ул да яшьли үпкә чире белән авырый башлый. Хәбирә апага әтисе Мөхәммәтвафа түбәндәгеләрне сөйләгән: «Без, балалар, абыйдан (Мөхәммәтсадыйк) гайре, өй эшләрен эшли алмый идек. Шунлыктан Шәрәфетдин бабай, авыру әни белән киңәшеп, Мөхәммәтсабит әтигә яшь хатынга өйләнергә, ягъни ике хатын белән яшәргә тәкъдим иткән.

Сөләйман кызы Миңлегөл 17дә, чибәр кыз булып җитлегеп килә. Дүрт абыйсы, әнисе, әтисе аны бердәнбер кыз, төпчек бала буларак яраталар, яклыйлар. Тирә-яктагы татар мәкруһ авылларыннан яучылар да килә башлый. Миңлегөл гашыйк була. Ләкин үзен сорап килгән егетләргә түгел. Үзеннән ике мәртәбә олырак кешегә, дүрт балалы Мөхәммәтсабитка—әтисенең дустына, кордашына гашыйк була ул. Алар өйләнешәләр. Никахны Янгилдедән килгән Шәрәфетдин бабайдан укыталар. Кыртапа мулласы куркып никах укудан баш тарта. Бу хәл 1867 елның 24 февралендә була. Мөхәммәтсабит яшь кәләшне яшерен төстә Янгилдегә алып кайта. Аны беренче хатыны Мәхүпҗамал белән таныштыра. Мәхүпҗамал әби көндәшен якты йөз белән каршы ала. Төпчек уллары өч яшьлек Вафа белән ул арт өйдәге йокы бүлмәсенә күчә. Алдагы өйнең йокы бүлмәсендә Сабит баба икенче хатыны белән кала. Шул рәвешле өч ай яшиләр. Кыртападан килгән киленне авыл халкы утырмага килгән кунак кызы итеп кабул итә. Халыкка, Мәхүпҗамал чирле булганга, аңа утырмада озаграк булырга туры киләчәк дип аңлаталар. Миңлегөл шулкадәр үткен-чая була ки, тиз арада авыл хатыннары белән дуслаша. Беренче көннән башлап өй эшенә керешә. Балалар Мөхәммәтсабит өендә тыныч кына эшләп йөрүче Миңлегөл апаларын Кыртапа авылыннан килгән кунак кыз дип аңлыйлар. Хәтта 15 яшьлек Мөхәммәтсадыйкка да мәгълүм булмый. Гасабиланып

нидер көткән кеше Шәрәфетдин була. Ул эшнең ачылысын сизә.

Без капчыкта ятмый диләр. Шәрәфетдин гаиләсендәге хәлләр Зөя һәм Тәтеш өязе урысларына, чиркәү руханиларына мәгълүм була. Бу яналык Гыйлажи белән Минажига да (Семен һәм Савелий Степановлар) барып житә. Әйтеп киткәнемчә, алар икесе дә Мәхүпжамал әбиебезнең энеләре булалар. Сабит бабайның каенишләрен, иманнарын саткан затлар буларак, бөтен Казан губернасында беләләр. Шуннан мәхшәр башлана. Шәрәфетдин йортына көн саен 2нче стан приставы килеп йөри башлый. Мөхәммәтсабитнын яна хатыны Миңлегөлне эзләп киләләр, тентү ясыйлар, әмма таба алмыйлар. Миңлегөлне хакимият, урыслар, шул исәптән хәтта күршеләре дә икенче хатын дип танымыйлар. Бу христиан кануннарына сыймый торган хәл, диләр. Миңлегөлне "девка из деревни Картапа" дип атыйлар. Мөхәммәтсабит эзләү шаукымы узганчы Миңлегөлне кеше уйламаслык урында—маржа күршеләре Домна исемле карчыкта яшереп тота. Миңлегөл ире Мөхәммәтсабитны шулкадәр ярата ки, алгарак узып булса да әйтим, Мөхәммәтсабит Себергә сөрелгәч, анын артыннан авырлы көенчә, Себергә дә китәчәк әле ул. Ә әлегә Мөхәммәтсабитнын икенче хатынын эзләү дәвам итә. Ярты авылны аякка бастыралар. Урыс милләтеннән булган авылдашларына тимиләр. Шуннан сон ни булганын аңлау өчен Казан губернаторына архиепископ Антоний тарафыннан жибәрелгән, заманында сер итеп саклаган хаттан, тәржемә итмичә генә, бер өзекнең күчермәсен китерәм.

«13го прошлого марта деревни Азелей из татар крещенный Семен Степанов (Гыйләжи—Т. В.) объявил ему, священнику Охотину, что зять его из деревни Янгильдиной из татар крещенный Василий Иванов, несмотря на то, что 16 лет имел в супружестве сестру его родную Матрену, 24 февраля сего года взял себе вторую жену Тетюшского уезда деревни Картапы дочь из татар крещенного по имени ему неизвестного, которую по татарски зовут Минусь, а русского имени не знает. Свидетелями при сем его объявления были села Куланги дьячки Алексей и Александр Петровы и крестьяне Семен Кондратьев и Филипп Андреев. Он же Иванов по словам Степанова был одним из первых возмутителей в дер. Янгильдиной, способствовал крещенным татарам к отпадению от православия к Магометанству, к подписанию адреса (императорга гариза язу). В настоящее время старается всеми мерами удержать крещенных татар от присоединения к православию. Имея это в виду, священник Охотин предложил Федоровскому волостному правлению узнать, действительно ли означенная Минусь находится в доме Иванова. На что правление отношением 14 марта за номером 217 уведомило священника Охотина, что помощник волостного старшины Ахметзян Мухаметзянов, с понятыми деревни Янгильдиной делал у крестьянина из татар крещенного Василия Иванова обыск, по коему действительно найдена девка не Минусь, а Миниган Сулейманова, приехавшая к нему из деревни Кыртапы Тетюшского уезда» (ТР МА.—Ф.1.—Тасв. 3.—Сакл. бер. 228.—Б.33).

Казан архиепископы хатын болай дип төгәлли: "Милостивый государь, покорнейше прошу Вас сделать распоряжения дабы главные возмутители по Кулангинскому приходу крещенные из татар деревни Азбабы: Иван Петров, Антон Иванов, Николай Никитин и деревни Янгильдиной Василий Иванов были преданы уголовному суду, и поступлено были с ними, ровно и с крестьянином деревни Чутеевой Цивильскрго уезда Махмудом Миркашиным по всей строгости законов; проживающую же в доме из татар крещенного Василия Иванова в качестве другой жены татарскую девку Миниган Сулейманову немедленно удалить из деревни Азбабы в место ее жительства, и о последующем почтить меня уведомлением".

Архиепископ Антоний, үзенең хатында тагын бер бик әһәмиятле мәгълүмат бирә: "12 мартта благочинный вазифаларын вакытлыча башкарган рухани Зайков хәбәр итүенчә, сонгысы Акхужа авылы мәкруһларын православиегә күчәргә өндәгәндә, Зөя, Цивильск, Тәтеш өязләре мәкруһларынын икенче мартәбә патшага Мөхәммәд динендә калдыруын сорап хат жибәрүләрен ишетә.

Хатны Чүти авылы крестьяны Мәхмүт Миркашин алып киткән. Ул җавап алып кайтканчыга кадәр православие динен башкаручы булмаячагы турында Зөя өязе авыллары мәкруһлары Колангы побы Виктор Охотинны алдан ук кисәтеп куялар."

Әбием Әмәйгел рәсми документлар буенча 1870 елда туган. Ләкин ул шактый өлкәнрәк күренә иде. Мин туганда аңа 65 яшь кенә булырга тиеш, ә ул 1870 елдагы вакыйгаларны да хәтерли иде. Әбинең үзе сөйләгәннәрне искә төшерсәк, ул булачак ире Мөхәммәтвафа белән бала вакытларында бергә уйнап үскән. Шул ук вакытта Вафа бабай рәсми документларда биш яшькә өлкәнрәк күрсәтелгән. 1867 елда әтисе Мөхәммәтсабит кулга алынганда ул өч яшьтә була. Әнисе Мәхүпҗамал вафаты вакытында аңа биш кенә яшь булса, Мәхүпҗамал әбинең вафаты 1869 елга карый. Бу турыда миңа әбинең иң өлкән кызы Мәрьям апа әйткән иде. Хәер, әбинең Берләш авылына Мәрьям кызы Сатмышка Хәбирә кызы янына барып сөйләшеп утырганнарын яхшы хәтерлим. Мин әбидән ишеткән мәгълүматлар тагын да элегрәк вакытка карыйдыр дип уйлыйм.

Үземне үзем белгәндә миңа дүрт яшь тирәсе булгандыр. Сугыш башланганда биш яшьтә идем. Әби әнисе Ләйли турында сөйләргә ярата иде. Ләйли әби исә әнисеннән ишеткәннәрне хәтерендә саклаган. Әби Мөхәммәтсабит баба йортына килен булып төшкән көннәрен хәтерли иде. Ләкин Сабит бабай бу вакытта еракта—Туруханкраенда була. Әби онытканнарны мин аның кызлары—әтинең апаларыннан сөйләтә идем. Алар минем өчен гомерем буена аяклы энциклопедия булдылар. Алар миңа Ләйли әбиләре сөйләгәннәрне дә бәян итәләр иде. Иң өлкәне—Мәрьям апа (әтиемнең беренче бертуган апасы). Ул 1899 елда туган, 1984 елда вафат булды. Икенче апа, мин бу хәлләрне яза башлагач, 100 яшенә 3 ай кала вафат булды. Иң кечеләре Бибисара апа 1912 елда туган, 2004 елда дарел-бакыйга китеп барды. Алар миңа хәтерләрендә сакланган мизгелләрне бәян иттеләр. Урыннары җәннәттә булсын. Мин бәләкәйдән кызыксынучан булдым, бигрәк тә үземнең әби-бабаларымның тормышы тынгы бирми иде. Бәлки әтисез үсү дә, дөнья авырлыклары да тәэсир иткәндер. Әбинең миннән башка тагын 12 оныгы бар иде. Ул аларга үзенең узган гомере турында сөйләргә яратмады, алар белән теләр-теләмәс кенә аралаша иде.

Безне, сеңлем Фәнзилә белән икебезне, әбиебез чын күңелдән яратты. Аның сәбәпләре дә булган, әлбәттә. Без—әбинең төпчек улы Гайфетдиннең балалары. Чәй эчәргә утырганда әби тезләрен чәнчеп утыра иде. Ә без, Фәнзилә белән икебез, башларыбызны әбинең тезенә салып ятабыз. Ара-тирә әбинең тезләрен бүлешә алмыйча пыр тузып талашып, кайчакта хәтта ки сугышып та китә идек. Шулай яткан көенчә әбинең сөйләгәннәрен тынлавы рәхәт тә иде соң. Ә ул сүзен гадәттә "Сабит бабагыз" дип башлый иде...

***

Төнге тентүгә поп Охотин җитәкчелек итәргә тиеш булса да, Янгилде авылына Зөя каласыннан Зөя өязе исправнигы килеп җитә һәм гомуми җитәкчелек аңарга йөкләнә. Әлбәттә, ул башта кулга алу планы белән таныша һәм хуплый. Вак-төяк сорауларны, боерыкларны Гыйлаҗи белән Минаҗи үтиләр.

Өяз приставы ун жандарм алып килә. Федоровск волосте старшинасы өйдә булмау сәбәпле, тентү үткәргәндә аның ярдәмчесе Әхмәтҗан Мөхәммәтҗанов катнашырга тиеш була. Ләкин аңа соңрак әйтелә—ул тентү узгач кына килеп җитә.

Минлегөл бу төнне өйдә була. Сабит бабай үзенең яшь хатыны белән йоклый. Хәер, гаилә тулысынча каты йокыга талган була. Төнге берләр тирәсендә Сабитның авылдагы иң кырый йорты жандармнар тарафыннан чолгап алына. Кыш көне булса, кешеләр йөргәне, кар шыгырдаган тавыштан беленер иде. Этләре Карач та өрми, Гыйлаҗи аны ашарга биргәләп ияләштергән була. Безнең Тау ягы кешеләре (урысы, татары) беркайчан да ишекләрен бикләмиләр. Жандармнар Гыйлаҗи күрсәткән ишектән өйгә бәреп керә. Өйдәгеләр барысы да йокыга

талган. Беренче булып тавышка Шәрәфетдин бабай торып утыра (ул мич башында йокларга яраткан). Гыйлажи сүгенә-сүгенә йоклаган Миңлегөлнең чәченә ябыша. Мөхәммәтсабит берни дә эшли алмый, чөнки аны жандармнар боргычлап ала. Гыйлажи Миңлегөлне чәченнән идәнгә сөйрәп төшерә. Күрше йортлардан урыс пүнәтәйләрен алып керәләр. Шул ук вакытта авылдаш урыслар каравыл ызбасы янындагы, кайчандыр поп Охотин Янгилде халкына "бүләк иткән" ярты потлы жиз чанны арба кендеге белән кыйный башлыйлар. Элек янгын чыкканда гына болай эшләгәннәр. Халык жыела. Гыйлажи белән Минажи Миңлегөлне бер кат эчке күлмәктән килеш чыбыркы белән кыйный-кыйный каравыл ызбасына алып кереп китәләр (ТР МА.—Ф.1.—- Тасв. 3.—Сакл. бер. 228.—Б.39.).

Миңлегөлне һәм богауланган Мөхәммәтсабитны Федоровск волость идарәсенә илтергә тиеш булалар. Шәрәфетдин олпат гәүдәсеннән салып Миңлегөлнең өстенә тун яба. Янгилде авылын чыгып, урман борынына житкәч, Мөхәммәтсабитның богауларын салдырып, жәяү барырга рөхсәт итәләр. Федоровскида боларны волость старшинасы карамагындагы ике камерада иртәнгә кадәр ябып торганнан соң, аларны, дөресрәге, Миңлегөлне, Тәтеш өязе Барыш волосте Кыртапа авылына, Сөләйман әтисенә илтеп тапшырырга тиешләр. Аларны волость старшинасы озатып барырга тиеш була. Ләкин аның өйдә булмавы сәбәпле волость старшинасының ярдәмчесе Әхмәтжан Мөхәммәтжановны жибәрәләр. Мөхәммәтсабит Әхмәтжаннан аны үзе белән алуын үтенә. Әхмәтжан, Сабит абыйсы белән якыннан таныш булмаса да, аның мажаралары турында белә.

Иртәнге уннарда юлга чыгалар.

Апрель бит инде. Көн жылы, азрак кар явып тора. Юлдагы кар изелә, ерганаклар турысында ат корсагына чаклы бата башлый. Шыгайны чыгып Зөя елгасына якыная башлагач, юл бөтенләй бозыла. Зөяне үткәч, Олы Барышка жәяүләп китәләр. Әхмәтжан беренче булып барган жиреннән, сукмак өстендә биленнән суга чума. Ана якындагы Күккүз авылына китүдән башка чара калмый. Әхмәтжан пристав тапшырган 1429нчы номерлы пакетны Мөхәммәтсабитның үзенә биреп, аны да Миңлегөлне дә Барыш волосте старшинасына тапшырырга куша. Болай дип тә әйтә: "Син, Сабит абый, яшь хатының белән азрак вакыт булса да бергә буласың килә икән, мин сине күрмәдем",—ди, үзе пакетны берничә мәртәбә суга манып ала да: "Бу пакетта укырлык бер хәреф тә калмады. Барыш волосте старшинасына пакет суга төште диярсен",—ди.

Карангы ингәч, Мөхәммәтсабит үзенең Миңлегөле белән Сөләйманның жылы өенә кайтып житә. Берничә көн Миңлегөлнең әнисенең абыйсы Хәкимулла Талипов мунчасында яшеренеп яшиләр.

Мөхәммәтсабитны урыс чиновниклары һәм чиркәү руханилары үлеп бетеп яратмаганнар. Ул аларны санламаган гына түгел, алардан көлгән дә. Аны шулай кулдан ычкындыру түрәләрне чыгырдан чыгара.

"...Заключил сектанта Василия Иванова по явке из отлучки отправить (арестовать) в город Свияжск для содержания при полицейском управлении, впредь до особого распоряжения."—Свияжск өязе исправнигы Казан губернаторына язган рапортыннан бу. Мөхәммәтсабиттан тыш аның фикердәш мәкрүһлары да кулга алынырга тиеш була.

## Кулга алулар

Патша хөкүмәте мәкрүһларны Себергә озатуны этаплап оештыра. Ягъни бишәр кешедән торган кечкенә төркемнәр булдыралар. Исемлекне губернатор шәхсән үзе раслый.

Мөхәммәтсабит эләккән 11 кешелек исемлек кеше язмышына мөнәсәбәт жәһәтеннән шаккатыра. Бернинди тикшерүсез, хөкемсез Себергә озатканнар. Бу исемлектә бабамның Акхужа авылындагы фикердәшләре Әбраретдин Рәхмәтуллин, Габделхәбир Зиннәтуллин һәм Хәкимулла Талиповлар да була. Этапташларның бишенчесе—Тажетдин Мөхәммәдъяров. Салтыган авылы

муллысы исемлеккә ни өчен кертелгән соң?

Зөя өязе исправнигы Казан губернаторына жибәргән рапортта болай дип әйтелгән: "18го июня 1867 года в праздник Курбан байрам мулла Мухамадияров Тазетдин допустил к богослужению в мечеть всех крещенных татар деревни Салтыганово. По выходу из мечети, когда русские крестьяне крещенным татарам заметили, что им воспрещено ходить в мечеть, крещенные татары ответили при мулле с ругательством, что они русскую веру знать не хотят, никого не боятся и русских скоро выгонят, мулла, услышав эти слова, ничего им не сказав, рассмеялся."

Салтыган мулласы Тажетдин Мөхәммәдъяровка бу көлүе бик кыйммәткә төшә.

Салтыган авылында туып-үскән, акыллы, белемле Тажетдин мулла тирә-як авылларында зур ихтирамга лаек була. Урыс хөкүмәте чиновниклары, чиркәү руханилары да мулла Тажетдинны популяр кеше дип бәялиләр.

Кулга алынган мәкруһларны этаплаштыру барганда мулла Мөхәммәдъяровка тимиләр әле. Хәзрәтне кулга алуны оештыруга губернатор да катыша. Анын күрсәтмәсе буенча вакыйга зур "огласка" алырга тиеш була.

Кулга алу "церемониясе" алдан төзелгән план буенча башланып китә. Мәйданда елаулар, камчы чыжлау, ат кешнәүләр, урысларның әшәке итеп татарча (янәсе татарча беләләр) сүгенүләре ишетелеп тора. (Безнең якта урысча сүгену сүгену булып исәпләнми).

Хәер, бу хакта "церемония"не оештырган кешенең үзеннән сөйләтик.

"...По случаю популярности муллы Мухаметзянова[1], имеющего огромный вес среди своих приверженцев, отпавших от православия крещенных татар, и чтобы дать случаю этому более важное значение, я имел необходимо нужным при взятии муллы Мухаметзянова принять следующие меры предосторожности. Отношением от 30го июля за №502 просил у начальника Свияжской уездной команды отправить в Салтыганово 20 рядовых при 2х унтер-офицеров для конвоирования муллы Мухаметзянова, командировать в помощь этому конвою 4х казаков и сам лично отправился в Салтыганово. Для большой гласности, я приказал господам становым приставам обязать лично все селение, в которых проживают крещенные татары и объявить им, что по распоряжению правительства за совращение и подстрекательство крещенных татар и за распущение между ними ложных слухов, будто-бы высочающего отказа на их просьбу ещё не последовало. Виновные мною будут 3 числа утром взяты в деревню Салтыганово и отправлены в отдалённые части Сибири. Приказал при этом выслать из каждого селения к 3му числу утра в деревню Салтыганово два или три человека доверенных от крещенных татар к сельским старостам. И полицейским сотским для присутствования при этой церемонии, кроме того пригласил туда же волостных старшин трех волостей Ульянковской, Азалейской и Кушманской, священников села Ульянково и села Багаево...

Утром 3-го июля явился туда сам начальник Свияжской уездной команды штаб-с капитан Г. Перецкий с выше упомянутом конвоем. Собрав всех крещенных татар деревни Салтыгановой и поставив против них собранных и туда же деревенских прочих...[2] лиц числом 150 человек, я приказал старшине позвать муллу Мухаметзянова, по прибытию его приказал скомандовать на «караул», объявил ему и всем присутствующим причину ссылки Мухаметзянова с прочими лицами в Сибирь. Тут же я приказал муллу Мухаметзянова заковать в наручники... Остальным всем присутствующим внушение образумиться, бросить свои безумные стремления в магометанскую веру...

Результат этой церемонии был тот, что все находящиеся при этом крещенные татары отпавшие от православия, вовсеуслышание дали обещание снова быть

[1] Тажетдин Мөхәммәдъяровның фамилиясе урыс документларында "Мухаметзянов" булып та теркәлгән.

[2] Писарь боргалап-сыргалап язган кайбер сүзләрне танып житкереп булмады – Т. В.

православными... Этому счастливому успеху способствовало немало появление воинской команды.

О чем Вашему Превосходительству (Казан губернаторы) имею честь донести.—Уездной исправник

Июль 8-го дня 1867 года."

Зөя өязе исправнигы Салтыган авылы мулласын кулга алу церемониясенең нәтиҗәле тәмамлануына бик тә риза булып кала. Кулга алу нәкъ губернатор кушканча килеп чыга.


ДѢЛО

КАНЦЕЛЯРІИ НАЧАЛЬНИКА КАЗАНСКОЙ ГУБЕРНІИ.

НАЧАЛОСЬ 10 ... 18.. ГОДА.

КОНЧИЛОСЬ 17 ... 18.. ГОДА.

***

Югарыда әйтеп киткәнемчә, Казан губернаторының 1867 елгы 22 апрель приказы нигезендә Мөхәммәтсабит бабамның, шул ук елның 24 апрелендә Сабит бабабызның фикердәшләрен-көрәштәшләрен, Аккужа авылыннан Әбраретдин Рәхмәтуллинны Габделхәбир Зиннәтуллинны, Хәкимулла Талиповны Зөя өязе полиция идарәсендә кулга алалар. Ине—ике, буе—дүрт, биеклеге өч ярым аршынлы[3], тимерләнгән зур гына тәрәзәле, ике караватъ, бер өстәлле бүлмәгә дүртесен бергә кертеп ябалар. Берәр сәгатьтән озын гәүдәле, сары мыеклы, яшел күзле бер урыс егете әлеге тишектән татарча: "Исәнме, земляклар",—дип эндәшә. Исәнләшкәннән соң: "Чәй суы китеримме?"—дип сорый. Чәйнекне кулына тотып чыгып киткән җиреннән, буш чәйнекне кайтарып бирә: "Надзиратель кайнатылтан суны иртәгә, православие диненә кайткач бирербез, салкын су эчсеннәр дип әйтте",—ди.

Болар полиция идарәсендә бер ай чамасы утыргач, камерага бишенче кеше итеп Салтыган авылы мулласы Таҗетдин Мөхәммәдъяровны кертәләр. Әлегә кадәр ике караватта дүрт кеше йокласалар, муллага хәтта утырып торырга да урын булмый. Ләкин аларга монда башка төн кунарга туры килми, бишесен дә "Казан сөрелүчеләр экспедициясе"нә күчерәләр, җәяүле этапка беркетәләр.

*Ахыры киләсе санда.*

3 Аршын – 71 см.

Тәлгат
Галиуллин

# "ГАЯЗ ӘФӘНДЕ ШАГЫЙРЬДЕР"

XX гасыр тарихына, милли җанлы инсаннар күңеленә янарыш чоры прозасының күренекле вәкиле, талантлы драматург, ялкынлы публицист, гаярь журналист, көрәшче, олуг сәясәтче, тарихчы буларак кереп калган һәм гомере буена халкын югалудан, инкыйраздан йолып калу өчен җан атып йөргән, большевизмның асылын вакытында аңлап мөһаҗирлек язмышын сайлаган бу шәхесне шигърият белән бәйләү сәеррәк күренергә мөмкин. Реалист Исхакый яшьлегендә дә шигырь белән мавыкмаган, Тукай иҗатын үзәккә алган, бәгырьне телгәләрлек ихлас мәкаләләрен дә бөек шагыйрьнең вафатыннан соң гына язган. Шуңа күрә "әдипнең шигърияткә галякасе булдымы икән?" дип шөбһә белдерүче дә табылыр. Алгарак китеп булса да, шуны искәртәсе килә: Тукай белән Җ. Вәлиди Г. Исхакый әсәрләренең өслүб, тел үзенчәлекләре ягыннан русларның Тургенев, Бунин әсәрләре шикелле үк шигырьдәй аһәңле янгырашына игътибар иткәннәр. "Һәркемнең үз фикере, төшенчәсе бар" (1906) исемле мәкаләсендә Тукаев фамилияле яшь әдип "Таң"чыларның баш мөхәррире Гаяз әфәнде шагыйрьдер" дип кистереп әйтә . Чорның зирәк тәнкыйтьчесе, әдәбият галиме, философ Җамал Вәлиди "Гаяз әфәнде" (1913) дигән эссесында шулай ук Исхакыйның "шагыйрьлегенә" басым ясый. "Ике йөз елдан соң инкыйраз"—җитди бер әсәр. Ләкин Гаяз әфәнде—бунда да шагыйрь" . Язучы "җитди" повестенда дөньяга шагыйрь күзе белән карый алган икән, башка әсәрләре турында сүз куертып торасы да юк дигән нәтиҗә соралып тора.

Чынлыкта "Исхакый һәм татар шигърияте" галимнәрнең игътибарыннан читтәрәк кала килгән, бары тик Тукай иҗатына мөнәсәбәттә генә азмы-күпме өйрәнелгән күп кырлы, киң тармаклы проблема. Ул ким дигәндә өч мөстәкыйль мәзһәбне үз эченә ала.

Берсе—Исхакый белән Тукай арасындагы матбугати мөнәсәбәтнең нәзари (теоретик) һәм гамәли (практик) әһәмияте, ике шәхес арасындагы рухани һәм иҗади якынлыкның асылы. Икенчесе—Исхакыйның үз чоры татар поэзиясенә карашы, аның үсеш үзенчәлекләренә, аерым шәхесләренә бәясе. Өченчесе һәм киләчәктәге үсеш мөмкинлекләре яссылыгыннан караганда бәлки иң мөһимедер—шигърияттә Исхакый образы, Исхакый шәхесе. Саналган мәүзугларның (темаларның) үзара тыгыз бәйләнгән булуын һәм миллилек, халык язмышы, телебезнең киләчәге өчен янып-көеп иҗат ителгән әдәби әсәрләргә Исхакый идеяләренең көчле ут шикелле юл күрсәтеп торуын да онытырга ярамый. Татар халкының үткәненә, бүгенгесенә, киләчәгенә бәйләнешле нинди генә юнәлешкә кагылма, Исхакый иҗатын, аның иҗтимагый яисә фәлсәфи фикерен читләтеп үтү мөмкин түгел. Бу титаник шәхес XX йөз әдәбияты, иҗтимагый фикере үсешенә юнәлеш биреп торучы милләтпәрвәр, халык бәхете өчен яшәүче изге зат буларак елдан-ел тиранрәк ачыла. Аның бөеклеге Тукай шәхесенә мөнәсәбәтендә бигрәк тә ачык күренә.

Тукай белән Исхакый арасындагы тарихта сирәк очрый торган сокландыргыч рухани якынлык, фикерләр уртаклыгы турында И. Нуруллин, Ф. Латыйфи, Б. Гали һ. б. язучылар, әдәбият галимнәре, тарихчылар төрле елларда шактый тәфсилле яздылар . Р. Ганиева, А. Әхмәдуллин, Х. Миннегулов, Ф. Мусин, Ә. Сәхапов кебек галимнәрнең монографик хезмәтләре, уку-укыту әсбаплары да бу теманы читләтеп үтмиләр. Дөрес, күрсәтелгән мәкаләләрнең беришесе Исхакый—Тукай мөнәсәбәтен гомуми соклану рухында кабул итү сәбәпле бер-берсен кабатлыйлар, гомуми мәгълүмат бирүдән узмыйлар. Бу ике даһи арасындагы бәйләнешләрне гадиләштереп, идиллик

Тәлгат ГАЛИУЛЛИН (1938)—*танылган язучы һәм әдәбият галиме, филология фәннәре докторы. Күп санлы проза һәм әдәби тәнкыйть китаплары авторы. Казанда яши.*

анлау һәм анлату очраклары да булды.

Таләпчән һәм туры холкына, кырыс һәм нәзберек рухына теләсә кемне якын китермәсә дә, Тукай үзенең Ф. Әмирхан, С. Сүнчәләй, С. Рәмиев, Г. Камал кебек талантлы чордашлары белән даими аралашып, очрашып, һич югында хат алышып яшәгән. Безнең чорга килеп житкән мәгълүматларга таянып фикер йөрткәндә, Исхакыйны ифрат ихтирам итеп, бер мәлне аның идеалларына табынып яшәсә дә, Тукай кумиры белән очрашу бәхетенә ирешә алмый. Мәгәр төрле "жәгърәфи киңлекләрдә" яшәсәләр дә, XX гасыр башы мәдәниятенең бу ике бөеге матбугат чаралары аша гына аралашып та бер-берсен һәр тарафтан иждади баетып, эзләнүләренә, ижатларына куәт биреп торганнар һәм милли тәрәккыятьнең символлары дәрәжәсенә күтәрелгәннәр.

Көрешә алмауларына житди сәбәпләр дә туа торган шул. 1907 елның көзендә "Пар ат"ына утырып Казанга килгәнче, Тукай Жаек (Уральск) шәһәрендә яши. Яшь шагыйрь дәртле, моңлы, нурлы Казанны "яулап алган", халкын назлы, моңлы шигърияте белән әсир иткән һәм гомумән ижаты чәчәк аткан, дан үренә күтәрелгән 1907-1913 елларда исә тынгы белмәс Исхакыйны язмыш йомычкадай бөтереп ала да, Чистай, Казан төрмәләре шулпасын татыткач, милләтенә башка халыклар белән тигез хокук, матбугат азатлыгы таләп иткән өчен кар-буранлы, салкын кышлы Архангелск губернасына ике тапкыр сөргенгә жибәрә. Әмма башбирмәс холыклы Гаяз, үзенә юлдашлар табып, аннан кача һәм шул чорда (1908-1909, 1910-1911) ике тапкыр Төркиядә яшәп ала. Илгә кайткач та полиция эзәрлекләвеннән качып яшәргә мәжбүр була. Романовлар патшалыгының 300 еллыгы унаеннан амнистиягә эләккән вакыты Тукайның дәфен көненә туры килә .

Үзара бер кәлимә сүз алышу насыйп булмаса да, ниндидер илаһи, күкләрдән ингән көч бу ике олуг шәхесне бер-берсенә бик якын туганнардай, ахири дуслардай мәңгелеккә якынлаштырып куйган. Сере нәрсәдә? Биредә тышкы һәм эчке берничә сәбәп-шарт бар дип уйлыйм. Беренчедән, талантлы шәхесләрнең бер-берсенә тартылып торуы—табигый. Исхакый белән Тукай әдәбиятның төп ике жанрында (проза, поэзия) мәйдан тотып, лидерлык итеп, татар сүз сәнгатенең тутыкмас йөзек кашлары дәрәжәсенә күтәреләләр. Димәк ки, ижат кешеләре арасында була торган көндәшлек, көнчелек галәмәтләре аларны чәкештерә алмый. (Тукайга—Дәрдемәндне һәм С. Рәмиевне, Исхакыйга Г. Ибраһимовны каршы кую очракларын искә төшерик). Монысын тышкы сәбәп дип бәялик.

Икенчедән, милләткә мәхәббәт тудырган кыйбла уртаклыгы, иманга тугрылык, таләпчәнлек, "туры" Тукайлык, караш үткенлеге, татар мәнфәгатьләрен яклаудагы Исхакый үжәтлеге—бу ике олы шәхесне, очраша алмасалар да, һәрдаим бер-берсенә тартылып торган Сак белән Сок дәрәжәсенә житкереп якынлаштыра.

XX йөз башы даһилары әнә шундый—гадәти атамалар илә аңлатуы мөмкин булмаган эчке сиземләүләре белән—милләт каршындагы бөек миссияләрен аңлап, хыял-гамәлләрен тормышка ашыруда бер-берсенә терәк булырга тиешлекләрен эчке тоемнары белән сиземләгәннәр. Жөмләдән, ижатка Исхакыйдан аз гына соңрак килсә дә, Тукай өлкән каләмдәшенең ижтимагый-сәяси эзләнүләреннән хәбәрдар булып, аның һәр яңа әсәре белән танышып барырга тырыша. Исхакыйга милләтпәрвәр көрәшче данын, язучы шөһрәтен "Ике йөз елдан соң инкыйраз" публицистик-утопик повесте алып килә. Ерак Уральскида нәшер ителгән, Тукай шунда әдәби хезмәткәр вазифаларын үтәгән "Әлгасрел-жәдид" (Яңа гасыр) журналы бу әсәргә югары бәя бирә. Ул гына да түгел. Журнал үз битләрендә Гогольнең "Старосветские помещики" хикәясен (Исхакый бу әсәр персонажларының исемнәрен татарчалаштырып тәржемә итә) урнаштыра.

"Таң йолдызы" газетасы аша Тукай әдипнең дөньяга карашы, милләтне яклаган чыгышлары, гайрәтсезлеккә, гамьсезлеккә каршы көрәш алымнары белән даими танышып бара. Әмма "Таң"чылар сәясәтен нигездә хупласа да, Тукай уйламыйча, теләсә нинди идеягә кырмавык кебек ябыша торган, куштанлык дәрәжәсенә төшә торган зат түгел, аның һәр шәйгә үз бәясе, үз мөнәсәбәте бар.

"Таң"чылар мөкиббән киткән "социализм" идеясен Тукай "мөкатдәс мәзһәб" дип атый. Без "таң"чыларның (укы—Исхакыйның—Т. Г.) шул мәсләккә ияреп, татарларга: менә дөньяда шундый мәзһәб тә бар дигәннәренә рәхмәт укыйбыз". Әмма Тукай социализм турындагы тәгълиматка сукырларча иярүгә каршы. Аерым алганда, ул татар халкына белем, мәгърифәт Исхакый "таң"чылык чорында мөкиббән китеп йөргән социализм идеясеннән кирәклерәк, файдалырак дигән фикердә тора. Татар халкын азатлык, бәйсезлек, коллык психологиясеннән арындыру юлына белемнең, югары дәрәҗәдәге мәгарифнең генә алып чыгасына ул ихластан ышана. Яшь Тукай—югары

кимәлдәге мәгърифәтче.

Социализм нәзариятен милләтебезгә тәкъдим итүнең иртәрәк икәнлеген Тукай, икеләнүгә урын калдырмыйча, чагыштыру-метафораларны мул кулланып, ачык аңлатып бирә. "Социализм никадәр мөкаддәс булса да, уку вә укытудан алда түгел... (курсив безнеке—Т. Г.) Без надан көенчә социалист булып мәйданга чыксак, койрыгына тутый кош җоннары кыстырган ала карга төсле, бөтен дөньяны көлдерербез... Хуҗа Насретдин шикелле, атның артына карап атланмыйк" .

Соңрак та Тукай Исхакый иҗатын, аның иҗтимагый-сәяси эшчәнлеген күз уңыннан төшерми. Үзе шикелле үк милли рухлы, гысъян холыклы бу көрәшче шәхес турында уйлануларын, бәясен, фикерләренә теләктәшлеген җәмәгатьчелеккә җиткерүнең иң үтемле алымы шигъри әсәр икәнлекне Тукай аңлап эш итә.

Шул чорда исән-имин шәхесләрдән Тукайның җылы шигъри сүзенә бары тик Гаяз Исхакый гына лаек дисәк тә зур хата булмастыр. Еракгагы якын фикердәше Исхакыйның иҗтимагый эшчәнлеге Тукайны күк йөзендәге якты йолдыз кебек үзенә тартып тора. Ул Гаяз әфәнденең халыкны агарту, милли сәясәтне төрле катлам кешеләренә җиткерү юнәлешендәге үҗәтлеген хуплап 1907 елда бер-бер артлы диярлек ике шигырь язып чыга: "Тавыш хакында" һәм "Кем ул?"

Патша цензурасы Исхакыйның "Таң йолдызы" гәзитәсен япкач, ана алмашка "Тавыш" нәшер ителә башлый. Яңа басманың да сәяси мәсләген Исхакый һәм аның даирәсе билгели. Гәзитәнең чыгуын тантаналы рәвештә яклап һәм хуплап яшь Тукай кайнап торган вулкан шикелле күтәрелә:

*Эшчеләр! Шатлык сезгә: чыкты "Тавыш",*
*Авыш, эшче! Бу "Тавыш"ка табан авыш.*
*"Таң"нан ятим булып калган бичаралар,*
*"Таң" урынына инде "Тавыш" белән таныш.*

("Тавыш" хакында. 1907).

Эшчеләргә мөрәҗәгать итеп язылган шигыренә Тукай гарәп-фарсы, төрки алынмаларын кертмичә, катлаулы метафоралар эзләп баш ватмыйча, "Тартыш, эшче! Тартыш, зинһар, тартыш, тартыш!" дип саф татар теленә, публицистик өслүбкә өстенлек бирә.

Шул ук 1907 елда иҗат ителгән һәм Тукайның совет чорында чыккан җыентыкларына кертелмичә килгән "Кем ул?" шигыре, әйтерсең лә, бөтенләй башка каләмнән төшкән:

*Бәһаимнән безе тәхриф идән кем?*
*Төбеннән вәхшәте тәгърйф идән кем?.—*
*(Безне хайваннардан аерган кем?*
*Вәхшәт төбеннән аерып алган кем?)*

Алдагы юлларда "Таң", "Инкыйраз" мисле нәкъ Исхакыйга нисбәтән генә әйтелә алган атамаларга юлыккач, сүзнең кем, нәрсә турында барганлыгын аңлыйсың. "Әлгасрел-җәдид" журналының 5нче санында нәшер ителгән бу шигырь композиция һәм кафия (рифма) хасиятләре белән шактый үзенчәлекле әсәр. Ундүрт юлдан торуы, кафияләшү үзенчәлеге, ягъни төзелеше белән сонетны хәтерләткән "Кем ул?" шигыре лирик геройны сәләтен, рухи куәсен халык мәнфәгатьләрен яклауга багышлаган мөрәүвәтле зат итеп сурәтли. Беренче ике юлда кәс (кеше) белән сәсне (аваз) рифмалаштырса, алдагы уникe юлда фонетик аһәңдәшлекне мәгънәви ачкыч ролен үтәгән "кем" сүзенә йөкли. "Кем ул?" соравына беренче юлда "Кеше" (кәс) дип үзе үк җавап бирсә дә, "Кеше" бит әле җир йөзендә яшәүче барча адәми затларга ачыкламыш бирүче, һәммәбезгә карата әйтелә торган нисби төшенчә. Алдагы юлларда автор үзе үк каһарманының "кем"леген тәфсилле аңлатып бирә. Ул—хәсрәтле милләтен зыялы, белемле юлга чыгару өчен җан атып йөргән, татарны башын югары тотып, мескенләнмичә, кемгәдер тез чүкмичә яшәргә өйрәтүче олы шәхес икән. "Кем ул?" тарих тарафыннан рәнҗетелгән татар өммәтенен халыклар харитәсендә үзенә лаеклы урынын даулап йөргән көрәшчене мөнбәргә күтәргән шигырь.

"Кем ул?" шигыренең журналда басылган нөсхәсенең астына "Соңы бар" дип язылса да, дәвамы язылмый кала .

Дөрес, 1913 елда Тукай уникe юлдан торган, гарәп-фарсы, төрек лөгатьләреннән алынмаларны мул кулланган, димәк ки, зыялы укучыны күздә тотып язылган

"Мөхәррирргә" (Мәктәп, 1913, № 3) исемле шигырен бастыра. Юрама рәвешендә генә бу әсәр вәгъдә ителгән "Кем ул?"нын дәвамы түгелме икән дигән сорауны калкытып куясы килә. "Мөхәррирргә" астына ачыкламыш итеп "кыйтга" (кисәк, өлеш) сүзе куелган. Ижек саннары да, тоташ рифмалаштыру алымы да, миллилекне алгы нәүбәткә чыгарып кую да ике шигырь өчен уртак. "Мөхәррирргә" шигыре язылган чорда Исхакый ижтимагый-сәяси, журналистлык эшеннән читләштерелгән була. Архангельск губернасынын Мезень шәһәрендә утырган тоткын язучыга аны туган илендә онытмаулары үзенә бер юаныч та, шатлык та булгандыр әле.

Шигырен хисси риторик эндәш белән башлап җибәргәч ("И мөхәррир!"), Тукай бу затнын атаклы сүз остасы, әсәрләре белән шөһрәткә, данга лаеклы зат икәнне искәртә. Алдагы юлларда мәшһүр шәхеснен каядыр еракта, туып-үскән җиреннән читтә яшәргә мәҗбүр булуы ачыклана. Ватанга кайту анардан гына тормаганын белсә дә, шул ук риторик мөрәҗәгать алымы белән шагыйрь үзенен күнеленнән ургылып чыккан катгый үтенечен алга чыгара: "Кайт әле монда ватанга, кайт әле, саргайтмәле?" Иленә чакырылган мөхәррир алдында шагыйрь "хисап" тота. Синнән башка татар җәмгыяте "Алты ел торды чупансыз (житәкчесез, көтүчесез), айрылышты яшь көтү, Карт бүре күк, бары корган аерым-аерым бер оя" дип, кешеләр арасындагы мөнәсәбәттә зыялылыкны—сәүдәгәрлек, намусны икейөзлелек алыштыруы, сүзләрнен, атамаларнын мәгънәләре начар якка үзгәрүе хакында бәян итә. Синен "пакь вә чын сүз"еннән, "Күз карашыннан керер җир тапмас"лар иде гамьсезләр, надан әрсезләр, ди шагыйрь үрсәләнеп.

Шигъри кичереш үзәгенә алынган шәхесне автор авыр, буталчык заманда таянырга, хакыйкатьне якларга лаеклы, абруй "кәс" дип саный. Түбәндәге юллар бу фикернен дөреслеген шик астына алырга юл калдырмас кебек. "Бер карашын ин шома ялганчыны сүздән тыя..." Тукай аны Мөхәммәд Рәсүлнен фикердәше, сәхабәсе Гомәр батыр белән янәшә куя. Дини риваять каһарманы динсезләрне, сатлык җаннарны, шайтаннарны дер селкетеп, куркытып торган. Хәзерге көндә татар җәмгыятенә милли мәнфәгатьләр өчен көрәшүче кыю фидакарь затлар җитешми. Исхакый кебек милләтпәрвар шәхесләргә ихтыяҗ һәр чорда да зур була.

"Даһигә" (1913) шигырендә Тукай халыкнын киләчәге турында борчылып яшәгән камил инсан образын сурәтли. Ул салкын алтын яктысына, башка ымсындыргыч җимнәргә алданып, якты идеалыннан чигенми, гел алга бара. Күпмәгънәле фәлсәфи "Даһигә" әсәре кайбер мәгънәви, сәнгати нокталарда "Мөхәррирргә" шигыре белән дә аваздаш. Бу әсәрен иҗат иткәндә дә Тукай Мәрҗани, Исхакый кебек бөек шәхесләребезне күз унында, идеалында тоткан булуы бәхәссез.

Бер яктан, мәдхия жанрынын ин гүзәл үрнәкләреннән берсе булган "Даһигә" шигырендә милли ялкын югары ноктасына күтәрелә. Икенчедән, автор зиһен көченә, мәгърифәткә таянып, үзен халыкка хезмәткә багышлаган, якты идеалны Аллада тапкан, эшлекле, акыллы, югары ихтыяр көченә ия затны эзли. Тукай суфыйчылыкнын канатсыз идеалыннан арына килеп, тормышчан позициядә торучы шәхесне күтәрә.

Шул рәвешле, Тукай кыска гына иҗат дәверендә Исхакыйнын милләтне саклап калу, үстерү юнәлешендә алып барган колачлы эшчәнлеге белән даими кызыксынып, унай мөнәсәбәтен матбугатта белдерә бара, ана берничә шигъри энҗесен багышлый. Кунак ашы кара-каршы дигәндәй, "олуг прозаикнын, мөхәррирнен татар шигъриятен сәнгать дәрәҗәсенә күтәргән, халыкнын җан авазы булган Тукайга, анын иҗатына мөнәсәбәте ничегрәк булды икән" дигән сораулнен тууы табигый.

Исхакыйнын яшь шагыйрь иҗатына биргән тәүге бәяләренен берсен 1910 елда татар әдәбияты турындагы Төркиядә укылган докладтан табабыз. Сөргеннән качып, кардәш илгә килеп сыенган Гаяз бу нотыгын "Төрек дөрнәге"ндә (оешмасында) ясый. "Бүген тезмә әсәр язганнарымыз, ягъни үзенә генә хас булган фикерле шагыйрьләремез бардыр, ләкин аларнын ин алдынгы карашлысы, һич шөбһәсез, Габдулла әфәнде Тукаев исемле егерме-егерме бер яшьләрендәге бер яшь егеттер. Тукаевтан сонрак Сәгыйть Рәмиев, Дәрдеменд кушаматы артына яшеренгән хөрмәтле вә шактый яшь бер зат илә Габделмәҗит Гафури, Нәҗип Думави, Укмасый, Бәшири кебек яшьләр килә... Шагыйрьләремезнен ин бөеге авыл баласы Габдулла Тукаевтыр. Бу авыл малае бишалты ел эчендә милләтемезгә кочак-кочак шигырь чәчәкләре таратты, әдәбиятымызнын шигырь нигезен корды... Ул халыкнын бетмәс-төкәнмәс бер хәзинәсе булган телен бик яхшы белә һәм аннан шундый җәүһәрләр табып чыгара ки—бөтен күзләр камаша".

Шунысы үзенчәлекле: Габдинен (Г. Ибраһимовнын тәхәллүсе) "Татар матбугаты" (1910) мәкаләсендә әдәбиятнын төп көчләренә биргән бәясе Исхакый фикеренә аһәндәш. "Хасил: татар шигыре мәйданында Тукаев исә, тасвирымыз мәйданында ин югары ноктада Гаяз әфәндедер". Бик кызганыч: 1913 елда язылган "Татар

шагыйрьләре" хезмәтендә төрле сәбәпләр нәтиҗәсендә (күбрәк Тукайның "тырма" теле аркасында дип уйлыйм) Г. Ибраһимов бу фикерен үзгәртә.

Г. Исхакыйның Тукай иҗатына, тулаем әдәби барышка, XX гасыр башы сүз сәнгатендәге гомуми сыйфат сикерешенә бәясе белән килешкән тәкъдирдә, аның бер фикере сәерсенү катыш килешмәү хисе уята. "Әфәнделәр!—ди ул шул нотыгында,—шунысы дикъкатькә лаектыр ки, безнең шималь төркиләрендә башта проза әсәрләре мәйданга чыккан, тезмә әсәрләр исә бары тик биш-алты ел соңрак күренә башлаган". Бу ни дигән сүз? Мең еллык тарихы булган татар шигърияте казанышларын күрмәмешкә салышып, юри кимсетүме яисә үзе хезмәт иткән проза жанрының абруен күтәрүгә омтылумы? Бик борынгы ядкарьләрне уртак төрки әдәби кыйммәтләре дип санаган очракта да, аңлаешлы, саф татар телендә иҗат иткән Г. Кандалый, Я. Емельянов, Акмулла кебек бөекләребезне нинди чапан итәгенә яшерәсен? Исхакыйның һәр өлкәдәге абруен таныган, Тукайга биргән югары бәясе өчен рәхмәтле булган тәкъдирдә дә, татар шигъриятенә карата кимсетүле бәясе белән килешү мөмкин түгел. Күфер фикер булса да, бу очракта Исхакыйны сүз сәнгатебезнең олы тарихын белмәүдә, наданлыкта гаеплисе килә. Докладның укылу вакыты галимнәр арасында фикер төрлелеге тудыра. Профессор И. Нуруллин белән Һ. Мәхмүтов чыгыш ясалу чоры итеп 1912-1913 елны күрсәтәләр. Мәкаләне игътибар белән укысаң, мондый бәхәсләргә урын да калмый кебек, безгә мәгълүм чыганакларда күрсәтелгән 1910 ел дөреслеккә килә. Исхакый чыгышында Тукай егерме-егерме бер яшьлек шагыйрь буларак тәкъдим ителә. Тукай белән С. Рәмиев иҗатларыннан китерелгән шигъри үрнәкләр һәммәсе 1910 елга чаклы иҗат ителгән әсәрләрдән. *("Шүрәле", 1908; "Шагыйрь", 1908).* Исхакыйның башка чыгышларында, тәнкыйди-публицистик мәкаләләрендә Тукай исеме, димәк ки, шигърият проблемалары телгә алынмый диярлек.

1913 елда бөек шагыйрь Газраил белән бил алышканда, Исхакый патша амнистиясен көтеп, Төркиядә качып ята. Тукайның вафаты турындагы хәбәр аны тетрәндереп, йокысыннан уятып җибәргәндәй була. "Кояш" гәзитәсендә басылган телеграммасы шуңа дәлил: "Олуг шагыйрь Тукаевның вафаты сәбәпле тирән кайгыга төшкәнем хәлдә, күп хәсрәтләр күргән халкымны саф күңелем белән тәгъзия (сабыр итәргә) кылам". *(1913, 8 апрель).*

Күңеле тынычлыгын югалтып, җаны бәргәләнсә дә, Тукайның үзенә һәм мирасына мөнәсәбәтен белдерү, бәясен бирү өчен, зур әйбер ерактан яхшырак күренә дигәндәй, вакыт аралыгы кирәк була. Кеше гомеренең кадерен белгән реалист Исхакыйга балавыз сыгып, кул салындырып утыру чит нәрсә. Иманы камил: Тукай олы талантына лаеклы бәясен, татар әдәбияты тарихында тәгаен урынын алырга тиеш. Үз чорында ук танылган шагыйрьнең үлеменә бер ел тулганда Г. Исхакый фәнни һәм хисси күзаллавына, аңлавына күңел сыкравын кушып, Тукай һәм аның мирасы турында уйлануларын кәгазьгә төшерә башлый һәм тирән эчтәлекле, дөрләп янган йөрәгеннән өзелеп төшкән язмаларын бер-бер артлы татар җәмәгатьчелегенә ирештерә. "Петербург, 29 март" мәкаләсен ("Ил"—1914, 29 март) язуга аны буйсындырылган милләтләргә нисбәтән эшләнгән иҗтимагый гаделсезлек этәрә. Исхакый бу чыгышында халык хокукларын теше-тырнагы белән яклауга күтәрелгән арысланны хәтерләтә. Хикмәт шунда: Рәсәй башкаласы татарлары Тукайның еллыгын лекцияләр укып, һәйкәл кую нияте белән акчалар җыеп, зурлап уздыру хыялы белән янып йөриләр, әмма татарча сөйләшүләрне тикшереп торучы булмауны (милли телне белүчеләр арасында әләкче шымчы таба алмаганнар дип аңла!) сәбәп итеп, граданачальник бу җыелышны тыя. Казан хакимияте дә Петербург түрәсеннән калышмый, "Тукай җәмгыяте"н оештыруга рөхсәт бирми. Петербург татарларының изге ниятен яклап, Исхакый саллы дәлилләрен китерә. "Алланың биргән көнендә латыш, эстон, әрмән, грузин вә яһүдиләр үз телләрендә лекция, моназарәләр (бәхәс, дискуссия) ясап торганда без бердәнбер шагыйребезне (курсив минеке,—Т. Г.) хөрмәтләр өчен генә дә лекция ясарга хакыбыз юкмыни?" Тукай истәлеген, мирасын олылауга, пропагандалауга юл куймаучылар, Исхакый фикеренчә, зур хата кылалар, "язгы суга буа тоттырып булмаган кебек, уянган халыкка каршы да киртә салып булмыйдыр. Тукай бар иде. Тукай бар.

Һәр үткән көн, һәр мәдәни атланган адым Тукайны зур итәчәк, үстерәчәк кенәдер". Халык йөрәгендә асыл затларның берсе булып кадерләп йөртелгән шагыйрьне олылауны берәүнең дә тыярга хакы юк дигән фикер уздыра автор.

1914 елның апрелендә Исхакый, Тукай истәлеген яд итеп, житди уйланылган, хәзергәчә әһәмиятен җуймаган ике мәкаләсен бастыра: "Милли фаҗига", баш мәкалә *("Ил"—1914, 2 апрель № 23)* һәм "Тукай мәктәптә" *("Мәктәп"—1914, № 6, 10 апрель).*

Илаһи тылсым, фикер һәм сүз куәсе, халыкка хезмәт итү рухы шагыйрьгә табигатьтән, тумыштан бирелү турында фәлсәфи, әхлакый уйланулардан соң (алдарак әйтеләсе төп фикере дәлилле булсын дип Исхакый колачны киң алып, сүзне ерактан башларга ярата), әдип Идел буенда туып-үскән Габдулла исемле шагыйрь шәхесен тасвирлауга күчә. Тукайны ул югары сыйфатлы, халык, чынбарлык эшкәрткән алмазга тинли, аны олы йөрәкле, үз чоры мохитеннән кыя төсле күтәрелеп торган самими каләм һәм акыл иясе, исән чакта ук үлемсезлек бусагасын үткән халыкчан шагыйрь дип олылый. Исхакый фикеренчә, татарның фаҗигале тарихы, артта калган иҗтимагый фикере Тукайның тагын да югарырак күтәрелүенә киртә булып тора. Дөрес, ул берәүне дә гаепләми. Әмма сорауларның уйландыра, сискәндерә торганнарын калкытып куя. "Татар милләте табигатьнең шул зур куәтеннән кирәк кадәре файдалана алдымы? Татарның аңлы кыйсьме (өлеше) аның зур көчен әрәм итмәдеме, исрафка сарыф итмәдеме?" кебек четерекле, үкенечле сорауларына үзе үк җавабын да тота. "Бу фаҗигадә гаеп кенә бар, гаепле юк. Гаепле булса—татарның бөтен тормышы, бөтен тормышының китеше... Иске гаепләремез өчен тарихның безнең янакка ялтыратуыдыр".

Исхакыйның сүз сөрешеннән аңлашылганча, автор һәр укучыда үзен гаепле санау хисен уятуга, сагыш хисенә, ягъни экзистенциаль башлангычка өстенлек бирә. Ошбу мәкаләсендә Исхакый шагыйрьнең милләт язмышында тоткан урынын, халыкчанлыгын, бөеклеген үтемле һәм калку итеп күрсәтүгә ирешә. "Тукай безнең күңелебездән чыкмыйча, безнең шатлыгыбыз белән сөенеп, безнең белән бергә барырга тиештер". Исхакыйның һәр сүзе җылы һәм хисле, тере һәм туры, шигырьгә битараф татарны да уйландыра торган тирән кичерешле.

Исеме үк җисеменә ишарә ясаганча, "Тукай мәктәптә" мәкаләсендә шагыйрь иҗатын уку йортларында өйрәнү мәсьәләләре калкытып куела.

Исхакыйның бу чыгышы мәктәптә әдәбиятны фән буларак өйрәнүнең методологик әсасларына (нигезләренә) кагыла; әдәби әсәрнең яшь буынны тормышка кертүгә өйрәтүдәге, әдәп-әхлак кагыйдәләрен, халыкның гореф-гадәтләрен саклаудагы һәм, иң мөһиме, милли лек тәрбияләүдәге бәяләп бетергесез әһәмияте турында әдип үзәккә төшеп, төпле итеп яза. Әдәбият аша "милли рухның иң кирәклеләрен кадаклыйбыз. Аны мәңгегә татар итеп куябыз. Әдәбияттан башка милли бер нигезне дә кора алмыйбыз".

Татар әдәбияты йогынтысында үскән бала рухани яктан баерак, өметлерәк, милли җанлы булу өстенә, акыллырак та булачак, ди Исхакый. Сәбәбен дә ачып бирә. Ихласи шигъри аваз—яшәеш һәм табигать тудырган иң көчле, иң саф рухи эшчәнлек сөземтәсе. Төпле фәлсәфи фаразлар белән әйтәсе шундый фикеренә күпер салганнан соң, автор Тукай иҗаты кырына килә, иң әүвәл аның татар шигърияте бирә алган иң халыкчан һәм табигый сәләткә ия шагыйрь булуын искә төшерә. Бу асыл сыйфатлары Тукайның нәрсәне мөкиббән китеп ятратканын һәм нәрсәне яратмаганын кистереп әйтә белү, табигый нәфислеккә тиң сурәтләр тудыра алуы нәтиҗәсе икән.

Миллилек белән бергә матурлыкны, табигатьне аңлау хисе балага Тукайның "Шүрәле", "Су анасы", "Мияубикә" әсәрләре аша инсә, тормышның ачысын-төчесен татып, аның катлаулылыгын, иҗтимагый тигезсезлеген аңлау дәрәҗәсенә күтәрелү юлында бөек шагыйребезнең "Сөялгәнсең баганага", "Ишеттем мин берәү җырлый", "Кичке азан" шигырьләре рухи таяныч булыр, ди Исхакый.

Мәгълүм булганча, Тукай әдәбият дәреслекләре төзегәндә аларның бала күңеленә гүзәллекне сеңдерү, югары әхлак кагыйдәләрен өйрәтү, милләткә мәхәббәт тәрбияләү максатына җавап бирүен үзәккә куйган. Исхакый фикеренчә, халык шагыйренең үз иҗаты да менә шундый олы таләпләргә хезмәт итә.

Мәкалә авторының төп нәтиҗәсе дә ике төрле фикер йөртүгә , бәхәскә урын калдырмый: "Тукай халык шагыйре булып туды, халык шагыйре булып үсте, Тукай халык шагыйре булып авыллардагы картлар, яшьләрнең күңелендә сакланырга тиештер".

Тукай кебек даһи затны рәтле тормыш шартлары тудырып саклый алмаган өчен җәмгыятькә, мохиткә, хәлле татар кешеләренә, назыннан мәхрүм иткән өчен хатын-кызга үпкәсе җанлы җеп кебек Исхакыйның бер мәкаләсеннән икенчесенә сузыла. Рәнҗү хисе "Тукай мәрхүм" ("Ил"—1915, 28 март) мәкаләсенең мәгънәви-фәлсәфи юнәлешен, кичереш үзәген тәшкил итә дисәк тә, хата түгелдер. Бу язмасы Исхакыйның рухи дөньясына аеруча якын булгандыр дип уйларга нигез бар. Бер елдан соң аз гына стилистик үзгәртүләр кертеп, аерым алганда "мәрхүм" сүзен беренче итеп куеп, "Сүз" газитәсендә (1916—3 апрель, № 4) баш мәкалә итеп урнаштыра. Мәрхүм сүзен Тукай үзе дә Заһир Бигиевка багышланган мәрсиясендә кулланган иде. Бу мәгънәгә, күрәсең,

олы тарих белән чагыштырганда фани дөньяның бер көнлеген әрнетеп искә төшерү белән беррәттән, араларыннан киткән кешегә карата уңай мөнәсәбәтне (тыныч йокла, урының җәннәттә булсын) сиздерү төсмере дә салына торгандыр.

Тукайның арысланлыкка тиң каһарманлыгын яклап, шул ук вакытта исәннәрне сискәндерерлек, язмыш турында уйландырырлык мәкаләләрендә Исхакыйның шагыйрь исемен халык, милләт төшенчәләре белән янәшә куюында, тирән эчке мәгънә бар. "Тукай халык шагыйре булып туды, халык шагыйре булып үсте" фикерен мәкаләдән мәкаләгә кабатлап, ышанычын замандашлары, киләчәк буын күңеленә сеңдерү иде әдипнең теләге, изге нияте. Исхакый Тукайның югарыда телгә алынган шигырьләрендә З. Бигиев, Ш. Мәрҗани кебек олы затларга биргән бәяләрен турыдан-туры диярлек кабатлый. "Татар милләте яшәгәнгә кадәре Тукай яшәячәк". Шул ук рухта дәвам иткән фикере дә күңелгә ятышлы: "Тукай безнең олуг шагыйремез иде. Чүп өстенә үскән матур чәчәгемез иде... милли бер каһарманыбыз".

Шагыйрьнең вафатыннан соң Тукай мәхәббәте, гомумән аның асыл затлардан читләшүе, өйләнүгә мөнәсәбәте (дөрес, үзе дә дусларына язган хатларында буш тел шартлатуларга урын калдыра) тирәсендә гайбәтләр, фаразлар, уйдырмалар чүпрәле камыр кебек кабара. Аерым алганда, шул чорның урта кул шагыйре, журналист Жамалетдин Юмаев үзен Тукайның якын дусты дип тәкъдим итеп, "Сөембикә" журналында бастырган "Яшерен мәхәббәт" исемле зыялылыктан ерак торган, арзанлы сенсациягә корылган мәкаләсендә Тукайны мәхәббәтеннән, гомумән хатын-кыздан куркып, качып яшәгән мәхлук итеп сурәтли. "Тукай мәхәббәте" ("Ил"—1914, 2 сентябрь) исемле язмасын Исхакый Ж. Юмаев мәкаләсенә җавап буларак язуын искәртә. "Яшерен мәхәббәт"нең "басылганына, укылганына шактый вакыт үтсә дә, мәкаләнең калдырган начар тәэсире онытыла төшсә дә, кирәк, мәрхүм шагыйремезгә ихтирамнан вә, кирәк, хакыйкатьне ачар өчен, соң булса да, бу хакта язарга мәҗбүр булдым". Ул үзен шагыйрьнең мирасын гына түгел, ә шәхси тормышын да яман сүзләрдән, пычратулардан сакларга, арындырырга тиешле җаваплы шәхес итеп күрә, каләмдәшенең йөз суын, намусын, бөтенлеген яклап оран сала. Аның фикеренчә, Тукай мәхәббәте—гамьсез кешеләр, сагыз чәйнәүчеләр аңламый торган михнәтле, үкенечле вә ак җилкән киергән романтик, эчкерсез, саф, җавапсыз сөю үрнәге. Тукай гыйшкы—Йосыф-Зөләйха, Таһир-Зөһрә, Ромео-Джульетталар арасындагы илаһи, фаҗигале мөнәсәбәт кебек мәңгелек белән бәйле торган олы, изге хис. "Тукай турында аз булса да шөбһә белдерү зарардыр". Чөнки Тукайның мәхәббәте "Шагыйрьне нечкә шигырьләр сөйләргә мәҗбүр иткән яну-көюдер". Ике яшь йөрәк арасындагы үзләре дә аңлап, сиземләп бетерә алмаган тартылу тойгысы татар шигъриятен, гашыйклар үзләре шикелле үк, мәңге яшь, нәзакәтле, натуралистик ваклыклардан азат мәхәббәт гөләндәме белән баета. Серен, тылсымын ахыргача ачып житкермәгән Тукай мәхәббәте Р. Харисны "Шагыйрь мәхәббәте" исемле опера либреттосы язуга рухландырды.

Исхакыйның бу мәкаләсе турында галимнәр шактый тәфсилле һәм сокланып яздылар. Янәдән ике сыйфатка игътибар юнәлтәсе килә. Тукай яшерен гыйшык тотып йөргән кызның киләчәк тормышын истә тотып, Исхакый үз мәкаләсендә аның исемен дә, кем икәнлеген, нәсел-нәсәбен дә телгә алмый. Кызны аклаган дәлилләре нигезле. Шагыйрьнең әүвәл күзе, аннан серле мәхәббәт ялкыны төшкән кыз бик яшь була һәм Тукай белән якыннан танышкан тәкъдирдә дә аның нинди бөек шагыйрь һәм намуслы шәхес икәнен дә, сөю сулышын да тиешенчә бәяли алырлык дәрәҗәдә булмый. "Тагы иң иң әһәмиятлесе: мәгълүм туташ Габдулла сөйгән вакытта 15-16 яшьлек бер кыз булганга, Габдулланы аңламавы табигыйдер. Аның Габдулланың үзен сөюен белмәве дә бик ышанычлыдыр". Тукай үзе турында гына уйлап, кызга мәхәббәтен сиздерсә, итагатьле, зыялы гаиләдә тәрбия алган бала "Габдулланы сөймәсә Габдулланың тормышын матурлатыр өчен генә үзен-үзе фида кылырлык дәрәҗәдә галиҗәнаблеген белгән".

Мәхәббәте ничек кенә көчле булмасын, Тукай үзен-үзе "тәкъдим итү", кызны эзәрлекләү, басым ясау кебек арзанлы юлга басмый, яшерен мәхәббәте төшкән затның намусын саклау бәрабәренә хисләрен йөгәнли, йозакка "утырта".

Икенчедән, Исхакый Ж.Юмаевның кызны "байлыкка", "солидный кавалерга" кызыга торган җилбәзәк итеп күрсәтергә тырышуын уйдырма фараз дип кискен кире кага, Тукай сөюендә дә "яшь буыныбыз өчен милли каһарманыбыз" булып калырга тиеш дигән фикеренә басым ясый.

Һәр мәкаләсендәге шикелле биредә дә Исхакый шагыйрьнең халыкчан моң саркып, нур сирпеп торган кичерешләренә мөнәсәбәтенең искиткеч ихлас, табигый булуын һәр юлыннан, җөмләсеннән сиздереп бара. Ясалмалыкның, көчәнеп мактауның эзе дә юк.

Исхакыйның югарыда каралган мәкаләләре Тукай шәхесенең ("Тукай мәхәббәте"), иҗатының ("Тукай мәктәптә") берәр үзенчәлеген, юнәлешен үзәккә алсалар, сонрак язылган "Мәрхүм Тукай" (Баш мәкалә) ("Сүз"—1916—3 апрель, № 4) язмасында шагыйрьнең татар мәгърифәтендә, сүз сәнгате үсешендә тоткан урынын билгеләүдә татар халкын милләт буларак саклау юнәлешендәге эшчәнлеген бәяләүдә киң гомумиләштерү юлына чыга. Татар дөньясы үсешенең иң авыр,катлаулы (реакция еллары күздә тотыла) чорында "татар шигыре Тукайсыз, милли Тукайсыз калды. Ниһаять татарның мәдәни, иҗтимагый хәрәкәтләрендәге мәтәлүләр, асты өскә килүләр... Тукайның кискен сатирасы, пак күңеленнән ятим булып барды".

Исхакыйның Тукай намена, шигъриятенә багышланган мәкаләләре гади публицистик яисә кизү (дежур) чыгышлар гына түгел. Һәркайсы үзәккә бер теманы, проблеманы алса да, Тукайның бөеклеген, халыкчанлыгын, миллилеген, гомумкешелек идеалларын кире какмавын, шигъри даһилек янәшәсендә калыккан шәхси бәхетсезлеген алга чыгарган, мәкаләдән мәкаләгә күчә килгән уртак мотивлар аларны бер бөтен әсәр—эссе дип карарга мөмкинлек бирәләр.

Исхакый шагыйрь шәхесен иҗаты белән бердәмлектә өйрәнеп, янәшә куеп, шигъриятенең тетрәндерерлек, сискәндерерлек кичереш дөньясына, тел-өслүб үзенчәлекләренә үтеп керә, аз сүз белән тирән мәгънә, җанлы образ, рухи халәт тудыруга ирешә.

Тукай кебек асыл шәхес һәм сүз остасы турында истәлек-хатирәләрне, фәнни уйлануларны коры, ярлы тел, битараф лексика белән язуның муафикъ булмавын Исхакый аңлап иҗат итә. Һәр җөмләсенең үтемле һәм образлы булуына омтыла. Олуг әдипнең үзе турында язган мәкаләләрен укый алса, Тукай кулларын чәбәкләп, "Гаяз әфәнде шагыйрьдер һәм галимдер" дип куяр иде. Әдип Тукай иҗатында миллилек белән сурәтлелек, образлылык белән халыкчанлык арасында эчке, аерылмас бердәмлек үрнәге күрә. Бәяләрендә кабатланмаска тырыша. Бер мәкаләсендә каләме мәҗүси моңга манчылып, экзистенциональ башлангыч, сагыш, хис "бәйдән" ычкынса ("Петербург, 29 март, "Милли фаҗига"), кичереш агышы өстенлек итсә ("Тукай мәхәббәте"), икенчесендә психологик анализ, әдәп-әхлак кагыйдәләренә, психологик анализга таянган реалист, аналитик фикерле аек фәнни акыл алгы нәүбәткә чыга ("Тукай мәктәптә").

Исхакыйның берсе икенчесен тулыландыра килгән мәкаләләрендә "эшкә җигелгән" барча әдәби, публицистик чаралар татар шигъриятенең алтын баганасы—Тукай образын якты, күркәм шәхес итеп сурәтләү максатына багышланганнар.

Исхакыйның тынгысыз рухлы, хаксызлыкны, ялганны, битарафлыкны җаны-тәне белән кабул итми торган полемик шәхес икәнлеген бер мизгелгә дә истән чыгарырга ярамый. Аның өчен Тукайның һәр сүзе—изге дога, һәр фикере камил. Шуңа укучыны ышандыру юлында әдип ачык чагыштыруларны кулланудан да, югары өслүб алымнарыннан, кыска, хисси сыйдырышлы җөмләләрдән дә, кабатлау ысулыннан да баш тартмый: "Тукай бар иде. Тукай бар. Тукай яши. Тукай яшәячәк".

Үзеннән тормаган иҗтимагый-сәяси сәбәпләр нәтиҗәсендә Исхакый гомеренең зур өлешен туган иленнән читтә, мөһаҗирлектә яшәргә мәҗбүр булса да, Тукайны бервакытта да күңеленнән чыгармаган, чыгышларында аның бөеклеген, миллилеген һәрдаим искә төшереп торган. Аерым алганда, әдипнең "Петербург, 29 март" мәкаләсен Тукай үлеменә 20 ел тулу көненә туры китереп, "Яңа юл" (1933—4 сан) журналында бастырып чыгаруы мәгълүм (Бу хакта проф. И. Нуруллин язып чыкты).

Шул рәвешле, Исхакый Тукай намена, мирасына багышланган мәкаләләр бәйләмендә шагыйрь иҗатының халыкчанлыгын, үлемсезлеген искәртүдән туймыйча, аны милләтнең таянычы, намусы, вөҗданы, җан авазы, юл күрсәтүче якты йолдызы итеп сурәтли, үзен дә шигъриятне йөрәге, җаны белән тирәнтен сиземләүче шәхес буларак таныта. Иҗаты, милләт мәнфәгатьләре белән яшәве җәһәтеннән Тукай бөеклегендә торган Исхакыйның XX гасыр әдәби барышына, шул исәптән шигъриятенә, йогынтысы елдан-ел үсә баруы сизелә. Сүземез шул хакта.

Исхакый үзен татар әдәбияты үсеше өчен җаваплы кешеләрнең берсе дип санаган. Шуңа да ул тезмә сүз сәнгате хәрәкәтенә вәкари ваемсызлык белән карап, бармакларын җилет кесәсенә тыгып, балалар уенын күзәткәндәй битараф була алмаган. Татар шигъриятенең сыйфат дилбегәсе туры Тукай кулында чакта ул жанр үсешенә гомуми бәя бирү белән генә канәгатьләнгән. Агымдагы поэзиягә мөнәсәбәтен 1910 елда Төркиядә "Төрек дәрнәге"ндә ясаган чыгышында ачып бирүен искәрткән идек. Тукай иҗатына югары бәясен ул беркайчан да, шул исәптән мөһаҗирлек чорында

да, үзгәртми, үз ышанычында, иманында ахыргача тора. 1913 елда бөек шагыйребез фани дөньяны ташлагач, Исхакый аерым бер үҗәтлек илә аның мирасын өйрәнүгә күч кую белән беррәттән, үзен татар поэзиясе үсеше өчен дә җаваплы кеше итеп сизә кебек. Күп язмый, әмма төпле һәм нигезле итеп, сүзен сеңдереп әйтә. Бу очракта аның "Шигырь күп—шагыйрь юк" (*"Ил".—1914, 22 февраль.—№ 17)* һәм "Бер азах" (аңлатма) (*"Кояш".—1915, 13 октябрь.—№ 819)* исемле мәкаләләрен күздә тотам. Шулар буенча гына да кырыс һәм мәрхәмәтле Исхакыйны танып, аны шул исәптән татар поэзиясенең, Тукай аны "Мөхәрриргә" шигырендә атаганча, яхшы мәгънәсендәге "чапанчысы" (көтүчесе), сакчысы дип олыларга була.

Усал, тырма төсле ачы телле "Шигырь күп—шагыйрь юк" мәкаләсен Исхакый фельетоннар бүлегендә бастыра һәм максаты итеп "Ил" гәзитәсенә килгән шигырьләрне анализлауны гына калкытып куйса да, әдип татар поэзиясе үсешенә кагылышлы гомумирәк фикерләрен дә укучы колагына житкерү жаен таба.

Фәлсәфи-әхлакый уйлануларын эченә алган тәнкыйди нотыгын ул газиз милләтенә тап төшерергә яратучылар белән бәхәстән башлый. "Безнең халыкны юкка гына тәнкыйтьчеләремез, шигърияте юк, дорфа уйлы... матур сүздән, бизәкле тәкъбирдән тәм таба алмый, дип көләләр". Мондый бәяне ул татар халкын, аның пассионарлык көчен, хисси мөмкинлекләрен белмәү аркасында туган хата караш дип саный. "Безнең халыкта зур бер куәи шигърия (шигъри сәләт, көч) бар. Безнең халыкта искитәрлек шигырьгә дәрт һәм дә шигырьне укырга гына түгел, язарга да дәрт бар. Шул дәрт тә көннән-көн үсә булырга кирәк". Шуңа дәлил рәвешендә үзе житәкчелек иткән гәзитәгә килгән шигырьләрнең саны, хисабы күбәя, телләренең, стильләренең чуарлана баруын атый. Шигырь язучылар сафы ишәя бару сыйфат дәрәҗәсенә таләпчәнлекне көчәйтүне таләп итә, ди мәкалә авторы. Аның уенча, Тукайның вафатыннан соң татар шигърияте көрәшче сыйфатларын югалтып, вак-төяк көнкүреш темаларына кереп бата бара. Киләчәге, милли хокуклары өчен көрәшү урынына кайтарып булмаслык үткәнне (анда да хыялый фонда) идеаллаштыру белән мавыга. Бу хәл, әлбәттә, Исхакыйны битараф калдыра алмый. Шигъриятнең фикерләү киңлеген, иҗтимагый тонусын күтәрүне таләп итү җәһәтеннән мәкаләнең Тукай сатирасына аһәңдәшлеген сиземләү кыен түгел. Автор шигырьләрдә купшы, бизәкле, буш сүзләр арта барып, шапшак уй-фикерләрнең матурлыкны, табигыйлекне кысрыклый килүенә үкенеч белдерә. Мисаллар китереп, мактаган булып, астыртын төрттерә, йомшак җәеп катыга утырта. Менә ул китергән мисал.

*Бәхет табыла, дөрест юллар табылгач,*
*Агып күз яшьләре, күкрәп яналгач.*

"Фәлсәфә бик дөрест, ләкин моның шигырьлеге кая? Шул зур мәгънә үзенә муафыйк сүзләргә бөркәнгәнме? Юк! Шуның өчен аның шигырьлеге юк. Фәлсәфәсе генә бар. Менә бер шагыйрь кайларга барып житкән:

*Һич тә... май безнең Хәдичә,*
*...дип әйтмәдем кичә.*

Күрәмсез никадәр шигърият!—ди Исхакый сарказм белән.—Мин, бер дә шагыйрь булмасам да, шул шигъри сүзләрне гәзитә битләрендә баса алмыйм. Яза алмыйм гына түгел, хәтта кеше алдында укый да алмыйм".

Әдипне шигырь мәйданында "назик" мәгънәләр (укы: порнографик), ялтыравык гыйбарәләр, "фәлсәфи" фикер дип арзанлы акыл сатуга корылган, кешенең рухи дөньясы байлыгы урынына арзанлы ләззәт тәкъдим итү очраклары борчый. Моның бер сәбәбе итеп жиңел кәсеп эзләүне, Тукай, Лермонтов кебек югары сыйфатлы шагыйрьләрдән үрнәк ала, өйрәнә белмәүне күрсәтә. Нәтиҗә ачык: "ул да—шигырь галәмендәге башбаштаклык". Бу хәлнең объектив сәбәпләре дә бар икән: "Тукай китте. Сәгыйть Рәмиев читкә сугылды... Алдагы саф буш калды. Арттан килә торганнар төртешәләр, тартышалар, ләкин алга имам иттереп берне чыгарып бастыра алмыйлар... Шигырьнең шигърияте томанлана, тузанлана. Шигырь гамәле, шагыйрь, чын зур шагыйрь көтә".

Кыскасы, Исхакый үз чорының шигъриятен Тукай биеклегеннән килеп бәяли, вакытлы матбугатка килгән шигырьләргә мөнәсәбәтендә ифрат кырыс, усал булса да, тәнкыйть сүзен, Туфан әйтмешли, "рифмач"ның колагына гына "пышылдый", җәмәгатьчелек, якыннары алдында ким-хур итеп исем-фамилияләрен атамый, "теге"

үзен-үзе "танығач", шул бик житкән дип саный.

Хәзерге әдәбият белгечләре Исхакыйның кызыбрак китеп (бер фельетон өслүбенә чыккач каләмне тиз генә башка юлга "күчереп утыртуы" кыен шәйдер), татар хатын-кызларының "кечкенә генә дә, нәни генә дә бер шагыйрә тудыра алмаулары ышанмаслык гажәп!" дигән фаразын искәрмәсез кабул итә алмыйлар. Чөнки ул чорда Газизә Сәмитова (1862-1929), Мәһруй Мозаффария (1873-1945), Мәхмүдә Мозаффария (1893-1969), Мәфтуха Вәлидия (1894-1969) кебек тәвәккәл яшьләр шигърият мәйданында тавышларын тулы көчкә ишеттерәләр. Күбесенең күңел җимешләре XX гасыр башы әдәбияты белгече Зөфәр Рәмиев төзегән "Татар шигърияте. XX йөз башы" *("Мәгариф", 2004)* җыентыгына теркәлгәннәр. Исхакый яшәгән, иҗат иткән чорда милли мәдәниятебез, шул исәптән шигъриятебез үсешендә тирән эз калдырган, хыял-өметләрен кәгазьгә төшергән мөхтәрәм исемнәр университет галимәсе Альта Мәхмүтованың "И нам пора зажечь зарю свободы..." *(Татар. кит. нәшр., 2006)* исемле китабында да китереләләр.

Исхакый үзе дә нәкъ бер елдан соң шул чорның иң укыла торган басмаларының берсе "Кояш" гәзитәсендәге "Бер изах" (аңлатма) исемле мәкаләсендә бер шагыйрәне— 1914-1915 елларда "Ил", "Сүз" гәзитәләрендә, "Аң" журналында актив басылган, 1917 ел борылышына чаклы шул чор өчен шактый зур, Зәр мен тираж белән берничә мәҗмуга чыгарып өлгергән Гыйффәт туташ (Заһидә Хөсәен кызы Бурнашева, 1895-1977) тәхәллүсен алган шагыйрәне яклап чаң кага. Үз фикеренә тугры калып, автор Гыйффәт туташны "татар хатын дөньясындагы беренче шагыйрәмез" (күрәсең, ул елларда әле Г. Сәмитова иҗаты җәмәгатьчелеккә мәгълүм булмагандыр) дип игълан итә. Аңлатмасында Исхакый шагыйрәнең иҗатын җентекле өйрәнүне, поэтик ачышларына бәя бирүне максат итеп куймый. Гадәтенчә, әдип фикерен киң алдырып, шул чорда иҗатка килгән шәхес белән тиләлек, мохит арасындагы катлаулы мөнәсәбәтләрнең хәзергәчә әһәмиятен югалтмаган әхлакый яклары турында уйлана. Гомуми бәяне чыгару, җәмгыятькә дәгъваны калкытып кую өчен яшь шагыйрә язмышы ифрат кулай булып чыга. Гыйффәт туташ хатын-кызны "дүрт дивар арасында" гомер кичерергә тиешле зат дип санаган кадими карашлы гаиләдә, 5 мең мөселман яшәгән, "дүрт-биш йөз ак якалы ирләре, корсетның төрле-төрле модаларын белгән 2-3 йөз ханымнары булган Әҗидә" (Рязань өлкәсенең Ермеш районында урнашкан авыл) туып, "һичбер төрле ярдәм таба алмаенча", "ялгыз калган Гыйффәт туташ юридический ярдәм сорап, "Вакыт" газетасында мөрәҗәгать итте". Ата-анасыннан (әнисе аны бүлмәдә бикләп тота, җыентыкларын яндыра), кардәш-кабиләсеннән матди ярдәм ала алмаган, караклыкта гаепләнеп, паспортсыз калган яшь шагыйрәне яклап гәзитә укучы җәмәгатьчелек күтәрелә, үзеннән-үзе акча җыю башлана, "русларның саф күңелләре чыдамады, кенәз Гагаринның ярдәме аркасында" (татардан чыккан нәселләрдә коммунистлар әле үткәннәренә нәфрәт тәрбияләп өлгермәгәннәр!) "аның каләменнән, муеныннан чылбыр алынды". Шуннан соң Гыйффәт туташ Мәскәүгә барып урнаша, эше дә табыла, төрле курсларда укуын да дәвам иттерә, гонорары да килә башлый, авыллардан 15-20 тиенләп җыелган акчалардан баш тарта. Горур шагыйрәнең авыл мәәзиннәре мисле сәдака исәбенә яшисе килми, хәтта халыктан килгән тәнкәләрне кире хуҗаларына кайтара башлый. Гыйффәт туташ язмышын бәян итүдән Исхакый берничә әхлакый нәтиҗә чыгара. "Үземнән шуны да әйтим. Бер халыкның арасыннан бер шагыйрь, бер рәссам, бер артист, бер музыкант, бер галим чыкса, вә шул кеше хәл-әхвәленең китеше белән матди вә мәгънәви ярдәмгә мохтаҗ булса, шөбһәсез, милләт, милләтнең аңлылары аңарга ярдәмгә җитешергә тиештер, фараздыр".

Исхакый "аңлылар" сүзенә басым ясап, бу сүз-төшенчәгә хәлле, зыялы, ярдәмчел, ягъни милләтнең иртәгесе турында кайгырта белүче фәһемле затларын күздә тота. Чөнки алдагы юлларда әдип иҗат кешеләрен авылның хәерче мәәзиннәре дәрәҗәсенә төшереп, вак акчалар җибәреп, шул хакта матбугатта тавыш, шау-шу күтәреп мыскыл итмәскә өнди. Бу хакта түбәндәге юллар ачык сөйли. "Гыйффәт туташка ярдәм" дип, 5-10 тиен сәдакалар җыеп, гәзитә битләрендә шагыйрәмезнең исемене өстерәтеп йөртмәүләрен бик үтенәмез... Шагыйрьнең, мөхәрририрнең, рәссамның, артистның һәдияче мәәзин түгел икәнлеген аңларга вакыт инде". Күп хәсрәт, золым күреп тә шигъри рухын югалтмаган, шәхесенә хөрмәтен саклаган Гыйффәт туташ кебек затлар милләтнең йөзек кашлары дәрәҗәсендә йөртелсәләр, шунда гомумән татар әдәбиятына, аның киләчәгенә ихтирамыбыз, өметебез күренер дигән ышаныч, чакыру белән тәмамлый Исхакый "Бер азах"ын.

Мәкаләнең мантыйкый эчтәлегендә Гыйффәт туташ шигъриятенең иҗат юнәлешен хуплау сизелә. Һәм моның тәгаен ачылып, күренеп торган берничә сәбәбе бар.

Беренчедән, яшь шагыйрәнең мөселман хатын-кызларының аянычлы язмышын сурәтләү аша аларның кешелек хокукларын яклап чыгуы Исхакый күнеленә хуш килгәндер дип уйлыйм. "Тарсыну" шигырендә Гыйффәт туташ бу хакта, ягъни җәбер-золым турында бик үтемле яза. Җәрәхәтле күңел серләрен шәрран ярып ачып сала.

*Яшим читлек эчендә: юк ямьле, гүзәл көннәр,*
*Караңгы дүрт ягым, юк, ичмасам йолдызлы ак төннәр.*

Икенчедән, яшь шагыйрәнең Тукай мәктәбенә, остазының фикерләү үзенчәлекләренә, өслүбенә якын юлдан атлавы Исхакыйны хуплау сүзен әйтүгә, кулына каләм алуга рухландыргандыр. Үзенең "Бер кисәк" парчасына шагыйрә "Тукайга ияреп" дигән ачыкламыш та кертә. Аның тормыш, язмыш, яшәү белән үлем, яктылык белән карангылык турында хисси уйлануларга корылган иң унышлы шигырьләре исемнәре белән үк Тукай күтәргән мәүзигъларга тартылып торалар. "Өмидкә" (Тукайда "Өмидсезлек", "Өзелгән өмет"), "Даhига" ("Даhига"), "Шагыйрьгә" ("Шагыйрь"), "Милли көй" шигыренең "Синнән килә миңа ләззәт, хозур, Әй кадерле, дустым, милли көй" юллары Тукайның "Чын безнеңчә матур, милли көй" ("Милли моңнар") кебек сызлану-моңсулануларның дәвамы, бер үк мотивның икенче яктанрак, әмма шул нотада яңгыравы, чыңы кебек кабул ителәләр."Сихерле көйләреннe көйлә шунда...", "Хыял", "Идеал эзләгәндә" кебек шигырьләрендә Гыйффәт туташ җан эзләнүенә ирек биреп, аң төпкеленә, рух тирәнлегенә юл эзли. Үзәктә шул ук экзистенциаль сагыш, әрнү, ачыргалану. Ике шагыйрьнең иҗат җимешләре, эзләнү юллары, тапкан нәтиҗә-кыйтгалары арасында өстән-өстән генә ясалган чагыштыру да (сүз фикерләү кинлеге, иҗтимагый-фәлсәфи яссылык, тел-өслүб сыйфаты дәрәҗәсе турында бармый) Гыйффәт туташны Тукай мәктәбе шагыйрәсе дип атарга мөмкинлек бирә. Тематик кинлек, шигъри калыб төрлелеге җәһәтеннән аларны янәшә кую турында сүз бармаса да, Гыйффәт туташ эпигон, шәүлә шагыйрә түгел. Ул шәхси тормыш дисбесенә ияреп, зирәк нәтиҗәләргә дә килә.

*Яши ул дәрт белән, төшми, егылмый ул, һаман рухлы.*
*Аңар тәмле хыяллар күрсәтәләр алда нур, утны.*

("Тарсыну").

Шагыйрь исеменә дәгъва итүнең никадәр җаваплы йөк, саваплы эш булуын ул аңлый һәм шул уңай белән үзенең күзаллавын, таләбен шигъри юлларга чыгара.

*Ашык нурлы, мөкатдәс йолдызыңа, изге кыйблаңа;*
*Синең күгеңдә балкый таң, күзең ач вәхи—илһамга.*
*Кара: алдыңда нинди саф, тирән, зур чишмәләр шаулый,*
*Синең таңны сәламләп, назлы былбыллар ничек сайрый!*

("Шагыйрьгә").

Гыйффәт туташ лирикасында мәхәббәт драматизмын, сөю сагышын хатын-кыз язмышы белән үреп сурәтләгән шигырьләр зур урын тота. Бу хис турында ул саклык һәм нәзакәтлелек белән яза.

*Сөйдем сезне... Минем утлы мәхәббәт сүнмәгән. Бәлки*
*Хәзер дә һәм минем күңлемдәдер, яки калыр мәңге.*
*Сөйдем, бәлки сөярмен һәм үзгәләр сөйсеннәр сезне,*
*Мәхәббәт тәңресе алдында бит һәркем чүгәр тезне.*

("Сөйдем сезне...").

"Табигать", "Язда", "Сандугач сайраганда" шигырьләрендә ул табигатьнең ямьле күренешләрен сурәтләү аша рухи дөнья гүзәллекләрен ачуга омтылыш ясый. Дөрес, аларга серлелек, күпмәгънәле киная, ишарә житенкерәми. Шул ук вакытта Гыйффәт туташ—һәвәскәрлек, үзешчәнлек чикләрен узган шагыйрә.

Чорның олы әдибе Исхакый фатихасы һәм анын Гыйффәт туташ шәхесен, ирегең, димәк ки, аның шигърияген яклап аваз салуы эзсез югалмагандыр дип уйлыйм. "Бер азах" мәкаләсеннән соң шагыйрәнең төрле нәшриятләрдә бер-бер артлы өч җыентык чыгарганын искәрткән идек.

Шагыйрьлек куәсе көчле булса да, дөньяга карашы, сәяси аңы милли мәнфәгатьләр

жирлегендә калыпка утырып житмәгән Гыйффәт туташ 1917 ел Октябрь борылышын хуплап каршы ала, 1918 елда коммунистлар фиркасенә кереп, оештыру, үгет-нәсихәт шөгыльләре белән Урта Азиягә җибәрелә. Табигый ки, аннан соң ул шигърият кебек "вак-төяк" эштән читләшә. Большевикларның алдаучан шигарьләрен (лозунгларын), мәкерле сәясәтен вакытында аңлап, бар борчылуы милләт гаме булган, халкын инкыйраздан, юкка чыгудан саклау өчен көрәшен мөһаҗирлектә дәвам иткән Исхакый өчен башка идеалларга табынган Гыйффәт туташ инде кызыклы шәхес булудан туктый. Алдагы елларда "беренче татар шагыйрәсе" дип күтәреп алган кеше турында ләм-мим сүз әйтми. Күңеленнән үк сызып ташлагандыр дип фараз итәргә генә кала.

Шул рәвешле, XX гасыр башы тезмә сүз сәнгатебезнең еракларданн килгән шигъри куәсен, лирик эчтәлеген, тылсымлы, сыгылмалы телен саклау юнәлешендә Исхакый Тукай кулыннан төшкән миллилек байрагын күтәреп ала һәм киләчәк буыннарга васыяте итеп калдыра.

* * *

XX гасырда татар сүз сәнгатенә һәм халкына ихластан һәм нәтиҗәле хезмәт иткән иң бөек затыбыз кем дип сорасалар, ирешнәр, аң шәрифләреннән дә сорап тормыйча, "Исхакый"ны әйтә. Чит илләрдә яшәүче татарлар аны үзе исән чакта ук милләт юлын яктыртып торучы кояшка тиңләгәннәр. Минһаҗ Исмәгыйли (1910—1995) аңа түбәндәге шигъри юлларын багышлый:

*Гаяз ага, син безгә кояш идең,*
*Синең юлың ак юл, бәхет юлы иде.*
*Шуңа күрә курыкмадың дошманнардан,*
*Чөнки син батыр татар улы идең!*

Әдипнең тууына 120 ел тулуга багышланган халыкара фәнни конференция материалларын туплаган китапның "Гаяз Исхакый һәм татар дөньясы" (2000) дип аталуы да күп нәрсә турында сөйли. 2008 елда Исхакыйның 130 еллыгын билгеләп үттек. Айдар Хәлим "Исхакый—титан" исемле мәкаләсендә тирән нәтиҗәләргә килә. "Генийлык, даһилык титанлыкның бер бүлемтеге генә. Бездә, татарда әлегә бер генә титан бар. Исхакый. Аның титанлыгы шунда гына да яхшы чагыла: Тукай аның янында үзен "самавырчы" малай кебегрәк тойса да, Гаяз Исхакый, Везувий кебек, югары күтәрелеп, Тукайны үзеннән дә югарырак чөя һәм аны милләтнең бәхет кошы дип атый... Бу бары тик титаннарга гына бирелгән кечеклелек" . Балачактан Тукайны укып, Тукайга табынып үскән җан бу сүзләрне авырсынырак кабул итсә дә, акыл ярдәмгә килгәч, һәммәсе үз урынына утыра. Исхакыйны күтәрү Тукай данына шәүлә төшерми икән. Бөекләребез без булдыра, хәтта аңлый алмас дәрәҗәдә бер-берсенә бәяне үзләре биреп калдырганнар, лабаса. Олы шигърияткә аяк баскан чорында ук Тукай Исхакыйның шөһрәтле киләчәген сиземләп "Кем ул?" (сез кем дә ул кем, янәсе, чамалап сөйләшегез) дигән риторик соравын калкытып куйган. Исхакый исә "Тукай бар иде. Тукай бар. Тукай яши. Тукай яшәячәк" кебек күңелләргә якын канатлы җөмләләрне кабатлаудан туймаган да, тартынып та тормаган. Аның бөек шагыйребезгә багышланган мәкаләләре, чыгышлары XX гасыр татар шигъриятенең иҗтимагый дәрәҗәсен, тонусын күтәреп җибәрәләр. Тукайны пәйгамбәрлек изгелеге кагылган халык шагыйре дип атап, Исхакый аның иҗаты, шәхси тормышы тирәсендә куертылган сафсатага чик куеп, Тукай шигъриятен фәнни-гамәли өйрәнүгә ныклы юнәлеш биреп, терәк баганаларны кагып калдырды.

Ниһаять, Тукай белән Исхакыйның иҗади дуслыгы XX гасыр башы татар сүз сәнгатенең, тизләтелгән үсеш юлын үтеп, дөнья мәдәнияте дәрәҗәсенә күтәрелүенә дә хәлиткеч йогынты ясамадымы икән? Бу илаһи мөнәсәбәт безнең чорда еш кына бер-берсен аңлый, кыен мизгелләрдә иңнәрен куя белмәгән язучыларыбызга үрнәк була алмыймы? XXI гасыр башында аз санлы милләтләрне кысу, гаделсезлек хөкем сөргән шартларда Исхакый белән Тукай алга сөргән миллилек идеясе халкыбызны инкыйраздан саклап калу юлында төп таянычларның берсе булып калкырга тиеш түгелме?

♣

# ОЛУГ МӨГАЛЛИМ ҺӘМ ӘДӘБИЯТЧЫ

*"Милли әдәбият хисапсыз заманнардан бирле сузылып һәм безне изеп килгән гафләт йокыбыздан уяну "ВАКЫТ"лары житкәнен аңлатадыр. Караңгы төннәрдә, "ЙОЛДЫЗ" булып ялтырап, башыбызга "АҢ" тутыра, һичбер туймаслык дәрәҗәдә татлы-татлы "КИНӘШ" мәҗлесләре ясый. Аңламаган тирән мәсьәләләребездә ышанычлы "ТӘРҖЕМАН"ыбыз була. Болытлы көннәрдә "КОЯШ" урынын тота. Сөекле бабаларыбызның ... йөргән юл вә эзләреннән, "ИДЕЛ" буйларыннан хәбәр биреп торадыр. Яшерен вә караңгы калган җәһаләт почмакларына кадәр "НУР"ын чәчәдер. "ХОКУК"ымызны таныта, "ИКЪТИСАД"ның әһәмиятен сөйли, шуңа юл күрсәтә. "СӘҮДӘ" турысындагы кирәкле нәрсәләрне вә хакларны "БӘЯН" итә. "МӘКТӘП"ләребезгә жан кертеп, белмәгәннәребезне ачык итеп белдерүче икътидарлы (көчле-куәтле.—Х.М.) " МӨГАЛЛИМ"ебез буладыр.*

*(Г. Сәгъди, 1913)*

*...Газиз балалар! Сезнең өчен һәм барыбыз өчен дә иң зур бәхет—үзебезнең милли туган телебезне укуда, шуңа бик ябышуда, шуны чын күңелебез белән сөюдә генә икәнен күңелебезгә һичбер вакытта да онытылмаслык итеп урнаштырыйк..."*[1]

*(Г. Сәгъди, 1913)*

XX йөз башы—соңгы дәвер яшәешебезнең иң бай, тулы канлы чоры: әдәбият, матбугат, театр, китап басу гөрләп үсә; татар, кайда гына тереклек итмәсен, үз телендә сөйләшә, укый; татарлык һәр кавемдәшебезнең күңелен биләп ала. Шунысы мөһим: бу рухи күтәрелешнең нигезен, асылын милли мәгариф, тел-әдәбиятны уку-укыту өчен көрәш тәшкил итә. Халкыбызның Р. Фәхреддин, Г. Исхакый, Г. Тукай, Г. Ибраһимов һәм кайбер башка күренекле затлары мәгариф, белем-тәрбия эшен милли алгарышның төп чаралары итеп карап, үзләре дә бу хәрәкәтнең үзәгендә кайнадылар: мөгаллимлек кылдылар, мәкаләләр, дәреслек-әсбаплар яздылар. Болар арасында Габдрахман Гайнан угылы Сәгъди (27.03.1889—6.11.1956) мөхтәрәм урынны били. Ул 67 еллык гомеренең 46 елын педагогик эшкә, гыйльми-тикшеренүләргә багышлый, югары уку йортларында өч дистә елдан артык эшли, 22 ел кафедра мөдире булып тора; татар, урыс, үзбәк, төрекмән, казакъ һәм кайбер башка телләрдә 162 исемдә 355 табаклык хезмәт яза. Шуларның кырыклабы аерым китап рәвешендә дөнья күрә. Аның эшчәнлеге 1946 елда "Хезмәт Кызыл Байрагы" ордены белән бәяләнә.

Г. Сәгъдинең гомер юлы шактый катлаулы, гыйбрәтле. Ул хәзерге Башкортстанның төньяк-көнчыгышындагы Салават районы Таймый (халык телендәге атамасы—Атау) исемле татар авылында рухани, хаҗи гаиләсендә дөньяга килә. Шунысын да искәртик: 1769—1842 елларда яшәгән Сәгъдинең бай нәсел шәҗәрәсе бар [Мөхәммәтһади Сәгъди (1883-1933)—Башкортстанның күренекле мәгърифәтчесе, педагогы; Агиш Гыйрфанов (1928—1999)—әдип; Артур Сагадеев (1931—1997)—философия фәннәре докторы, профессор һ.б.]. Сәгъдинең оныгы Эльвира Фуат кызы "Саади" (1952 елда туган)—нәфис гимнастика буенча СССР (1973), дөнья (1974), Олимпия уеннары (1972, 1976) чемпионы.

Габдрахман әүвәл туган авылында әтисендә белем ала. 1902-06 елларда инде ул—Троицкидагы атаклы "Рәсүлия" мәдрәсәсе шәкерте. Аннан ике ел Таймый һәм Мәчетле авылларында татар теле һәм әдәбияты укыта. Яшь мөгаллимнең

[1] Һәр ике өзекнең дә чыганагы: Шәхесләребез; Габдрахман Сәгъди.—К.: "Җыен", 2008.—19, 28-29 б. Алга таба бу чыганакның битләр саны җәяләр эчендә генә күрсәтеләчәк.

тырышлыгы, җәдитчә укытуы җәмәгатьчелекнең дә игътибарын җәлеп итә. "Мөгаллим Сәгъди әфәнденең гүзәл нәмүнәлеге ("тәҗрибәсе".—Х.Ю.)" хакында хәтта "Вакыт" гәҗите дә язып чыга (16.04.1909).

Үз даирәсендә укымышлы исәпләнгән, гарәп, фарсы, төрки телләреннән һәм әдәбиятларыннан шактый гына хәбәрдар булган, урысчаны да бераз үзләштергән яшь мөгаллим укуын дәвам итәргә, югары белем алырга омтыла. Ахыр чиктә аны бу теләк Госманлы мәмләкәтенә китерә: 1908-11 елларда Г. Сәгъди Истанбул университетының филология факультетында ("дарелмөгаллимин"ендә) укый, башкаланың иҗтимагый, сәяси, гыйльми, мәдәни, дини тормышы белән якыннан таныша, биредәге милләттәшләре белән дә аралаша. Шушы елларда аның "Шура", "Вакыт" кебек басмаларда мәкаләләре, шигырьләре басыла башлый. Соңгыларын ул укучыларга, нигездә, "Зәүкый", "Рухи", "Атави" тәхәллүсләре белән тәкъдим итә. Шунысын да әйтик: Г. Сәгъди, гәрчә сирәгрәк булса да, гомере буе әдәби иҗат белән шөгыльләнә. Тәүге шигырьләрендә романтик рух, символик яңгыраш өстенлек итә. Типологик яктан алар госманлы классик поэзиясенә, Дәрдемәнд әсәрләренә аваздаш. Г. Сәгъдинең төрекчәдән, үзбәкчәдән шигъри тәрҗемәләре дә бар. Г. Нәваинең "Фәрһад вә Ширин" әсәреннән өзекләр, мәсәлән, оригиналга якынлыгы, сәнгати камиллеге белән бүгенге татар укучысының да күңеленә хуш килерлек.

Университетны тәгаллүгәч, Г. Сәгъди Актүбә (биредә Кави Нәҗмине дә бераз укыта), Верный (Алма-Ата), Екатеринбург, Ыргыз калаларындагы, Златоуст өязендәге татар, татар-урыс мәктәпләрендә татар теле һәм әдәбияты укыта, хәтта кайберләрендә мөдир булып та тора. Алдынгы карашлы, милләтпәрвәр рухлы мөгаллим сәяси эзәрлекләүләргә дә дучар ителә. Мәсәлән, 1914 елның башында ул жандармерия әмере белән 24 сәгать эчендә Алма-Атадан китәргә мәҗбүр була. Бу факт шул вакыттагы татар вакытлы матбугатында да чагылыш тапкан.

Г. Сәгъди 1917 елның җәендә Бөгелмә шәһәренә чакырыла. Биредәге мөгаллимнәр әзерли торган курсларда ул татар теле һәм әдәбияты, педагогика предметларын укыта, җәмәгать эшләрендә актив катнаша. Аның тырышлыгы белән бу курслар укытучылар семинариясенә әверелә. Хәзерге Бөгелмә педагогия училищесы нәкъ әнә шул уку йорты белән бәйле.

Университетны тәмамлаганнан соңгы 10 елда Г. Сәгъди шактый гына мәкалә-хезмәтләр яза. Алар, нигездә, "Шура" журналында дөнья күрә. Шулай ук аның бу елларда "Мохтәсаре кавагыйде әдәбия" (1911), "Мөхтәсаре кавагыйде әдәбиягә гыйлавә (өстәмә.—Х.М.)" (1911), "Әдәбият ысуллары" (1912), "Әдәбият мөгаллиме" (1913) китаплары, телнең сарфы (морфологиясе), нәхүе (синтаксисы) турында әсбаплары басылып чыга. Боларның һәммәсе дә педагогик ихтыяҗны күздә тотып язылган. Уку-укыту процессын яхшы белү, җанлы тәҗрибә, тел-әдәбиятны тирәнтен аңлау Г. Сәгъди хезмәтләрен абруйлы итә. Шунысы мөһим: язмалары белән ул татар әдәбият теориясенең шәкелләшү-үсешенә дә үзеннән зур өлеш кертә. Аның 1918 елда Уфада дөнья күргән "Фәне тәрбия һәм тәгълим" исемле 258 битлек китабын татар телендәге тәүге педагогика дәреслеге дип тә атарга мөмкин. Ул дөнья гыйльми-педагогик казанышлары югарылыгында язылган. /Бу китап һәм гомумән Г. Сәгъдинең методик эшчәнлеге хакында без узган гасырның 70нче елларында курс-диплом эшләре яздырткан идек. Студентларның "Фәне тәрбия һәм тәгълим" китабына сокланулары хәзер дә хәтеремдә/.

1921 ел—үзенең дәһшәтле ачлыгы, сугыш-инкыйлабларның аянычлы нәтиҗәләре белән татар тарихында иң фаҗигале сәхифәләрнең берсе: халык кырыла, төрле якларга, аеруча көньяк тарафларга күпләп күчеп китә. Бу вакыйга-хәлләр Г. Сәгъди язмышына да китереп суга: ул каты авырый; дәваланырга дип Кавказ якларына барып чыга. Бераз вакыт Бакудагы педагогик курсларда дәресләр уздыра. Төркестан Республикасы халык мәгариф комиссариаты чакыруы буенча 1921 елның көзендә Ташкентка килә. Биредә ул Шәрык институтында, рабфакта, Урта Азия дәүләт университетында (САГУда) тел-әдәбият укыта, матбугатта күп санлы мәкаләләр бастыра.

1925 елның көзендә Г. Сәгъди рәсми рәвештә Казанга чакырыла. Бу эш Г. Ибраһимов рәислегендәге Академик Үзәк тәкъдиме белән башкарыла. Татарстан башкаласындагы 5 еллык вакыт—галим эшчәнлегенең иң нәтиҗәле чоры. Биредә Г. Сәгъди әүвәл Татар коммунистлар университетында, педтехникумда әдәбият укыта. 1926 елда Казан Көнчыгыш педагогия институтына доцент, өч елдан соң

профессор итеп сайлана, югары дәрәҗәле гыйльми-педагогик кадрлар әзерләүгә үзеннән гаять зур өлеш кертә; Академик Үзәк эшчәнлегендә, әдәби хәрәкәттә актив катнаша, вакытлы матбугатта, төрле фәнни, мәдәни чараларда чыгышлар ясый.

Казанда яшәү елларында Г.Сәгъдинең "Татар әдәбияты тарихы" (1926.—300 б.), "Кешелек дөньясында тел, әдәбият, язу һәм аларның тарихи үсүләре" (1926.—247 б.), "Пролетариат диктатурасы дәверендә татар әдәбияты" (1930.—200 б.) кебек саллы хезмәтләре, Г. Ибраһимов, татар театры, әдәби тәнкыйтьнең торышы, Мәүла Колый, Г. Кандалый һәм кайбер башка әдипләр хакындагы мәкаләләре дөнья күрә, "Символизм турында" исемле мәшһүр монографиясе язылa (ул 1932 елда Мәскәүдә нәшер ителә.—135 б.). Бу хезмәтләр—Г. Сәгъди мирасында гына түгел, гомумән татар фәнендә, рухи тормышында вакыйга тудырган, гаять житди ядкарьләр. Аларда автор әдәбият тарихчысы һәм теоретигы, тәнкыйтьче, философ, педагог, язма мәдәниятнең олуг белгече буларак чыгыш ясый. Әгәр дә Г. Рәхим, Г. Газиз китапларында татар әдәбиятының Борынгы һәм Урта гасыр дәвере, XIX йөзнең шактый өлеше яктыртылган булса, Г. Сәгъди шуны алга таба дәвам иттерә. Шунысын да искәртик: күбесенчә ул үз чорының әле тиешенчә оешмаган, утырмаган материаллары белән эш итә, Г. Камал, М. Гафури, Дәрдемәнд, Г. Тукай, С. Рәмиев, Н. Думави, Ф. Әмирхан, Ш. Камал, Ш. Бабич ("... татарда... иң көчле яшь талантларның берсе"), Н. Исәнбәт, Ә. Тангатар һәм башка чордашлары хакында кызыклы фикер-күзәтүләр ясый, аларның иҗади эшчәнлеген әдәби-тарихи яссылыкта яктыртырга омтыла. Биредә бер гыйбрәтле факт игътибарны җәлеп итә. Узган гасырның 20 нче елларында "...Инкыйраз" авторын юкка чыгару, оныттыру хәрәкәте башлана. Кызганыч ки, бу шаукымның башында Г. Ибраһимов тора. Әмма Г. Сәгъди бу мәсьәләдә кыюлык күрсәтә: фәнни объективлыкка тугры калып, ул "Татар әдәбияты тарихы" китабында (1926) Г. Исхакыйга зур урын бирә, иҗатына тәнкыйди анализ ясый. "Гаязның,—ди ул, ...—бөтен хикәя, романнары, пьесалары аның киң шашкын, котырык хыяллы һәм тасвирның күренешле (картиналы), җиңел алынмалы булуын күрсәтәләр"; аның "...Инкыйразы" "шашкынлы бер сүз куәте", "утлы бер каләм белән" язылган. (52, 58 б.)

Мәгълүм ки, Г. Сәгъди гаять катлаулы, каршылыклы елларда яши. Сыйнфый көрәш, партия сәясәте аның эшчәнлегенә дә теге яки бу дәрәҗәдә йогынты ясый. Рухани гаиләсеннән булуы, Төркиядә укып кайтуы, татар мәнфәгатьләрен эзлекле яклавы галимнең хәлен тагын да катлауландыра. Вакыты белән артык "кызарып" китүе, социализмга бирелүе, хәтта рухани әтисенә тәнкыйди карашы да шул чор чынбарлыгы белән аңлатыла. Хезмәтләрендә бәхәсле, берьяклы фикерләр дә күзгә ташлана. Әмма, куанычка, аның күпкырлы эшчәнлегендә позитив башлангыч, рухи мирасны, әдәбиятны тирәнтен аңлау һәм гадел бәяләү өстенлек итә.

20нче еллар ахырында татар зыялыларын, руханиларын эзәрлекләү, милләтчелектә, сәяси сукырлыкта гаепләү киң колач ала. Г. Сәгъди өстендә дә болытлар куера башлый. Бер-бер артлы галимне "фаш иткән" язмалар күренә. Гали Сафиуллин дигән бер зат "Эшче" гәҗитенең 1929 ел 9 октябрь санында Г. Сәгъдине "советларга каршы көрәш оештыручы", "буржуа" тарафдары дип атый, аның эшчәнлеген, "марксизм битлеге астында пролетариатның эченә кереп, кызыл буяуга буялып, иске буржуа, кулак, мулла идеологиясен тарату" дип бәяли (309-310 б.). 1930 елның гыйнвар башларында "Татар Совет Язучылар оешмасы"ның Г. Сәгъдине "тазартуга" багышланган махсус җыелышы үткәрелә. "Кызыл Татарстан" гәҗите язуынча (21.01.1930), ул "бер кичкә (5-6 сәгатькә)" сузыла (311 б.). Һ. Такташ та "Серле күзлек" исемле шигырендә Г. Сәгъдине икейөзлелектә, байларга хезмәт итүдә гаепли.

Рәсми сәясәтнең кая баруын яхшы тоемлаган галим ахыр чиктә Казанны ташлап, янә Үзбәкстанга китәргә мәҗбүр ителә. Әгәр дә Г. Сәгъди Идел-йортта калган булса, ул да Ф. Кәрими, Г. Гобәйдуллин, Н. Хәким, Г. Рәхим, Г. Нигъмәти һәм кайбер башка хезмәттәшләренең фаҗигале язмышына дучар булыр иде. Мәгълүм ки, Октябрьдән соң Г. Исхакыйларны, С. Максудыйларны, иң беренче чиратта, Төркия үзенә сыендыра. Ә инде татар зыялыларының бер өлеше Урта Азия якларына китеп исән кала. Моның өчен без төрки кардәшләребезгә аеруча рәхмәтле.

Г.Сәгъди гомеренең 30 елы Үзбәкстан белән бәйле. Ул биредә 1921-25, 1930—1956 елларда яши. Әйткәнебезчә, бу җөмһүрияттә яшәвенең беренче чорында Г. Сәгъди Ташкенттагы университетларда укыта. 1930—1956 елларда да ул шушы

эшен дәвам иттерә: әүвәл Сәмәрканд Педагогия академиясендә лекцияләр укый. Үзенен тәржемәи хәлендә профессор биредә үзбәк әдәбияты кафедрасын һәм тел-әдәбият бүлеген оештыруын искәртә. Үзбәкстан Мәгариф житәкчелеге аны 1932 елда Ташкенттагы Индустриаль-педагогия һәм Кичке педагогия институтларына профессор итеп күчерә. Бу елларда ул Фирганә педагогия институтларында үзбәк теле һәм әдәбияты кафедрасы оештырып, анын мөдире дә булып тора. 1937—1941, 1944-46 елларда Г. Сәгъди Сәмәрканд дәүләт университетында үзбәк әдәбияты кафедрасы мөдире. 1941-44, 1946—1952 елларда ул Ташкенттагы Урта Азия дәүләт университеты профессоры һәм андагы кафедра житәкчесе. Г. Сәгъди Үзбәкстанда яшәү чорында биредәге Фәннәр Академиясенен тел-әдәбият институты һәм кайбер башка оешмалар, уку йортлары белән дә хезмәттәшлек итә. Галим 1952 елдан алып, гомеренен ахырына кадәр янә Сәмәрканд университетында эшли. 1956 елнын 6 ноябрендә вафат булып, шушы борынгы һәм тарихи калада жирләнә дә.

Үзбәкстанда яшәү елларында Г. Сәгъди уку-укыту, белгечләр хәзерләү, оештыру, жәмәгать эшләре белән тыгыз бәйләнештә бик нәтижәле гыйльми-тикшеренү эшләре дә алып бара. Бу чорда анын үзбәк, урыс, казакъ, төрекмән телләрендә күп санлы мәкалә-хезмәтләре нәшер ителә. Алар төрле характерда. Бер өлеше педагогик, методик мәсьәләләргә, әдәбият теориясе проблемаларын яктыртуга багышланган. Аларда автор билгеле бер дәрәжәдә татар телендә элегрәк басылган хезмәтләрен дә файдалана. Икенче бер төркем язмаларында Мөселман Көнчыгышындагы фәлсәфи, ижтимагый фикер мәсьәләләре яктыртыла. Анын, мәсәлән, Газзали, Фәрәби, суфыйчылык турындагы күзәтүләре кызыклы гына. Шулай ук ул борынгы ядкярләр, төрки телләр тарихы мәсьәләләрен дә игътибардан читтә калдырмый. Белгечләр анын казакъ классигы Абай( 1845—1904), каракалпак шагыйре Бердах (1827—1900) турындагы язмаларын да унай бәялиләр.

Мәгълүм ки, Идел-йортта яшәү елларында Г.Сәгъди татар әдәбияты тарихы белән ныклап шөгыльләнә. Үзбәкстанда ул үз эшчәнлегенен үзегенә үзбәк сүз сәнгатен куя. Анын күп санлы язмаларында үзбәк әдәбиятынын тарихы да, хәзергесе дә, Хәмид Алимжан, Гайрәти, Гафур Голәм, Мөкими кебек әдипләрнен ижатлары да яктыртылыш таба. Татар галиме үзбәк әдәбиятынын принципиаль тәнкыйтьчесе буларак та танылa.

Г. Сәгъдинен үзбәк әдәбиятынын бөек шагыйре Г. Нәваи (1441—1501) ижатын тикшерүгә багышланган ике дистәдән артык хезмәте бар. 1949 елда Г. Сәгъди "Нәваи ижаты—үзбәк классик әдәбияты үсешенен югары этабы" темасына докторлык диссертациясе яклый һәм ул ВАК тарафыннан 1950 елнын 22 апрелендә раслана да.

Кыскасы, Г. Сәгъди үзбәкләрнен генә түгел, гомумән Урта Азия халыкларынын мәгарифен, фәнен, мәдәниятен үстерүдә, югары дәрәжәле кадрлар тәрбияләүдә гаять нәтижәле эшли. Ул чын мәгънәсендә Дамелла, Остаз буларак таныла. Филология фәннәре докторы, профессор, Үзбәкстаннын атказанган фән эшлеклесе Рәхим Мөкимов үз укытучысын югары бәяләп, болай ди: "Хәйран калдырганы шул: татар милләтеннән булган бу укытучынын саф үзбәк телендә үзбәк әдәбияты тарихын укытуы гына түгел, ә Шәрыкнын шушы төбәгендә яшәүче күп кенә халыкларнын әдәбият вә мәдәният тарихын да су кебек эчүе иде. Ул урыс, үзбәк, гарәп, фарсы-таҗик, грек һәм кытай галимнәренен дә дөньяга карашы белән дә таныш һәм шул хакта иркен фикер йөртер иде". Ул Алишер Нәваи "ижади мирасын өйрәнү фәненен башында торучылардан иде" (326-327 б.)

Мин 1978 елнын көзендә Дүшәнбе шәһәрендәге дәүләт университетында стажировка уздым. Туп-туры классик таҗик әдәбияты кафедрасы мөдире Шәрифжан ага Хөсәензадә (1907 елгы) кабинетына кердем. Таҗик сүзләре катнаштырып бу мәшһүр галимгә мөрәжәгать иттем. Шунда ул: "Ярар, интекмәгез инде",—дип мине туктатты да, саф татар телендә сөйләшә башлады. Мина бу гажәп тоелды. Шунда Шәрифжан ага Ташкент университетында Г. Сәгъдидә укуын, анын "бөек Остаз" булуын рәхәтләнеп сөйләп китте. "Шунын тәэсирендә,—диде,—безнен күбебез татар теленә, татар әдәбиятына гашыйк булды".

Г. Сәгъди Үзбәкстанда яшәвенен икенче чорында, ягъни 1930—1956 еллар аралыгында Казанга бары бер мәртәбә—1944 елнын көзендә килеп китә. "Совет әдәбияты" журналында К. Насыйри турындагы мәкаләсен бастыра. Әмма ул, гәрчә Идел-йорттан еракта яшәсә дә, татарлар белән аралашып, татар әдәбияты, фәне белән кызыксынып тора. Татар әдипләрен, аеруча Тукайны үз лекцияләрендә, фәнни

хезмәтләрендә еш телгә ала, Нәваиның татар дөньясындагы урыны хакында мөһим фикерләр әйтә. “Фәрһад вә Ширин” поэмасын татар телендә бастырырга да йөри. Әмма Казан аның бу теләген кире кага.

Күренекле галим Мөхәммәд ага Гайнуллин заманында Г. Сәгъдинең лекцияләрен тыңлаган, аның белән очрашкалаган да. Соңгысы Сәмәркандта остазының үлеменә бер ай кала була. Бервакыт мин бу соңгы очрашу хакында Мөхәммәд агадан сораган идем. Аның: “Габдрахман абый җирсеп, Казанны сагынып яши”, дигән сүзләре хәзер дә хәтердә саклана. Әйе, күпме зыялыларыбыз, талантларыбыз мөһаҗирлектә яшәп, җирсеп, якты дөньядан китеп барганнар шул. Нишләтәсең, татарның кара язмышы...

***

Габдрахман Сәгъдинең шәхесе, эшчәнлеге күпләрнең игътибарын үзенә җәлеп итә. Болар арасында Е. Э. Бертельс (Г. Сәгъди—”татар әдәбияты тарихын өйрәнүнең пионеры”), Р. Мөкимов кебек урыс, үзбәк галимнәре дә, Х. Вәли, Л. Яфаров, В. Хаков шикелле татар филологлары да бар. Г. Сәгъди хакында аның шәкерте М. Гайнуллин дистәләп язмасын калдырды. Соңгы елларда олуг мөгаллим эшчәнлеген өйрәнүдә Д. Заһидуллина, Э. Галиева, Т. Гыйлаҗев уңышлы гына эшли. Чулпан Гыйлаҗева 2006 елда “Г. Сәгъдинең әдәби-тарихи мирасында әдәбият белеме мәсьәләләре” темасына кандидатлык диссертациясе яклады (Фәнни җитәкчесе—Д.Заһидуллина), бер китапчык та бастырды. Бу ике галимә “Шәхесләребез” сериясендә “Габдрахман Сәгъди: Фәнни-биографик җыентык” исемле китапны әзерләп чыгардылар (Казан: Җыен, 2008.—416 б.). М. Госманов мөхәррирлегендә нәшер ителгән бу басмада Г. Сәгъди хакында мәкаләләр, архив материаллары, фотоматериаллар, биобиблиографик мәгълүматлар бирелгән. Аеруча мөһиме шул: китапта Г. Сәгъди хезмәтләреннән, әдәби иҗатыннан аерым үрнәкләр дә урнаштырылган. Бу җыентык—галимнең тууына 120 ел тулуга менә дигән бүләк (Бу мәкаләдә инде без аннан файдаландык та). Киләчәктә Г. Сәгъдинең башка мөһим хезмәтләре дә басылып чыгар дигән өметтә калабыз.

*3.01.2009*

**Хатыйп МИҢНЕГУЛОВ**

---

## *Алхәбәр. “Казан утлары” — 2009*

Илдус Илдарханов

## УЛ БӨЕК ИДЕ, ЛӘКИН...

КӨРӘШЧЕ ШӘЗАМ САФИННЫҢ КҮТӘРЕЛҮ ҺӘМ ТӨШҮ ТАРИХЫ

**В. Белоглазов**, СССРның спорт остасы,рәссам:

—Ул—Бөек тренерның Бөек шәкерте иде. Ул якты йолдыз булып тиз кабынды, тик озак янмады,тиз сүнде...

**А. Мазур**, СССРның атказанган спорт остасы,Россиянең атказанган мәдәният хезмәткәре:

—Шәзам Сафин Советлар иле көрәшчеләре арасында өченче булып Олимпия уеннары чемпионы исемен яулаган спортчы. Ләкин Украина да,Эстония дә аерым дәүләтләргә әйләнгәч,без Шәзам Сафа улын Россиянең Олимпия чемпионы исемен алган беренче көрәшчесе дип санарга тиешбез.

**Я. Старобыховский,** СССРның спорт остасы,Россиянең атказанган тренеры:

—Андыйлар онытылырга тиеш түгел. Татар халкы аны үзенең бөек уллары рәтендә санарга тиеш...



Әнвәр
Давыдов
(1919—1968)

# ТӨРЛЕ ЕЛЛАРДАН

***

**Мин диңгезче түгел.
Тик шулай да
Беркөнне мин сездән китәрмен
Мәңгелекнең диңгезенә чыгып...
Ә сез бәлки һәр кич-иртәне
Үткәрерсез
Мине искә алып.
Мине сагынып...
Ә мин—хәйләкәр—
Бер дә кайтмам инде...
Чөнки шундук
Мине искә алудан
Туктар идегез, кайтсам мин әгәр.
Шуның өчен
Бер дә кайтмам инде.
Бер дә кайтмам инде.
Юри бер дә
Кайтмам.**

*1964*

## Татар китабына

**Рәхмәт сиңа!
Ертып минем күздән
Бөтен уйдырмалар пәрдәсен,—
Син күрсәттең бөтен бөеклектә
Гадилеген һәрбер нәрсәнең.**

**Дөнья танудагы тәүге юлым
Артык гади:
Мин бит күрмәдем
Ерак гасырлардан кала килгән
Бөек һәйкәлләрнең үрнәген.**

**Мин узмадым ул чак,
Тетрәнеп,**

"Тәмуг"лары аша Дантеның...
Минем пирамидалар:
Тирес түккән
Калкулыгы ындыр артының...

Әйе, алар
шомлы төскә кереп,
Серләр тулы эңгер-меңгердә
Дәһшәтлелек дәгъва итеп торган
Әби әкияте белән бергә.
Тигәнәкләр,
Шайтан таяклары,
Төнге кошлар очкан тавышлар—
Кичен пышылдаган дога белән
Бар да серлелеккә авышкан.
Менә шуңа синең хәрефләрең
Карашыма минем калыккан.
Күңелемә
Хаклык алып кергәнсең,
Үзең хаклык алып халыктан.
Һәм син шунда,
Ертып минем күздән
Бөтен уйдырмалар пәрдәсен,—
Күрсәткәнсең бөтен бөеклектә
Гадилеген һәрбер нәрсәнең...

*1965*



*Фронтовик шагыйрьләр. Уңнан-сулга—
Әнвәр Давыдов, Мәхмүт Хөсәен,
Сибгат Хәким. 50нче еллар.*

***

Кара син, ә, һаман кабаланып
Үтеп китте бит, әй, тормыш та!
Ә мин һаман: үз өстенә алган
Йөктән арыналмаган кырмыска.

*1964*

***

Дус кеше ул—гүя җанга дару,
Сыкрау туган чакта күңелдә,
Дустың килсә, була шундый ару,
Сихәт дулкынына күмелә.

Ләкин табип, яхшы дару булса,
Юкка гына бирми дозалап.
Дуслык та шул бер чамадан узса,
Агу була, ягъни бозыла.

## Тарихка карата

Тикшермәдем, мин тарихчы түгел.
Минем ата-бабам йөреткән
Татар исеме ялгыш исем диләр,
Без болгарлар, диләр, электән.
Ләкин тарих битләреннән миңа
Күптән карап килгән усал күз
Үзеннән һич мине ычкындырмый,
Купмый миннән татар дигән сүз.
Шуңа күрә кат-кат кайтам инде,
Татар, синең үткән юлыңа.
Артык исем китми Чыңгызларның
Алтын кылыч тоткан кулына,
Мин теләмим яулар юлындагы
Тузаннарның күзем каплавын;
Бик күрәсем килә шул яудагы
Ябай бер кешенең атлавын.
Ул булгандыр, бәлки, кысык күзле,
Ямьсез йөзле, чандыр яңаклы...
Монгол, татар, үзбәк—башкагамы,
Тик бу чорда барыбер кемгәдер ул
Бабай булу өчен яраклы.
Походларда кипкән какча күкрәк
Тере йөрәк утын саклаган.
Ирке юкка ачы әрнү белән
Атлаган ул, һаман атлаган.
Европаң да аңа кирәк түгел,
Кирәк түгел урыс капкасы,
Туган даласында сыенасы да,
Җиргә нәсел ясап ятасы.
Ятасы да юкса, булмаган шул. ...
Күз теккән ул безнең көннәргә,
Океанда батып баручыдай—
Хыялында кораб күргәндер...
Шул кешеме «явыз татар» булган?..
Минем анда нинди эшем бар?
Аннан ераграк торыйм, дисәм,
Минем болгар дигән исемем бар.
Әмма никтер, минем әле никтер
Эшем бар күк шушы татарда.
Күңел бармый Чыңгыз-Батыйлардан
Пычрак алып аңа атарга.

Татар, татар, син бүген дә юлда,
Көчең әле тора бөркелеп.
Тик исемеңне ерак гасырлардан
Өстерисең авыр гер кебек.
Варислыкка хакың юктыр синең.
Ни алдың син Чыңгыз-Мамайдан?..
Әйе, алар
Европага таба
Тәкәббрана адым атлаганда
Рөхсәт сорамаган әнә теге
Кызыл галстуклы малайдан.

Малай бүген тарих битләреннән
Әрнеп укый: «Явыз татар», дип
Ә этисе ерак Днепрда
СССРны саклап һәлак булган,—
Икесе дә алар «татар!» бит.
Мин дә татар,
Мин качмаска булдым
Тарих ябыштырган атымнан...
Бу исемнән күз алдына килә
Зур юл үткән йөнтәс атында—
Авыр малахаен төзәткәләп,
Күзен төбәп ерак офыкка,
Тузан аша үз язмышын күзләп
Тетрәнүче ябай, ертык карт...
Һәм мин аны нәләтләргә тиеш,
Авыр исемем–аның мирасы...
Үткәннәрнең калын тавын ярып,
Ах,
Бүгенгенең бөек яктысыннан
Тик бер кәррә аңа бирәсе!

*1958-59*



*Әнвәр Давыдов туганнан туган энесе Алик Нарбеков белән. 1966 ел.*

***

Белмим, иркәм, бәлки, мин чынлап та
Гаепледер синең каршыңда?
Кар бөртеге кебек бер теләксез
Эри алмам синең кашыңда.

Куна алмам чык бөртеге кебек
Сафлык белән синең чәчеңә...
Яңгыр тамчысыдай кушыла алмам
Синең яшерен сагыш яшеңә.

Юк, мин телим тау елгасыдай сине
Дулкыныма алып агарга,
Сыешалмыйча, биек таш кыялар
Басып торган текә ярларга.

Тормыш гөре булып ыргылырга
Синең тыныч аккан көннәргә,
Ияртергә сине ярсуыма,
Өйрәтергә шаулап көләргә!

*1953*

## ҮЗЕБЕЗНЕҢ РӘССАМ

Күренекле рәссам Рәшит Фатих улы Имашев 2007 елның мартында вафат булды, яна әсәр язганда йөрәге туктады. Ул 1939 елның 30 мартында Миякә районы Азнай авылында туа. Әти-әнисе укытучылар. Фатих абый Рейхстагны камаганда, Берлинда ятып кала. Рәшит Уфаның тугызынчы интернат (хәзер Дәүләткилдиев исемендәге республика гимназиясе), Казан сынлы сәнгать училищесы һәм Суриков исемендәге Мәскәү дәүләт сынлы сәнгать институтын тәмамлый. Урта мәктәптә укыганда рәсемнәре «Азат хатын», "Һәнәк", «Чаян», «Детский мир», «Юность» журналларында басыла башлый. Ул—рәсем сәнгате, китап, гәзит-журнал графикасы остасы. Меннән артык рәсем авторы. Аның әсәрләре Россия һәм күп чит ил галереяларында, «Иртә»—Мәскәү Третьяков күргәзмәсендә, «Хат» Санкт-Петербург Рус музеенда, Казандагы «Космос», Салаваттагы Салават мозаик-монумент эше ике шәһәрнен дә сокландыргыч күрке. Әсәрләре белән халыкара, бөтенроссия, зона һәм республикалар күргәзмәләрендә катнашты. Г. Тукай, Г. Ибраһимов, Х. Туфан, С. Сәйдәшен, М. Җәлил, Н. Җиһанов, К. Кулиев, Ф. Хемингуэй, Ф. Кастро, Л. Корвалан һәм башка дәүләт эшлеклеләре, азатлык һәм бәйсезлек өчен көрәшүчеләрнен портретларын язды. Ике республика президентлары М. Рәхимов һәм М. Шәймиевнен югары сәнгатьле рәсемен эшләде. Рәссам озак еллар Казанда яшәде. Хатыны Тәнзилә республика профсоюз комитетында эшләп хаклы ялга чыкты. Улы Рауль Канадада, кино-актер, кызы Наилә тарих фәннәре кандидаты, гыйльми институтта эшли.

### Балачак

1941 ел. Җырларда җырланган гүзәл Өязе буена сыенып утырган Азнай авылы очында, өянке, тирәк, шомыртлар янәшәсендә күркәм яңа йорт калкып чыкты. Ифрат тырышсалар да, көне-төне алны-ялны белми эшләсәләр дә, мич чыгарырга, тәрәзә куярга өлгермәделәр. Сугыш тиз тәмамлана, дип сөйлиләр—әнисендә яшәп торыр. Ил өстенә ябырылган газап, кыйралыш, фаҗиганен 1410 көнгә сузыласын беркем дә белми иде әле. Зур өметләр баглап төзегән өйдә яшәргә насыйп булмады. Ире Фатихны фронтка озаткач, ике яшьлек улы Рәшитне ияртеп, Сәгыйдә тау итәгендәге сукмактан турыдан Азнайдан Исламголга—"очып чыккан оясына", әнисе Җәмилә янына кайтты. Рәшит әнисенен бертуган сенлесе, яшьтәше Факия белән картәнисе Җәмилә апа тәрбиясендә үсте. Чыр-чу килеп уйныйлар- уйныйлар да, сугышалар, аннан дуслашалар. "Бар да фронт өчен, бар да Җиңү өчен!"—диган омтылыш белән яшәгән һәм эшләгән еллар. Тиздән Сәгыйдәне, Кыргыз-Миякәгә, мәгариф бүлегенә чакыртып алалар һәм... 70 чакрымдагы Өршәк авылына укытучы итеп тәгаенлиләр. Атлар йончу, корчангы, ачлыктан җәфа чиккән, кешеләре дә кытлыктан изаланган, җәяү йөрегән мәл. Сәгыйдәсе бала белән җәфаланмасын, дип, Җәмилә апа Рәшитне алып калды. Ана улын өзелеп сагынса да, сирәк кайтты: ара ерак, ачлык, бер кайтканда ике пар чабата туза, дәрес өстенә дәресләр... Сирәк күрешкәнлектән, Рәшит Факияга ияреп, картәнисенә әни, әнисенә апа, дип дәшә торган иде.

—Рәшит кечкенәдән рәсем белән мавыкты,—дип искә ала "Миякә" совхозында яшәүче хезмәт ветераны Факия Гобәйдулла кызы Туганова (Имашева).—Малай тиендәй, җәлт кенә биек тирәк башына менеп утыра да, сәгатьләр буена агачларның елгадагы күләгәсен, чагылышын күзәтә бирә. Бу, бәлки, реаль чынбарлыкны рәсем сәнгатендә чагылдыруда беренче адымнар булгандыр. Кесәсендә агач күмере, акбур йөртә. Каршы таута менә дә, ишек зурлыгындагы ташларга рәсем төшерә, дистәләгән

эскизлар ясый. Ниһаять, шатланып, этюд эшләргә керешә. Авыл капкаларына акбур белән аккош, поши, җәнлек, хайваннар, агачлар сурәтләре төшерә, кешеләр моңа һич ачуланмый: яратып, елмаеп карыйлар рәсемнәрне. Берчак сабакташына шаян шарж эшләгән, ә тегесе аны кыйнаган, авызын-борынын бәлшәйтеп, елап кайткан иде. Ул һәрчак үзе эшләп алган блокнот һәм кыска гына каләм йөртә. Уйлап, иҗади рәсемнәр эшли.

## Җәмилә апа җомгалары

Һәр җомгада Җәмилә апа өенә хатын-кызлар җыела. Ирләр сугышта. Үлем кәгазьләреннән авыл сыкрый. Һәрчак сүз Җинү турында. Җыр-моң, уен-көлке белән кайчакны күңелләрен күтәрсәләр дә, сагыш-кайгы аларның йөрәген әрнетә. «Буранбай», «Сәлимәкәй», «Таштугай» кебек озын көйләрне сузалар. "Әпипә"не дә биеп алалар. Алар бер үк вакытта эшли дә: Җәмилә апа фронт өчен бәрәңге киптерә, калганнар оек-оекбаш, бияләй бәйли, йон эрли, яугирләргә тәмәке янчыгы нәгышлый.

Җәмилә апа акыллы, басынкы, җор сүзле, ахирәтләре әйтмешли, «коеп куйган әртис», «көлке капчыгы», борынгы йолаларны яхшы белә. Хатын- кызлар белән сабанга җигелеп җир сөрә, тырмата, биек-биек эскертләргә ынтылып, көлтә ыргыта. Ул—киерелеп тарткан йөк аты, орденсыз герой. Соңгы вакытта йөрәк әрнүләренә түзәлми. Сугыш сызыгына якынлашканда, дошман поездны бомбага тота, Гобәйдулласы вагонда үлеп кала. Җәмилә апа күз яшьләрен Рәшиттән яшерә торган иде. Рәссам сугыш еллары хатын- кызлары рәсемнәрендә картәнисен мәңгеләштерде. Аның күркәм сыйфатларына таянып, югары сәнгатьле образлар тудырды. Җәмилә апа—билгеле һәм онытылган талантлар биргән ыру килене. Аны үз итәләр, якын күрәләр, яраталар, хөрмәтлиләр. Династия дигәндәй, иренең энесе Булат Имашев 1939-44 елларда Башкорт опера һәм балет театры генераль директоры һәм баш режиссеры, күп сәхнә әсәрләрен сәхнәләштергән күренекле сәнгать әһеле. 1944 елда иҗади хезмәте, фидакарь эше өчен Хезмәт Кызыл байрак ордены белән бүләкләнгән. Тагын бер талант, Башкорт драма театрының рәссам- бизәүчесе Галия Имашева сәнгать офыкларын тагын да киңәйтеп җибәрде. Тарих, әдәбият, сәнгать, культура өлкәсендә яңа Имашевлар күтәрелеп килә.

Сәләтле, булдыклы, иҗади, талант иясе алар, Имашевлар нәселе. Үрге Дим-Өязе буенда Рәшитнең әнисе Сәгыйдә ападан да оста җырчы юк, дисәм һич тә ялгыш булмас.

Моң чишмәсе... Миңа калса, 92 яшьлек Сәгыйдә әбинең еракларга таралган үзәк өзгеч бүгенге моңын-сагышын Татарстан җирендә "йокыга талган" сөекле улы Рәшит Имашев тынлап ята һәм үзе дә кушылып моңаядыр сыман. Халык җырларына сокланып туймаган рәссам, үзе дә оста, моңлы, әһәнле итеп җырлый торган иде.

## Күренекле кешеләр белән аралашу

Без, ике якташ, 60 еллар башында бергә укыдык, Рәшит—Казан сынлы сәнгать училищесында, мин—университетта. Ул минем янга килеп йөрсә дә «кулга да тими кала». Аны "ә" дигәнче Равил Фәйзуллин (хәзер "Казан утлары"ның баш мөхәррире), Миркасыйм Усманов (тарих фәннәре докторы, академик), Индус Таһиров (тарих фәннәре докторы, академик), Тәлгат Галиуллин (филология фәннәре докторы), Вакыйф Нуруллин (язучы), Шамил Маннапов (шагыйрь) кебек талантлы егетләр уратып ала. Кемдер хикәя, повестьларына иллюстрация ясауны, берәүләр чыгачак китапларына графика эшләүне үтенәләр. Рәссам һәрчак һәркемгә ярдәмләште. Рәшитне тарих-филология факультетында үткәрелгән кичәләргә чакыралар иде. Биредә һәм язучылар үткәргән "Әдәби җомга"ларда ул язучы, шагыйрь, сәнгать кешеләре, галимнәр белән аралашты.

Рәшит Имашев сәнгать училищесының соңгы курсларында рәссам буларак формалашты. Серле һөнәрнең нечкәлекләренә төшенде. Хыялын тормышка ашыру өчен киеренке, тынгысыз эшкә чумды. Ниһаять, Имашев стиле барлыкка килде. Х. Туфан һәм С. Хәким Рәшитнең якын дусларына әверелде. Рәссам аларны озак-озак үзенең каршында утыртты, позировать итте. Ике шагыйрь һәм рәссам

арасындагы дуслык озакка сузылды. Берчак Х. Туфан якташыма "Давыллы еллар" лирикасын бүләк иткән иде. Анда автор болай дип язган:

*... Син дә бит бер*
*Туктарсыңдыр, йөрәк.*
*Ә шулай да, нигә син... тыныч*
*Менә шундый—яшәп туялмаслык*
*Гаҗәп нәрсә шул син, и Тормыш.*

## Иҗат үрләренә менгәндә

Рәшит пакъ күнелле, тыныч холыклы, шаян, юморга бай булгангамы, кешеләр вә мәшһүр шәхесләр белән дә тиз аралаша иде. Ике республиканың ике президенты да рәссамның уңышларына шатлана иде. Бу юлларны язганда минем өстәлемдә М. Рәхимов һәм М. Шәймиевнын рәссам белән шатлыклы минутларында төшкән рәсемнәре ята. Рәшит, яшь аралары зур булуга карамастан, Х. Туфан белән аерылгысыз дус булды. Х. Туфан, С Хәким, М. Кәрим яшь рәссамнын рухи үсешенә, иҗади эшчәнлегенә зур этәргеч һәм тәэсир ясадылар. Бу өч әдип Рәшитнен иҗади уңышларына чиксез шатланалар иде. Рәссамның 1986 елның 10 июнендә үткәрелгән күргәзмәсе уңае белән М. Кәрим болай дип язды: «Бүген минем якташым, күптән яраткан рәссамым Рәшит Имашевның күргәзмәсе ачыла. Монда куелган эшләрне күреп бик куандым. Рәшитнен елдан-ел үсә баруын күреп, эчке горурлык кичердем. Татарстанның игелекле иҗади туфрагында гайрәт алган талант матур җимешләр биргән».



Р. Имашев—күпкырлы темага мөрәҗәгать иткән сәнгать остасы. Анын әсәрләрендә тарихи чор, сугыш, илне торгызу геройлары, солдатлар, тыл кешеләре, төзелештә катнашучылар, эшче, крестьян, нефтьче, металлург, студентлар, яшьләр, балалар, кин халык вәкилләре, санап бетерерлек түгел. Әмма анын һәр рәсемендә кеше, анын уй-фикерләре, шатлык-кайгылары, омтылышы чагылган.

Р. Имашев торган саен иҗат үрләренә күтәрелде. Ана зур казанышлар, фидакарь хезмәте өчен Башкортстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе дигән мактаулы исем бирелде. Ул—Фатих Кәрим, Мифтахетдин Акмулла премиясе лауреаты.

2003 елның 30 декабре рәссамга тагын бер зур шатлык алып килде. Татарстан республикасы президенты Указы белән сынлы сәнгать өлкәсендәге олы казанышлары һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен Имашев Рәшит Фатих улына "Татарстан Республикасынын халык рәссамы" дигән мактаулы исем бирелде.

## Якташ образын тудыручы якташ

Татар әдәбияты кафедрасы мөдире, филология фәннәре докторы Хатип ага Госман бер очрашканда: «Күргәзмәдә якташыгыз Рәшит Имашев рәсемнәрен караганда тетрәндем, сугыш еллары газапларын кичергән хатын- кызларны ничек оста тасвирлаган, аларны күргәч, тәннәрем чымырдап китте, күземнән яшьләр чыкты... Җаен табып, икәүләп бер килеп китегез әле, зинһар»,—диде.

Галим безне шатланып каршы алды. «Уфада булып кайттым,—дип сүзен башлады.—Якташыгыз Мифтахетдин Акмулланың иҗатын халыкка кайтарып бирү

буенча житди чаралар эшләргә җыеналар. Сез, Рәшит туган, Акмулла мирасына кагылышлы рәсемнәр иҗат итсәгез, гомум эшкә зур өлеш булыр иде»,—диде дә әдипнең Казанда басылган бердәнбер җыентыгының шигырьләр күчермәләрен бирде.

Рәссам уйланырга мәҗбүр булды. Җәйге каникулда аралары җиде-сигез чакрым булган Исламгол-Азнай-Туксанбайда еш булды. Туксанбай һәм Тамьян-Таймас авылларына барып әдипнең тормышын һәм иҗатын белгән картлар: Хәбетдин, Исмәгыйль, Мортаза Аллаяров, Илһам Базаровлар белән сөйләште. Дим буе авылларында, мең ыруы вәкилләре арасында озак, бик озак эзләде прототипны—барыбер тапты.

Рәшит Имашев ел саен диярлек туган якларына кайтып йөрде, районда урыннарда булып, менләгән кешеләр белән очрашты, якташларына үзенең иҗаты турында сөйләде.

2006 елның декабрендә унлаган төбәк вәкилләре катнашында Кыргыз-Миякә район мәдәният йортында Акмулланың 175 еллык юбилеен үткәргәндә көчле кул чабулар астында Рәшит Имашев үзенең «Балачак», «Егет», «Соңгы намаз» дигән рәсемнәрен якташларына бүләк итте.

«Соңгы намаз» күңелдә бик авыр тәэсир калдыра, тетрәндерә, нишлисен—тормыш чынбарлыгын чагылдырган рәсем.

...Күзгә дала. Эңгер-меңгер. Караңгылык көчәя барган сыман. Яшеллектә саргаю төсмере. Һавада саран нурларын чәчеп уракка охшаган яңа туган ай. Урыны белән җиргә кире әйләнеп кайткан сихри, очраклы, саран, куе кан төсендәге кояш нурлары төшә. Бер урында «кан тасмасы». Анда, әйтерсең, ерткыч үзенең корбанын кансыратып сөйрәп йөргән.

Үлән өстендә намазлыкта аякларын бөкләп утырган, намустай ак, пакъ киемле олпат ир утыра. Намаз укыганнан соң, кулларын кушырып, күкрәгенә күтәреп, амин тотарга хәзерләнә. Рәссам төп игътибарны персонажның йөзен тасвирлауга биргән, күркәм сыйфатлар туплаган үзебезнең милләт кешесенең типик картинасы: түгәрәк сакал-мыек, киң маңгай, җил-яңгырларда чыныккан кара-кучкыл йөз, акыллы, монсу, борчулы караш, эштә чыныккан куллар. Рәсем өшеткән, калтыраткан сыман итә. Җан яктылыкка, җылыга омтыла, ашыга. Әмма таңга ерак, әйтерсең вакыт тукталып калган. Туасы таңда Акмулланың гомере өзеләчәк.

Әдипнең тормышын, иҗатын, эстетикасын, идеалларын, көрәш мотивларын белгән һәр кеше рәсемгә битараф булып калалмый.

Залда утырганда минем күз алдыннан, кинодагы кебек, бер-бер артлы күренешләр үтте: менә чабаталы, сәләмә киемле, ятим, ябык, ач малай һәм... халык рәссамы...

Шатлыктан дулкынланган шыгрым тулы зал Рәшит Имашевны хөрмәтләп, зурлап озак кул чапты, күпләр күз яшьләрен яшерергә теләсәләр дә, булдыра алмады...

**Ким САДЫЙКОВ**
*Башкортстан, Миякә.*

---

## *Алхәбәр. "Казан утлары" — 2009*

Лерон
Хәмидуллин

### ЕРАКТАГЫ АК ҖИЛКӘННӘР

ТАРИХИ ОЧЕРК

"Татар Каргалысы","Оренбург Каргалысы","Каргалы бистәсе","Сәгыйд бистәсе", "Бәләбәй Каргалысы","Сакмар буе Каргалысы"— бу исемнәрнең бөтенесе дә Казан губернасыннан күчеп килгән татар сәүдә халкы бар иткән, башта авыл,соңрак шәһәр булган бер үк торак пункт атамалары. Биредән әледән-әле Урта Азия тарафына сәүдә кәрваннары китеп торган...



Миргалим
Харисов

# МАЙОРНЫ ӨРКЕТТЕМ

Никита Хрущев 60нчы еллар башында армияне офицерлардан шактый бушатты. Әмма үзен алып ташлагач, моның зур хата булуы ачыкланды. Дөньялар тыныч түгел, житмәсә Кытай белән мөнәсәбәтләр нык бозылды, хәтерләсәгез, 1969 елның язында Даманск утравында кораллы бәрелеш тә булып алды. Хакимияткә яна килгән абзыйлар армияне офицер кадрлар белән вузларда азмы-күпме хәрби әзерлек үткән кече офицерлар исәбенә нығытырга уйлады. 1968 елда утыз яше тулмаган запастагы офицерларны армиягә ала башладылар. Бәхетсезлеккә каршы, утыз тулырга ярты ел калган иде—шулар рәтенә мин дә эләктем. Бер ай элек кенә өйләнгән идем. «Гаиләм бар!»—дип тә карадым юкса. «Бик әйбәт, хезмәт хакын ару булачак, барып, ике айлык әзерлек курслары узгач, хатыныңны да үз янына чакырырсың»,—диделәр!

Казанның Идел буе районы хәрби комиссариатында, фәлән-фәлән вакытка Хабаровскидагы хәрби округка барып житәсең, дигән повестка тоттырдылар. Киттем поездга утырып көнчыгыш тарафларына. Ирле-хатынлы танышларым хезмәт итәргә Сахалинга бара иде, бер вагонда бару юл күңелсезлеген бераз киметте. Бер тәүлектән соң Свердловскида төшеп, башка поездга утырырга тиеш идек. Көндез бераз шәһәр белән таныштык. 24 сентябрь иде бу, кичке дүртләр тирәсендә кояш тотылды, Кояшның ул дәрәҗәдә үк тотылуын элек тә, аннан соң да күргәнем булмады. Яп-якты дөнья әкрен генә сары төскә керә башлады. Ул тагын да куерды һәм караңгыланды. Бернинди жил-мазар, кош-корт, кеше тавышы юк—тып-тын. Күңелне әллә нинди шом, курку биләп алды, әйтерсең лә, менә хәзер дөнья бетәчәк. Бу хакта алдан белеп, кара пыяла әзерләп куйган идек, шуның аша кояшны күзәтәбез. Ул күмелгәннән-күмелә барды, бик аз өлеше генә капланмый калды. Жир өсте куркыныч куе соры караңгылыкка чумгач, бераздан аз гына яктыра башлады. Без дә жиңел сулап куйдык.

Икенче поезд белән юлдашларым алга таба китте, мин Хабаровскида төшеп калдым. Хәрби округта миңа Уссурийскидагы армия штабына юллама, шәһәрнең үзәк мәйданы янындагы кунакханәдә кунып чыгарга талон бирделәр. Нәкъ шул көнне шәһәргә Иран шаһы Риза Пәһләви килгән иде. Үзәк мәйданда аның хөрмәтенә үткәрелгән чараларны мин кунакханәнең бишенче катыннан бик ачык күреп тордым.

Пограничный поселогында урнашкан УР («укрепленный район"нан кыскартылган) командиры полковник Гуслистый округта даны чыккан офицерларның берсе икән. Аю гәүдәле, гөрелдәп чыккан тавыш, усал йөз. Бер елдан аны башка бер дивизиягә күчерделәр, генерал-майор дәрәҗәсе бирделәр.

Хезмәт итәргә килгән һәр кеше белән Гуслистый үзе шәхсән сөйләшә дә, кайсы частьта хезмәт итәсен билгели икән. Чын профессиям артист булгангадыр инде, мине шушында, поселоктагы батальонда калдырырга кушты. УР үзешчәннәре белән дан тота икән. Кадрлар бүлеге башлыгы майорга кереп, бу хакта әйттем дә, Безымянная сопкасы итәгендәге бер частька ике айлык курсларга киттем.

Бернichә көннән безнең төркемгә Ткачев фамилияле өйләнмәгән бер украин

егете дә килеп кушылды. Ул курслардан соң шушы сопкалар арасында хезмәт итәчәк икән.

Курслар беткәндә кемнең кайсы частьта хезмәт итәчәген кабат әйттеләр. Ни гаҗәп, мин шушында калачакмын, теге украин егете исә Пограничныйга китәчәк икән. Күңелемне кара кайгы басты. Беренчедән, поселоктан ерак—сигез-ун чакрым чамасында урнашкан караңгы бер почмак, икенчедән, офицерлар яшәячәк бина шыксыз, мичләре дә җимерелеп беткән, җылыдан бигрәк сасы соры төтен чыгара торган күмер ягасы, тәрәзәләре ватык, туалеты тышта, суын әллә каян ташыйсы.

Нишләп болай килеп чыкты соң әле бу? Туктале, минәйтәм, теге майорның этлеге түгелме икән бу? Ул да украин кешесе бит. Киттем икенче көнне төп штабка. Полковник үзе юк иде, кердем майор янына. «Шулай, шулай, минәйтәм, полковник мине монда калдырырга кушты, ә Ткачевны тегендә. Ә сез, милләттәшегезне яклап, безнең урыннарны алыштыргансыз». Ык-мык итә бу, төрле сәбәп таба, имеш, фәлән дә төгән. «Ярый алайса,—дим,—иртәгә полковникның үзе янына керәм!»

Икенче көнне "Харисов Пограничныйга килә. Ткачев шунда кала",—дигән хәбәр алынды.

## КӨЧКӘ ТАБЫШТЫК

Яңа елның һәркайсысы матур, истәлекле инде аның. Ә шулай да минем өчен 1968 елның соңгы, Яңа елны каршыларга әзерләнгән ике көне һич онытылмаслык булды.

1969 ел башланырга ике көн калганда: «Каршы ал, фәлән рейс белән киләм», дигән телеграмма алдым. Киттем поездга утырып Владивостокка. Карыйм: килүче-китүче самолетлар арасында андый рейс юк. Бер-бер ялгышлык булгандыр, дип уйлап, Казан аша килгән һәр самолетны каршы алам—юк кына бит хатыным! Аэропорт кунакханәсендә кунып, икенче көнне тагын ярты көн көтеп: «Мин тоткарланырга мәҗбүрмен» дип частька телеграмма сугарга дип почта бүлекчәсе янына килеп баскан идем, шул вакыт кемдер инсәмә чак кына кагылып: «Сез Харисов түгелме?"—дип сорады. Борылып карасам, хатыным! Елаплар җибәрә яздым.

Эш болай булган икән. Ул телеграммада Казанда алган билетындагы рейс номерын күрсәткән. Тик, ниндидер сәбәп белән, әлеге самолет Мәскәүгә очып, Домодедово аэропортында аларны икенче бер самолетка утыртып җибәргәннәр. Расписаниедән тыш килгәнгәме, мин хатынымның әлеге самолеттан төшкәнен күрми калганмын. Ул исә, каршылаучылар арасында мине күрмәгәч, пассажирлар залына кереп бер почмакка сыенган, төнен шунда үткәргән. Аның бит әле мине хәрби киемнән күргәне юк. Ә аэропортта минем кебек яшь офицер шактый.

—Карап-карап торам,—дип сөйләде соңыннан хатын,—берсе сиңа охшаган да кебек. Тик барып дәшәргә җөрьәт итмәдем, үзе табар әле,—дип уйладым.

Мин дә пассажирлар утырган зал рәтләреннән үткәләдем. Тик салкын залда кышкы киемнәргә төренеп утырган күп кеше арасыннан хатынымны шәйләмәдем. Ә ул, ниһаять, "миңа охшаган" лейтенантка дәшәсе иткән.

31 декабрь иде бу. Часть офицерлары кичен ресторанда гаиләләре белән Яңа елны каршылый. Квартирга кайтып, тиз генә өсне-башны алыштырдык та, шунда киттек. Мәҗлес башланган иде инде. Кысык күзле монгол токымын күрербез дип көткән хезмәттәшләр, минем хатынны күргәч, аның чибәрлегенә соклануларын яшерә алмадылар.

Беренче тәнәфескә кадәр генә утырдык та, гафу итегез, юлдан соң арылган, дип кайтып киттек. Ике айдан артык күрешмәгән япь-яшь хатының килгәч, өлкәннәр арасында мәҗлестә утыру кайгысымыни?!

***Редакциядән:***

**1961 елны Мәскәүдә М. С. Щепкин исемендәге театр училищесын тәмамлаган Миргалим Харис улы Харисов үзен журналистикада һәм әдәбиятта тапты: озак еллар "Ватаным Татарстан" газетасында эшләде. 70 яшьлек юбилеен прозаик һәм әдәби тәрҗемәче, Татар энциклопедиясе институтының өлкән фәнни хезмәткәре булып каршылый. Котлыйбыз!**

## Хәмит Латыйповка 60 яшь



Хәмит Латыйпов 1949 елның 5 мартында Пермь өлкәсендәге Губаха шәһәрчегендә туа. Ата-анасы белән шул ук елны Башкортстанның Илеш районы Бүләр авылына күченеп кайталар. Хәмиткә 7 ай тулгач—әнисе, 13 яшькә житкәндә әтисе дөнья куя. Бу тетрәнүләр булачак рәссам һәм шагыйрьнең күңелендә гаҗәеп тирән эз калдыра һәм дә гомере буе иҗатында чагылыш таба.

Хәмит Латыйповның тәүге шигырьләре Илеш районында нәшер ителүче "Маяк" газетасында 1966 елда дөнья күрә.

1967 елда ул Уфа шәһәрендәге балта осталары әзерли торган махсус училищега укырга керә. Аны тәмамлагач, төрле төзелешләрдә эшли, 1973 елда исә Мәскәү янындагы бер еллык "Богородская резьба" курсларында укып, агачка уеп сурәт ясау серләренә өйрәнә.

1974-78 елларда Хәмит Нәжип улы Уфа сәнгать училищесында белем алып, "Агач эшкәртү сәнгате остасы" дигән дипломга ия була. Шуннан соң ул Чаллыдагы корылмаларны бизәүдә, сырлы бизәкле капкалар, төрле мифологик образлар төшерелгән сурәтләр, сыннар тудыруда катнаша. Ә 1988 елдан "Туймазы фарфоры" фабрикасында эшли, шамот, пыяла һәм керамикадан төрле катлаулы сыннар иҗат итә. Шул ук шәһәрдәге "Медицина пыяласы" заводында төрле сувенирлар, вазалар ясау өчен формалар уйлап чыгара, киндердә 50гә якын рәсем-картинасын эшли. Шул ук вакытта шигырьләр язуын да дәвам итә. Алар Татарстан һәм Башкортстан гәзит-журналларында еш дөнья күрә.

1997 елда Туймазы шәһәрендә үзе ясаган рәсемнәр белән бизәлгән "Жир һәм күк" исемле китабы басылып чыга. Ә 2006 елда исә аның Татарстан китап нәшриятында "Галәми гамь" дип аталган, сынлы сәнгать әсәрләре һәм шигырьләре тупланган саллы китап-альбомы дөнья күрде. Аның иҗатында—сурәтләрендә дә, шигырьләрендә дә—нигездә, фәлсәфи фикерләү, галәми-дөньяви гамь кебек олы төшенчәләр чагылыш таба.

Хәмит Латыйпов—1998 елда—Россиянең Рәссамнар берлеге, 2002 елдан Татарстанның Язучылар берлеге әгъзасы. Шәхси күргәзмәләре Казан, Төмән, Уфа, Чаллы һәм Туймазы шәһәрләрендә куелган. Сәнгати эшләренең аерым үрнәкләре Россия, Германия, АКШ, Израиль, Төркия һәм Франциядәге шәхси тупланмаларда саклана.

Яңа гасыр бусагасында ул болай дип язган иде:

*Кабат-кабат утта яндым,*
*Кар-буранда ялгыз калдым,*
*Өметләрне суга салдым,*
*Таш яуса да алга бардым,*
*Һәрчак үзем булып калдым.*

Рәссам-шагыйрь олы бәйрәмен өр-яңа иҗат шатлыклары белән каршы ала, үз-үзең булып кала алу куанычын кичерә.

♣




Нәкый Исәнбәт фатирында кунакта. Уңнан-сулга: Нәкый Исәнбәт, Роберт Миңнуллин, Госман Садә, Илсөяр Иксанова, Нәҗибә ханым. 1989 ел.



Ике Шамил.
Композиторлар Шамил Шәрифуллин (уңда) һәм Шамил Тимербулатов. 1974 ел.



Башкортстанның халык шагыйре Сәйфи Кудаш (уңда) һәм шагыйрь Самат Шакир. 1976 ел. Уфа.



*Баскычлардан мену дә, төшү дә җиңел түгел.*
*Уңнан-сулга: Гомәр Бәширов, Рәмис Аймәт,*
*Ринат Мөхәммәдиев. 1996 ел.*



*Язучы һәм галим*
*Тәбриз Мөбарәков*
*(1932–1996)*



*Чаллы хакимияте башлыгы Рәшит Хәмәдиев (уңда)—язучы Рабит Батулла һәм артист Наил Дунаев белән. 1997 ел.*

### ИЛГӘ ДАН ӨСТӘҮЧЕЛӘР

Январь аенда "КамАЗ" узышчылары сигезенче тапкыр "Дакар" автораллиенда җиңүгә иреште. Татарстанлыларның җиңүе триумфаль булды: Фирдәвес Кәбиров экипажы беренче урын алды, Владимир Чагин—икенче, ә Илгизәр Мәрдиев экипажы, техник ярдәмче булган килеш, гомуми зачетта дүртенче килде. Бары голландияле Де Рой гына татарстанлылар арасына керә алып, өченче урынны яулый алды. Республикабыз спорт елын әнә шундый җиңүләр белән башлады.

Татарстан Республикасы Президенты Минтимер Шәймиев үз резиденциясендә «Дакар-2009» марафон ралли-рейдында җиңүчеләр—«КамАЗ-Мастер» командасы әгъзаларын кабул итте һәм аларга дәүләт бүләкләре тапшырды. « Кайсы гына материкка барсагыз да, сез барысында да уңышка ирешәсез. Бер, ике мәртәбә җиңү очраклылык та булырга мөмкин. Әмма сез «Дакар»да 8 тапкыр җиңү яуладыгыз. Сез илгә, предприятиегә, шәһәргә имидж булдырасыз. Сезнең җиңүләрегез аркасында «КамАЗ» үз машиналарын күпләп чит илләргә сата»,—дип белдерде М. Шәймиев.

Бер атнадан соң җиңүчеләрне Россия Президенты Дмитрий Медведев кабул итте.

Команда әгъзалары, Семен Якубов һәм "КамАЗ" ААҖ генераль директоры Сергей Когогин житәкчелегендә, Дмитрий Медведев белән Кремль мәйданчыгында үз машиналары янында очрашты. Шуннан соң Президент кунакларны резиденциясенә чакырды.

Очрашу барышында Дмитрий Медведев пилотларны җиңү белән котлап, "КамАЗ"ның алга таба да бу ярышларда алдынгылыкны ычкындырмаячагына ышаныч белдерде.

"Сезне искиткеч җиңүегез белән котлыйм! Бу җиңүләр—сезнең осталык нәтиҗәсе. Сез беренче, икенче һәм дүртенче урыннарны яуладыгыз. Бу, әлбәттә, искитмәле, күренекле нәтиҗә",—диде Дмитрий Медведев.

### БӘҺАСЕЗ МИРАС ИЯСЕ

Бөек фикер иясе, дин белгече, тарихчы, язучы һәм педагог Ризаэддин Фәхреддиннең тууына 150 ел тулды. Бу уңайдан ТР Премьер-министры урынбасары—мәдәният министры Зилә Вәлиеваның мөрәҗәгатендә әйтелгәнчә, галим татар мәгърифәтчелеге символларының берсе булып тора.

XIX гасыр ахыры—XX гасыр башы иҗтимагый тормышының уникаль күренеше саналган мәгърифәтчелек дөньяга бертөркем күренекле фикер иясен бирә һәм милли мәдәният, гуманизм идеаллары, әхлак үсешенә куәтле этәргеч була. Татар иҗтимагый фикере һәм мәдәнияте тарихына Р. Фәхреддин энциклопедияче-галим, дини схоластика дошманы, фәнни белем һәм тарихны, әдәбият һәм сәнгать әсәрләре җәүһәрләрен пропагандалаучы буларак кереп калды. Ризаэддин Фәхреддин фән, мәгърифәтчелек һәм рухи камиллекнең дөньяны һәм кешене үзгәртүнең бердәнбер юлы булуына инанган.

Галим талантының күпкырлылыгы һәм мәнфәгатьләренең төрлелеге зур хөрмәткә лаек. Ризаэддин Фәхреддин тарих, фәлсәфә, педагогика, юриспруденция, тел белеме, әдәбият, халык иҗаты, география, этнография белән тирәнтен кызыксына һәм житди шөгыльләнә. Аның күпсанлы хезмәтләре бүген дә фәнни һәм әдәби кыйммәтен югалтмаган. Р. Фәхреддиннең иҗади мирасы гаять бай: этика, әхлак һәм педагогика буенча популяр брошюралары, меңгә якын мөселман мәдәнияте әһеленең тормыш юлын сурәтләгән "Асар" дигән күптомлы тарихи-биографик хезмәтләре...

Р. Фәхреддин шәхесендә югары-милли үзаң һәм толерантлык бергә ярашкан. Ул гомере буе туган халкының бәхете, татар телен һәм мәдәниятен үстерү өчен көрәшә, гарәп классик әдәбиятын югары бәяли, алдынгы рус мәдәниятен пропагандалаучы була. Р. Фәхреддиннең хезмәтләре һәм энциклопедик белеме Шәрекъне өйрәнүче рус галимнәре даирәсендә дә киң танылган.

Күренекле фикер иясенең юбилее безнең игътибарыбызны кабат аның бәя биреп бетермәслек кыйммәтле мирасына юнәлтә, бу исә, үз чиратында, милләт тарихы һәм аның мәдәнияте белән кызыксыну уятачак, яшь буынны бөек гуманизм идеалларына якынайтачак.

### ГЕРОЙ-ШАГЫЙРЬ ЮБИЛЕЕ

Г. Камал театры бинасында күренекле әдип, герой-шагыйрь Абдулла Алишның тууына 100 ел тулуга багышланган кичә узды. Ул Татарстан дәүләт җыр һәм бию ансамбле башкаруында «Тәфтиләү» җыры

белән башланды һәм бу бер дә очраклы түгел, ул жыр әдипнең иң яраткан җырларының берсе булган.

Мәдәният министры урынбасары Гөлшат Нигъмәтуллина А. Алишның туган ягында узган ел шактый чаралар үткәрелүе, андагы музее төзекләндерелүе хакында әйтеп узды. Ул А. Алиш исемендәге бүләкнең биелгысын язучы Вакыйф Нуриевка һәм Казан дәүләт «Әкият» курчак театры коллективына тапшырды. «Әкият»леләр исә язучының әкият геройларын сәхнәдә гәүдәләндерделәр.

Язучылар берлеге рәисе Илфак Ибраһимов үзенең чыгышында: «А. Алиш безгә М. Җәлил, Ф. Кәрим, Х. Мөҗәй кебек үк кадерле. Ул балалар әдәбиятын үстерүдә үзеннән зур өлеш керткән кеше»,—дип белдерде.

Сәхнәдә театр артистлары белән бергә мәктәп балалары да А. Алиш шигырьләрен укыдылар.

*...Алиш исеме безнең йөрәкләрдә*
*һәм мәңгегә шунда калыр да.*

Кичәдә шулай ук шагыйрь сүзләренә язылган җырлар да яңгырады.

## КИТАПХАНӘЛӘР ЯРДӘМГӘ МОХТАҖ

ТР Дәүләт Советы Рәисе Ф. Мөхәммәтшин Мәскәүдә Россия китапханәләрен үстерүгә ярдәм итү иҗтимагый комитетының чираттагы утырышында катнашты.

Иҗтимагый комитет 2006 елның ноябрендә гамәлгә куелган иде. Аның составына федераль министрлыклар һәм ведомстволар вәкилләре, кайбер төбәкләр (шул исәптән Татарстан) җитәкчеләре һәм парламент рәисләре, шулай ук танылган галимнәр һәм җәмәгать эшлеклеләре керде.

Дәүләт Думасы Рәисе Б. Грызлов җитәкчелегендә уздырылган утырышта муниципаль китапханәләр эшчәнлегенең хокукый яклары тикшерелде.

Татарстан парламенты башлыгы Ф. Мөхәммәтшин шулай ук РФ Федераль Җыены Федерация Советының РФ субъектлары дәүләт хакимиятенең законнар чыгару (вәкиллекле) органнары белән берлектә эшләү советы президиумы утырышында катнашты.

## «ҖИСЕМ» КИНОФЕСТИВАЛЕ

Казанда балаларның һәм яшүсмерләрнең «Җисем» дип аталган икенче кинофестиваленең сайлап алу туры башланды. Быел кинофестивальне оештыручылар ул тагын да профессиональрәк, жанр ягыннан тагын да баерак булыр һәм географиясе тагын да киңәер дип өметләнә. Анда катнашучыларның яше чикләнмәгән: кинофестивальдә 1-11 нче сыйныф укучылары да, 1-VI курс студентлары да катнаша ала. Иҗат эшләренең Татарстаннан гына һәм татарча булуы мәҗбүри түгел, бары тик татар телендә булмаган фильмнарны татар теленә тәрҗемә итеп җибәрү сорала.

Кинотасмалар «Кыска метражлы нәфис фильм», «Иң яхшы юмористик фильм», «Иң яхшы документаль фильм», «Иң яхшы анимацион фильм», «Хатын-кыз һәм ир-ат рольләрен иң яхшы башкаручы», «Иң яхшы оператор эше», «Иң яхшы сценарист», «Иң яхшы режиссура» номинацияләрендә бәяләнә. Жюрины Рамил Төхвәтуллин җитәкли.

Конкурсның йомгаклау этабы 25-26 апрельдә булыр дип көтелә. Кинофестивальгә килгән фильмнарның Татарстан телевидениесеннән күрсәтелү мөмкинлеге бар.

## КАНДИДАТЛАР БИЛГЕЛЕ

Январь аенда Татарстан Язучылар берлеге идарәсе утырышы булды. Берлек рәисе И. Ибраһимов алып барган утырышта соңгы айларда башкарылган эшләргә хисап ясалды. Катнашучылар ТР Язучылар берлеге идарәсенең 2009 елның беренче яртысына эш планын карап тикшерделәр.

Утырышта Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы һәм Язучылар берлеге премияләренә кандидатлар күрсәтелде. Галим, язучы И. Гыйләҗев—Г. Исхакый, сатирик язучы Ф. Баттал—Ф. Хөсни, шагыйрь, прозаик Р. Низами—Һ. Такташ, театр белгече, тәнкыйтьче Д. Гыйммранова Ж. Вәлиди премияләренә тәкъдим ителде.

Идарәнең 6 февральдә уздырылган икенче утырышында Татарстанның Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә кандидат итеп шагыйрь З. Мансуров тәкъдим ителде.

## ИСЕМНӘРЕ ҮЗГӘРӘ

Казанда бер үк исемдәге йөзгә якын урам барлыгы ачыкланды. Бу башкалага төрле бистәләрнең кушылуы нәтиҗәсендә барлыкка килде.

Бер үк исемнәрнең кабатланып килүе шәһәрнең төрле хезмәтләре (почта, товарларны китерү, авария бригадалары, беренче ярдәм күрсәтү оешмалары һ.б.) эшендә шактый уңайсызлыклар тудыра. Башкала кунаклары һәм хәтта казанлылар үзләре дә мондый очракларда аптырашта кала. Исемнәрнең кабатлануы 2010 елда Бөтенроссия халык санын алу барышына да тоткарлык ясар иде.

Урам исемнәрен үзгәртү берничә этапта узачак. Шул уңайдан топонимика буенча комиссия казанлыларга урам исемнәрен алыштыруда актив катнашырга чакыра. Тәкъдимнәр белән Казан шәһәре Думасының Кремль урамының 3 нче йортында урнашкан топонимика буенча комиссиясенә мөрәҗәгать итәргә була. Шулай ук gorduma_kazan@mail.ru, safguz@inbox.ru электрон почтасы аша яисә 299-18-37 телефоны буенча шалтыратып, үз тәләкфикерләрегезне җиткерергә мөмкин.

## ҮЗЕБЕЗНЕҢ ЖЫРЧЫ

М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет академия театрында Татарстанның халык, Россиянең атказанган артисты, жырчы Альберт Әсәдуллин 60 яшьлеген билгеләп үтте.

Билгеле булганча, А. Әсәдуллин жырчылыкка махсус укымаган. Ул Казан сәнгать училищесында белем алган, Ленинградта И. Репин исемендәге нәкыш, скульптура, архитектура институтының архитектура бүлеген тәмамлаган. Шул ук елны "Поющие гитары" вокаль-инструменталь ансамбленең солисты булып киткән. 1975 елда исә "Орфей и Эвридика" исемле беренче совет рок-операсында төп партияне башкарган. А. Әсәдуллин татар халык жырларын да яратып башкара. Р. Кәлимуллинның "Кәккүк авазы", М. Шәмсетдинованың "Мәһди" рок-опералларында, Р. Әхиярованың "Шагыйрь мәхәббәте" операсында Шүрәле партиясендә чыгыш ясап та, А. Әсәдуллин музыка сәнгатен үстерүгә һәм баетуга үзеннән зур өлеш кертте.

Жырчы Альберт Әсәдуллинны бездә генә түгел, чит илләрдә дә беләләр. Ул Польша, Финляндия, Һиндстан, Алманиядә һ.б. илләрдә гастрольләрдә булды. Жырчы Болгариядә үткән халыкара "Алтын Орфей" бәйгесендә беренчелекне алды, Ленинград, Сочи шәһәрләрендә уздырылган Бөтенроссия, Бөтенсоюз конкурсларында жиңү яулады.

Юбилей кичәсендә Ә. Әсәдуллинны сәхнәдәшләре—жырчылар И. Шакиров, В. Ганиева, "Казан егетләре", "Зә-Ләй-Лә" төркемнәре һ.б. тәбрикләде.

Казан шәһәре хакимияте башлыгы И. Метшин юбилярга Президентыбыз М. Шәймиевнең котлау хатын укып иреште. Чаллы шәһәре хакимияте башлыгы И. Халиков та жырчыга иң изге теләкләрен житкерде.

Кичәдә татар халык жырлары да, заманча жырларыбыз да, рок-опералардан арияләр, дуэтлар да, чит ил музыкасы да башкарылды.

## ШИГЫРЬ БӘЙГЕСЕ

Россия Мөфтиләр шурасы «Дөньяга рәхмәт йөзеннән жибәрелгән Мөхәммәд Пәйгамбәр (с.г.в.)» дигән III Бөтенроссия шигырь бәйгесе игълан итте. Конкурска Пәйгамбәребез тормышына һәм аның дөнья тарихында тоткан урынына багышланган, шуны шигъри юллар белән ачкан рус һәм татар телләрендәге эшләр кабул ителә. Жиңүчеләргә махсус дипломнар һәм истәлекле бүләкләр тапшырылачак. 1 урынга—25 мең сум, 2 урынга—20 мең, 3 урынга 15 мең сум акча да каралган. Бәйге кысаларында он-лайн режимында тамашачылар мәхәббәте призы да уйнатылачак. Эшләрне март аеннан да калмыйча Россия Мөфтиләр шурасына (129090, Мәскәү шәһәре, Выползов урамы, 7) жибәрергә кирәк.

## "ИСЛАМ ДӘРЕСЛӘРЕ"

Россия Мөфтиләр шурасы башлыгы Равил Гайнетдиннең "Ислам дәресләре" дигән китабы дөнья күрде.

Ул ислам мәдәниятенә, фән һәм мәгарифенә ярдәм итү фонды ярдәмендә бастырылып, дини уку йортлары укытучылары, шәкертләр, шулай ук укучыларның киң даирәсе өчен билгеләнгән.

Мөфтиләр шурасының рәсми сайтында хәбәр ителгәнчә, "бүгенге Россиядә ислам нигезләре турында системага салынган уку кулланмасын булдыруның тәүге омтылышы бу". Әлеге китапның бүген ислам мәгърифәтчелеге өлкәсендәге сорауларга жавап табу йөзеннән әзерләнгәнлеген искәртик.

Китап ике бүлектән һәм кереш өлешеннән тора. Р. Гайнетдин анда "Мөселман булу нәрсә дигән сүз?" дигән сорауга жавап бирә. Китапның беренче бүлегендә автор Коръән һем Мөхәммәд пәйгамбәр хәдисләрен игътибар үзәгенә ала. Икенче бүлек диннең алты терәк баганасы мәгънәсен ачуга багышланган.

## АЙРАТ—ЖИҢҮЧЕ

Якташыбыз Айрат Ишморатов (драматург Риза Ишморат оныгы) Канаданың Квебек шәһәрендә узган дирижерлар арасындагы конкурста катнашты. Анда 60 кеше арасында жиңү яулаган Айратны 85 кешедән торган симфоник оркестрга дирижер итеп билгеләделәр. Ул бер үк вакытта «Королевские скрипки» ансамблендә дә эшли.

А. Ишморатов коллектив белән шушы көннәрдә генә Нью-Йорктан кайтты. Быел алар Кытайга, Австралиягә чакыру алганнар.

## АЛПАРОВ ӘЛИФБАСЫ

Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты Гыйльми советының чираттагы киңәйтелгән утырышы танылган тел белгече, педагог, профессор Гыйбад Алпаровның тууына 120 ел тулуга багышланды. Алпаровның гыйльми эшчәнлеге бик иртә башлана. Ул инде 24 яшендә үк "Хәреф һәм имлябыз", "Татар әлифбасы" дигән китапларын бастыра. Төрекмән галиме М. Гилдиев белән берлектә 1924 елда төрекмән мәктәпләре өчен әлифба нәшер итәләр. Галим 30лап китап, 40тан артык фәнни хезмәт, 100гә якын ижтимагый-публицистик мәкалә авторы.

## ӘМИРХАННАР НӘСЕЛЕ

Күптән түгел Казанның «Сөембикә» кафесында күренекле дин эшлеклесе, тарихчы, озак еллар Яңа татар бистәсендәге Иске таш мәчет имамы булып хезмәт иткән

Хөсәен Әмирхан улы Әмирханның тууына 195 ел тулуга багышланган мәҗлес үткәрелде. Хөсәен Әмирхан—татар милли тарихы фәненә нигез салучыларның берсе.

Кичә Рәсим Әмирханның Коръән-Кәримнән сүрәләр укуы белән башланып китте. Мәҗлестә күпсанлы Әмирханнар нәселе вәкилләре белән бергә Татарстан Фәннәр Академиясенең Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институтыннан тарих фәннәре кандидатлары Зөбәрҗәт Гарипова, Әлфия Галләмова, Тәэминә Биктимерова, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтыннан фән докторлары Фирдәвес Гарипова, Нурмөхәммәт Хисамов, Флера Баязитова Әмирханнарның татар тарихында тоткан урыны хакында сөйләделәр.

Кичәне мәшһүр Әмирханнар нәселе вәкиле, күренекле галим Илдус Әмирханов алып барды.

## 94ТӘ ДӘ СӘХНӘДӘ

Театр әһелләре берлеге һәм Ветераннар советы тамашачыларны Актерлар йортына җыйды. "Муса Җәлил һәм музыка" дип аталган кичә М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет академия театрының опера студиясенә 70 ел тулу уңаеннан оештырылды. Анда Флюра Сөләйманова, Рөстәм Маликов, Эмиль Җәләлетдинов кебек халкыбызның яраткан җырчыларын тамашачы яратып каршы алды. Заманында М. Җәлилне күреп белгән Татарстанның халык артисты, тиздән 94 яшен тутырырга җыенучы Усман Әлмиевнең чыгыш ясавы күпләрне сокландырды. М. Җәлил шигырьләрен күренекле артистлар Илдус Әхмәтҗанов, Равил Шәрәфиев, шагыйрә Салисә Гәрәева укыды.

## БЕРЕНЧЕЛЕКНЕ БИРМИ

Мөслим кызы Айназ Җәләлова Санкт-Петербург шәһәрендә үткән Бөтенроссия халык биюләре фестивалендә җиңү яулаган. Ул инде икенче ел рәттән әлеге бәйгедә беренчелекне бирми. Былтыр кабат I дәрәҗәдәге лауреат булган. Айназ Мәскәүдә узган Бөтендөнья бию олимпиадасында да бронза медальгә лаек булган иде. Үзенең матур биюләре белән таң калдырган кыз Казан дәүләт техник университетында белем ала. Шундый уңышларга ирешкәне өчен, Айназ укытучысы—Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Ләйсән Шаяздановага рәхмәтле.

## "ВАТАНДАШЛАРЫБЫЗ" ТАТАР ТЕЛЕНДӘ

Татарстанны, гомумән татар халкын данлаган атаклы кешеләр турында сөйләүче "Ватандашларыбыз" телевизион фильмнар циклы татар теленә тәрҗемә ителгән.

"Ватандашлар" премьерасы узган елда булды. Авторлар тарафыннан илле фильм әзерләнде. Тормышы һәм иҗатлары Татарстан белән аерылгысыз бәйле шәхесләр турында илле тарихи сәхифә бу. Галимнәр, шагыйрь, философ, рәссам, тарихчылар... "Панорама-телефильм" иҗат берләшмәсе, һәр фильм өстендә эшләгәндә, архивларны җентекләп өйрәнә, уникаль кинохроника кадрларын җыя. "Софья Губайдуллина. Прикосновение к душе" фильмы "Вместе" халыкара форумында иң яхшы документаль фильм буларак танылды.

"Татарстан—яңа гасыр" телеканалыннан татар телендә күрсәтелгән фильмнарның беренчесе бөек галим Шиһабетдин Мәрҗани турында булды. "Ватандашлар" сериясендәге фильмнар һәр якшәмбе көнне 12 сәгатьтә күрсәтеләчәк.

## БЫЕЛ КҮБРӘК

2009 елда хаҗ кылу өчен татарстанлыларга 3000 урын бүлеп биреләчәк. Бу, узган ел белән чагыштырганда, 1 мең урынга күбрәк.

Квоталар турында сөйләшү Мәскәүнең Хакимият йортында узган утырышта билгеле булды. Анда ТР Мөселманнары диния нәзарәте рәисе мөфти Госман хәзрәт Исхакый һәм аның хаҗ мәсьәләләре буенча урынбасары Аяз Минвәлиев, ТР Министрлар Кабинеты каршындагы дин эшләре буенча идарә башлыгы Ренат Вәлиуллин, шулай ук «Идел-Хаҗ» төбәкара хаҗ үзәге директорлар советы рәисе Рөстәм Гатауллин катнашты.

## ЧИЛӘБЕЛӘР ШАГЫЙРӘНЕ ЗУРЛАДЫ

Чиләбе өлкәсенең М. Акмулла исемендәге әдәби берләшмәсе әгъзалары шагыйрә Салисә Гәрәеваның 70 яшьлек юбилеена багышлап әдәби-музыкаль кичә уздырды.

Салисә Гәрәева озак еллар Чиләбе шәһәрендә яшәп иҗат итте, 1967-71 елларда М. Җәлил исемендәге әдәби берләшмәне җитәкләде. Быел бу берләшмәнең оешуына 45 ел тулды, ул инде хәзер М. Акмулла исемен йөртә.

Чиләбе өлкә радио-телевидение комитетында эшләгәндә үк С. Гәрәева татарлар, башкортлар өчен тапшырулар оештырды. 1991 елда Чиләбе телевидениесендә "Чишмә" дип аталган тапшыруларны алып барды. С. Гәрәеваның әдәби-иҗади эшчәнлеге болар белән генә чикләнми. Ул татар телендә нәшер ителүче "Дуслык" һәм башкорт телендә чыгучы "Туган як" газеталарының җаваплы сәркәтибе булып та эшләде. Шәһәр үзәгендәге Ак мәчетне дин тотучыларга кайтарып бирү артыннан йөрүче дә Сәлисә ханым үзе булды.

Әлеге кичәдә аның "Диңгездән бер тамчы—бер шәлкем" шигырьләр җыентыгы да тәкъдим ителде.

## КИТАПТА—МАВЫКТЫРГЫЧ ТАРИХ

«Шәрык—Көнбатыш: мәдәниятләр һәм цивилизацияләр бәйләнешы» дигән фәнни-популяр сериянең чираттагы 8 нче чыгарылышы дөнья күрде. Аны нәшер итүдә Россия гуманитар-фәнни фонды һәм Татарстан Фәннәр академиясе катнашты. Китап күренекле тарихчы-археолог һәм шәрыкны өйрәнүче галим, ТДГПУның тарих һәм этноархеология кафедрасы мөдире, профессор Альберт Борһанов редакциясендә чыккан. Әлеге хезмәттә Идел-Урал регионы һәм Үзәк Азия кинлекләрендә соңгы елларда табылган тарихи-археологик материаллар хакында тәфсилләп бәян ителә. Китап авторлары арасында Мәскәү, Казан, Новосибирск, Төмән, Улан-Удэ, Әстерхан, Алма-Ата, Ташкент, Ашхабад тарихчылары белән беррәттән Төркия һәм Италия галимнәре дә бар.

Бөек Болгар, Алтын Урда чоры һәм аннан соңгы татар дәүләтчелеге белән кызыксынучылар өчен бу китап аеруча кызыклы булачак.

## КАРДӘШЛЕК ҮРНӘГЕ

Әстерхан шәһәренең юбилее уңаеннан үткәрелә торган бәйрәм чараларында Казан шәһәре мэры И. Метшин җитәкчелегендәге зур делегация катнашты. Ак мәчет ачылышында әйтелгәнчә, аны төзекләндерүгә 40 млн. сум чамасы акча сарыф ителгән һәм ул Казан мөселманнарының хәйрия акчасына һәм республика предприятиеләре акчалары хисабына башкарылган. Ак мәчетне төзекләндереп бирү Әстерханга нигез салынуның 450 еллыгына казанлыларның символик бүләге булып тора. Өлкә күләмендәге архитектура һәйкәле саналган Ак мәчеткә XVII гасырда нигез салынган, 1810 елда сәүдәгәр Исмәгыйлев аны кирпечтән яңадан төзеткән һәм ул шәһәрнең Җәмигъ мәчете дип йөртелгән. Октябрь революциясенә кадәр Ак мәчеттә татар мәктәп-мәдрәсәсе урнашкан булган, мәхәлләдәге мең кеше шушы мәчеткә гыйбадәт кылырга йөргән.

## ТАТАР МОРЗАЛАРЫ ҖЫЕЛДЫ

Казанда татар морзалары җыелышының еллык утырышы узды. Шул уңайдан башкалага 30га якын танылган морзалар нәселе вәкилләре килде. Дөньяда барлыгы рәсми төстә теркәлгән 238 данлыклы татар нәселе исәпләнә.

Узган шимбәдә татар морзалар җыелышы рәисе Айрат Терегулов тагын 9 әгъзага таныклык тапшырды. Морза исемен һәм таныклык алу өчен архив һәм шәҗәрәдән дәлилле мәгълүмат булырга тиеш. Нәсел агачын төзү өчен кайвакыт ун ел вакыт китәргә мөмкин.

Киләсе елның җәендә татар морзалары җыелышының бөтендөнья фәнни конференциясе республиканың Кукмара районында узар дип көтелә.

## БЕЛМӘСӘҢ—ӨЙРӘТӘЛӘР

“5 сәгать эчендә майлы буяулар белән картина ясау”. Казан рәссамы Миләүшә Нуруллина (күренекле язучы Вакыйф Нуруллин кызы) менә инде биш ел буе шундый формула буенча мастер-класслар уздыра. Моңарчы кулларына пумала тотып та карамаган кешеләр дәрес вакытында чын рәссамнар кебек иҗат итә башлый. Узган сишәмбе “Казан” милли мәдәният үзәгендә ачылган “На одном дыхании” исемле күргәзмәнең экспозициясе нәкъ менә шундый дебютантларның эшләреннән гыйбарәт. Бу картиналарга карагач, Нуруллина шәкертләренең иҗат кагыйдәсе белән килешми дә булмый: “Беркайчан да моңарчы кулыңнан килмәгән әйберне эшләргә курыкма. Шуны истә тот: Нух көймәсен һәвәскәр корган, ә “Титаник” профессионаллар тарафыннан төзелгән”.

***

Татарстан Республикасы хакына күпьеллык нәтиҗәле хезмәте, татар мәдәниятен үстерүгә, чит илләрдәге милләттәшләребез белән элемтәләрне ныгытуга лаеклы өлеше өчен Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты рәисе урынбасары **Гыйсметдинов Дамир Минсәгыйрь** улы Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәт хатына лаек булды.

2009 елның 8 февралендә язучы, тәрҗемәче (халык язучысы Гариф Ахуновның хатыны), **Максудова Гөлшаһидә Габдрахман** кызы 83 нче яшендә вафат булды.

*Тышлыктагы сурәтләр*

*Беренче биттә: Композитор Заһидулла Яруллин*—Р. Имашев эше.

*Дүртенче биттә:* галимә, әдәби тәнкыйтьче **Дания Заһидуллина**.

# Яңа китаплар




**Әренҗән Карадауан.** Чыңгыз хан: эссе. Казан: Татар. кит. нәшр., 2008.—313 б. Тиражы—3000 данә.

Әренҗән Карадауан (1883-1942)—калмык халкының данлы улы, табиб, тарихчы-галим. Дөньяда тиңе булмаган җиһангир шәхес—Чыңгыз ханның тууына 700 ел тулу уңаеннан язылган бу хезмәт “Чингиз-хан как полководец и его наследие” дигән исем белән 1929 елда беренче мәртәбә (Белградта) дөнья күрә. Язучы Марсель Галиев аны татарчага тәрҗемә иткән. Басма тәрҗемәче тарафыннан өстәмәләр белән тулыландырылган. Китапның фәнни мөхәррире—Динә Мостафина. Китап бер үк вакытта рус телендә дә чыккан.




**Рәфыйк Шәрәфиев.** Ник сызланасың, йөрәк? Публицистик мәкаләләр, эссе-язмалар. Казан: “Сүз” нәшр., 2008.—200 б. Тиражы—500 данә.

Китапның арткы тышлыгында авторның мондый сүзләре язылган: “Зур булмаган хәләл пенсия акчамны үз исәбемнән китап чыгару өчен җыеп барырга мөмкинлек биргән гаиләмә, шул китапның чыгымын кысып кына исәпләгән “Сүз” нәшрияты төркеменә, мине аңлаган, “каләмдәшем” дип үсендереп, китапка “Кереш сүз” язган, тыйнак кына хезмәтемә югары бәһа биргән дуслар-фикердәшләргә Аллаһның рәхмәтләре булса иде.” Журналыбызның актив авторы, Татарстанның Балтач районында яшәп иҗат итүче Рәфыйк Шәрәфиевнең бу китабы аның 70 яшьлек юбилее уңаеннан чыгарылган.



Дания Заһидуллина

КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)